# казан утлары

8

АВГУСТ—1970

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК ТУГЫЗЫНЧЫ ЕЛ ЧЫГА

8

АВГУСТ
1970

## Бу санда:

РОМАН, ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯ, ШИГЫРЬЛӘР

**Н. ФӘТТАХ.** Әтил суы ака торур. Тарихи роман . 3
**Ә. ДАВЫДОВ.** Иптәш секретарь. Бик борчылган чак була... Совет халкым... Без бу урамнарны... Мәхәббәтнең тәмуг газапларын... Уздылар байтак гомерләр... Бу дөньяның... Бөтен язган җырларымны... Шигырьләр. . . . . . . . 49
**В. НУРУЛЛИН.** Күпер чыкканда. Повесть. . . . 53
**Г. ЛАТЫЙП.** Ленинизм таңы. Россиянең урта бер җирендә... Килдем мин Урал ягыннан... Чехов каены. Аргы очка таба... Шуларның берсе мин булырмын. Шигырьләр. . . . . . . . . 97
**М. РАФИКОВ.** Ишгилде. Этюдлар. . . . . . . 101
**Ә. ШӘМИН.** Алтын медальон. Хикәя. . . . . 118

ЯШЬЛӘР ИҖАТЫ

**Р. ВӘЛИЕВ.** Аппассионата. Вакыт. Мизгел. Мәхәббәт. Шигырьләр. . . . . . . . . . . . 129

БЕЗДӘ КУНАКТА

**Г. КРАСИЛЬНИКОВ.** Тугандаш халыклар семьясында. . . . . . . . . . . . . . . . 131
**Ф. ЕРМАКОВ.** Бүгенге удмурт әдәбияты. . . . 133
**А. КЛАБУКОВ-БАГАЙ.** Ленин янына бару. Баллада. 136
**С. САМСОНОВ.** Туган көнемне мин белмим. Повестьтан өзек. . . . . . . . . . . . . 138
**Д. ЯШИН.** Икмәк турында җыр. Нарат. Шигырьләр. . . . . . . . . . . . . . . . . 145
**Ф. ВАСИЛЬЕВ.** Дөм караңгы... Урманнарда... Яз килүгә... Шигырьләр. . . . . . . . . . 145
**Н. БАЙТИРӘКОВ.** Зифа сынлы... Юлыңа кызлар юлыкса... Шигырьләр. . . . . . . . . . . 146

ШАГЫЙРЬ ТУРЫНДА — ШАГЫЙРЬ

**Г. РАМАЗАНОВ.** Чын шигърият иленда . . . . 147

ӘДӘБИЯТ ТАРИХЫНА МАТЕРИАЛЛАР

Давыллы елларда туган дуслык. . . . . . . 153
**З. МАКСУДОВА.** Шагыйрь Вәлиулла Чүпрәле. . 156

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

СӘНГАТЬ КЕШЕЛӘРЕ

Г. ЗӘЙНАШЕВА. Сандугач . . . . . . . . . . 158

АЛАР БЕЗДӘ БУЛГАННАР

ВЛ. КЛИМЕНТОВСКИЙ. Г. Р. Державин. . . . . 165

ИСТӘЛЕКЛӘР, ЯЗМАЛАР

К. МОСТАКАЕВ. Габдулла Тукай һәм Фатих Әмирхан белән көрешү. . . . . . . . . 169

ТӨРЛЕСЕННӘН

П. М. САВЕЛЬЕВ. Муса исеме алар телендә. . . 174

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ә. ФАСЕЕВ. Кетеп алынган сүзлек. . . . . . 178
Бәләкәй рецензияләр. . . . . . . . . . . 181

БЕЗНЕҢ КАЛЕНДАРЬ

Халикъ Садри. . . . . . . . . . . . . . 184
Н. ГАЙНУЛЛИН. В. М. Бахметьев. . . . . . . 185

ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...

Г. РӘХИМ. Муеннмнан... Ачуланган минутта. Борын-борынгыдан. Шигырьләр. . . . . . . 187
И. ТУКТАР. Җөмләләр. . . . . . . . . . . 188
Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары. . . . . . . 189

Редакциягә килгән
кульязмалар
кире кайтарылмый

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: баш редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-39-52,
бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Баш редактор: Зәки Нури.
Редколлегия: Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Ләбибә Ихсанова, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рафикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир.

Производствога бирелде 28/V-1970 ел. Басарга кул куелды 10/VII-1970 ел. ПФ 09072. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 83546 экз. Заказ С-321. Бәясе 50 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, 19. 1970 ел.

## Нурихан Фәттах

# ӘТИЛ СУЫ АКА ТОРУР

ТАРИХИ РОМАН

Әтил суы ака торур,
Кыя төби кака торур,
Балык тәлим бака торур,
Күлең такый күшәрер[1].

*Борынгы заман татар халык җыры.*

Ага сулар, ага сулар,
Ага сулар Болгарга.
Кызганам моңлы баланы
Үзем моңлы булганга.

*Хәзерге заман татар халык җыры.*

## Сүз башы

Татар халкының бай тарихы бар. Диңгездән бер тамчы алган кебек, менә шул бай тарихтан мин дүрт-биш елны аерып алдым. Дүрт-биш ел тарих өчен генә түгел, аерым кеше гомере өчен дә бик аз вакыт. Ләкин мин алган дүрт-биш елның әһәмияте тарих өчен чиксез зур.

Кайсы чор соң ул шулай да?

Ул — Болгар чоры. Ачыграк итеп әйткәндә, Болгар йортның туу, үсешу чоры.

922 елның маенда Болгарга ерак Багдадтан илче килә. Болгар рәсми төстә ислам дине кабул итә һәм замэнында иң зур, көчле дәүләтләрнең берсе белән дипломатик мөнәсәбәт урнаштыра. Шулай итеп, Идел-Чулман буендагы беренче дәүләт — Болгар дәүләтенең рәсми тарихы башлана.

Багдад илчелегенең секретаре, борынгы тел белән әйткәндә, битекчесе Әхмәт ибн Фадлан шул чордагы болгарлар һәм башка халыклар турында истәлекләр язып калдыра. Әгәр ибн Фадланның һәм гомумән гарәп сәяхәтчеләренең истәлекләре булмаса, тарихыбызның болгар чоры турында без, ихтимал, бик күп нәрсәне белмәгән булыр идек һәм, күрәсең, мин дә бу әсәремне иҗат итә алмаган булыр идем.

Бу романымда мин, нигездә, менә шул кыйммәтле истәлекләргә таянып, Болгарга ерак илчеләр килер алдыннан һәм килгәч булган хәлләрне тасвирладым.

Алдан ук шуны искәртеп куясым килә: монда сурәтләнгән кайбер вакыйгалар, кайбер күренешләр бүгенге күзлектән караганда сәер тоелырга мөмкин. Ләкин шуны да онытмаска кирәк — ул борынгы көннәр, вакыйгалар, кешеләр... бик еракта, бик тирәндә күмелеп калган. Аларга инде мең дә илле ел чамасы!

Шулай итеп, тугыз йөз дә унсигезенче елга аяк басабыз.

---

[1] Идел суы ага торыр,
Кыя төбен кага торыр,
Күлләрендә бака һәм балык күп булыр.

# Беренче бүлек

## I



Менә тагын яз җитте. Кышкы озын төннәрдән соң, каты салкыннардан, ачы бураннардан соң тагын яз килде. Тәбәнәк, болангыр күктә ягымлы кояш күренде; тирә-якны яктыга, куанычка күмеп, җирдәге барлык терегә күз кысып, шаярып, кайнар укларын яудырды. Калын кар астында басылып яткан тигезлекләр, калкулыклар, урманнар, чокыр-чакырлар әкренләп-әкренләп авыр йөктән арына бардылар. Кыш буена тынып торган җирнең өсте озакламый өтәләнгән тунын салып ташлады. Сыртларда яшел үләннәр мыек төртте. Яр буйларында тал бөреләре күзләрен ачтылар. Басулардан, үзәннәрдән челтерәп беренче сулар акты.

Сулар акты... Аҗун [1] яралганнан бирле сулар кая таба аккан булса, быел яз да сулар шул бер якка юнәлделәр. Инешләр, чишмәләр, елгалар, ермаклар, ташулар — барысы да Чулман атлы олуг суның кочагына омтылдылар... кушылдылар, көчәйделәр, ургып-шаулап, алга ыргылдылар. Чулман исә ерактан, якыннардан җыеп алган язгы суны, сыяларны [2], бозны-карны тагын ары алып китте. Кайдадыр кояш баешта, кыялы ярлар янында олуг Чулман үзенең бөек туганын очратырга тиеш. Алар шунда кавышалар, бергәләшеп, кочаклашып, көн ягына юл тоталар. Кайнар ком, кояш илендә, тау-ташлар, камышлар илендә Этил-Чулман суын ямансулап иксез-чиксез тиңгез, төпсез тиңгез көтеп ята. Хазар тиңгезе көтеп ята. Анда изге Хазар җире, анда изге каган [3]...

Сулар ага... Җир йөзендә сулар бертуктаусыз агалар да агалар. Җәй агалар, яз агалар, көз агалар... Агым сулар кешеләрнең, киекләрнең чирчорларын, кайгыларын, языкларын алалар да еракларда упкыннарга, чоңгылларга ыргыталар. Агым сулар, җир өстенең чүп-чарларын, үлекләрен юып алып, үзләрендә юк итәләр. Шулай ел да җир янара, җир яшәрә.

Җир яңара, җир яшәрә... Өзелмичә, туктамыйча, бөек Чулман кебек, Этил кебек, көн-төн җирдә тормыш ага.

Яз килде, яз!

Киң Чулманга — кояш белән, ай-йолдызлар белән яшьтәш Чулманга ашыгып төрле яктан сулар ага...

Утташ кам [4], туры караган кояшка күзләрен кысыштырып, атына җинел генә атланды да ишегалдан чыкты. Ялына, маңгай чәчләренә, койрыгына төрле төстәге тасмалар, сөяк, тимер кисәкләре тагылган акбүз ат, су исе, кырлар исе сизеп, куанып кешнәп җибәрде, куганны да көтмәстән, кызуларга тотынды. Аның кешнәвенә якындагы башка атлар тавыш бирделәр. Кайдадыр яңгыратып әтәчләр кычкырды, анасыннан аерылган

---

[1] Аҗун — дөнья.
[2] Сыя — язгы ташу вакытында елгада ага торган эре кар кисәге.
[3] Каган — хан, патша.
[4] Кам — йола-дин башлыгы.

бәтиләр чәрелдәде. Түбә өстендә генә, биек тирәк башында, талпынып-талпынып сыерчык сайрады. Яз килде, яз!

Урамда очраган кешеләр Утташ камга олылап баш иделәр. Язгы суда йомычка агызып, чыр-чу килгән бала-чагалар, Утташ камның бизәлгән, чылтыр-чылтыр килгән атын күреп, баштанаяк ап-ак киемен, каны качкан кырыс йөзен күреп, уеннарыннан туктап калдылар. Кечкенәләр, кинәт котлары алынып, җыларга тотындылар, өлкәнрәкләре, бу безне тотып ала күрмәсен, дигән сыман, тизрәк читкә тайпылырга ашыктылар. Усал кам узып киткәч, кешеләр артларына борылып карадылар. Куркып кына балалар янадан уеннарына тотындылар, ярым пышылдап, ерактагы камны үртәргә тотындылар:

Камчы-кам,
Тамчы там!
Кем башына? —
Җам башына!

«Утташ кам өеннән чыккан. Имингә генә булсын!» дип уйладылар кешеләр, пошынып.

Утташ кам, үзен күргәч кешеләрнең телсез-өнсез калуларына да, балаларның җылауларына да әз генә дә исе китмичә, киресенчә, үзеннән куркуларына күңеле булып, эре генә баруында булды. Урамның ике ягында да тыгызланып утырган тәбәнәк өйләр арасыннан чыгып, ул бераздан кар суы инде күптән агып беткән, шәрәләнеп, караеп калган калкулык итәгенә килеп җитте. Таш җәелгән тар гына юл кыйгачлап үргә менде, уңга борылды. Калкулыкның урта бер төшендә, иң биек җирдә биек койма белән уратып алынган би өе күренде. Тышкы якта, капка төбендә, кояшта йокымсырап утырган сакчы, тояк тавышын ишетеп, кабаланып аягына басты, күкрәген киерде.

— Иминлекме, балам? — диде Утташ кам, теләр-теләмәс кенә.

— Иминлек, кам баба! — диде сакчы, ашыгып, күзләрен челт-мелт ачып.

Утташ кам, аны-моны сорашып тормыйча, ярым ачык капкадан кереп тә китте. Сакчы капканы ишегалдагы пычрак сулар аксын дип ачып куйган иде. Ул Утташ камның шулай шома гына кереп китүенә аптырагандай итеп торды да ачу белән төкереп куйды, капкасын япты, сөңгесен кочаклап, янадан йокымсырый башлады.

Үзсүзле, кырыс йөзле кам бинең өй ишегеннән дә шулай сорамыйча гына, җинел генә үтеп китмәкче булды, тик мондагы сакчы аңа аркылы төште.

— Би өйдә юк. Яр-капкада,— диде сакчы.

## II

Ак бүре ыруының башы Күрән би үзенең ырудашлары белән яши торган Кызыл Яр катау [1] Чулманның уң ягына — биек, текә ярга җитеп, кырт кына киселгән ачык сырт өстенә урнашкан иде. Чулман ярыннан ераклашкан саен киңәя барган, тигезләнә, яссылана барган сыртның ике

---

[1] Катау — коймалар, урлар белән ныгытылган, коралы гаскәр тарафыннан саклана торган торак урын. Катауларда гадәттә биләр, ханнар яшәгән.

ягыннан да су ашаган тирән чокыр сузыла. Катаудан бер-ике чакрым арыда, куе урман эчендә атлап чыгарлык кинлектә генә булган, катау янында исә чын-чынлап упкынга әйләнгән чокырлар төбеннән җәй көне челтерәп чишмәләр йөгерә, яз көнендә — болганчык сулар ага. Шуңа күрә, күз күреме җиткән барлык җирне Чулман инләп алган чакта, кыргый урманнар, таулар-калкулыклар арасында, иксез-чиксез су уртасында утрау гына булып күренгән Кызыл Яр катау бөтен аҗуннан аерылган сыман тоела иде.

Тигезле-тигезсез өчпочмак шикелле калку җир кисәге текә ярлар буенча сузылган ике катлы койма белән уратып алынган. Катауның басуларга, урманнарга барып тоташа торган тигез ягы яу өчен иң уңай урын булып саналганга, сыртның батынкы билен аркылыга кисеп, бер як чокырдан икенче як чокыргача сузылган коймалар аеруча нык итеп корылган. Имән, нарат агачларыннан салынган ике кат бура арасына балчык, ком катыш чуер таш тутырылган, өстенә күпер җәелгән. Тышкы яктан койма буйлап өч кат тирән ур [1] казылган, ур кырыйларына очлы башлы юан казыклар утыртылган. Койма янынннан үтә торган иң тирән урга казык башларын күмәр-күммәс су тутырылган.

Катауның ике капкасы бар. Капкаларның берсе — Чулман яры буендагысы «яр-капка» дип, тигезлек ягындагысы «басу-капка» дип атала. Койма өстендәге каравыл өйләрендә, сырганнарда [2], каргуларда [3], капка төпләрендә көнен-төнен сакчылар кизү торалар. Чулманга су төшкәндә аеруча сак, уяу булырга кирәк. Мондый чакта астан да, өстән дә каеклар-да юлбасарларның, я булмаса канга сусаган күршеләрнең килеп чыгуы бар.

Мондый чакта катау кешеләре, билгеле, яу килүен генә көтмиләр иде. Мондый чакта — каекларга, көймәләргә тоткарлыксыз юллар ачылганда, катау кешеләре чит илләрдән, чит җирләрдән шулай ук яхшы кунакларны да көтәләр иде.

Ак бүре ыруының башы Күрән би яр-капка янындагы сырганга менеп карарга ярата иде. Бөтен катауда бу — иң биек җир. Чулман өсте дә, ерактагы урманнар, калкулыклар да моннан уч төбендәгедәй күренә. Менә бүген дә ыру башы, сырганның тар төннегенә капланып, ерактагы күк читен шактый озак күзәтте. Бик бирелеп караганга, аның күзләре авыртты, су чите белән күк чите исә, бергә буталып, болганчык томанга әйләнде. Күрән би, яшь чакларындагы шикелле озак карый алмавына, башы әйләнүенә, йөрәге сугуына эче пошып, көрсенеп куйды. Күзләрен йомган килеш, беравык тамга [4] сөялеп торды да икенче як төннек [5] янына килде. Чәнечкеле кара урманнар, калкулыклар белән чикләнгән су өстен ул бик теләмичә генә күзәтте — төн ягы аны артык кызыксындырмады.

Беравык онытылып торгач, би янадан көн якка — Чулманның түбән ягына текәлде. Елга өстеннән салкынча җил исте; аста, яр буенда, балыкчыларның өзек-өзек тавышлары ишетелеп китте. Кешеләр тавышы туктальп торган арада, бөтен тирә-якны тигез бер шауга күмеп, берөзлексез дулкыннар шауләды.

Күпме генә караса да, су өстендә би бернәрсә дә күрә алмады. Ул тагын көрсенеп куйды, аптырап төннек каршында беравык басып торды да, авыр аякларын көчкә кузгатып, тар, текә баскычтан аска төшә башлады. Ул баскан саен басма яркаклары, авырлыкка түзә алмыйча, шыңшып-ыңгырашып калдылар. Басмалар гына түгел, буралап салынган сырган да би әкрен генә атлап аска төшкәндә як-якка чайкалып торган-

---

[1] Ур — катау тирәсен әйләндереп алган тирән чокыр, канау.
[2] Сырган — манара.
[3] Каргу — манара сыман биек корылма. Яу килгәндә, шуннан төтен җибәрелеп, тирә-якка хәбәр таратылган.
[4] Там — стена, дивар.
[5] Төннек — монда «тәрәзә» мәгънәсендә килә.

дай булды. Илле яшьләр чамасындагы Күрән би богадай таза, имәндәй тәз, озын буйлы иде. Тик бу тыштан караганда гына шулай иде. Таза «имән»нең эченә корт төшкән иде. Кыш урталарыннан бирле инде бине ниндидер яман чир тынгысызлый. Аның эче авырта. Элеккечә инде ул чиләкләп буза да эчә алмый, терсәгеннән май агызып, симез итләр дә ашый алмый. Язга таба исә аның бу эчке авыруы тагын да көчәя башлагандай булды. Сул як касыгында ул бертуктаусыз авырту тойды, ниндидер көйсезлек тойды. Шуның өстәвенә тагын бер дә юктан, бөтенләй искәрмәстән башы әйләнә, күз аллары карангылана торган булып китте. Кайчакларда йөрәге дә авырта шикелле тоелды. «Үлемем якынлаша микәнни?» дип уйлады еш кына би, коты алынып. Әлегә ул үзенең чире турында имчеләргә дә, күрәзәчеләргә дә берни белдермәде. Әлегә ул эчтән генә көяләнде. Шулай да аның көннән-көн сүлпәнләнә баруын, ыру эшләре, катау эшләре белән бик үк кызыксынмый башлавын якын кешеләре күрми калмадылар. Бу инде Күрән бинең кулыннан көч китә барганлыгын белдерә иде, бу инде аның кояшы баюга таба тәгәри дигән сүз иде. Ни генә булмасын, үзенең чирен би шуна юрады. Бу аның туктаусыз күңелен тырнап торды. Әч пошу, күңел тырналу исә аның күзгә күренмәгән әлеге чирен генә көчәйтте.

Быелгы язны Күрән би менә шундый борчулар белән, аннан да бигрәк, яшерен теләкләр, ныклы ышанычлар белән каршылады. Чулманда боз кузгалу белән, ул көн дә шулай әле сырган, әле каргу башына менде, киң болыннарга җәелгән су өстен күзәтте. Ул үзе генә түгел, башкалар да күзәттеләр.

Бөек үзән боздан әрчелгәнгә инде бишенче көн булды. Башка елларда инде алар күптән килеп җитә торганнар иде. Кыр казлары сыман тезелешеп килерләр иде. Килеп җитәрләр иде дә, ач бүредәй комсызланып, ярга ташланырлар иде.

Быел менә юк... күренмиләр. Ни булган аларга? Җил-давыл чыгып, барысын да су иясе йотканмы? Хазар белән берәрсе үзара яу башлаганмы, әллә соң Этил буйлап юлбасар руслар төшеп, барысын да кырып бетергәннәрме? Әйе, быел алар сонга калдылар. Биш көнгә... ун көнгә, бер елгә сонга калдылар.

Инде нишләргә? Көн дә менә шулай сырганга менеп, күзләрен талганчы күк читен күзәтеп торыргамы, әллә соң аларның килеп житкәнен көтеп тормастан, тизрәк үзенә юлга жыена башларгамы? Килмәсәләр, нишләтергә барлык таварынны? Маңгай тирең түгеп тапкан еллык байлыгынны нишләтергә? Киштәләрне сыгып төшкән төлке, кеш, ас, кондыз тиреләрен, тәпән-тәпән балларны, таудай өелгән ул күннәрне, савыт-сабаны, агач-ташны нишләтергә? Аннан да бигрәк... аларныкы кебек имчеләрне каян табарга монда, аларныкы кебек им утларын, им суларын каян алырга? Бар ышаныч бары аларда, бары аларда!

Күрән би, күңелсез уйлар уйланып, койма өстендәге күпергә килеп чыкты. Текмә читенә якын килеп, су ягына тагын бер карыйсы килсә дә, карамады — ары китте. Койма өстендә, ышыкта, җилсез иде, җылы иде. Аның бер дә моннан кайтып китәсе килмәде. Шулай үз-үзен кая куярга белми басып торганда ул яр-капкага якынлашып килүче Утташ камны күреп алды. Аның болай да карангы йөзе тагын да карангыланып китте, ниндидер күңелсез сөйләшү буласын сизенеп, касыктан өстәрәк эче сызлый башлады.

III

— Иминлекме, би? — диде Утташ кам, койма өстенә менә торган баскыч янында туктап.

— Иминлек, кам баба,— диде би тыелып кына, урыныннан кузгалмыйча.

Ул, култыксаны кысып тоткан көе, Утташ камның аттан төшүен, үз янына менүен көтеп торды. Утташ кам, теләр-теләмәс кенә, өзәңгедән аягын алды, ашыкмыйча гына, үзенең кемлеген белеп кенә баскычтан менде дә, би алдында бүреген салып, башын иде.

— Илгә тынычлык, бигә байлык бирсен, тәңрем,— диде кам.

— Шулай булсын,— диде би, камның йөзеннән күзен алмыйча.

— Су азрак икән шул быел,— диде Утташ кам, текмә янына килеп.

— Юк, алай ук аз түгел, кам баба,— диде би.— Сырган башыннан яхшы күренә — менәбезме?

— Юк, юк! — диде Утташ кам, кулын селтәп.— Монда кил. Аска төшик булмаса. Сөйләшәсе сүзем барые синең белән, би.

— Ник аска төшеп торырга? — диде би.— Әйдә каравыл өендә сөйләшәбез.

Ул, Утташ камның ни дә булса әйткәнен көтеп тормастан, кире борылды. Койма өстенә салынган каравыл өенең ишек бавын тартып җибәрде. Каравыл өе тар гына, кысан гына иде. Аның Чулманга караган ягына озынча төннек, түшәменә — төтен юлы уелган иде. Балчык идән уртасына эре ташлардан өеп учак ясалган, учакның ике ягына, капма-каршыга утыргычлар куелган иде.

Би килеп кергәндә, ике яшь сакчы, җылы учак өстенә иелә төшеп, көлешеп нидер сөйләнеп утыралар иде. Бине күрү белән, алар икесе дә урыннарыннан сикереп тордылар, ниндидер язык эштә тотылган кешеләр сыман, кызарынып үрә каттылар, телсез калдылар.

— Чыгып торыгыз,— диде би аларга.

Сакчылар ишеккә ташландылар, би артыннан килгән камны күрмичә, аңа килеп бәрелделәр — чак-чак кына аяктан екмадылар. Ярый әле Утташ кам ишеккә тотынып калды.

— Күзегез чыкканмы әллә? — дип кычкырды кам, ачу белән.

Сакчылар, агарынып, камның аяк астына егылдылар.

— Игелексезләр! — дип сукранды Утташ кам, сакчыларны чыбыркысы белән сыдырып.

Ыру башы белән икәүдән-икәү генә калгач та ул шактый тынычлана алмады. Күрән би, аның ыңгырашуына, сыкрануына эчтән генә көлемсерәп, тар утыргычка җәелеп утырды да кыска тунының көмеш каптырмаларын ычкындырып җибәрде — елгадан төннек аша салкын җил исеп торса да, учак янында эссе иде.

— Ни йомыш, кам баба? — диде би, сүзгә башлап.

— Йомышыңны да онытырсың монда,— диде кам, сөякчел куллары белән озын, нечкә сакалын сыйпаштырып.

— Шулай тиз онытырлык йомышмыни, кам баба? — диде Күрән би, көлемсерәп.— Кызың исән-сау... илдә тынычлык... Күреп торасың, тәңренең боерыгына буйсынып, Чулман боздан әрчелде... Ишек артында беркемнең күзе юк.

— Тын алырга ирек бир, кияү,— диде Утташ кам, бинең шулай килделе-киттеле сөйләнеп утыруын ошатмыйча.— Мин синең белән эш турында сөйләшергә килдем.

— Сөйләшик, бабай.

— Яшел чирәм җирдән борын төрткән, кияү! — диде кам, ясалма бер күтәренкелек белән.

— Күргәнем булмады,— диде би сүлпән генә.— Бу арада башлар катып тора.

— Каткандыр, кияү, каткандыр,— диде кам баба, тынычланып.

Тынычлангач, ул үзен бидән өстен сизә башлады. Үзен өстен сизгәч исә аның күз алдында Күрән би, башка барлык ырудашлары кебек, аңсыз, белексез бер кешегә әйләнде. Бөек тәңре турында, изге ияләр, яман ияләр турында, йола турында үзе нәрсә генә әйтмәсен, Күрән бинең бер сүзсез ышаначагын, үзе белән килешәчәген ул алдан ук белеп утырды.

Моны шулай ук би үзе дә белде. Утташ камны ул үзенең бабасы буларак кына түгел, ыруда беренче урынны яулап алырга, ыру башы булырга омтылучы көндәше, ягысы буларак та күралмады, шулай да түзде. Ак бүре ыруының өлкән камы, имчесе, күрәзәчесе, аксакалы булган Утташны ул, би буларак, ыру башы буларак, олыларга тиеш иде. Элек тә ул еш кына аннан шүрләп куйгалый иде. Үзен чир корты кимерә башлагач, бу шүрләү еш кына анда чын-чынлап куркуга әйләнә иде.

— Аннары шул: сигез көннән, кияү, төн үзәге авышкач, беренче этәч кычкырыр алдыннан яңа ай тула,— диде Утташ кам, ашыкмыйча гына, күзләрен йома төшеп.

— Шулаймы? — диде би, күңелендә ургыган каршылыклы уйларын җиңеп, камның сүзләренә ярарга тырышып.

— Яңа ай туар алдыннан барлык эшләрне төгәлләү кирәк, кияү,— диде Утташ кам.— Нинди ай тулганын беләсеңдер, кияү... Яшел чирәм ае. Яшел чирәм белән бергә изгеияләр дә, явызияләр дә — айналар, албастылар да уяна. Бөтен аҗун күзен ача! Быел су күп түгел. Быелгы җыл яман килә, кияү!

— Сыгыр җылы! [1] — диде би, көрсенеп, Утташ камның куркыныч сүзләре йогынтысына бирелеп.— Сыгыр җылында орыш күп була, дип белми әйтмәгәннәр бабайлар. Яман килере инде күренеп үк тора — бүген бишенче көн, әнә беркем юк.

— Явыз ияләр яшел чирәмнән дә элегрәк уянганнардыр,— диде Утташ кам, бине тыңламыйча.— Чокырларда пычрак сулар торып калды, агачларга чүп-чар эләгеп калды. Җыл яман килә. Йолык [2] туен зурлап ясарга туры килер, кияү!

— Зурлап ясарбыз,— диде би, килешеп.

Шулай диде дә кинәт сагаеп калды. Бабасының нинди уй белән килүен ул элегәчә белә алмый интегә иде. «Зурлап» дигәндә Утташ камның коры, шыгырдавык тавышы чак-чак кына калтыранып киткәндәй булды. Нәрсә каермакчы була бу? Ука белән каелган төлке-тамак тунмы, энҗеле камчат бүрекме, көмешләнгән иярме, кырнакмы [3] — нәрсә?

— Бүген төш күрдем, кияү,— диде Утташ кам, беравык тынып утырганнан соң, әкрен генә, серле генә яңадан сүзгә башлап.— Атка атланып үзебезнең басу-капкадан күпер аша чыгып барам, имеш. Күпер уртасына җиткәнием, каршыма Әрлик хан ялчысы Октуган килде-чыкты! Бер кулы белән атның ялыннан тотты, икенче кулы белән сакалымнан тотып алды. Тешләрен ыржайткан, күзләре уттай яна! Йолаларны бозасыз, ди, йолык бирмисез, ди. Атыңны бирәсеңме, ыруыңны, җиреңне-суыңны бирәсеңме, ди...

— Ялган! — диде кинәт би, башын калкытып.

— Ни нәрсә ялган, балам? — диде Утташ кам, өстенлеген, тынычлыгын әз генә дә үзгәртмичә, авыр күз кабакларын калкыткандай итеп.— Минем сүзләрем ялганмы, явыз Октуган ялганмы? Тфү-тфү! Телемә дә аласым килми атын... котымны ала язды, көчкә котылдым.

Күрән би эндәшмәде, очлы бүрек кигән авыр башын салындырып, ачуыннан кызарынып-бүртенеп тик утырды.

---

[1] Борынгы төрек халыкларында, ислам дине кабул ителгәнчегә кадәр, елларны беренче, икенче... йөзенче... меңенче дип санамаганнар, бәлки төрле хайван исемнәре белән атап йөрткәннәр. Унике ел буена һәр ел бер хайван исеме белән атап әйтелгән, унике елдан соң шул ук исемнәр яңадан кабатлана башлаган. Беренче ел — Тычкан елы. Икенче ел — Сыгыр (сыер) елы. 3. Барс елы. 4. Куян елы. 5. Балык елы. 6. Җылан елы. 7. Ат (жылкы) елы. 8. Куй (сарык) елы. 9. Маймул (бичин) елы. 10. Тавык елы. 11. Эт елы. 12. Дуңгыз елы. Борынгылар Сыгыр елында орыш күп була, Тавык елында — азык мул, ләкин кешедә борчу күп, Балык елында — яңгыр күп ява, Куян елында — ачлык, Дуңгыз елында — суык һәм фетнә була дип уйлаганнар. Бу календарьның кайбер калдыкларын бүгенге көндә дә очратырга мөмкин.

[2] Йолык — корбан чалу. Йолык туе — корбан чалу бәйрәме.

[3] Кырнак — кол кыз, җария.

— Эрлик хан ялчысы явыз Октуган сүзләре ялган, кам баба,— диде ул бераздан, ачуын эчкә йотып.

— Менә шул...— диде кам, өзелгән сүзен ялгап,— сакалымнан тотып алды бу. Тарта. Авызына якын ук китерде. Инде йота дип торам. Җиргәсуга да, ыруыма да тимә, атымны бирермен, мин әйтәм...

— Нинди атка атланганыең соң син, кам баба? — диде би, ачыктаначык мыскыл сиздергән бер тавыш белән.

— Мин, кияү, Йолдыз-кашкага атланганыем,— диде Утташ кам тыйнак кына.

— Юк! — диде Күрән би, аягына басып.— Йолдыз-кашкага синең беркайчан да атланганың юк... төшеңдә дә! Атлана да алмыйсың, син аның янына да бара алмыйсың!

— Ялгышасың, кияү,— диде Утташ кам, коры, усал күз карашы белән бине өтеп.— Изге эшкә тел тидереп тору үзе язык! Күңелең бозык синең, кияү, шуңа да эшең алга бармый.

— Монысы инде яла,— диде Күрән би.

— Мин синең белән ызгышырга килмәдем,— диде Утташ кам, урыныннан торып, эре генә.— Яңа айның дүртенче көнендә йолык туе ясарбыз. Син шуңа каршы түгелдер ич?

— Ясарбыз,— диде би, теш арасыннан сыгып.

## IV

Ак бүре ыруының башы Күрән би белән Утташ кам туганнан туганнар иде. Ыруда иң көчле кешеләр буларак, алар моңарчы үзара тату гына яшәделәр. Каршылыклар килеп чыкса да, беркайчан да алар эшне зурга җибәрмәделәр, ничек тә җайларга, үзара килешергә тырыштылар. Бозылышу, чын-чынлап бозылышу узган көздән башланды. Бинең өлкән хатыны Әди тилчәдән үлгәч, аның урынына кемнең өлкән хатын булырга тиешлеге турында туган-тумача арасында тартыш булып алды. Ыру йоласы буенча, өлкән хатын булып бинең яшькә иң өлкән хатыны, карт хатыны Каракүз калырга тиеш иде. Каракүз исә Утташ камның кызы иде. Карт, чулак хатынын Күрән би яратмый иде. Чулаклыгы, ямьсезлеге өстенә Каракүз бераз гына аңгырарак та иде. Би аңа яшь чагында да «йола буенча» гына өйләнгән иде. Шулай ук бергә торганда да ул аның белән «йола буенча» гына торды — аннан аның бер генә баласы да булмады. Бөтен ыруда Күрән би уң кул булса, Утташ кам сул кул кебек иде. Шуңа күрә, бары яратмаган өчен генә ул аның кызын аерып та җибәрә алмый, читкә дә тибәрә алмый иде.

Шулай да Күрән би яңа өлкән хатын билгеләгәндә үзенчә эшләргә булды. Беренче тапкыр ул ыру йоласын бозды, беренче тапкыр бөтен туган-тумача алдында, бөтен ыру алдында үзенең Утташ кам белән санлашмавын күрсәтте. Өлкән хатыны итеп ул Каракүздән яшьрәк Койтым бикәне куйды.

Бинең өлкән хатыны булу ул мактаулы ат кына түгел иде. Бинең өлкән хатыны булу ул туктаусыз эш, кайгы, борчу дигән сүз иде. Өлкән хатын ул ашау-эчүне, өй карауны, кием-салым җитештерүне, терлек карауны, бинең бүтән хатыннарын, барлык балаларын, колларын-чураларын, кыз-кыркыннарын үз кулында тотарга тиеш иде. Катлаулы, чуалчык бу эштә аңа ныклы кул да, яхшы, тиз уйлый торган баш та, ару-талу белмәс йөрәк тә кирәк иде. Бинең бетмәс-төкәнмәс көндәлек эшен, таудай эшен Койтым бикәдән башка чыннан да беркем дә башкара алачак түгел иде. Моның шулай икәнлеген Каракүз үзе дә бик яхшы аңлады, шуңа күрә ул өлкән хатын булу турында бернинди теләк белдермәде. Аның өлкән хатын булуын, барыннан да бигрәк, аның усал атасы теләде, Каракүз аркасында ыруда тагын да зуррак көчкә, байлыкка ия булырга тырышкан туган-тумачалары теләде.

Өлкән хатын булып Койтым бикәнең билгеләнүен белгәч, Утташ кам ачуыннан шартлый язды. Күктәге тәңрегә, җирдәге ияләргә таянган, шуңа күрә үзенең көченә кирәгеннән артык ышанган Утташ кам ырудашларын ачыктан-ачык та, яшертен дә бигә каршы котырта башлады: аның үзе турында, Койтым бикә турында яман сүзләр сөйләде, йола бозган өчен бөтен ыруга, катауга киләчәк кыран[1] белән, яу белән, талау белән куркытты. Үзенә каршы коткы тараткан өчен Күрән би, теләсә, билгеле, Утташ камны бер селтәнүдә юк итә алган булыр иде. Бабасы белән бик каты ызгыштан соң ул чыннан да шулай итмәкче булды. Койтым бикә аңа икенче төрлерәк киңәш бирде: син йоланы боздың, шулай булгач, сиңа Утташ кам белән килешүдән башка юл юк, диде; моның өчен сиңа иң элек аксакаллар белән килешергә кирәк, юкса сине Утташ камның әйләндереп салуы бар, диде.

Күрән би өлкән хатынының сүзен тыңларга булды. Ул аксакаллар киңәше җыйды, үзенең ни өчен йоланы бозарга тиеш булуын аңлатып бирде. Аксакаллар бине яклап чыктылар. Утташ кам җиңелде, тик шуннан соң ул үзенең киявенә каршы эшне уйлабрак, астыртынрак эшли башлады. Әле генә Йолдыз-кашканы йолыкка соравы аның менә шул астыртын эшнең бер чагылышы иде.

Үзенең бабасын би каравыл өеннән озата чыкты, аска төшә торган баскычкача ул аның белән янәшә атлап барды. Шулай да ул җиргә төшеп тормады, койма өстендә торып калды. Мыек чылгыйларын чәйнәп, би Утташ камның атка атлануын, иярдә буен төз тотып, китеп баруын карап торды.

Менә, бер елны бүдәнә симерсә, икенче елны — тартар... Көрәш әле тукталмаган. Монысында ул җиңде. Йолдыз-кашка инде юк! Чыннан да, ялгышмады микән ул йоланы бозып? Ни отачак ул бабасы белән тартышып? Күрәсең, берни дә отмаячак. Бүген Йолдыз-кашка, иртәгә тагын башка нәрсә... Аның көче чиксез, турыдан-туры аңа каршы чыгып булмый. Ни дигән сүз бу? Әллә чыннан да аның каргышы төштеме? Ул чире, ул сартлары[2]... соңга калган ул сартлар-базарганнар[3]... Нишләп уйламады соң әле ул моңарчы бу турыда?! Йа тәңрем, үзең ярлыка барлык языкларны!

Утташ кам күздән югалгач та Күрән би баганаларга салынган басмалар буенча, койма өстеннән басу-капка ягына юнәлде. Аның күңелен икеләнү корты кимерде. Аннары аның юкка-барга ачуы килә башлады. Аның кемне дә булса тотып янаклыйсы, тибеп җибәрәсе, я булмаса кылыч белән башын чабып өзәсе килде. Тик койма сакчылары барысы да урыннарында иде, барысы да коралллы, тыныч, кырыс иде.

Чирек чакрым чамасы баргач, койма буендагы басмадан уң якка икенче басма аерылды. Бу басма да биек баганаларга салынган иде, тик аның янында койма гына юк иде. Күп тә үтмәде, басмалар буенча би үзенең урдасына кайтып керде.

Яшь, чибәр хатыны Койтым бикәне күрү белән, аның барлык ачуы юкка чыкты. «Юк, ялгышмаганмын,— диде ул үзенә үзе, баштагы уйларына кире кайтып.— Утташ кам теләсә ни сөйләсен — көч барыбер минем кулда!»

«Шулай да этне үскетмәвең яхшы,— дип уйлады ул бераздан.— Ярар, Йолдыз-кашка ике арадагы ызгышка чик куйсын. Шуның белән тамагы тыгылсын. Тату яшәүгә ни җитә!»

Өлкән хатынына ул үзенең әлерәк кенә Утташ кам белән очрашуы турында сөйләде.

---

[1] Кыран — бала-каза, зыян.
[2] Сарт — сәүдәгәр, Урта Азия кешесе.
[3] Базарган — чит ил сатучысы.

— Мин каршы түгел,— диде Койтым бикә, беравык тынып утырганнан соң, иренең сүзенә артык куаныч белдермичә.— Шулай да атның иясе белән дә кинәшсәк ничек булыр икән?

— Тотыш беләнме?! — диде би, исе китеп.— Атасы-анасы белән кинәшергә аңа әле иртәрәк. Ни әйтсәләр, шуны тыңлар.

— Шулаен шулай да...— диде Койтым бикә күнелсез генә.— Тугач та Йолдыз-кашканы аңа үзең атадың. Ул аны карап үстерде. Инде килеп, берни әйтми тартып алсак, ни дияр ул бала? Аңа инде бала дип тә булмый...

— Өйләнмәгән,— димәк, бала! — диде ата кеше.

— Йола буенча — шулай, чынында инде ул — җитлеккән ир,— диде Койтым бикә, бердәнбер углын яклап.

V

Язгы йолык туен кешеләр кояш көткән кебек көтеп алалар иде. Бу көнгә һәркемнең яшерен уе-теләге була. Авырулар, явызияләргә йолык биреп, чирдән котылу, авырлылар — баладан, языклылар — языктан котылу турында уйлап юаналар иде.

Йолык туенын кайчан буласы билгеле булгач та, катау кешеләрен күңелле бер көтәренкелек биләп алды. Кешеләр, бу олы көнне тиешенчә каршылау, тиешенчә озатып җибәрү өчен җыена да башладылар: өлкәннәр йолыкка биреләсе терлек-туар турында, аш-су турында кайгырттылар, яшьләр көн-төн үзара бәйге тоттылар — ук аттылар, сөнге чөйделәр, көчләрен сынаштылар.

Иртәгә туй була дигән көнне катау кешеләре мунча керделәр, баштанаяк таза киемнәрен киенделәр — кышкы чирләрдән, языклардан, кайгылардан арыну шуннан башланды. Аннары, артыш яндырып, өй эчендәге почмакларны, абзар-кураларны төтәсләделәр — күздән кереп калган явыз ияләрне куалап чыгардылар.

Икенче көнне барлык катау кешеләре — яше-карты, тазасы-чирлесе — башка көннәргә караганда иртәрәк тордылар. Кояш чыкмас борын ишекләр, капкалар ачылды. Олуг Чулман аръягыннан, су астыннан чыгып килгән кояшның беренче яктысын кешеләр, җиргә ялан аяк баскан килеш, йөзләрен көнчыгышка төбәгән килеш, елмаеп-куанып каршыладылар. Ырудашлар бер-берсен яңа туган көн белән котладылар, берберсенә изге теләкләр белдерделәр.

Кояш чыгу белән бер үк мәлдә дип әйтерлек, көндәлек тормыш башланганлыгын аңлатып, учакларга утлар ягылды, катауның меңләгән очлы түбәләреннән күккә зәңгәр төтеннәр үрләде. Төтеннәрдән бераз гына соңгарып, басу-капка ягында да, яр-капка ягында да быргылар уйнап җибәрде. Капкалар ягыннан килгән таныш көй тынарга да өлгермәде, катау өстендә икенче төрле тавышлар яңгырады. Басу-капкадан яр-капкагача сузылган борма-сырма урамнан Чулман ягына — кояшка каршы атлылар төркеме бара иде.

Барлыгы алар унлап кеше иде. Барысы да акбүз атларга атланганнар, барысы да баштанаяк ак киемнәргә киенгәннәр. Аларның атларына чигүле япмалар ябылган. Атларның ялларына, койрыкларына, маңгай чәчләренә очлы тимер, җиз кисәкләре, бөркет каурыйлары, балык сөякләре, бүре тешләре белән аралаштырып, төрле төстәге тасмалар тагылган. Шулай ук җайдакларның үз киемнәре дә иске-москы чүпрәк, тимер-томыр, агач-сөяк ише нәрсәләр белән бизәлгән. Шунлыктан атлар да, кешеләр дә әкрен генә атлап барган уңайга чыңлаган, чылтыраган, шакылдаган тавышлар чыгаралар. Шушы шалтыр-шолтыр тавышларга әледән-әле дөңгер тавышлары кушыла иде.

Акбүз атларга атланган ак киемле төркемнән берничә адым алдарак, төрлечә кыланып, ихахайланып, җылап, тырнашып юл буенда нин-

дидер карачкылар кыймылдый. Алар барысы да эшәке, сәләмә киемнәргә киенгәннәр. Алар коточкыч ямьсезләр: берсенең авызы кыек, икенчесенең күзе сукыр, өченчесенең аягы аксак. Болар шулай төрләчә киендерелгән, битләренә, маңгайларына корым буялган «явыз ияләр» — айналар, албастылар, өрәкләр иде. Дөңгер[1], быргы тавышлары белән куркытып, артларыннан уклар атып, аларны Чулманга куалар иде. Урамнарда, капка төпләрендә җыелышып торган кешеләр, бигрәк тә бала-чагалар, бу «албасты-өрәкләргә» таш, балчык кисәкләре ыргытып, каргыш сүзләре яудырып калалар иде.

Ак җайдаклар төркеменең башында, озын саплы ал байрагын югары күтәреп, ыруның өлкән йолачысы Утташ кам бара. Ат койрыгы сыман озын, тар байракның уртасына Ак бүре ыруының билгесе — ак бүре башы төшерелгән иде.

— Кайраккан! Кайраккан! Алас! Алас![2] — дип кычкырды Утташ.

Аның тавышы тынар-тынмас, арттагылар бердәмләшеп аның соңгы сүзен күтәреп алдылар, бөтен катауны яңгыратып: «Алас!» дип кычкырдылар. Бераз җир тын гына баргач, дөңгер, быргы тавышлары тыну белән, Утташ кам янадан башлады:

— Төрек бөдүн! Ыру бөдүн![3] Уянызыз — көн тугды! Уянызыз — йолык туе!

Аның артыннан тагын да яшьрәк, көррәк тавышлар:

— Алас! Алас! — дип кычкырдылар.

Шушы беренче төркемнәрдән соң бераз калышып, басу-капка ягыннан икенче бер җайдаклар төркеме кузгалды. Болары барлыгы уналты кеше иде. Алар барысы да, яуга чыккан сыман, баштанаяк күн, тимер киемнәргә киенгәннәр, билләренә кылыч, уклык тагып, кулларына сөңге тотканнар. Аларның да атларына төрле тасмалар тагылган, аларның да иң алдагысы ыру байрагын күтәреп бара иде.

Коралды ирләр күренү белән, урамдагы кешеләр капка, койма артларына качышып беттеләр. Шул ук мәлдә дип әйтерлек коймаларга, капкаларга, берәр багана төбендәге ташка-нигә, я булмаса өй түбәләренә шап та шоп уклар килеп тия башлады. Бу изге уклар иде. Өенә, каралты-курасына изге ук тигән кеше үзен өлешле итеп, бер ел буена үзен чир-чордан, талаудан, кайгы-борчудан котылган итеп саный иде.

Менә сөрәнчеләр дә узып китте. Күңелле ыгы-зыгы башланды. Ишекләр, капкалар яңадан ачылды. Капка төпләренә, урам якка озын колгаларга беркетелгән төрле төсләрдәге байраклар чыгарып куйдылар; баганалардан баганаларга, өйләрдән өйләргә ыру тамгалары төшерелгән чүпрәкләр, агач, сөяк кисәкләре бәйләнгән баулар сузылды; ишек төпләренә, учак яннарына, каралты-кураларга балаларны, карт-корыларны, терлек-туарны яман күзләрдән сакларга тиеш булган абаклар[4], сарыганнар[5] чыгарып утырттылар.

Еракта, йөрәкләрне җилкетеп, кам бабаның:

— Уянызыз — көн тугды! Уянызыз — йолык туе! — дигән сүзләре яңгырап торды.

## VI

Кояш су астыннан чыгып бер-ике таяк күтәрелгәндә, сөрәнчеләр, яр-капкага җитеп, кире борылдылар. Күрән би урдасы янында аксакаллар төркеме туктап калды. Би өендәгеләр дә быргы уйнап җибәрделәр.

[1] Дөңгер — барабан.

[2] Кайраккан! Кайраккан! Алас! Алас! — Монда: изге иияләргә олылап эндәшү сүзләре.

[3] Төрек бөдүн, ыру бөдүн — а) төрек — гомумән төркиләр; б) бөдүн — халык, улус.

[4] Абак — пот, табыну сыны.

[5] Сарыган — шул ук «абак»ның бер төре.

ал байракларын күтәрделәр. Капка сакчылары каерып имән капкаларны ачтылар. Капкада би углы Тотыш күренде.

Атасы кебек ул таза, эре сөякле иде. Тик ана караганда ул буйга тәбәнәгрәк, иңбашка киңрәк иде. Борын асты әле аның яңа гына караеп килә. Бүгенге көндә караңгы чырайлы булу язык саналса да, аның алсу иреннәре кысылган, матур кара кашлары җыерылган. Җылый-җылый аның күз төпләре кызарып беткән. Ул кайгылы, ул ачулы, ул ярсулы иде. Сул кулына ул яшел төстәге язгы йолык байрагын тоткан, уң кулына үзенең сөеклесе Йолдыз-кашканы җитәкләгән. Бүген ул туй башчысы санала. Аксакаллар кебек ул да бүген баштанаяк актан киенгән. Биленә аның көмеш аеллы киң каеш буылган, муенына көмеш чылбыр белән ыру сакчысы — кечкенә алтын бүре башы тагылган.

Яшь, чибәр егет Йолдыз-кашка белән икәүләп капкадан чыкты да, тирә-якта җыелып өлгергән кешеләрнең берсенә дә карамыйча, төп юлга төште. Углы артыннан ук капкадан Күрән би чыкты, Койтым бикә, бинең башка хатыннары, балалары, туганнары чыкты. Ыру башы белән Койтым бикәгә урам яктагы сигез аксакал кушылды. Барысы да, үзләренең урыннарын белеп, би артыннан, аксакаллар артыннан ияртә бардылар. Ясанган, бизәнгән, куанып елмайган кешеләр төркеме, көчле бер агым булып, урамнан басу-капка ягына юнәлде.

Тотыш җитәкләгән яшь байтал искиткеч матур иде. Ул уттай янып торган җирән төстә. Маңгаенда аның уч төбедәй генә ак табы — йолдызы бар. Аның күкрәге киң; нечкә, нык аяклары озын. Ялт-йолт килеп, очкынланып торган күзләре зур, матур. Атлаганда аның аяклары җиргә дә тими шикелле — биюче яшь кызлар кебек ул шундый җиңел, шундый матур атлый! Бүген аны кияү куенына керәсе кыздан да болайрак төзәндергәннәр. Өстенә аның ука белән матур итеп каелган күк төстәге зур япма салганнар. Япманың чит-читләреннән көмешләнгән ал, кызыл, сары чуклар асылынып тора. Япма өстенә сырлап, бизәп эшләнгән кечкенә генә, җиңел генә ияр салынган. Яллары, койрыгы аның матур итеп таралган, киселгән.

Барлык кешенең күзе бары Йолдыз-кашкада гына булды. Алар аңа, сокланудан бигрәк, куркып, аптырап карадылар. Бөтен ыруда тиңдәшсез байталның — Күрән бинең мактанычы, яшь Тотышның куанычы булган атаклы чаптарның бүген менә йолык туенда чалыначагына беркемнең дә ышанасы килмәде. Бу ничектер башка сыймый торган, аңлап булмый торган нәрсә булып тоелды. Тик шулай да бу турыда беркем дә ачыктан-ачык әйтергә батырчылык итмәде.

Тотыш белән янәшә атлаган Йолдыз-кашка басу-капкага йөз адым чамасы калгач, капка сакчылары, туйны каршылап, быргы уйнадылар, дөнгер кактылар. Шыгырдап авыр капкалар ачылды, аркан белән күтәртеп куелган күперләр төшә башлады. Кырлар-басулар иркенлеген тоеп, Йолдыз-кашка кинәт тынычсызлана башлады: башын югары күтәргән килеш, борын тишекләрен киереп, язгы җил белән басудан килгән исерткеч исләрне иснәде, бөтен катауны яңгыратып, күкрәк түреннән ургылып чыккан бер куанычлы тавыш белән кешнәп җибәрде. Дөп-дөп атлап күпердән чыкканда ул чын-чынлап ярсый башлады: авызлыгын чәйнәде, «Әйдә, чабабыз!» дигән сыман, йомшак иреннәре белән яшь егетнең иңбашына төртеп-төртеп алды, тартылды, колакларын шомартты.

Сөекле чаптарын кызганудан Тотышның күзләренә яшьләр килде. «Әллә качабызмы икәүләп?» диде ул, күңеленнән байталга эндәшеп. Кем куып җитәр аларны? Беркем дә! Качарга да китәргә күршеләргә, Биар иленә. Я булмаса урманга кереп яшеренергә. Яшәргә шунда Йолдыз-кашка белән үлгәнче бергәләп...

«Качыйк! Качыйк!» диде Йолдыз-кашка, юеш ирене белән аның битенә үрелеп. Әллә соң ул аны шулай үпмәкче булды микән?

Озакламый үзенең тәңре каршысына китәчәген аңлап, әллә шулай саубуллашырга теләде микән соң ул? Атлар, этләр, барлык терлекләр, киекләр ни буласын алдан белеп, аңлап торалар, ди иң. Тик аларның әйтергә телләре генә юк.

Алар артыннан ябырылып, аларның үкчәләренә басып, меңләгән кешеләр, атлар килде. Колак төбендә генә шаулаган, кычкырган, көлешкән тавышлар ишетелеп барды. Бизәнгән, шау-шулы, куанычлы кешеләр төркеме, сабадан сыгып чыгарылган әйрән төсле, басу-капка аша, күпер аша киң яланга агылдылар да агылдылар.

## VII

Күпердән чыгып, бер чакрым чамасы баргач, төркем сулга борылды, сөзәк сырт өстеннән түбән төшә башлады. Баштарак сирәк-мирәк куаклар арасыннан сузылган, ары таба куе урман арасына барып кергәч иске киң юл кешеләрне озакламый зур гына аланга китереп чыгарды. Көньякка таба авышрак булган бу аланның як-ягында, сакчылар кебек булып, төз, биек чыршылар, каеннар, усаклар калкып утыра. Тирәякта язгы кояш исе, яңа җир, яңа чирәм исе аңкый. Монда үзенә бер төрле җиңеллек, иркенлек сизелә иде.

Аланның тач уртасында ялгыз нарат, бу тирәдә бердәнбер нарат үсеп утыра иде. Якындагы чыршы-усаклар белән чагыштырганда ул тәз дә, биек тә түгел иде. Аның кәкре-бөкре кызгылт ботаклары, ниндидер куллар сыман булып, бер-берсе белән аралашып беткән. Төптән ул бик юан, тирмә сыман җәелгән ябалдашы шундый киң,— яңгыр яуганда аның астына күпме генә кеше керел утырса да, ул аларның барысын да сыйдыра алыр шикелле. Кәүсәсенең җиргә якын төшенә аның җир астыннан бүртеп-кабарып көчле тамырлар килеп тоташа. Җиргә нык берегеп утырганлыгы аның әллә каян күренеп тора. Бу искиткеч нык, юан наратны, карт, олы наратны, әйтерсең, бернинди җил-давыл да, бернинди күк күкрәүләр дә, җир тетрәүләр дә урыннан кузгатырлык түгел иде.

Тик нишләптер бу наратның яшел ылысларында, кызгылт шома ботакларында агарып терлек сөякләре күренгәли иде. Ат, сыер, сарык сөякләре... тешләрен ыржайткан, кара күз төпләрен акайткан баш сөякләре, кабырга, умыртка сөякләре... кыл, йон кисәкләре... тояклар... Язгы кояшта күзләрне чагылдырган, агарып, шомарып беткән шундый ук сөякләр, тояклар, кыл-йон кисәкләре тирә-якта җир өстендә дә аунап ята. Яшел чирәм белән капланган җирнең битендә зур-зур яралар булып, кара тап булып, иске учак эзләре, чокырлар, кара күмергә әйләнгән агач башлары күренгәли.

Куе урман эчендәге бу алан — Ак бүре ыруының келәүлеге, келәүлек уртасындагы изге нарат — Ак бүре ыруының табына торган изге нараты иде. Монда — йолык урыны. Ыруның барлык язгы-җәйге, көзге туйлары шушында уздырыла иде.

Уйнап-көлеп, җырлар җырлап, шау-шу килеп кешеләр изге аланга җыела тордылар, күче-күче белән үзләренең ата-бабадан килгән билгеле урыннарына тарала тордылар. Атланып килгән, җигеп килгән атларны туарып, тышаулап, түбәндәге инеш буена утларга җибәрделәр. Арбаларны, изге нараттан билгеле бер ара калдырып, ялан уртасына божра сыман тезеп чыктылар. Ялгыз нарат божраның кыл уртасында калды. Изге түгәрәккә керү-чыгу өчен ике якта ике капка калдырылды. Капкалар янына, катаудагы кебек, сакчылар куелды. Шунда ук ал байраклар кадалды. Башка төстәге байракларны божраның капкасыз төшләренә — «койма» буйларына кадап чыктылар. Изге түгәрәкнең эченә үзләре белән алып килгән сыннарны: абакларны, сарыганнарны утыртып куйдылар. Арбадан арбага чуклы баулар эленде.

Коллар, чуралар арбалардан ачы бал, буза тулы кисмәкләр, чүлмәкләр, чапчаклар [1] алдылар, төргәкләрне бушаттылар. Ирләр урманга утынга кереп киттеләр, хатыннар, иске урыннарга учаклар ягып, казан асарга тотындылар. Сугымчылар пычак кайрады, аксакаллар, Утташ кам житәкчелегендә, изге түгәрәктә мәш килделәр.

Изге божра эчендәге учакларда ут кабынып, күккә зәңгәр төтен күтәрелү белән, аландагы шау-шу кинәт тынып калды. Кешеләр, эшләрен ташлап, арбалар янына җыелдылар. Алданрак өлгергәннәр арбаларына менеп басты, кайберләре атларга атланды, яшьләр, бала-чага агач башларына үрмәләде.

Менә, җил-давыл чыккан сыман, кинәт кенә дөңгер каккан, һай-һулап кычкырган тавышлар яңгырап китте. Кешеләр, тыннарын кысып, мөңләгән күзләр белән изге нарат ягына текәлделәр.

Йолык кылу башланганны белдергән тавыш — кинәт купкан шау-шу шулай ук кинәт кенә тынып калды. Ыру башы Күрән би, атыннан төшмичә генә, ырудашларын бүелгы яз белән, җылы кояш белән котлады, аннары, изге нарат ботаклары аша күккә карап, тәңрегә үзенең теләкләрен юллады. Тәңредән ул бүелгы язның, җәйнең Ак бүре ыруы өчен игелекле булуын, чир-чорларның юкка чыгуын, терлек-туарның көрлеген, игеннәрнең уңуын, үз кешеләренең бай, көләч булуын теләде. Күрән бидән соң Утташ кам келәү әйтте. Ул тәңрегә ырудашларының аерым-аерым ялынычларын юллады.

Шул чакны көнчыгыш капка ягында ниндидер шау-шу купты. Кешеләр барысы да шул якка борылып карадылар. Кылычларын баш өстендә селтәп, капкадан уналты җәяүле ир йөгереп керде. Алар барысы да яшьләр, тазалар иде. Бик каты ярсыган-ачуланган шикелле кыланып, алар изге нарат янына йөгереп килделәр дә наратны бар яктан да уратып алдылар. Изге аланны яңгыратып, бөтенесе бер авыздан: «Алас! Алас!» дип кычкыра-кычкыра, алар күзгә күренмәгән явыз ияләрне кылыч белән туракларга тотындылар. Шуннан соң тиз генә кире чигенделәр. Чигенгәч, алар, киек эзәрлекләгән сыман, ярым иелеп, як-якка ялтйолт каранып, наратны бер-ике кат әйләнеп чыктылар да искәрмәстән җиргә капландылар. Шул ук мәлдә аларның баш өстеннән очып, каяндыр нарат төбенә ак каурыйлы уклар килеп төште. Шундый ук уклар, сызгырып, бер-берсенең юлын кисеп, баш өстеннән дә очып киттеләр. Бу укларны көнбатыш капкадан килеп кергән ирләр атты. Алар да, бердәм тавыш белән урман яңгыратып: «Алас! Алас!» дип кычкырдылар.

Кылычлы, уклы ирләрдән соң изге түгәрәккә сөңгечеләр килеп керде. Сөңгечеләр, айналарны [2] кадый-кадый, күздән югалырга да өлгермәделәр, ике як капкадан да утчылар килеп кергәне күренде. Кулларына алар янып, төтәсләп торган артыш, миләш, юкә, шомырт агачлары тотканнар иде. Утлы агачларын баш өстендә кылыч сыман селтәп, сөңге белән кадаган сыман уңга-сулга төртеп-айкап, утчылар да изге түгәрәктә әйләнеп йөрделәр. Ул арада кылычлы, калканлы ирләр янадан түгәрәк эченә килеп керделәр, янадан күкрәк киереп кычкырып жибәрделәр. Аларны тагын укчылар, сөңгечеләр, утчылар алыштырды.

Шулай итеп, Әрлик ханның әшәке ялчыларын ике тапкыр туран, атып, чәнчеп чыккач, үләксәләрен яндырып, төтен белән бергә күккә очыргач, изге нарат яны тулысынча арыкланып калды. Изге җиргә, арык җиргә, кулга-кул тотынышып, елмаеп, яшь, чибәр кызлар керде. Өсләренә алар төрле төстәге җинел күлмәкләр кигәннәр иде. Муеннарына тал бөреләреннән тезеп сыргалар такканнар, чәчләренә, күлмәк-

[1] Чапчак — агач кисмәкнең (мичкәнең) бер төре.
[2] Айна — явыз рух, иблис.

ләренә төрле төстәге чәчәкләр кадаганнар иде. Алар барысы да ялан аяк иде. Бу яшь кызлар, ышану буенча, яз килүен белдерәләр иде.

Менә алар, бөжра булып, изге наратны әйләндереп алдылар да, күктәге тәңрене, кояшны, җирдәге тереклекне мактап, җыр башлап җибәрделәр. Аларга бөтен алан кушылды. Йөзләрчә, меңнәрчә күкрәкләрдән чыккан куанычлы җыр тавышы шундый көчле булды — бөтен тирә-як, давыл чыккандагы сыман, күкрәп, гүләп торды.

Ил-көн биргән тәңребезгә
Атак! Атак!
Җир-суларга, урманнарга
Атак! Атак!
Бөек Чулман, Әтилемә
Атак! Атак!
Төрек бәдүн, ыруыма —
Ак бүрегә
Атак! Атак! [1]

## VIII

Күмәк җыр тавышы тынуга, колакларны тондырып, аланның төрле җирендә унлап быргы чинап җибәрде, аларга кушылып, дөңгерләр дөпелдәргә кереште. Көнчыгыш капкадан Тотыш углан күзләре бәйләнгән, як-якка ыргылган Йолдыз кашканы алып керде. Яшь кызлар, өсләренә су сипкәндәй, таралып беттеләр. Күрән би белән Койтым бикә дә читкәрәк тайпылды. Изге нарат янында бары тик Утташ кам да, ялан башлы, ялан аяклы аксакаллар гына торып калды.

Аксакаллар, йөзләре белән кояшка таба борылып, изге нарат ботаклары аша күккә карап, йолык келәве әйттеләр.

Күккә куе булып, ургылып зәңгәр төтен күтәрелде. Яшь байтал төтен эчендә күмелеп калды. Берәзгә тынып торган быргылар, дөңгерләр яңадан ярсып чинарга, дөпелдәргә тотындылар. Ул арада ирләр Йолдыз-кашканың дүрт аягына бәйләнгән дүрт арканны берьюлы тартып җибәрделәр. Йолдыз-кашка гөрселдәп җиргә ауды. Тик дөңгер, быргы тавышлары арасында аның гөрселдәве дә, пошкыруы, мышнавы, гыжлавы да беркемгә ишетелмәде — җирдәге кешеләргә дә, күктәге ияләргә дә ишетелмәде. Каен тузыннан тегелгән битлек кигән Утташ кам сылу байталның керештәй нык тартылган тыгыз бугазына үткер пычагын күз ачып йомганчы ышкып та җибәрде. Бугаздан ургылып, сулкылдап кайнар кан атылып чыкты. Ирләр Йолдыз-кашканы белеп ектылар — аның киселгән бугазы изге нарат кәүсәсенә туры гына килде: изге канның тамчысы да читкә чәчрәмәде.

Атны тунадылар, сөякләренә пычак йөзе тидермичә, итен аердылар. Итне тигез итеп ыруның барлык күчләренә өләштеләр. Үзләренә тигән кисәкләрне бик сак кына тотып, пешекчеләр үз учакларына ашыктылар. Алар аны тимер шешкә кидереп утта кыздырачаклар, аннары үз күчләрендәге барлык кешеләргә бүлгәләп таратып чыгачаклар. Изге аланга килгән бер генә кеше дә йолык итеннән авыз итми калмаячак.

Йолык кылынган Йолдыз-кашканы итеннән-тиресеннән, эчәк-бавырыннан арындыргач, шәрә сөлтәрне [2] иплән кенә аягына бастырдылар, ычкынырга гына торган сөякләрен бер-берсенә бәйләп куйдылар. Шуннан соң тирене яңадан сөлтәргә кидерделәр, эченә коры ут-үлән тутырдылар. Тирене тектеләр, атны башыннан, билennән нечкә кыл-аркан белән нарат ботакларына тарттырып куйдылар. Шулай итеп, Йолдыз-

---

[1] Атак —
[2] Сөлтәр — скелет.

кашка янадан элекке төсенә керде. Бары тик аның күзләре генә сүнеп калган иде дә, торышында элеккечә тереклек, омтылыш, кайнарлык кына сизелми иде.

Бу эшләрнең барысын да аксакаллар башкарды. Алар үзара берни сөйләшмәделәр, бер-берсенә берәр нәрсә әйтергә кирәк булса, бары ымлап кына күрсәттеләр. Алар бик тиз, бик житез кыландылар. Утташ кам, читтәге явыз ияләрне куркытып, бертуктаусыз аксакаллар тирәсендә йөренеп торды, дөңгер какты, кычкырды, әле уңга, әле сулга карап, әле кинәт артына борылып, бары үзенә генә күренгән айналарга каргышлар яудырды.

Йолдыз-кашкадан соң быел кысыр калган ике сыерны, аннары иллеләп сарыкны чалдылар. Аларны да шулай ук тунадылар, итен, эчен алдылар, сөлтәрләренә тиреләрен кидереп, тегеп куйдылар. Тик аларның карачкыларын барысын да нарат төбенә түгел, аланның төрле почмакларына утыртып чыктылар. Йолдыз-кашка янына бары бер сыер да, бер сарык карачкысы гына куелды.

Күп тә үтмәде, дөрләп янган учакларда итләр пешеп чыкты. Кисмәкләр, чүлмәкләр ачылды. Пешекчеләр ырудашларына ит тараттылар, ачы бал, буза тараттылар. Кояш яктысында балкып яткан киң аланда күңелле шау-шу әз генә дә тукталып тормады.

Ит исе, кан исе сизеп, түбә өстендә болыттай булып каргалар, козгыннар очып йөрде, якында гына агачлар арасында, күзләрен уттай яндырып, тешләрен ыржайтып, ач бүреләр уладылар.

Язгы кояш кичкә авышу белән, тамаклары карлыгып беткән кешеләр кайтырга җыена башладылар. Коллар, чуралар тышаулы атларны алып килделәр, җигеләсен җиктеләр, иярлисен иярләделәр. Байракларның, сыннарның бер ишен монда калдырдылар, бер ишен үзләре белән алдылар.

Кайтканда да ыру башы үзенең йөз кешелек куче белән иң алдан кузгалды. Башкалар әкренләп-әкренләп алар артыннан иярә бардылар.

Сырт өстенә менеп, катауга туры илтә торган ачык юлга чыккач, Курән би, үзенең өлкән хатынын алдан җибәреп, үзе читкә чыкты да артта калды. Юл читендә туктап торган килеш ул үз кешеләрен күздән кичерде.

— Тотыш юк,— диде ул, Койтым бикәне куып җитеп.— Төштән соң мин аны күрмәдем. Истән чыккан.

— Мин күрдем,— диде бикә, пышылдап.— Ул өйгә кайтып китте. Аягыма су үтте, туңам, диде.

— Туңгандыр! — диде би.

— Аңа да ачуланып булмый инде,— диде ана, углын яклап.

— Ярар, бетте! Әйттем исә кайттым! Йәк[1] колагы саңгырау булсын! — диде би, ачулы пышылдап.

— Аларның күзләре дә бар шул,— диде Койтым бикә.

— Капка каравылчысын үзең җайларсың. Мин берни белмим! — диде би, кырт кисеп.

Атасы белән анасы үзе турында шулай борчылып кайтканда, Тотыш изге алан янындагы тәбәнәк чыршы астында утыра иде. Яу чабарга җыенган ир кебек, кулына ул алдан монда яшереп куелган сөңгесен, калканын тоткан иде. Шунда ук агулы уклар белән тулы ике уклык җәя ята иде. Башына ул тимер алпак, өстенә күбә киган иде. Ул чыннан да монда орышка дип килгән иде. Түземсезлек белән ул кешеләрнең тизрәк изге аланнан китеп бетүләрен көтә иде.

---

[1] Йәк — шайтан.

## IX

Икенче көнне, таң атар-атмас борын, Күрән белән капка төбенә Утташ кам килеп житте. Ул чамадан тыш ачулы иде. Үзен капкадан кертергә теләмәгән сакчыларга ул яман сүзләр әйтте. Сакчылар аңа бинең йокыдан уянганын көтәргә куштылар. Утташ кам, теләсә дә, теләмәсә дә көтәргә тиеш булды.

Би аны үзенең ак өендә каршы алды.

— Нишләп бик иртә? Бер-бер эш чыктымы әллә? — диде ул, бабасының таң тишегеннән килеп житүен ошатмыйча.

— Чыкты, кияү! — диде Утташ кам, ачуыннан бүреген салырга да онытып.

Аның болай сөйләшүе, жимерелгән йөзе белән күңелендә йокымсырап яткан кире тойгыларын уятып жибәрде.

— Син бик тупас күренәсең, кам баба,— диде ул коры гына, урынына утырып.— Сал башыңны, утыр, сөйлә.

Утташ кам башындагы бүреген тотып алды да күрсәтелгән урынга терәлгәндәй итте.

— Эш чыкты, би... кияү! — дип кычкырды ул, чәрелдек тавыш белән.— Ниндидер явызлар изге наратны... бөтен ыруның изге сакчысын, яклаучысын мыскыллаганнар! Тәүбә! Тәүбә! Изге аланны бозганнар, би! Изге Кайракканның йөзенә төкергәннәр! Тәүбә! Тәүбә!

— Кемнәр?! Кайчан?! — диде би, коты алынып.

— Кемнәр, имеш! — дип чәрелдәде Утташ кам, күз яшьләренә буылып.— Килмешәк Койтым кырнакның игелексез Тотышыннан башка кемнең шуна кулы барсын?!

Би ап-ак булды. Шуннан соң ул бурлаттай кызарынды, еш-еш тын алып, йокысы качып бетмәгән усал күзләреннән куркыныч очкыннар чәчрәтеп, урыныннан торды да йөнтәс шәрә кулын ашыкмыйча гына алга сузды, бабасының сакалыннан учлап тотты.

— Аңлатыбрак сөйлә! — диде ул.

Өлкән камның тары бөртегедәй елтыр күзләре чәчрәп чыгардай булып акаеп калды. Кайнарлыгы, ярсуы шундук юкка чыкты, бөтен явызлыгы, бергә җыелып, кинәт каядыр эчкә төшеп китте. Тәне тотлыгып, беравык эндәшә алмый торгач, ул этенә-төртенә:

— Б-б-бүген иртән б-б-барсам...— диде.

— Шуннан? — диде би, аның сакалын бушайткандай итеп.

— Ш-шуннан...— диде Утташ кам.— Из-зге нарат төбенә... ч-ч-чүмәлә дисәң, ч-чүмәлә түгел... у-утын дисәң, утын түгел... Па тәңрем!! Үле бүреләр өелеп ята! Кайсын ук белән, кайсын кылыч, сөңге белән... Йөзләп, меңләп! Бүре каны койганнар! Изге җиргә, изге нараткаебызга... бүре каны койганнар!

Утташ кам, сакалы ычкынгангамы, изге наратны кызганыпмы, кычкырып җылап җибәрде.

Күрән би, яшен суккан кебек, телсез-өнсез калды: бу чыннан да коточкыч иде, бу чыннан да беркайчан да булмаган, була алмастай яман бер эш иде.

— Чумаклар [1] түгел микән? — диде ул, аптырап, бабасының җирәнгеч йөзенә карамаска тырышып.— Әллә җөфүтләр [2], румнар [3] микән?

— Язык! язык! — дип такмаклады Утташ кам, тынычлана алмыйча.— Башы аягы астына гына килсен! Кулы корысын! Күзе чыксын! Йөргән җирендә җир йотсын!

— Кемне каргавыңны әйтеп карга,— диде би, кашларын җыерып.

— Тотыштан башка...— диде кире беткән кам, үксеп.

---

[1] Чумак — мөселман динен тотучылар.
[2] Җөфүт — яһүд динендәге кеше.
[3] Рум — монда: рум (грек), ягъни христиан динендәге кеше.

2*

Күрән би ике куллап бабасының инбашларыннан кысып тотты да, күзләренә карап:

— Күрдеңме? — диде әкрен генә.

«Юк» дигәнне аңлатып, Утташ кам башын чайкады.

— Күрүчеләр булганмы? — диде би.

— Юк,— диде кам, мыгырданып.

Күрән би җиңел сулап куйды, маңгаена бәреп чыккан тир бөртекләрен учы белән сыпырды да Утташ камнан читкәрәк китте, кинәт авырта башлаган эчен тотып, йөзен чытып, кояш яктысы төшкән төннек аша беравык тышка карап торгандай итте. Шуннан соң, ул яңадан Утташ кам янына килде.

— Бу турыда беркемгә лыгырдыйсы булма! — диде ул, боерып, янап.

Монда килгәндә Утташ кам бине чын-чынлап өркетә алырмын дип уйлаган иде. Бинең бу кыланышы аның уйларын үзгәртеп җибәрде. Ул инде изге нарат турында да, үтерелгән бүреләр турында да уйламады, ул бары үзенең мыскыллануы турында гына уйлады. Бинең яңадан үзенә якынлашуын күреп, ул:

— Кычкырам! Сөрән салам! — диде, ишеккә ташланып.

Күрән би аның артыннан ыргылды, ишек бавын аның кулыннан йолкып алды да үзен идән уртасына төртеп җибәрде.

— Син... белексез! — диде ул, төкрекләрен чәчеп.— Син минем Йолдыз-кашкамны алдың — каршы килмәдем. Инде минем углыма теш кайрыйсыңмы?! Мин сиңа углымны чалырга юл куймам! Әллә син үзең кыргандырсың ул бүреләрне... юрамалый... каян белим мин аны!

— А, тәңрем! А, кояш! — диде Утташ кам, кулларын югары күтәреп.

— Бар, кычкыр! — диде би.— Синең миңа аяк чалырга матаўуыңны ырудашлар белмиме әллә? Мин әйтермен: миннән, Койтым бикәдән үч алмакчы булып, үзе үтерткән, диярмен. Бар, ник кычкырмыйсың?! Шунда ук муеныңа элмәк салып, агач башына асып куярга боерырмын. Бар, бар, кам баба, бар, сөрән сал!

— Юк, болай булгач, салмыйм, кияү,— диде Утташ кам, өзелеп чыкмады микән, дигән сыман, сакалын сыйпалап.— Шулай да куркытым дип уйлама.

— Изгелек, турылык эзләп йөри, имеш! — диде би, кызганнан-кыза барып.— Ыру кайгысын кайгыртып йөри, имеш,— үле бүреләр күргән дә, аҗунның астын өскә әйләндерергә дә күп сорамас! Ыруда кем коткы тарата — син! Кем башбаштакланып йөри — син!

— Язык, язык! Тел тидермә, язык! — диде кам, мыгырданып.

Башка чакта Күрән бине юашландыра торган, куркыта-өркетә торган сүзләр бу мәлдә аңа бөтенләй көчсез тоелды. Камның мыгырдануын ул колагына да элмәде.

— Мин инде языктан арындым,— диде ул, әз генә дә исе китмичә.— Кирәк булса, тагын арынырмын.

— Тотышның бүреләрне үтергәнен мин күрмәдем, башкалар да күрмәгән,— диде Утташ кам да, би эзенә төшеп, тышкы бер тынычлык белән.— Шулай да мин шикләнмим, би, ул үтергән! Анда аның уклары ята. Мин барысын да беләм, кияү! Төштән соң аның келәүлектән китүен дә беләм, кичә кич өендә булмавын да беләм. Синең углың башкисәр булып үсә. Йолаларга төкереп карый. Йола бозып язык ясыйсың да, языгымны йолып, тынычландым, дип уйлыйсың. Ялгышасың, би! Ыруның иминлеге, тынычлыгы синең беләгеңә генә карамый, ыруны ата-баба йоласы тота. Кешеләр арасында мин түгел, син коткы таратасың, син башбаштаклык эшлисең. Агач башында мин түгел, синең углың асылынып торыр, кияү! Углыңны алып калырга тырышсаң, тәңре синең үзеңне янына чакыртып алудан да тартынмас!

— Житәр! — диде би.

— Житмәс! — диде кам, кире чигенеп.— Төрек йоласы, төрек түрәсе барлык кеше өчен бер... бигә дә, чурага да...

Күрән би йомарланган йодрыгын Утташ камның борын төбенә китерде.

— Менә, күрәсеңме... берме бармаклар? — диде.— Шуларны тигезлә, аннары бер булыр!

Кияү белән бабай, ыру башы белән кам шулай әйтешләр-әйтешләр дә кинәт тынып калдылар. Утташ камның күз алдында, әйтерсең, яктылык чаткысы кабынып китте. Болай ачыктан-ачык талашып, бозылышып берни кыра алмаячагын ул тагы бер тапкыр аңларга тиеш булды. Утны ничек тә астанрак йөртергә кирәк иде!

— Синеке көч! — диде ул, уфтанган булып.— Тәнре каргышыннан курыкмаган булсам, мин монда килеп тә йөрмәгән булырыем.

— Кеше-кара күргәнче аларны юк итәргә кирәк, бабай,— диде би дә, юашланып.

— Шулай итәрбез, кияү,— диде Утташ кам.

Кешеләр торып йөренә башлаганчы дип, ашыгып, Күрән би белән Утташ кам ике колны алдылар да келәүлеккә киттеләр. Изге нарат төбендә чыннан да таудай булып бүре үләксәләре өелеп ята иде. Шунда ук, наратның икенче ягында, берни булмагандай Йолдыз-кашка басып тора иде. Аландагы сыер, сарык карачкыларының барысы да ботарланып, теткәләнеп беткән. Бу, билгеле, изге бүреләрнең генә эше түгел, монда тагын изге булмаган ике аяклы бүренең бик каты эшләгәне күренеп тора иде. Ул ике аяклы бүренең кем булуы турында күңелендә әз генә дә шикләнмәсә дә, Күрән би, үләксәләрне күргәч, ах-вах килде.

— Кемнең йөрәге житкән моңа?! — диде ул, шаккатып.— Ничек жир күтәрә ул кешене?! Тәңрем, кичер аны! [1]

Коллар бүре үләксәләрен, шулай ук барлык карачкыларның сөяксанакларын урман арасындагы тирән чокырга илтеп ташладылар. Берәрсе ялгыш күрә-нитә күрмәсен дип, Күрән би үләксәләргә ут төртергә кушты.

Өенә ул бик күңелсезләнеп кайтты. Кайткач та Койтым бикә белән Тотыш угланны үз янына чакыртты.

— Кем эше булыр икән бу? — диде ул авыр гына, изге аланда күргәннәрен сөйләгәч.

— Мин! — диде Тотыш, өй эчен яңгыратып.

Ул алай кычкырып та әйтмәде бугай, шулай да ата белән анага аның бу «мин» дигән сүзе күк күкрәве сыман булып ишетелде. Койтым бикә чак-чак кына артына аумады. Күрән би тораташтай катты да калды.

— Син... син...— диде ул, тотлыгып.— Беләсеңме шуны — бөтен ыруга... атаңа-анаңа каргышы төшәр!..

Кинәт ишек ачылып китте, күзе-башы акайган яшь сакчы, тамак ярып:

— Сөенче! — дип кычкырып жибәрде.— Киләләр! Каеклар килә!

## X

Үргә таба әкрен генә кыймылдап, унлап-унбишләп каек килә иде. Аларның кем каеклары икәнлеген әле бик үк аерырлык та түгел иде. Шулай да ни генә булмасын, алар киләләр! Астан — Болгар ягын-

---

[1] Төрки халыкларының күбесендә бүре изге саналган, чөнки дини ышану буенча, төрек нәселе, имеш, бүредән башланган. Монда шуңа ишарә.

нан, Хазар ягыннан, кояшлы Хәрәземнән, я булмаса ерак Румнан, Багдад якларыннан киләләр!

Каекларның килүе турында ку[1] тиз арада бөтен катауга таралды. Кешеләр ашыгып яр-капкага агылдылар, ябырылып койма өстенә мендeләр, каргу, сырган башларына үрмәләделәр, текмә араларына кысылдылар. Койма сакчылары кешеләрне әле бер җирдән, әле икенче җирдән кудылар, шулай да артык усаллык та күрсәтмәделәр — катауга ерактан каеклар килүе Күрән би өчен генә түгел, башкалар өчен дә зур куаныч иде.

Би дә, бикә дә шундук терелеп киткәндәй булдылар. Бүреләр кайгысы, Тотыш кайгысы онытылды, бөтен катауны, бөтен өй эчен көндезге кояштай якты куаныч биләп алды. Әйе, киләләр, соңлабрак булса да киләләр. Соң булса да уң булсын... Төкле аяклары белән!

Күрән би үзенең өлкән углы, каравыл башы Акбогага төтен үрләтергә, икенче углы — субашы Котанга ун каек, йөз ир белән кунакларга каршы китәргә боерды. Текә яр өстенә, коймага кушып салынган каргулардан тиз арада зәңгәр төтен күтәрелде. Яр-капканы ачып җибәрделәр. Яр битенең куен сыман уйдыкланып торган җирендәге баганалар өстенә авыр күпер сузылып ятты. Юан баганалар яныннан башланып, аска таба озын, текә баскыч сузыла иде. Котанның юлдашлары, иңбашларына ишкәкләр күтәреп, йөгергәләп тар баскычтан бер-бер артлы төшә башладылар. Аста, Чулман яры буенда, киң генә коры җир кисәге бар иде. Монда катауның тамгасы — каеклар, көймәләр, улаклар туктый торган корылмасы урнашкан иде. Тамга янында, Чулман дулкыннарында чайкалып, Күрән бинең йөзләп каегы, көймәләре-улаклары тора. Шунда ук балыкчылар, бала-чагалар ыгы-зыгы киләләр иде.

Күрән би ишкәкчеләрнең яр астына төшеп житүләрен, каекларга төялеп, кузгалып китүләрен өстән карап торды да өенә таба кузгалды— кунакларны тиешенчә каршылау өчен җыена башларга кирәк иде.

Кояш төшлеккә күтәрелеп житкәндә, ерактан килүче җилкәнле каеклар да, аларны каршыларга китүчеләр дә катауга килеп житә яздылар. Кунаклар, бер җепкә тагылгандай, бер-бер артлы тезелеп киләләр иде. Акбүреләрнең каеклары, кунакларның артына да, алдына да төшеп, шулай ук тезелеп, тигез ара саклап киләләр иде.

Менә озын ишкәкләрнең салмак кына күтәрелеп төшүе, җилкәннәр, өрлек башларындагы байраклар, байраклардагы билгеләр, язулар аермачык күренә башлады. Күрән би, күзләрен кыскалап, аларның кемнәр икәнлеген чамаларга тырышып карады. Тик, күпме генә каранса да, әлегә ул берни аермады. Бу кунаклар сартлар да, румнар да, гарәпләр дә түгел иде, ахрысы. Кемнәр булыр бу шулай да?

— Базарганнар түгел, атай! — дип кычкырды шул чакны Тотыш углан.

— Телеңә тилчә! — диде ата кеше.

— Ямгырчы би килә! — диде Тотыш.— Әнә, байракларында өч чатлы каз тәпие.

— Туктыйсыңмы син?! — диде би, үртәлеп.

Тотыш углан тынып калды. Ул тыну белән генә бинең күңеле барыбер тынычлана алмады. Ул инде үзе дә күреп тора — болар чыннан да сатучылар түгел, болар чыннан да казаяклар бугай. Күрән би авызлыгын чәйнәп, баскан урынында биеп торган Акколакның — Йолдыз-кашка анасының корсагына ачу белән тертеп алды. Акколак куркып читкә ыргылды. Үртәлгән би бар көченә тезгенне тартып җибәрде. Иясенең нишләргә теләвен аңламыйча, Акколак, авыр мышнап алгы аякларын күтәрде.

[1] Ку — хәбәр.

— Ныграк кара, кунаклар килә! — диде би мыскыл белән, атына эндәшеп.

Тамга күперенә иң элек Котан каегы килеп төртелде. Каектагы борынчы ыргакчыга аркан ташлады.

— Кая тыкшынасың — ары кит! — дип кычкырды би үзенең углына.

Борынчы ярга ташланган арканны бер сүз әйтмичә кире тартып алды. Атасы кебек үк чытык йөзле Котан ярга сикерде. Котан артыннан бераз ара калдырып, яр буена икенче каек килеп житте. Монысы инде кунаклар каегы иде.

Борыннан, койрыктан казаяклар аркан ыргыттылар, уртадан басма суздылар. Каек, күпер читенә терәлеп, чайкалудан туктап калгач та, унлап кеше аягүрә басты. Кыска итеп киселгән сакал-мыеклы, озынча битле, очкынланып торган шаян, тере күз карашлы чандыр бер кеше, елмаеп, Ак бүре ыруының башы алдында бүреген салды, башын иде. Аңа күп булса утыз биш-кырык яшьләр чамасы булыр иде.

— Казаяк ыруының башы Ямгырчы би синең жиреңә килде,— диде ул, Күрән бигә эндәшеп.

— Илме, яумы? — диде Күрән би.

— Ил! — диде Ямгырчы би.

— Төкле аягың белән, туганым Ямгырчы би! — диде Күрән би, бозылган йөзенә елмаю билгесе чыгарып.

Ашыкмыйча гына ул атыннан төште. Койтым бикә дә, бинең башка хатыннары белән балалары да, аксакаллар да — барысы да атларыннан төштеләр, бер тирәгәрәк жыелдылар.

Ямгырчы би басмага атлады, үзенә сузылган кулларга тотынып, елмаеп жиргә төште. Аның юлдашлары да шулай ук жиргә төштеләр. Үзләрен каршылаучы кешеләргә бер-ике адым килеп житмичә, алар туктап калдылар. Күрән бине, аның якыннарын олылап, билләрен бөктеләр, башларын иделәр. Ямгырчы би, яхшы, бай тунының каптырмаларын чишеп жибәрде, бил каешына бәйләнгән калтасының — көтүдән кайткан сыер жиленедәй бүлтәйгән зур калтасының [1] — авызын чиште. Калтадан учлап-учлап ул көмеш ярмаклар алды, Күрән бинең, Койтым бикәнең, балаларының, ырудашларының аяк астына акча сипте.

Көмеш табакка салып, кыздырылган ит, пешкән балык, богдай көлчәсе тоткан Койтым бикә алгарак чыкты, кунакларга шулай ук баш иде. Кулындагы табакны ул Ямгырчы бигә тоттырды. Кунак би, бармак очлары белән генә чеметеп, табактан бераз ит, балык, көлчә алды, авыз итеп карады. Шуннан соң казаяклар табакны кулдан-кулга жибәрделәр.

Кунаклар үз каекларыннан өч тартма төшерделәр. Тартмаларны ачып, Ямгырчы би Акбүренең өлкәннәренә бүләкләр өләшә башлады: Күрән бигә кышкы төлке тун белән бүрек бирде, Койтым бикәгә шулай ук тун бирде, көмеш беләзек бирде. Башкаларга да шактый өлеш чыкты. Кайберсенә күлмәк, кыекча [2], кайберсенә итек-читек, беләзек, йөзек, муенса ише нәрсәләр тиде. Кунакларны каршыларга төшкән кешеләрнең берсе дә бүләксез, күчтәнәчсез калмады. Акбүреләрнең күңелләре куаныч белән тулды. Салкын, кырыс чырайлар яктырып китте — Ямгырчы би үзе белән бүләкләр генә түгел, әйтерсең, көньяк жылысын да алып килгән иде. Кызыл Яр катауга килгән бер генә кунакның да әле беркайчан да бу чаклы күп бүләк өләшкәне юк иде бугай. Менә ичмасам юмарт икән, менә ичмасам бай икән бу Ямгырчы би!

Казаяк ыруының башы Ямгырчы би белән Кызыл Яр катауга йөзләп кораллы ир килгән иде. Йөзләп ир арасында бер хатын-кыз да бар иде. Ул да булса, Ямгырчы бинең кызы — Таңкә иде.

---

[1] Калта — акча янчыгы.
[2] Кыекча — яулык.

## XI

Казаяк ыруы белән Акбүре ыруы арасында борын-борыннан туганлык яшәп килгән. Алар икесе дә бер тамырдан — Ак хан йортындагы Ак жылан ыруыннан аерылып чыккан булганнар. Ак ханның тамыры үзе бөек тәрек бөдүнен барлык җир-суларга, барлык илләргә, телләргә баш ясаган бөек Көн каган углының углына тоташкан булган. Казаяк белән Акбүре ырулары кайчандыр Чулманның түбән агымында — Этил белән бергә кушылып, өчпочмак ясаган иркен җирләрне биләгәннәр. Бер-берсе белән алар җир-су өчен дә, терлек-туар өчен дә ызгышып-талашып яшәмәгәннәр. Киресенчә, бер-берсенә кыенлык килсә, үләт, кыран килсә, шундук бер-берсенә булышка ашыкканнар. Шуның өстенә алар йорт башы Ак ханның иң көчле, ышанычлы ыруларыннан саналганнар.

Шулай итеп, ике ыру кешеләре, кайгы, талау күрмәенчә, тыныч кына, тату гына тормыш кичергәннәр. Тик шулай да мондый тыныч, тату тормыш мәңгелек булмаган. Көннәрдән бер көнне — моннан бик күп еллар элек — язгы сулар китеп, җирләр кипкәч, көн ягыннан Этил буйлап кара яулар басып килгән. Кара яуның башында явыз Кара хан торган. Аның кешеләре бик күп булган. Алар көчле, кансыз булганнар. Аларның укларына, сөнге, кылычына каршы беркем, берни каршы тора алмаган. Язгы ташкын суны берничек тә тотып торып булмаган кук, Кара ханның чирүен дә беркем, берни тоткарлый алмаган.

Каяндыр Азак тиңгезе буйларыннан кубып, алар шулай ташкын кебек, кара болыт кебек килгәннәр дә, урман-кырларны таптап, сулар кичеп, төн ягына таба юл тотканнар. Бөек Этил буенда, ике тау арасында Кара ханның кара явы белән иң беренче орыш булган. Ак ханның уң кулы Буртас би үтерелгән, чирүе кырылып түгелгән. Буртас үлгәч, мукшы, чирмеш бер-бер артлы арт биргәннәр. Шулай итеп, кара яу ике елга кушылган төшкә — Акбүре, Казаяк җирләренә якынлашкан.

Чирмешән суы буенда, киң болында икенче орыш булган. Сугыш көне буе барган. Ике як та бер-берсенә каршы нык торганнар. Кычкырган, ыңгырашкан тавышлар, тимергә тимер бәрелгән, атлар кешнәгән тавышлардан җир-күк тетрәп торган. Сугыша-сугыша кешеләр арып беткәннәр. Сөңгеләр, кылычлар сынып беткән, киемнәр ертકаланган, битләрне-күзләрне кара кан баскан.

Мена кич булган. Караңгы төшкән. Ике як та, арып-талып җиргә ауган. Батыр алыпларның җеп өзәрлек көчләре калмаган.

Шул чагында көтмәгәндә Кара ханга арттан өстәү килгән.

Ак хан кешеләре тагын җиңелгәннәр. Килмешәкләр тагын өстен чыккан. Бөек Этил, канлы дулкыннарын чайпалдырып, үксеп-үксеп яшен түккән. Этил буе бөркетләре, тилгәннәре туган җирнең алыплары баш өстеннән кайгырышып, сыкранышып очып йөргән. Ач бүреләр, таныш кешеләргә тимәенчә, Кара ханның үлекләрен сайлап ашаганнар. Үлгән-үтерелгән кеше белән бөтен болын чуарланган булган.

Соңгы орышта олуг йортның башы Ак хан кергеннәргә тоткын булган. Ханның, балаларының, туганнарының башын чабып өзгәннәр. Шулай итеп, тамырга балта чабылган, йорт-ил юкка чыккан. Исән калган ирләр, куркып-каушап, кайсы кая качып киткән. Кайберәүләр, башын саклап, Кара ханга бил бөккәннәр.

Әйе, Ак хан йорты юкка чыккан. Ирләр үлгән, ирләр качкан, Кара ханга бил бөккәннәр. Тик шулай да үтә батыр ирләр килмешәккә баш бирергә теләмәгән. Туган җирен-суын ташлап, тәлим[1] кеше югарыга — төн ягына күчеп киткән. Шуларның беренчесе акбүреләр булган. Каза-

[1] Тәлим — күп.

яклар, Кара ханга калан[1] түләп, Чулман-суының түбәнендә, уң як ярда торып калган.

Бөтен Чулман буе — бозлы тиңгезгәчә — бик борыннан Ак хан җире булган. Акбүреләр Чулман буйлап, үз җирләре буйлап югарыга, бик еракка үрләгәннәр. Бернинди яу килә алмаслык кыргый урманнар арасына, сазлар, күлләр арасына кереп яшеренгәннәр. Берничә ел шулай качып-посып яшәгәннәр дә, яулар тынгач, ачык җиргә — яр буена, болыннарга таралганнар. Катау корганнар, авыллар салганнар. Җир ачканнар — иген иккәннәр, ауга, балыкка йөргәннәр, сату иткәннәр. Беркемгә буйсынмыйча, беркемгә калан түләмичә, үз көннәрен үзләре күргәннәр.

Тик шулай да явыз язмыш Акбүрене тулысынча тыныч калдырмаган. Бөек су юлларын биләп алган Кара хан токымнары елдан-ел көч җыйганнар, байлык җыйганнар. Аларга инде Этил буе гына түгел, Чулман да кирәк булган. Үзен хан дип атаган кансыз Шелке би моннан күп еллар элек бу якка да үтеп керә алды. Бөтен Чулман буен Биаргача канга батырып, талап, яндырып, күп җирләрне Шелке үз кулына алды. Моңа инде егерме ел узды. Акбүреләр болгарларга унҗиде ел калан түләделәр. Шуннан соң, узган өч елда, болгарларның үз өйләрендә үзара талашуларын күреп, алар белән алыш-бирешне бөтенләй өзделәр. Өч ел буе инде Акбүре үзенә бер йорт-ил булып, болгарларны санламыйча яши иде.

Бер-берсеннән бик еракта булсалар да, акбүреләр, казаяклар элегрәк бер-берсе белән аралашып торалар иде. Болгарлар белән ара өзелгәч, алар белән дә өзелде. Өченче ел инде Күрән бинең бер генә Казаяк кешесен дә күргәне юк иде. Болгарларның борын төбендә генә борынгы ата-баба җирен биләп яткан бай, атаклы Ямгырчы би әнә үзе килгән.

Ник килгән ул монда? Нинди җилләр, нинди уй-теләкләр куалаган аны монда киң Чулманның салкын агымына каршы?

## XII

Казаяклар өчен Күрән би үз урдасында киез тирмәләр кордырды, казан асарга дип бер көтү сарык, бер көтү җылкы бирде. Шул ук көнне ул олы кунакның үзен, кызы Тәңкәне, тагын берничә якын кешесен үзенә ашка чакырды. Авыр, озын юлдан соң кунаклар бераз тын алдылар, ашадылар-эчтеләр дә җыйнаулашып мунчага киттеләр.

Мунча икенче көнне дә ягылды, тик монысы, юынудан бигрәк, сөйләшү-аңлашу өчен кирәк булды.

Казаяклар белән буласы зур сөйләшүгә Күрән би акбүреләр ягыннан Койтым бикәне дә алды. Сөйләшүдә тагын Утташ кам белән Майчан аксакал да, Күрән бинең өлкән угыллары Акбога белән Котан да катнашты. Ямгырчы би үзе белән бары ике генә юлдашын алып килде.

Казаяклар тезелеп бүлмәнең бер ягына утырдылар, акбүреләр икенче ягына — алар каршысына утырдылар. Аякчы зур чүлмәк белән ачы бал — сычук кертте. Күрән би көмеш аякка сычук агызып башта үзе эчте, аннары кунакларны сыйлады. Зур сөйләшү алдыннан ачы бал белән тамак чылатып алу изге эш санала иде, ачы бал телләрне яза, күңелләрне йомшарта иде.

Күрән би, җир идән уртасындагы учакның утлы кузларын бер тирәгәрәк өеп куйды да, үзенең кунагына эндәшеп:

— Башлап карыйк, алайса, би,— диде.

— Ә? — диде Ямгырчы би, сискәнеп.

Ул, онытылып, каршыдагы яшь, сылу бикәгә карап утыра иде.

Акбүреләр тыелып кына көлешеп алдылар. Үзенең ипсезлегеннән Ямгырчы би үзе дә көлеп куйды. Кинәт аның теле тотлыккандай булды.

---

[1] Калан — сугышта җиңелүчеләр җиңүчеләргә түли торган еллык салым, ясак.

«Чумаклар төректән белеклерәк — хатын-кызның урыны ирләр белән бергә түгел, аның урыны — чыбылдык артында!» — дип уйлады үз алдына.

Сүзне ул бик ерактан башлады: ике ыруның борынгыда бер-берсенә кардәш булуларын, элеккечә иркен тормышны, Ак хан, Кара хан турында бабайлар сүзен — барысын да искә төшерде дә әкренләп-әкренләп бүгенге көнгә күчте. Акбүреләр аны тыныч кына тыңлап утырдылар.

— Син, Күрән би, базарганнарны көтәсең булыр? — диде ул кинәт болай гына, сүз арасында гына сөйләнгән сыман.— Көтмә. Быел алар килмәячәк.

Акбүреләрнең шундук колаклары үрә торды.

— Ник килмәсләр икән? — диде Күрән би.

Олы кунак беравык көттерергә кирәк тапты. Аннары әкрен генә, үз-үзенә ышанып:

— Алмыш хан сезне... безне буып үтермәкче була,— диде.

Мунчада, сүнәр-сүнмәс яткан учак янында тагын да ныграк тынлык урнашты.

— Ничегрәк бумакчы була инде ул... аты корыгыры... ни Алмыш хан? — диде Майчан аксакал бераздан, исен җыеп.

Ямгырчы би, күрәсең, кирәкле сүзен таба алмыйча, тынып утыргандай итте дә тагын да ерактан урамакчы булып:

— Моңарчы сез ирекгә яшәдегез...— диде.

— Без әле дә ирекгә,— диде Котан углан, аның сүзен бүлеп.

Аның шулай кирәкмәгәндә өлкәннәр сүзенә кысыла торган бер тыйнаксызлыгы бар иде.

— Ирекгәсен ирекгә дә...— диде Ямгырчы би, Котан угланга каршы килеп,— сату-алусыз, сартларсыз ирекнең кемгә кирәге бар?

Акбүреләр җиңелчә генә гөрләшеп алдылар.

— Сартларга да, Алмышка да безнең кендек бәйләнмәгән,— диде Күрән би, кисәк кенә авырта башлаган эчен тотып.— Кендек безнең үз җиребездә. Сартлар килмәсә, без үзебез барырбыз аларга!

— Коры җирдәнме? — диде Ямгырчы би, күрәләтә шикләнү белдереп.— Тау-ташлар, сазлык-баткаклар ашамы? Үз җирегездән чыгу белән сезне кыргый башгыртлар кырып ташлаячак.

— Ташламаячак! — диде Күрән би.— Элек тә булган мондый эшләр. Безнең бабайлар коры җирдән барганнар көньякка. Күп көч белән. Ник безгә бармаска?! Ул тиреләрне су төбенә салмам ла мин!

Быел астан базарганнар килмәгәнгә аның эчтән януын, тик тыштан гына мыс бирмәскә тырышуын Ямгырчы би сизми калмады.

— Көньякка булмаса, төньякка барырга була! — диде тиктормас Котан углан, атасын яклап.— Биар аша боз тиңгезенә, Урыска, Франкка.

Үтә белексез сүз сөйләгән кешегә караган кебек, барысы да ана аптырап, исләре китеп карадылар.

— Өлкәннәр сөйләгәнне тыңлап утырсагыз яхшы булмасмы? — диде Койтым онкә үги углына, кырыс кына.

— Ышанам сүзеңә, Күрән би,— диде Ямгырчы би, өзелгән сүзен ялгап,— ата-баба йөргән юл булган анысы... Шулай да ата-баба юлы белән генә йөреп булмый. Безгә инде аю өнендә яткан кебек, урман арасында качып-посып ятарга ярамый. Болгарлардан куркып инде туганлыкны да онытып бетердек: бер-беребезгә барышмыйбыз, килешмибез... Йортың-илең белән кырылып ятсаң да, сиңа булышка кул сузучы беркем юк.

Ак бүреләр, башларын иеп, тыңлап утыруларында булдылар. Кая бора соң бу сүзне? Ни әйтмәкче була бу шулай да?

— Нәрсә булган бу болгарга, Алмыш хан нишләмәкче була дисезме? — диде Ямгырчы би тәмләп кенә яңадан сүзгә башлап.— Монда эш Алмышта гына түгел — Хазарда. Итил-торада эшләр елдан-ел чуала

бара. Җөфүтләр бөек Хазар-йортны жыкка терәделәр. Тәнренең каргышы төште Хазар каганына. Ел саен корылык. Көтүлекләрен ком баса. Карасы ачтан интегә, аксөякләр үзара талаша. Быел да биш меңләп кешесе Этил буйлап югары менделәр, Алмыш ханнан торыр җир сорадылар. Бер яктан Рум кыса, икенче яктан Хәрәзем кыса, угызлар, каңгылылар тынгы бирми, Куябыда урыслар бычкы кайрыйлар. Инде килеп монда Алмыш хан көчәеп бара. Эшләр болай барса, бөек Хазар йорт, көяләгән тире кебек, таркалып юкка чыгачак.

— Бирсен тәңрем! — диде Котан углан, кулларын югары күтәреп.

— Ашыкма! — диде Ямгырчы би.— Хазар йорт таркалганнан безгә ассу[1] юк.

— Нишләп булмасын? — диде тыйнаксыз углан.

— Шундый бөек йорт таркалса, ата улны, ана кызны белмәс,— диде Ямгырчы би.— Үзара ызгыш, талаш башланачак, яу китәр. Әйе, безнең ишеләргә ассу юк. Алмыш ханга бар!

Ямгырчы би авыр сулап куйды. Күрән би аңа чүлмәктән сычук агызып бирде.

— Муеныңдагы муенчагы бушый башлаганга сикерә дә Алмыш хан,— диде Ямгырчы би, эчеп җибәргәч, нечкә, матур мыегын сыпырып.— Үзенең муенындагы муенчагын алып ташладымы, шундук ул аны безгә кидерәчәк: сезгә, миңа... Бүләр, Суарга... булдыралса — Биарга.

— Син, Ямгырчы би, тыңлап-тыңлап торам да, кыек сөйлисең! — диде кинәт Койтым бикә, кунакның сүзен бүлеп.— Алмыш хан инде күптән сиңа муенчак кидергән. Акбүрегә әле кидерәсе бар!

Күрән би, күңеле булып, хатынына ягымлы күз карашы ташлап алды. Кунак, сүзеннән бүленеп, тотлыгып калды, аннары мыскыллы гына көлемсерәде дә, Койтым бикәгә карап:

— Син дә бик үк турысын сөйләмисең, бикә,— диде.— Сезнең муенга да муенчак күптән салынган. Муенчак кына да түгел — богау!

— Болгарлар муенчагын өзеп ташлаганга быел дүртенче ел китте, би! — диде аңа каршы Койтым бикә.

— Сартларны үз теләкләре белән килмәгәннәрдер дисезме? — диде Ямгырчы би, башлап та очланмаган сүзенә яңадан тотынып.— Юк, бикә, аларны монда Алмыш хан җибәрмәде. Алмыш! Юл бикле, Чулман ябык! Менә шул була инде ул муенчак, Койтым бикә!

— Сартлар сиңа да килмәдеме? — диде Күрән би.

— Миңа да,— диде Ямгырчы би.— Ага-базар миңа якын. Мин аларны көтеп ятмадым. Сезнең эшләр башкачарак. Чулман баш бирми, Чулман калан түләми. Шуңа ачу итеп быел Алмыш хан барлык сатучыларны Этил буйлап югары җибәрде... үзенә буйсынган ыруларга.

— Ярар, шулай да булсын,— диде Майчан аксакал. Монда ятып без берни белмибез. Читтән килгән сатучылар ни диләр соң? Сату-алу безгә генә түгел, аларга да кирәк ич! Быел сартлар безгә килмәс, җирингә — болгарга килмәс. Базар эшләмәсә... Ни... аты коргыры... кем... Алмыш ханга акча каян килер?

— Шула-ай! — диештеләр акбүреләр, аксакалны яклап.

— Күреп торам: син миңа яңалыклар алып килгәнсең,— диде Күрән би кунакка.— Шулай да турысын гына әйт: уең ни?

Ямгырчы би җентекләп акбүреләргә карап чыкты, тирән итеп тын алды да:

— Уем шул,— диде.— Алмыш хан көчәйгәнче, безгә берләшергә кирәк, Күрән би! Без — Ак хан токымнары! Бөтен Чулман бер булып безгә болгарларга каршы чыгарга кирәк. Бүре безне берәм-берәм тотып ашаганчы, тупланып, безгә аның үзен ашарга кирәк! Менә шуңа килдем

---

[1] Ассу — файда.

дә мин сезгә, туганнар, акбүреләр. Сез көчле, бай. Бөтен Чулман буенда сезнең кебек көчле ыру юк. Сез кузгалсагыз, башкалар да кузгалачак.

— Алай микән? — диде Күрәм би, эчен уып.

— Алай! — диде Ямгырчы би.— Күтәр байрагыңны, күтәр кылычыңны, Күрән би! Бөтен Чулман синең кул астыңа җыелачак. Мин сине үземнән өстен итеп, өлкән итеп таныйм, Күрән би!

— Таныйбыз, таныйбыз! — диделәр Ямгырчы бинең юлдашлары.

— Болгарларның муенын сындырсак, Чулман йортның ханы ясыйбыз сине, Күрән би! — диде Ямгырчы би.

— Ясыйбыз, ясыйбыз! — диделәр аның юлдашлары.

## XIII

Күзләре уттай янган акбүреләр, тынычсызланып, утырган урыннарында кыймылдашып алдылар. Берсе елмайды, икенчесе кашларын җыерды, өченчесе җилкәсен кашыды. Күрән би әлегә берни эндәшмәде. Ул яңадан чүлмәгенә тотынды, онытылып, сычук тулы аякны эчеп җибәрде, аннары кунакларны, ырудашларын сыйлады. Эчә-эчә сүз бөтенләй икенчегә борылып китте. Алар мунчаның икенче як бүлмәсенә керделәр дә юындылар, коендылар, аннары кайту ягына борылдылар. Чарачада [1] йокымсырап аларны кырнаклар көтеп утыра иде. Кол кызлар аларга киенергә булыштылар. Кызларны күрү белән кызмача Ямгырчы би чын-чынлап исереп китте: як-якка чайкалган булды, бәйләнешсез сүзләр сөйләде.

— Бер теләгең үтәлер, Ямгырчы би,— диде Күрән би, көлемсерәп.— Кызларның берсен үз яныңа алырсың. Икенче теләгең үтәлерме, юкмы — анысын үзара уйлашып әйтербез.

Күрән би кунакларга, үз кешеләренә тыныч йокы теләде дә кунарга Койтым бикә белән аның агач өенә китте.

Башкаларга тыныч йокы теләсә дә, ул үзе бик озак тынычлана алмый ятты.

Хан булырга! Чулман-Этил йортның башы булырга! Мондый уйның килеп караганы булды микән бер әр тапкыр аның күңеленә? Әйе, яшь чагында ул да уйламады түгел. Ул да болгарларны Чулман, Этил буйларыннан себереп түгү, ниндидер бабайлар сөйләгән Ак хан йортын аякка бастыру турында татлы уйлар уйламады түгел. Ул алай уйланып кына да калмады, ныклап торып сугышка да җыена башлады, күршеләренә итәк астыннан ут җибәрде. Тач Ямгырчы би кебек котлы таратып йөрде! Чулман биләре каршы килмәделәр, тик шулай да сикереп тә төшмәделәр. Аннан-моннан ике-өч мең кеше җыеп, ул каекларда Чулман тамагына төште. Анда алар, коры җиргә чыгып, ат менделәр, болгарларга каршы яу чаптылар. Ямгырчы бинең атасы Кылыч би ул чакта беркемгә катнашмыйча читтә калды. Әйе, орыштылар, җиңелделәр... Биш йөздән артык ир җирдә ятып калды.

Шула-ай... Кайчандыр ул да тилереп йөрде. Болгарлар кирәген биреп кайтаргач, шуннан соң беркайчан да үзенең катавыннан ул якка борынын тыгып карамады. Кая ул! Кайчагында тик урман арасындагы ерларга яу чапты да бер-ике тапкыр биарларны талап кайтты. Соңгы елларда анысы да онытылды. Ни әйтсән дә, картаелды. Менә ничә ел инде ул күршеләре белән тату гына, тыныч кына яшәп ята.

Ник кычытынып йөри соң әле бу Ямгырчы би? Казаяк ыруының башы аны — Күрән бине — хан ясарга килгән. Нинди җиңел икән ул хан булуы! Юк, булмый ул алай. Тора салып беркемнең дә икенче берәүгә

---

[1] Чарача — мунчаның салкын бүлмәсе.

буйсынып яшисе килми. Әле ул Алмыш ханга буйсынып яши, инде аның никтер Күрән ханга буйсынасы килә. Юк, булмыйрак торсын әле! Ямгырчы белән астына су кергән — миңа нигә килгән ул монда! Ана никтер булыш кирәк, Акбүренең көче, байлыгы кирәк. Туп-туры әйтергә аның кыюлыгы җитми. Күрәсең, болгарлар аның үзенә янәйлардыр, аның үзенең Алмыш хан белән алыш-биреш ясыйсы бардыр. Менә шуңа да инде үзенең ерак туганын исенә төшергән дә ул. Юк, юк, алдыннан арты яхшы. Үгезе үлгән, уртагыннан аерылган. Казаяклар өчен кан коярга монда акбүреләрнең башына тай типмәгән. Кирәк икән, сугышсын үзе. Монда беркем үтеп керә алмаячак. Монда килеп җиткәнче әле Алмыш ханнарга иксез-чиксез киртәләрне җимерергә туры киләчәк. Алмыш хан Шелке түгел. Су юлы белән монда тикле килеп җитәргә аның каеклары юк. Коры җирдән килергә ул беркайчан да батырчылык итмәячәк.

Икенче көнне иртән ыру башы иң якын агай-энене, аксакалларны үзенең ак өенә киңәшкә чакырды. Киңәштә бары ирләр генә катнашты. Яу эше тулысынча алар кулында иде. Киңәш озакка сузылды. Беркайчан да зур сугыш-орыш күрмәгән яшьләр бүгеннән үк болгарларга каршы тупланырга, яу чабарга кирәк, диделәр. Өлкәннәр каршы килде. Майчан аксакал әйтте: үзенә килеп ябышмыйча торып, болгарларга каршы кылыч күтәрү ул башсызлык булачак, диде; Чулман иле таркау, аны инде Ямгырчы би дә, Күрән би дә туплый алмаячак, диде; угызлар безгә булышка килмәячәк — Алмыш хан аларның кияве, башгыртлар ышанычсыз — бер көнне алар синең яклы, икенче көнне болгар яклы, диде; Суар, Бүләр бездән ерак, Биарның үз кайгысы кайгы, диде.

Күрән би дә Майчан аксакалны яклады. Сугышка атлыгып торган яшьләр — шулар арасында Акбога белән Котан да инде бирелә башлаганнар иде, шул чакны Утташ камның тавышы ишетелде.

Утташ кам яшьләрне яклады. Ул әйтте: Ямгырчы би шул тикле ерак җирдән тикмәгә килеп йөрмәс, диде; Күрән би баш булырга теләми икән, Ямгырчы бине хан дип танырга да, барысын аңа ышанып тапшырырга кирәк, диде; ул яшьрәк, белеклерәк, көчлерәк, диде; болгарлар аныңмоны сизенгәнче, тупланып, көч җыеп алсак, олуг тәңре белән, изге иäләр белән без аларның үзләрен туздырырбыз, диде; менә шулай кулны кушырып утырсак, көннәрдән бер көнне Алмыш хан, атасы Шелке кебек, монда да килеп җитәр, безнең бугаздан алыр, диде; ата-баба йоласын аяк астына салып таптаган Алмыш ханга каршы изге яуга кузгалыгыз, акбүреләр! диде.

Башка чакта мондый эшләргә бик үк катнашмый торган камның шулай кайнарланып яуга өндәве өлкәннәрне шактый аптырашта калдырды. Яшьләр исә башларын югарырак күтәрделәр — ыру башының эче пошып куйды. Белексез углы кырган бүреләрне үз күзләре белән күргәч күңелен билә алган бер ямьсез сизену — тәңренең каргышын татырга туры килмәгәе, дигән сизену, курку-өрку, яшен камчысыдай булып, аның бөтен эчен айкап алды. Аның чырае бозылды. Болай булгач, булмады бу! Утташ кам аяк чалгач... ачыктан-ачык аяк чалгач, булмады бу!

— Уртак сүз табылмады,— диде ул үзенең ырудашларына.— Корылтай җыябыз!

Шул ук көнне Күрән би Акбүренең өлкәннәрен — аксакалларны, авыл башларын чакырып тартыклар[1] җибәрде. Корылтайга шулай ук игенчеләр, балыкчылар, аучылар, юллардагы, чик буйларындагы, яр буйларындагы каравыл башлары да чакырылды. Икенче көн туды дигәндә, чакырылган кешеләрнең барысы да катауга җыелып бетте. Ко-

[1] Тартык — ханга, бигә буйсынган кешеләрне ашыгыч рәвештә чакыртып алу өчен җибәрелгән махсус кеше.

рылтайны урданың тышкы ягына калку үр өстенә корылган йөз кешә сыйдырышлы чатыр эчендә ясадылар. Корылтай киңәшкә караганда да шау-шулырак булды. Яшьләр, Утташ кам яклылар яуга чакырдылар. Картраклар, куркаграклар, шулай ук белеклерәкләр бер дә юктан ут белән шаярмаска өндәделәр. Безне әлегә кысучы юк, безгә җир-су житә, Чулманда балыкның, урманда киекнең беткәне юк, тыныч кына яшәп ятыйк, диделәр.

Күпчелек картларны, куркагракларны, шулай ук белеклерәкләрне тыңлады. Акбүре ыруы болгарларга каршы яу чыгудан баш тартты.

«Җыясы азыгым, эчәсе суым бетмәгән икән әле! Инде тынычлап йокларга да була»,— дип уйлады Күрән би, җиңел сулап.

## XIV

Казаяклар акбүреләрнең соңгы сүзен аяк өсте тыңлап тордылар. Корылтайның нинди уйга килүен ишеткәч тә, кунакларның йөзләре бозылды. Арысландай алып [1] Күрән би дә яудан баш тарткач, бүтәннәргә ни сан?! Бозылды ажун. Ак хан токымының күкрәгендә ялкын сүнде, арыслан дигәннәре сычкан булып чыкты. Барысы да үзенчә генә яшәргә, качып-посып яшәргә тырыша. Ил турында, бөек ата-бабаларның атагы турында кайгыртырдай беркем калмады. Өрлексез өй булмас, терәксез тирмә булмас. Каян табарга өрлекне, каян табарга терәкне?!

Күңеле кырылган Ямгырчы би Күрән бигә шундыйрак үпкә сүзләрен әйтте. Шул ук көнне ул юлга чыкмакчы булды. Ак бүре ыруының башы аны болай үпкәләгән килеш кайтарып җибәрергә теләмәде. Ул аны тагын бераз кунак булырга үгетләде.

Чынында Ямгырчы би болай гына үпкәләгән булып кыланды. Аның әле бер дә буш кул белән кайтып китәсе килмәде. Аның уйлары, Күрән би сизенгәнчә, бик тирәнгә яшеренгән иде. Күрән бине хан ясау турында ул, билгеле, башына да китереп карамады. Аның үзенең хан буласы килде. Тик шулай да бар тотка Акбүредә иде! Аларны кузгатып булса, башкаларны кузгату чыннан да җиңелрәк булачак иде.

Юк, ул әле әз генә дә чигенергә теләмәде.

Ямгырчы би, Койтым бикәнең үзе генә өйдә чагын белешеп, сагалап торды да, яхшырак киенеп, чәченә, сакал-мыегына исле майлар сөртенеп, ялгыз өйгә юнәлде.

Ул барып кергәндә, бикә өйдә иде. Әлерәк кенә төшке аш ашаганга ул, күрәсең, бераз тын алмакчы булып, алсу ефәк тышлы мендәрләр өелгән йомшак урын-җирдә кырын-ярын ятып тора иде. Ике ягындагы ике кыз, аның чәчендәге энҗеле каптырмаларын, тезмәләрен салып-чишеп торалар иде. Шунда ук өченче берсе аның аягындагы каюлы читекләрен тартып ята иде.

Кунак килеп кергәч, бикә чишенүеннән туктап калды, артка ташланган башын күтәргәндәй итте дә, күз карашы белән генә ымлап, кызларга чыгып китәргә кушты.

— Түрдән уз, би,— диде Койтым бикә, керүчегә йөзен борып.

Ямгырчы би елмаеп түргә узды, күрсәтелгән урынга — бикә каршына килеп утырды. Бикә аңа никтер борчулы, күңелсез күренде. Аннары ул бераз гына таркау да, бераз гына салкын да, ачулы да шикелле тоелды. Кунакның Койтым бикәне мондый йөз белән күргәне юк иде әле.

Корылтайда Койтым бикә дә катнашты. Баштарак ул шаулашучыларның берсенә дә кушылмады. Башкалар түгел, аның ире дә бикәнең ни уйлаганын анык кына белә алмады. Баштарак бикә Күрән бигә: син ничек уйласаң, мин дә шулай уйлыйм, дигән иде. Бу көннәрдә башы каткан Күрән би артык төпченеп тормады, ул чыннан да бикәнең үз

[1] Алып — батыр.

сүзеннән чыкмаячагын яхшы белде. Аксакаллар аңа сорауны төрәп куйдылар: син ил яклымы, яу яклымы? диделәр. Менә шунда инде Койтым бикә үзенең күңелендәгесен әйтте дә бирде. Иренә каршы чыгасы килмәсә дә, явыз Утташ камчы яклыйсы килмәсә дә, барлык ырудашлары алдында ул турысын әйтте.

— Мин Алмыш ханга каршы яу чыгарырга өндим! — диде бикә.

Нәрсә уйласа, ул шуны әйтте. Күрән бинең йөзе карангыланып киткәнен бикә, билгеле, күрми калмады.

Менә шуның өчен дә — иренен күңелен кырган өчен, ахрысы, аның әле булса эче поша иде. Әллә тагын бүгән төрле кайгылары, борчулары бар иде микән соң аның?

## XV

Койтым бикәнең бала чагы Чулман буйларыннан ерактa, Җаек далаларында үтте. Ул Җаекның урта агымында көченеп йөргән кангылыларның Карабай ыруында туды. Карабай ыруының башы Кайду бикнең[1] икенче ишеннән[2] туган икенче бала иде ул. Кайду бикнен илле мең баш куе, дүрт мең баш жылкысы бар иде. Җаек буенда тоткарланып калган кангылы ырулары арасында ул иң бае, иң көчлесе иде. Шуның өстәвенә, Кайду бик алып ир иде. Ук атышта, сөңге ыргытышта, кылыч белән чабуда беркем аннан уздыралмый иде. Бөтен тирә-як — кангылылар гына түгел, угызлар, башгыртлар да — аннан куркып, котлары алынып торалар иде.

Кайду бикнең балалары аталарына охшап үстеләр. Алар бар яктан да уңган булдылар, көчле, усал булдылар. Койтым бикә дә үзенең ир туганнарыннан калышмады. Алар кебек җилдәй җилеп ул атта да чапты, ук та атышты, сөңге дә ыргытты. Чаялыгы, батырлыгы өчен аңа яшьтән үк «Алыпша» дигән кушамат тактылар.

Үзенең туган даласында, туган ыруында — яшьтәшләре, туганнары арасында, терлек-туар арасында ул шулай уйнап, күңел ачып, кайгысагыш күрмәенчә, унбиш яшькә тикле яшп алды. Унбишне тутырып уналты белән барганда, көннәрдән бер көнне, җәйге чилләнең уртасында Җаек буе кангылыларына олы талау килде. Төн ягыннан көтмәгәндә кара болыт булып, кара яу килеп басты. Кояш сүнде, жир сыкранды, киң даланы ялкын чорнап алды. Ягы көчле иде, санаусыз күп иде. Кангылылар соңгы тамчы каннарына тикле сугыштылар. Кайду алып, арысландай ярсып, кылычы белән уңга-сулга чапты — берсен урталай кисте, икенчесенең башын кыеп төшерде, өченчесен кулсыз калдырды. Аның янында таудай булып, туралган ягылар[3] өелде.

Кангылылар каты сугыштылар, кангылылар тын да алмый орыштылар. Тик шулай да ягы көчле иде, санаусыз күп иде. Кайду алып янындагы ирләр әкренләп-әкренләп кими барды.

Ирләр кебек тимер күбә киеп, кылыч тотып, Койтым-Алыпша да атасы янында торып сугышты. Ук янгыры яудырып, карабайларны ягы кысрыклый башлагач та ул атасы яныннан, алып туганнары яныннан бер адым да чигенмәде — ярсып кара яуга уклар атты, якын килгәннәрен кылыч белән чапты.

Барысын да ул үз күзләре белән күрде, барысын да үзе тойды. Көтмәгәндә Кайду биккә агулы ук тиде. Ыру башы ияреннән җиргә ауды. Шул чагында кинәт кояш сүнде, жирнен асты өскә килде! Кангылылар каушап калды, кача башлады. Шул чагында кинәт кояш сүнде...

---

[1] Бик — би, эре жир-су хуҗасы, феодал.
[2] Иш — монда: хатын.
[3] Ягы — дошман.

Озын буйлы, яшь, таза ир ыргып алга чыкты... кара яуның кара ире ыргып алга чыкты. Шул чагында кинәт жирнең асты өскә килде!.. Чабып килеп, бар көченә яшь, таза ир — кара яуның кара ире Кайду бикнең... Койтым бикә атасының муенына кылыч орды. Ах, шул чагында, тәңрем, җирдә кояш сүнде... Тимер алпак кигән зур, авыр баш, кызыл кара канын кара җиргә коеп, кылган арасына тәгәрәде.

Барысын да Койтым-Алыпша үз күзләре белән күрде. Чабылган баш, озын, чибәр егет... кара егет мәңге аның күңеленә сеңеп калды.

Алар җиңелделәр. Ыру юкка чыкты. Сарыкларны, жылкыларны, сыерларны ягы куып үз иленә алып китте. Исән калган кешеләрне, сарык, сыер кебек итеп, көтү-көтү төн ягына кауладылар.

Карабайны килеп баскан явыз ягы... кара ягы болгар ханы Шелке иде.

Үз кулына төшкән сарыкларны, сыерларны, жылкыларны Шелке болгарларга бүлеп бирде. Кулга төшкән кешеләрне коллар итеп сатып җибәрде. Койтым-Алыпшаның дүрт абыйсы, биш энесе, богауланган килеш, чит җирләргә озатылды. Яшь кызларны, хатыннарны Шелке үзендә калдырды. Шулар арасында өч сеңелесе, өч апасы белән, ике үги анасы белән Койтым-Алыпша да бар иде. Кызалактай[1] сылу, күз яшедәй керсез Көй-Тәм кыз да бар иде.

Гүзәллеге, тазалыгы аның күзгә бәрелеп тора иде. Аның көчле ялкын бөркеп торган күз карашы, яшь, сылу йөзе, тубыгына җиткән кара толымнары, тулы, төгәл буй-сыны бер карауда ирләр токымының аңын җуяр иде. Илле биш яшьлек Шелке аны күреп алды. Күрде, телсез-өнсез калды. Ул аны башкалардан аерырга кушты. Ул аның үзен генә аерым тирмәгә бикләргә кушты.

Илен-көнен таркатучы, атасының, анасының канын агызучы, туганнарын кол ясаучы җирәнгеч карт, исерек карт шул ук төнне аңа кияү булып керде. Ут-ялкыннан исән калган алсу чәчәк, гүзәл чәчәк — кызалакны кансыз Шелке таптап китте.

Берничә көн үткәч, качып-посып төнлә аның янына икенче ир килә башлады. Монысы яшь иде, чибәр иде. Монысы Шелке ханның өлкән углы Алмыш углан иде. Алпак кигән башны чабып өзгән, аннары шул башны сөңгегә элеп, куанып, үзенекеләр ягына чапкан яшь, өлгер Алмыш углан иде.

Көн дә шулай кабатланды: караңгы төшү белән аны ярым үлек килеш Шелке ханның тирмәсенә алып киттеләр дә төн уртасында үз өенә китереп куйдылар. Ул аңына килергә дә өлгермәде, өрәк булып, явыз ия булып, мыштым гына Алмыш углан килеп керде. Шулай итеп, бер-ике ай ата белән углы качыш-качыш уйнадылар.

Ата кеше шулай да нидер сизенә, төпченә башлады. Сулган алсу чәчәк берни эндәшмәде, бары озын керфек очларыннан иртәнге чык сыман эре, кайнар күз яшьләрен генә түкте. Көндәгечә төнге өрәк үз янына килгәч, шулай да ул аңа картның сизенүен әйтте. Йа тәңрем, ул, ахрысы, аны ярата иде!

Шуннан соң икенче төнне качып-посып аның янына икенче бер яшь ир керде — Алмыш угланның яшь энесе керде. Керүен керде... чибәрлеге белән болгарларны таң калдырган яшь кырнакның кайнар кочагын татырга шулай да аңа язмаган булып чыкты. Көтмәгәндә ишек ачылып китте, ярсып Шелке-ата килеп керде. Бер кулына чыртлап янган чырак тотып, бер кулына уттай ялтыраган кылыч тотып, көнчел ата килеп керде. Күзенә ак-кара күренмәгән ата кеше бер селтәүдә углын кыеп төшерде, икенче селтәүдә яшь кырнакны чабып ташламакчы булды, тик... Койтым кырнактан инде җилләр искән иде.

---

[1] Кызалак — тюльпан.

Аны бары таң алдыннан гына таптылар. Ул урда коймасы буенда, чүп-чар арасында песи баласыдай бөгәрләнеп ята иде. Аны хан каршына китерделәр. Шелке инде тынычланган иде. Ул аннан берни сораштырып тормады, аның күз яше белән чыланган, яшь, сылу йөзенә бер генә карап алды да, теш арасыннан сыгып:

— Сатарга,— диде.

Ага-базарда аны Биарга юл тотучы җөфүт сатып алды. Базарган Кызыл Яр аша узганда, Күрән би аны кулбау[1] итеп үзенә алып калды. Би баштарак аны кырнак итеп тотты, аннары Тотыш углан тугач, үзенең хатыны ясады. Күрән би аны яңадан тергезде. Изгелеген аның беркайчан да онытмас ул!

Ямгырчы би килеп бөтен эшне бозды... иске яраларны кузгатты да күкрәктәге кара кандай каткан үч, ачу тойгыларын актарып чыгарды. Ничек аңлатырга шуны Күрән бигә?!

## XVI

— Тәңре сина күп яшь бирсен, саулык-байлык бирсен, бикә! — диде Ямгырчы би, бикәнең чибәрлегенә соклануын яшермичә, аның йөзенә туры карап.— Изге иялэр йортыгызны-илегезне, ыруыгызны, терлектуарларыгызны уттан-күздән, яудан-кыраннан сакласын. Төн карасыдай ул чәчләрегезне, тулуын айдай сылу йөзләрегезне, дүрт саны да төгәл, күркәм буегызны тәңрем яман күзләрдән сакласын!

Бикә Ямгырчы бинең теләкләрен, мактауларын исе китмичә генә тыңлады. Аннары, чак-чак кына тешен агартып:

— Акбүре ыруында яман күзләр юк, булса шул чит ырудан гына булыр,— дип куйды.

— Чит ыру кешеләре сезгә бары яхшылык кына телиләр, бикә! — диде Ямгырчы би, елмаеп. Аның тынычсыз икәнлеге сизелеп тора иде.

— Үз ыруымда да миңа шуны ук телиләр, би,— диде Койтым бикә.— Аяк өсте тору сиңа килешми, би. Утыр.

— Сезнекедәй күркәмлек каршында... күктән иңгән якты йолдыз каршында миңа тезләнеп торсам да килешә, бикә! — диде Ямгырчы би.

— Синең миңа йомышың бар бугай, би? — диде бикә, туры сүзгә күчеп.

— Бар, бикә, бар! — диде Ямгырчы би, яңадан артсыз урындыкка утырып.— Төп йомышым үтәлмәде. Бик күңелем кырылды, бикә. Акбүрене мин Казаякның өлкән агасы дип беләм. Үзеңнең туган агаң белән уртак сүзгә килә алмау бик күңелсез булды, бикә. Авыр чакта үз туганың да булышмагач, кем булышыр безгә?

— Нинди авырлык килде соң әле сиңа, би? — диде бикә.

— Килде дип... килеп җитмәгән дә соң әле,— диде би, тотлыккандай итеп.— Алмыш хан кузгалса, иң элек кемгә ташланыр дисең — миңа!

— Шулай шул,— дип куйды бикә, килешеп.— Икенче йомышың ни?

— Икенче йомыш? — диде би.— Икенче йомыш... Мин бер нәрсә уйлаганыем, бикә. Килгәч-килгәч, коры кул белән кайтып китәсем килми. Туганлашып булмас микән безгә, дим, бикә.

— Без болай да туганнар түгелмени?

— Җырак туганнар икән шул, бикә. Ныграк якынаергае безгә.

— Ничек итеп?

— Минем кызым Тәңкә ошадымы сезгә? — диде Ямгырчы би, сакалмыегын сыйпаштырып.

Аның бу кыланышы бикәгә ниҗтер: «Мин ошыймы сиңа?» дигән сымаграк тоелды.

[1] Кулбау — бер бөтеннең күпмедер өлеше. Процент.

— Ошады...— диде Койтым бикә, көттереп.— Шулай да син исеннән чыгарасың, би: сез дә, без дә буртаслар түгел, ата-баба йоласы буенча, бездә егетне кызлар түгел, кызны егетләр сайлый.

— Чумак йоласын тотсам да, мин ата-баба йоласына каршы түгел,— диде Ямгырчы би.— Ата-ананың килешүе язык түгел лә, бикә! Чумак йоласы буенча...

— Мин төрек йоласын артыграк күрәм,— диде Койтым бикә, бине бүлдереп.

— Тәңкә минем бердәнбер кызым,— диде Ямгырчы би.— Ул иректә үсте. Анасыннан иртә ятим калганга, мин аны берниднән тыймадым, кысмадым. Ул да ата-баба йоласын артыграк күрә. Инде менә үзенә кияү сорый. Чын. Үзара гына әйткәндә, шуның өчен алып килдем дә мин аны. Алмыш ханның күзе төшкәнче дип... Сезнең белән килешеп булса...

— Син кемне күз алдында тотасың, би? — диде Койтым бикә, кызыксына төшеп.

— Синнән туган Тотыш угланны күз алдында тотам мин, бикә! — диде Казаяк ыруының башы.

Койтым бикә, телен тешләгәндәй, сүзсез калды.

Әле кайчан гына Койтым кырнак аны карынында йөрткән иде! Нинди авыр булды аңа ул баланы табу! Уналты-унҗиде яшьлек кырнак ул чагында нәрсә генә белә иде соң йөкле булу, тулгак тоту, бала табу турында? Аңа әйткәннәр иде: яшь чагында бала табу җиңелрәк була ул, дигәннәр иде. Белеп әйттеләр микән, белми әйттеләр микән ул сүзне, тик шулай да аңа җиңел булмады бала табу. Аныкы үлем белән бер булды. Кендек әби белән Язай имче баланы ярып алдылар, юкса, ул аны табалмаган булыр иде. Шулай итеп, аның улы аҗунга тәңре яраткан капугтан түгел, кеше кулы белән уелган капугтан чыкты. Шуңа да ул бүре булып түгел, арыслан булып үсте! [1]

Әйе, арыслан булып үсте... беркем сүзен тыңламыйча, беркемгә баш бирмәенчә... йолаларны, түрәләрне санламыйча... кыргый булып, усал булып үсте. Тугач аның зурлыгына, көрлегенә таң калдылар. Үсә төшкәч аның көченә, кыюлыгына... башсызлыгына шаккаттылар. Шушы көнгә тикле ул күпме баланың кулын-аягын имгәтте, күпме ырудашын канъяшь түктерде! Ыру башының улы булмаган булса, күптән инде аның итләрен карга, козгын чукып бетергән булыр иде.

Ник шулай ул? Нигә шундый кире, үҗәт, башсыз? Анда, күрәсең, ике төрле кан шулай талашадыр. Әллә тәңре аны болгарлардан ата-баба каны өчен үч алырга шулай көчле итеп, кыю итеп яратканмы? Әллә Утташ кам әйткәнчә, туган чакта аның йөзенә явыз Октуган үзенең сасы тынын өргәнме? Тфү! Тфү! Үз каргышы үзенә!

Ни генә булмасын, менә шул Тотышны өйләндерер чак та җиткән! Бу турыда инде быел кыш та сүз булып алган иде. Алар аңа кызын да сайлап куйганнар иде. Күрән бинең Биар ханы белән туганлашасы килә. Биар ханының җитен чәчәгедәй зәңгәр күзле, җитен сүседәй аксыл чәчле сылу Ай-ярукны сорамакчы иде алар. Биар ханына әле илче җибәрелмәгән, тик шулай да төн яктагы күршеләр Күрән бинең теләген белеләр булырга тиеш.

— Мин каршы түгел,— диде бикә, беравык тынып утырганнан соң, уйчан гына.— Шулай да өздереп кенә мин берни дә әйтә алмыйм. Анасыннан башка аның атасы да бар. Болгарларга каршы яу чыгаргамы, юкмы диган кебек, бу да бик катлаулы эш.

— Шуның өчен корылтай җыеп тормабыз ич? — диде би, көлемсерәп.

---

[1] Борынгы заманда: ир бала туса,— бүре туды, кыз бала туса,— төлке туды, дигәннәр.

— Жыймыйча да булмас,— диде бикә дә, елмаеп, йомшарып.— Кайгырма, ул корылтайда миннән башка бары Күрән би генә булыр. Үзем мин ничек тә синең теләгенне аяк астына салмаска тырышырмын. Моның инде минемчә булыр!

— Таңре сезгә чуктин-чук яшь бирсен, байлык, саулык бирсен, гүзәл бикә! Мин иртәгә тагын белешермен,— диде елгыр би, бикә алдында бишкә бөгелеп.

## XVII

Өлкәннәр Тотышны шулай башсыз дип, явыз дип уйласалар да, үзен ул бер дә алай дип белми иде. Ул яшь иде, көчле, кыю иде. Аның бертуктаусыз каядыр йөгерәсе, чабасы килә. Аның йөрәге беркайчан да тынгы белми шикелле иде. Шуңа күрә дә ул, үзенең көчен, ярсу тойгыларын кая куярга белмичә, интегеп бетә. Шуңа күрә дә ул, ачуы килеп, я үзенең яшьтәшләрен тукмап ташлый, я булмаса ат атланып чаба, ук ата, сөңге чөя. Инде ул да булмаса, Чулман ярындагы текә кыяларга, биек агач башларына менеп, кош ояларын туздыра, төрле куркыныч уеннар эзләп таба.

Яшь угланны гел котыртып торган тыелгысыз көчтән башка тагын икенче бер нәрсә дә бар иде.

Төрек йоласы буенча, өйләнгәндә кызның байлыгына, ярлылыгына карамыйлар иде. Чибәрлек, тазалык кызның иң зур байлыгы санала. Күрән би үзенең кырнагын хатын иткәч, беркемнең дә мона исе китмәде. Киресенчә, яшь бикәнең күркәмлеге, матурлыгы бик күпләрнең күнеленә юш килде. Аны өйдә чын күңелдән ярата, олылый башладылар.

Арада көнчелләр дә табылды. Өлкән хатын Әди Койтым бикәне аеруча яратмады. Баштарак ул кече хатынны күз кырыена да чыгармады: аңа төрле яман сүзләр белән эндәште, әледән-әле кырнаклыгы белән йөзен ертты, аннары ничек тә аннан авыр, пычрак эшләрне генә эшләтергә тырышты. Шук, таза Тотышка исә бигрәк тә нык эләкте. Кеше күрмәгәндә ул аны сугып та җибәрде, тибеп тә җибәрде. Өлкәннәр арасында, баланың яшьтәшләре арасында ул аңа карата күрәләтә саксызлык, салкынлык күрсәтте.

Куркытылган, исен җыеп өлгермәгән яшь бикә үзен дә, баласын да чын-чынлап яклый алмады. Яңа җирдә, яңа ыруда, яңа күчтә ул Әдидән генә түгел, аның башка кардәшләреннән дә, шулай ук үз иреннән дә өркеп яшәде. Тумыштан булган кыюлык, иркенлек тойгысы аңа бик әкрен кире кайтты, шактый соңлап кайтты.

Куркып-өркеп, кыерсытылып яшәгән ананың углы да баштарак куркып-өркеп үсте. Аннан да бигрәк, ул үзенең «кырнак баласы», «кимчелекле бала» икәнлеген аңлап үсте. Аның моңа ачуы килде, күңеле кырылды. Аның үч аласы килде, үги анасы Әдидән, әледән-әле кыерсыткан туганнарыннан, яшьтәшләреннән бик каты итеп үч аласы килде. Күкрәгендә, беләгендә көч барлыгын тоя башлагач, ул, бер дә юктан кабынып китәргә генә торган ярсуына, кимсенү тойгысына ирек биреп, үзен кыерсытучыларны еш кына тәпәләп тә ташлады. Кыйналган яшьтәшләренең шулай ук ачулары килде. Алар, аның юкка-барга үртәлүен күреп, тагын да ныграк үчекләделәр. Соңга таба, Тотыш углан үсә төшкәч, аның туганнарының теленда «юлбасар», «башкисәр» кебек сүзләр ешрак кабатлана башлады. Андый сүзләрне өлкәннәр дә бик теләп кабатладылар.

Шулай үсә-үсә бала күңеленә кара кан укмашты. Әле ул төшенкелеккә бирелде, әле аранын җимереп качкан яшь айгырдай тилерен йөрде. Үз яшьтәшләре арасында аның якын беркеме дә булмады. Унбишләп туганы арасында ул үзен ялгыз сизде. Аны бары үз анасы гына яратты. Турыдан-туры читкә какмаса да, Күрән би дә, башкаларның

йогынтысына бирелеп, күрәсең, үзенең «юлбасар» углына карата шактый кырыс булды.

Өлкән хатын Әди кинәт чирләп киткәч, Әдинең кулыннан эш китә башлагач, Койтым бикә башын күтәрде. Бинең үзен башкаларга караганда нығрак яратканлыгын ул инде күптән белеп, тоеп килә иде. Бу аңа икеләтә көч бирде. Ул инде үзен дә, углын да юкка-барга кыерсыттырмый башлады. Киресенчә, элеккеләрнең үчен кайтарырга теләп, көндәшләрен әкренләп-әкренләп үз кулына ала барды. Әди үлмәс борын ук инде ул өй эчендә бөтенесенә баш булып алган иде.

Әйе, искәрмәстән Койтым бикә бөтенесен үз кулына алды куйды. Тик Тотышны гына ул тулысынча буйсындыра алмады. Үсмер Тотыш, егет Тотыш, беркемгә дә баш имичә, койрык тоттырмыйча, үз көенчә яши бирде. Элекке ачы тойгыларга, үпкә-әрнүләргә яшьлек тилелеге, яшьлек кайнарлыгы өстәлде. Яшьтәшләре дә, өлкәннәр дә әле булса аңа чит кеше, ят кеше итебрәк карауларында булдылар. Әле булса ул моны сизеп-тоеп яшәде, әле булса үзен никтер, ни өчендер кыерсытылган итеп белде.

Атасы аңа быел беренче тапкыр ышанып эш йөкләде: кыш көне ул, этләр җигеп, кораллы йөз ир белән, алтмыш йөк тавар белән төн кешеләренә, боз тиңгезе ярларына сату-алуга барды. Атасы аны юри җибәрде, сынап карау өчен... Аннары ул аның көченә, кыюлыгына да ышанды. Шулай ук аның бу углында баш та юк түгел иде.

Кыш көнендә бер дә кояш чыкмый торган дөм-караңгы төн иленнән, боз иленнән Тотыш углан биш ай дигәндә кире кайтып төште. Чаналарга таудай тире төяп, бер тиенен, бер кешесен, бер этен дә югалтмыйча, баеп, кырысланып, олыгаеп кайтып төште. Моңа тикле «шар тибүдән» башканы белмәгән «башкисәр», «юлбасар» угланның исәнаман кайтып керүен күреп, бөтен катауның исе китте. Ата белән ананың исә куанычы эченә сыймады. «Булдырдың, углым! — диде аңа атасы.— Синең кебек чакта атай мине дә шулай тавар белән җибәргәние. Каты буранга юлыгып, этләрне, йөкләрне югалтып, кешеләрне туздырып, ярты юлдан кире кайттым. Болай булгач, атаңны уздырдың, углым».

Атасыннан мондый мактау сүзләре ишетеп, Тотыш угланның күзләренә яшь килде. Туганнан бирле бу аның атасыннан гына түгел, анасыннан кала барлык өлкәннәрдән ишеткән беренче мактау сүзе булгандыр. Ата белән угыл арасындагы салкынлык, кырыслык шул көннән соң, әйтерсең, мәңге юкка чыкты. Шул көннән соң Тотыш углан атасына тәңрегә табынган кебек табына башлады.

Ул, әйтерсең, кинәт үсеп китте. Күңеле белән, уй-теләкләре белән үсеп китте. Ул үзен өлкәннәргә тиң итеп, алар эшли алган барлык эшләрне эшләрдәй чын ир итеп тоя башлады. Атасы белән анасының киләсе көзгә Биар ханының кызына өйләндерергә җыенуларын белгәч, аның чын-чынлап түбәсе күккә тиде. Тиздән, тиздән ул күчле, хатынлы ир кеше булачак! Тиздән, тиздән ул да кеше арасына кереп, үзенең сүзен әйтә алачак. Аның белән санлаша башлаячаклар! Барлык ирләр кебек, ул да киңәшләрдә, корылтайда катнаша алачак, кулына корал тотып, сакта-каравылда торачак. Кем итәр икән аны атасы — каравыл башымы, агычымы [1], таварлык [2] башымы, битекчеме [3]? Субашы булырга ул әле яшь. Түрә [4] буенча, яшьләрне андый зур эшкә куймыйлар. Моның өчен яуда катнашырга, үз-үзенне батыр итеп, башлы, белекле итеп күрсәтергә кирәк. Әлегә кечкенә алай [5] башы, я булмаса базар башы,

---

[1] Агычы — хәзинәче.
[2] Таварлык — тавар, азык-төлек, тире-яры саклана торган урын; амбар.
[3] Битекче — язу-сызу эшләрен алып баручы.
[4] Түрә — билгеле бер кагыйдәләр җыелмасы; закон.
[5] Алай — гаскәри төркем, отряд.

тамга башы булып торсаң да ярый. Әллә соң сатучы итәр микән аны атасы? Анысы да яхшы булачак. Тавар белән тагын төн кешеләренәме, Биаргамы җибәрер. Җибәрсен! Чит илләрдә, чит телләр, чит токымнар арасында күңелле. Анда бик кызык. Ят нәрсәләр, ят кешеләр күрәсең, ят азыклар ашыйсың.

Әллә көчле чирү туплап, болгарларга каршы яу белән җибәрер микән соң аны атасы? Ике сүзнең берендә тиккә генә болгарларны, Алмыш ханны яман итеп телгә алмыйлардыр ич! Атасы ирек бирсә, болгарларның тетмәсен тетәр иде ул, урдаларын, авылларын көлгә әйләндерер, барлык ирләрен Әтилгә тутырыр иде. Ул бары тик чибәр кызларны гына кызганыр иде. Аларны коллар итеп Кызыл Ярга алып кайтыр иде...

Яшь егет еш кына шулай уйланды. Кулга төшерелгән чибәр кызларны, хатыннарны, алтын-көмешне каекларга төяп, күңеленнән катауга кайтып кергәч, аның күз аллары томаланды. Уйлары буталды. Шуннан соң нишләячәген ул ачык кына күз алдына да китерә алмады. Барлык теләкләр, татлы уйлар иң ахырда бары бер нәрсәгә — ир буласы, зур кеше буласы килүгә кайтып калды. Шул бер теләгенә иреште исә, никтер бөтен нәрсә үзгәрер, бөтен нәрсә бары ул теләгәнчә генә булыр шикелле тоелды.

Көтмәгәндә Ямгырчы бинең килеп төшүе, акбүреләрне болгарларга каршы яуга өндәве Тотыш угланны канатландырып җибәрде. Ул инде үз-үзен чын-чынлап яуда итеп күрә башлады. Ыру аксакалларының киңәше төкәнгәнне ул киеренке бер түземсезлек белән көтте. Аларның яу яклы булачагына ул әз генә дә шикләнмәде. Тик аксакаллар киңәше ул көткәнчә төкәнмәде. Шуннан соң ул бар ышанычын корылтайга баглады. Инде корылтай да баш тартса, ул чагында... ул чагында... юк, булмас! Акбүреләр болгарлардан үч алырга тиешләр, акбүреләр борынгы атакларын кайтарырга тиешләр! Корылтай да каршы килсә, ул Ямгырчы би белән бер үзе китәчәк! Бөтен ыру өчен ул бер үзе сугышачак!

Түрә буенча, йола буенча, ыруга кагылышлы эшләрне тикшергәндә балалар катнаша алмыйлар иде. Катнашканда да, аларның сүзе санга алынмый. Өйләнмәгән егетләр, кияүгә чыкмаган кызлар исә, нича яшьтә булуларына да карамастан, бала саналалар. Тотыш моны бик яхшы белә. Шулай да ул, кайгылы башын иеп, билен бөгеп, атасы янына керде, аның үзен корылтайга катнаштыруын үтенде.

Бу көннәрдә бинең чырае аеруча караңгы иде. Ул әле изге нарат янындагы күренешне дә онытмаган иде. Ук-җәя барлап, кылыч кайрап йөргән белексез углын ул пыр туздырып чыгарды.

— Мин синнән дә, туганнарыңнан да, аналарыңнан да, ырудагы барлык кешеләрдән дә олырак,— диде ул углына.— Мин бары ырудан, түрәдән, ата-баба йоласыннан гына олырак түгел. Син ырудан да, түрәдән дә, йоладан да... атаңнан да олырак булмакчы буласыңмы?

— Мин олы булырга тырышмыйм, атам! — диде Тотыш углан, атасы алдына тезләнеп.

— Бар, күземә күренмә! — диде Күрән би, җикеренеп.— Бер генә каршы сүз әйтсәң дә... Игелексез!

## XVIII

Тотыш угланның «корылтае» шуның белән төкәнде. Атасының тупаслыгы яшь егетнең кытыгына килеп тиде. Помыла башлаган күңел ярасы янадан ачылды. Янадан ул үзен читкә тибәрелгән, кимсетелгән итеп тойды. Аның тагын бар нәрсәгә ачуы килде, аның тагын кемнәрдәндер үч аласы килде. Йолдыз-кашканың йолыкка бирелгәсен белгән көнне дә аның бу тикле күңеле кырылмаган иде бугай.

Атасы яныннан ул туры ат абзарына ашыкты. Кузенә күренгән беренче атка атланды да, кояшта кызынып утырган карт-корыга, судан кайтучы хатын-кызга пычрак су, ләпек чәчрәтеп, чыбыркысы белән атын яра-яра, басу-капка ягына чапты.

Капка сакчылары ерактан ук аны күреп алдылар, туктатмакчы булып, юлына аркылы төштеләр. Капка ачык, күперләр төшерелгән иде, шулай да тикшерми-сорамый беркемне дә кертмиләр дә, чыгармыйлар да иде.

— Кит юлдан! — дип кычкырды Тотыш углан сакчыларга.

Атның йөгәненә тотынырга чамалаган Талутка ул бар көченә кизәнеп чыбыркы белән салды. Талут чинап җибәрде, тезгенгә сузылган кулын тиз генә тартып алды да чыбыркы очы тигән күзен учы белән каплады. Тавышка йөгереп башка сакчылар килеп җитте. Би углының холкын белгәнгә, алар аңа ныклап торып каршы килергә батырчылык итмәделәр.

— Китегез, кит! Берегезне калдырмый турап бетерәм! — дип кычкырды ярсыган яшь егет, кылычын кынидан суырып.

Сакчылар шундук як-якка сибелделәр, сүгену, мыгырдану тавышлары ишетелде. Тотыш углан, җилдәй очып, капкадан, күпердән чыкты да басу ягына элдерде. Аның артыннан тик күпер яркакларының дөпелдәгән тавышлары гына гүләп калды да ат тоягыннан каты балчыклар гына чәчрәде.

— Йоланы тотмый, түрәне санламый, атасын тыңламый,— кеше түгелдер бу, албастыдыр, йәктер, өрәктер! — диде сакчыларның берсе, сукранып.

— Би углына ничек телең бара? — диде икенчесе.

— Бара шул! — диде беренче сакчы.— Мин әле моны корылтайда әйтәм... бөтен ыру алдында. Теңкәне корытты инде, эттән туган! Китсен энә тәңре каршына! Муенына элмәк салып, асып куйсыннар агач башына.

— Юк, әйтмәссең,— диде икенче сакчы тыныч кына.— Әйтсәң, үзең дә тәңре катына юлларсың. Синең дә язмыкларың җитәрлек. Тотыш — бала. Балага нишләсә дә килешә.

Кичкә таба, караңгы төшә башлаганда, арып-алҗып, Җирәнкәйне эштән чыгарып, Тотыш углан катауга әйләнеп кайтты.

— Атайга әйтмәдегезме? — диде ул, көчсез, кызганыч бер өн белән.

— Юк, Тотыш, әйтмәдек,— диделәр сакчылар.— Юкка кыздың баягынак. Талут күзсез калды.

— Кичерсен мине,— диде Тотыш, үкенү белдереп.

Калтасыннан ул бернича бакыр акча алып, сакчыларга ыргытты.

— Талутка әйтегез: анай янына барсын — теләгәнен алыр.

— Әйтербез, Тотыш, әйтербез,— диештеләр сакчылар.

— Корылтай беттеме? — диде Тотыш.

— Беткән. Яу булмаячак,— диделәр сакчылар, куанып.

Яшь егетнең болай да бозылган йөзе тагын да ныграк бозылды. Сакчыларга ул бүтән эндәшмәде.

Ул өйгә кайтып кергәндә, аның энеләре, сеңелләре пыр тузып, шаулашып, «күз бәйләш» уйнап яталар иде. Учакта төтәп кисәү башы яна,— шуңа күрәдер, ахрысы, өй эченә бераз гына әчкелтем ис чыккан иде. Балаларны караучы инәкә өйдә юк иде. Күрәсең, ул чыгып киткән, я булмаса күрше бүлмәдә йокы симертә.

Балалар, уеннарын онытып, Тотышны сарып алдылар.

— Тотыш кайтты, Тотыш!

— Ашка өлгермәдең!

— Кайда йөрдең? — диештеләр аның туганнары, төрлесе төрле яктан кычкырып, шаулашып.

Шушы ыбыр-чыбыр арасына кайтып керү белән, кайчан гына бул-

масын, Тотыш үзенең балалыгыннан оялу, тартыну кебек бер нәрсә тоя иде. «Балалар өе» дип йөртелгән бу өйдә иң зурысы ул иде. Аның белән бергә тукмашып үскән туганнары инде барысы да аерым өйләрдә яшиләр — өйләнгәннәр, я булмаса кияүгә чыкканнар иде.

Үзенең аягына-кулына уралган, өстенә менгән, башына атланган, чыр-чу килгән энеләренә, сеңелләренә бүген аның аеруча ачуы килде. Ул аларның кайсын кая төртеп, этеп җибәрде дә, билендәге кылычын салып, бала-чага буе җитмәслек биек чөйгә элеп куйды. Төн кешеләренә җибәрер алдыннан кылычны аңа атасы бүләк итеп биргән иде.

Балалар, кайсы шүрләп, кайсы үпкәләп, кинәт кенә тынып калдылар; күзләрен уттай елтыратып, борыннарын тарткалап, зур, усал абыйларының чишенгәнен күзәтеп тора башладылар.

— Абый, без бүген кыздырылган балык белән ботка ашадык, бал эчтек! — диде бер сыбызгы борын, абыйсының күңелен тапмакчы булып.

— Абый, инәкәй сиңа да алып кайтты. Учак янында, чүлмәктә,— диде икенчесе.

— Кая, китерегез монда,— диде абый кеше.

Балалар, бер-берсен уздырырга тырышып, шундук учак янына ташландылар, кулларын пешереп, бер чүлмәкне биш-алтысы берьюлы тотып, абыйлары алдына китереп тә утырттылар. Күп тә үтмәде, балаларның күңеле янадан күтәрелеп китте. Кырыс абыйларын онытып, алар тагын уйнарга керешеп киттеләр. Тотыш, киез өстенә, тәбәнәк өстәл янына утырып, үзенә дип куелган азыкларны ашады.

Ашагач-эчкәч ул тынычланып калды. Ул учак янында беравык тынып утырды да, үзенең өлкән абый, усал абый икәнлеген онытып, кызыксынып, кечкенә туганнарының уенына карап тора башлады. Шул чакны ул балалар арасында, ярым караңгыда ниндидер ят кыз күреп алды. Баягынак ишектән килеп кергәч тә аңа өй эчендә нишләптер кеше күбәеп киткән шикеллерәк тоелган иде, аннары таныш чыр-чу арасында ят тавыш та ишетелгәндәй булган иде. Теге Ямгырчы би кызы ич бу. Менә кем кергән икән аларга! Монарчы ул аны читтән генә күреп калган иде. Озынча ак битле, кара кашлы бу чандыр кызның күз карашы, учак җылысы кебек, җылы да, ягымлы да иде.

— Абый, бу — Тәңкә! Кунак кызы! — диештеләр энеләр-сеңелләр, абыйларының ят кызга карап торуын күреп.

— Исәнме, Тотыш,— диде кыз, йомшак кына, оялчан гына елмаеп.

— Исәнме, Тәңкә,— диде Тотыш.

## XIX

Кунак кызы Тәңкәгә аерым тирмә корылган иде. Ул анда өлкән яшьтәге бер асрау белән тора иде. Төн уртасы якынлашып, балаларның кайсы йокыга киткәч, кайсы, уеннан арып-талып, йокыга җыена башлагач, Тәңкә дә үз тирмәсенә кайтып китмәкче булды.

— Кал бездә генә! — диде Тотышның Айсылу атлы зур сеңелесе.

— Кал, кал — бергә йокларбыз!

— Җомак[1] сөйләшербез! — диештеләр башкалар да.

Ярым караңгыда Тотыш кунак кызның беләгеннән тотып алды да, колагына пышылдап:

— Калма! Үзем озатып куям,— диде.

Пышылдаган чакта аның маңгае кызның кайнар чигәсенә тиеп китте. Кыз берни әйтмәде. Тотышка ул озак, бик озак эндәшми торды шикелле тоелды.

— Кайтам,— диде Тәңкә Айсылуга, калтыранып чыккан бер пышылдау белән.

---

[1] Җомак — әкият.

— Кайтсын, кайтсын! — диде абый кеше, кунак кызын яклап.— Курыкма, үзем озатып куярмын.

Тотыш, кинәт үзен искиткеч җиңел тоеп, кемнендер аягына басып, кемгәдер бәрелеп, түргә узды, чөйдән киемнәрен алды. Ул киенгән арада Тәңкә, ишек бавына тотынып, дер-дер калтыранып, ярым караңгыда аны көтеп торды.

Язгы төн караңгы, салкынча иде. Каршыда гына кап-кара булып, җир өстеннән тирмәләр калкып утыра, тирмәләрдән, каралты-куралардан арырак, койма ягында, озын муеннарын күккә сузып, кара сырганнар очлаеп күренә. Ул якта — койма өстендә, тычкан күзе төсле генә булып төнге сакчыларның утлары җемелдәшә. Күктән исә, җирдәге караңгылыкка исләре китеп, берән-сәрән йолдызлар карый.

Өй эчендә юаш, тыйнак тоелган Тәңкә тышка чыккач бер дә юктан көлеп җибәрде; Тотышның янбашына төртте дә, егет аны-моны абайлап өлгергәнче, караңгыда юк та булды. Тотыш аның тирмәләргә таба юнәлгән аяк тавышларын гына ишетеп калды. Үзенең җебегәнлегенә чак-чак кына үртәлеп, чак-чак кына үкенеп, ул качкан кызны куа китте. Бер-ике атлауда ул тирмәләр арасына барып керде. Туктап, як-ягына каранды. Якын-тирәдә беркем юк иде. Кайдадыр шунда гына кунак кызының тыелып кына көлгән тавышы ишетелде. Тотыш шундук тавыш килгән якка ташланды. Аның инде караңгыга күзе ияләнә башлаган иде — ул кызның җиңеннән чак кына эләктереп алмады. Үчекләшеп кыз тагын көлеп җибәрде.

— Тоталмыйсың, тоталмыйсың! — диде ул, әкрен генә көлеп.

Кинәт сулуы капкан Тотыш, берни эндәшмичә, уттай янган күзләре белән якындагы карачкыны күзәтте. Болай качышлы уйнаганда үзенең чыннан да аны тота алмаячагын ул бик яхшы төшенде.

Алар шулай караңгыда бер-берсенә карашып торгандай иттеләр дә, икесе дә берьюлы диярлек урыннарыннан кузгалып куйдылар. Тотыш, үзенең тиле көченә ышанып, ярсып яңадан куа башлады. Кыз, көлгән сыман бер өн чыгарды да, башын иеп, аның кул астыннан шуып китте.

— Тотмасаммы! — диде Тотыш, янап.

— Тоталмыйсың! — диде кыз, еш-еш тын алып.

Шул чакны якында гына, урам якта тояк тавышлары ишетелеп китте — үзара әкрен генә сөйләшеп, урда коймасы буеннан төнге сакчылар узып бара иде. Яшьләр, караклыкта тотылган угрылар кебек, икесе дә сискәнеп киттеләр, тынып калдылар, сагаеп урам якка колак салдылар.

Кызга караганда Тотыш элегрәк исенә килде. Сакчыларны онытып, ул кисәк кенә Тәңкәгә ташланды. Кунак кызы көчсез бер тавыш белән «аһ!» дияргә генә өлгерде — куйны эләктереп алган бүре кебек, егет аны ике куллап тотып алды. Тотып алды да, кочып, кысып, җирдән күтәрде.

— Җибәр! — диде кыз, аның башыннан кочып.

Кулыннан ычкындырмыйча гына Тотыш кызны җиргә бастырды. Бер ара каушап-калтыранып торгандай итте, бар кыюлыгын бергә җыеп, аны яңадан кочып алды. Яратып, иркәләп, оялып кочты.

— Миңа иш буласыңмы? — диде ул пышылдап, кызга кайнар сулыш өреп.

Кыз эндәшмәде.

— Әйт, буласыңмы? — диде егет, кабатлап.— Мин бер нәрсә уйладым. Бүген генә... әле генә... Әйтсәң, әйтәм. Мине монда беркем яратмый. Санламыйлар. Биарга китәм, аннан көч сорыйм. Алмыш ханга каршы яу чабам. Ишетәсеңме, Алмыш ханга каршы яу чабам! Синең атаңа булышка барам. Күрерсең менә, Алмыш ханны җиңсәм, бөтен Әтил буена үзем баш булам! Шуна күрә иң элек миңа иш кирәк, хатын... Хатыным булмаса, Биар ханы миңа көч бирмәячәк, мине Әтил-Чулман

йортның ханы да ясамаячаклар. Аңладыңмы инде? Буласыңмы иш... чыгасыңмы миңа кияүгә? Әйт, минем язмыш синең кулыңда!

Тоныкк кына йолдызлар яктысында кыз, үзенең яратуын белдереп, аның яңа мыек чыгып килгән сылу йөзенә карады, очкынланып торган тере күзләренә карады. Теле белән әйтергә аның көче җитмәде, дер-дер калтыранып ул кайнар куллары белән, кайнар бите белән аның күкрәгенә сыенды да авыз эченнән ниндидер изге келәүләр әйтте.

## XX

Бу төнне яшьләр генә түгел, өлкәннәр дә тынычсыз уздырдылар. Тик аларның тынычсызлыгы куанычлы тынычсызлык түгел,— кайгылы, борчулы тынычсызлык булды. Койтым бикә үзенең болгарларга, Алмыш ханга булган каршылыклы уйларыннан, яшьлегенең куркыныч истәлекләреннән арына алмады. Ямгырчы би үз эшләре турында баш ватты. Күрән бинең кайгысы исә Койтым бикәнекеннән дә, Казаяк ыруы башлыкыннан да зуррак, тирәнрәк иде.

Киштәләрдәге елкылдавык тиреләр, өем-өем күннәр, тәпән-тәпән баллар бер мәлгә дә аның күз алдыннан китеп тормады. Шунда ук борып-борып аның эче авыртты, Утташ камның каргышларын, үзенең Тотыш угланның эшләгән языкларын искә төшереп, анда әчтә нидер туктаусыз агулап, сызлап торды. Ул чын-чынлап куркуга төште. Аңа инде ул тәңренең каргышын татый башлады шикелле тоелды. Үзенең авыруын, үзенең эше гел кирегә китүен шулай тәңре каргышына юрагач, аның күңел төшенкелеге көчәйгәннән көчәйде. Чит ил сатучыларының килмәве генә түгел, Ямгырчы бинең көтмәгәндә килеп төшүе дә, аның шулай күңелләргә коткы салып, Алмыш ханга каршы яуга өндәве дә, корылтай да, Койтым бикәнең үзенә каршы чыгуы да — барысы да, барысы да шул ук олы каргышның бер чагылышы булып тоелды. «Күрәсең, яшәр көннәрем күп калмагандыр инде», дип уйлады ул әледән-әле, сызланып.

Бераз шулай уфтанып, сыкранып, ыңгырашып ятканнан соң ул янәдән сатылмаган товарлары турында, чит ил сатучыларында булырга тиешле ниндидер им үләннәре турында уйлана башлады. «Ярар, Алмыш хан быел безгә аяк чалды,— диде ул үз-үзенә.— Җәрингә дә, аннан соң да аяк чалса, ул чагында нишләргә?» Әйе, ул чагында нишләргә?! Ничек котылырга моннан? Алмыш ханны кемнәрдер килеп туздырып ташлаганны көтеп ятаргамы, әллә... Ямгырчы би әйткәнчә... Юк, булмас! Алайса, түләнмәгән каланны түләп, шуның белән буаны ерып җибәрергәмени? Кайсын сайларга — иреккеме, байлыкнымы? Ах, нинди кирәк алар икесе дә ир булган ир өчен!

Алайса, чыннан да коры җирдән аркыш[1] җибәрү кулайрак булыр микәнни? Башкача юл юк. Күрәсең, шулай итәргә туры килер. Ике ай барасы, ике ай кайтасы. Башка юл юк...

Соңгы уе Күрән бигә ышанычлырак тоелды. Бу турыда ул иртән тыныч күңел белән дә уйлап карады. «Бүгеннән җыена башларга кирәк»,— диде ул үз-үзенә. «Тик кемне җибәрергә?» — дип уйлады ул бераздан. Акбога булдыра алмас, Котан шулай ук. Булса-калса — Тотыш. Биш йөз, алты йөз кораллы сакчы, яхшы кылавызлар[2] булса, әйләнеп кайтыр. Товарларын эт ашасын, им утлары, им сулары алып кайтса, шул да җиткән. Көзгә тикле Әди шикелле китеп кенә бармаса ярар иде. Әди дә гел «әчем!» диде, менә ул кая таба бара эшләр! Китсен Тотыш, китсен тизрәк! Эшкә җигелсә, тилелеген онытыр, кеше булыр.

[1] Аркыш — кәрван.
[2] Кылавыз — юл күрсәтүче.

Үзенең нишләргә җыенуын ул бикәгә дә сөйләп бирде. Койтым бикә бүлдермичә тынлап торды да:

— Тотыш миңа да кирәгие. Минем дә сиңа аның турында сүзем бар,— диде.

— Нинди сүз? — диде би, сагаеп.

— Ямгырчы би безнең Тотыш углыбызга үзенең кызын бирмәкче була,— диде Койтым бикә.— Туганлашыйк ди. Безне олылап, ышанып шулай ерактан килгән... болай гына китеп барса, яхшы булмас.

«Котыртышып та өлгергәннәр,— дип уйлады би, кире бер тойгы белән.— Өйләнешми торсыннар әле! Җилкуар Ямгырчы би белән туганлашасы гына калганые!»

Хатынына аның шулай дип әйтәсе килде. Тел очына килгән сүзен ул әйтә алмады — өйалдына кемнендер ишектән кереп килгәне ишетелде. Бүлмәгә каравыл башы Акбога килеп керде. Акбога бинең Әдидән туган өлкән углы иде. Имән кискәседәй таза, кырыс, авыр холыклы бер кеше иде ул. Кулына ул ниндидер бау-шу тоткан иде.

— Менә, атай, бау баскыч,— диде ул, кулындагы бауны идәнгә ташлап.— Текмәдә эленеп калган. Чулман ягында... текә яр өстендә!

Акбога, ниндидер чиктән тыш куркыныч нәрсә булганлыгын аңлатырга теләп булса кирәк, дулкынланып, кулларын бутап сөйләде. Өй эчендә авыр тынлык урнашты.

— Тагын Тотышмыни? — диде ата кеше.

— Кем булсын башка — шул! — диде Акбога, авыр йодрыгын йомарлап.

— Каян белдең? — диде ата кеше.

— Каекчылар менеп әйтте: Ямгырчы бинең кызы Таңкәне алып киткән,— диде Акбога.

— Таңкәне?! — диде би, күзләрен шар итеп, урыныннан кузгалып.— Ямгырчы би кызын?! Урлап? Угры кебек алып качкан? Инде шул гына калды. Би углы — угры!

— Ах! — диде Койтым бикә, йөрәк ачысы белән.— Нишләтергә ул баланы?!

— Нишләтергә кирәген уйлап торасы калмаган инде, анай,— диде Акбога, эчке бер сөенү сиздергән усаллык белән.— Болай булгач, зурга китте бу.

Бер дә юктан би ярсып кычкырып җибәрде.

— Телләшмә! — диде Акбогага.— Анаңа каршы сөйләргә кем булдың? Ул качканда син кайда калдың? Уяу саклыйлар аны, каравыл башы! Куанычы эчеңә сыймый. Бер-берсен тотып ашарга гына торалар.

— Кичер, атам, кичер, анам,— диде Акбога, тезләнеп, мыгырданып.

— Бар, йөрмә буталып! — диде би, утыз алты яшьлек углына аяк тибеп.

Акбога мыштым гына чыгып китте. Ата кеше, базга төшкән бүре кебек, үртәлеп, үз сакалын йолыккалап, әрле-бирле йөренә башлады. Чынлап та, болай булгач, зурга китте эшләр. Чуалды эшләр, чуалды!

Ул шулай үз алдына ярсып йөренде-йөренде дә утырган урынында тынып калган хатыны каршында туктады; ачуын алыр кеше табылуына сөенгән сыман, каты гына, усал гына сорап куйды:

— Җә, нишләтәбез, анасы? — диде.— Синең дә балаң ич... нишләтәбез: асабызмы, кисәбезме, әллә төкерәбезме?

— Башкалар ни әйтер...— диде Койтым бикә, авыру кеше кебек, агарынып.— Ыру ни әйтер... Ямгырчы би... Шуннан куркам мин!

Күп тә үтмәде, өйалдында икенче бер кешенең кереп килгәне ишетелде. Ишек сакчысы, ишектән башын тыгып:

— Ямгырчы би килгән, керсенме? — диде.

Би белән бикә, телдән язган сыман, сакчыга карап тик тордылар. Сакчы соравын яңадан кабатлады.

— Керсен,— диде би төшенке генә.

Күзе-башы акаеп, тузынып, Ямгырчы би килеп керде. Керде дә, бигә дә, бикәгә дә туры карамыйча, ашыгып исәнлек-саулык сорады. Шуннан соң, сулуы кабып, үз-үзен тыя алмыйча, эчендәге бар нәрсәсен түгәргә кереште.

— Мин синен кунагын. Күрән би,— диде.— Кунактан болай көлмиләрне. Углын минем йөземне каралтты. Калым түләмичә, кызның атасына, туганнарына берни белдермичә... юлбасар кебек! Изге йоланы, изге түрәне бозып...

— Сиңа кем йоласы изгерәк соң, би? — диде Койтым бикә, мыскыл белән, бинен сүзен бүлдереп.— Син чумак йоласын тотасын түгелме соң?

— Миңа икесе дә изге! — диде Ямгырчы би, аптырап калмыйча.— Урынына карап мин чумак йоласын тотам, урынына карап — төрек йоласын. Эш анда түгел. Моның өчен син миңа түләргә тиеш, Күрән би. Мин болай гына китмәячәкмен!

— Без сиңа түләрбез, би,— диде Койтым бикә, ире әйткәнне көтмичә.— Шулай да нигә тузынасың әле син? Кичәгенәк кенә үзен туганлашыйк, дидең түгелме соң? Менә, син теләгәнчә булган. Балалар бездән сорап тормаганнар. Моның өчен аларны салып суктыру кирәк. Шулай да...

— Юк! — диде Ямгырчы би.— Туганлашу болай булмый. Мондый туганлыкның, мондый кода-кодагыйлыкның миңа кирәге юк. Казаяк ыруының башы Ямгырчы би кызы төшеп калганнардан түгел. Юлбасар... угры белән туганлашу миңа килешми!

Күрән би, сөзешергә җыенган тәкәдәй, баскан урынында сикереп куйды, кылычын кыныдан суырып чыгарды да...

Ямгырчы би дә аптырап калмады — аның да кулында үткер тимер ялтырап китте. Күз ачып йомган арада баш очында, чак-чак килеп, кылычлар орыша башлады.

— Туктагыз! — дип кычкырды Койтым бикә, сикереп торып.

Аны-моны уйламыйча, ул ирләр арасына ташланды — үз иренең кылычы чак-чак кына аның башын кыеп төшермәде. Күрән би, кылыч астына кергән хатынын күреп, беренче булып исенә килде, коралын атып бәрде дә, эчке бер омтылышка буйсынып, үзенең дуамаллыгы өчен кичерү үтенгән сыман, бикәне кочагына алды. Үпкәләшеп, бозылышып торган берничә көн эчендә ул инде аны сагынып та өлгергән иде.

Ямгырчы би дә кылычын идәнгә орды, аннары иелеп алды да кире кынына салып куйды.

— Әйдәгез ашарга,— диде Койтым бикә, тузган чәчләрен төзәткәләп.

— Башта эчик,— диде Күрән би, кипшергән иреннәрен ялмап, басынкы гына.

Аякчы чүлмәк кертте. Күрән би чүлмәктән әчкелтем әйрән агызды да йотлыгып эчеп җибәрде, аннары кунагы белән хатынын сыйлады.

— Инде тынычланып сөйләшергә дә була,— диде ул, урынына утырып.

— Була,— диде Ямгырчы би дә.

— Сүзенне кире ал,— диде Күрән би.

— Алам. Кире алам, кире алам,— диде кунак.

— Инде әйт: күпме сорыйсың? — диде Акбүре ыруының башы, җиңел сулап.

— Мең тиен. Булмаса — йөз төлке, булмаса — утыз кеш,— диде кунак.

— Күбрәк,— диде Күрән би.

— Күп түгел,— диде Койтым бикә, ирләрне тизрәк килештерергә теләп.— Тотыш угланның белексезлеге өчен ата-ана языклы булмаса да, Ямгырчы би чыннан да оятка калды.

— Белегез: бу — калым түгел,— диде Ямгырчы би, кисәтеп.— Кызымны мин үзем белән алып китәм.

— Калым да булмагач... күбрәк шул,— диде Күрән би, киреләнеп, шулай да килешкән сыман итенеп.

— Калым түгел. Кызымны алып китәм,— диде кунак, кабатлап.

— Ярар,— диде Күрән би, килешеп.— Талау күргән өчен сиңа миннән йөз төлке. Калым турында аерым сөйләшербез. Быел көз мин сиңа кодалар җибәрермен. Пола, түрә кушканча туганлашырбыз.

— Белмим әле, би,— диде кунак, ялындырасы килеп.— Күңелем бик кырылды. Иң элек кызны табарга кирәк, шуннан сөйләшербез.

— Тапкансың кайгырыр нәрсә, би! — диде Койтым бикә, елмаеп, сүзне үенга борып.— Тотыш угланның качып китүләренә, югалып торуларына без инде күнегеп беткән. Кызыңа да берни булмас. Яшь киекләр кебек туйганчы качып йөрерләр-йөрерләр дә үзләре үк кайтып килерләр.

## XXI

Ана кеше үзен шулай юатса да, качаклар икенче көнне дә, өченче көнне дә кайтмадылар. Ул арада Тотышның югалуы, кунак кызын алып качуы турында бөтен тирә-як белеп өлгерде. Төрле имеш-мимеш китте. Кайберәүләр ачыктан-ачык ачу белдерде; Тотышның мондый кыланышларына түзеп торырга ярамый, диделәр, бер-бер эш кылмыйча, без аннан котыла алмабыз, диделәр. Утташ кам инде сөенеп бетә алмады. Ул тагын да, бер да курыкмыйча, ыру башына, аның качак углына каршы яман сүзләр сөйли башлады.

Кеше арасындагы мондый имеш-мимешләр бинең үзенә дә, аның күчендәге башкаларга да ишетелде. Яшьләр югалуга дүртенче көн булды дигәндә, караңгы төшкәч, борчылып Күрән би үз янына Акбога белән Котанны чакыртып алды.

— Эзләргә кирәк булыр,— диде ул угылларына.— Бүген үк чыгып китегез. Берегез түбән төшәр, икенчегез югары менәр. Үзегез качыргансыз — үзегез табыгыз!

— Аның башбаштак булуында безнең эшебез юк,— диде Котан, йөзен чытып.

Төсе-бите белән дә, холкы белән дә Котан нишләптер Утташ кам ягына тарткан иде. Ул, туган атасының сүзен тыңлауга караганда, ана каршы кешеләрнең сүзенә күбрәк колак сала иде, ахрысы. Тотышны исә ул барысыннан да ныграк яратмый иде.

Ата кеше кызмады, кырыс, усал йөзе белән Котанга бер генә күтәрелеп карады — углан шундук шып булды.

— Кем генә булмасын — ул сезнең туганыгыз,— диде би.— Табыгыз, кайтарыгыз. Тотыш минем ышанычым, Тотыш — Акбүренең ышанычы. Күңелем шулай сизенә, балалар. Өйләнгәч, эшкә җигелгәч, басылыр.

— Боерыгың үтәлер, атай,— диде тиз килешүчән Акбога, атасы алдында баш иеп.— Мин түбән китәрмен. Каекчылар аны агым уңаена китте, диделәр. Балыкчылардан сорашырбыз, яр буендагы авылларда туктарбыз. Ике ишкәк белән әллә кая китә алмаслар.

— Энә түгелләр — табарбыз, атай,— диде Котан да, кирелеген җиңеп.

— Табыгыз, угылларым,— диде ата кеше, күз яшьләрен күрсәтмәскә тырышып.— Тәңренең каргышы болар барысы да. Минем инде күп яшисем дә калмагандыр... күңелем шулай сизенә, балалар. Бер генә углымның да юлдан язуын теләмим. Үзем исән чакта мин аны ипкә кертергә тиешмен. Унар каекка унар кеше алыгыз да көн-төн юлда булыгыз. Кайтканда якты күздә кайтмагыз катауга, кеше шаулаша, ул-бу була күрмәсен.

Ыру башының сүзләре чынга чыкты. Икенче көнне үк урда капкасы

алдына шаулашып кешеләр жыела башлады. Алар эчкә, би янына керергә теләделәр, янадылар, кычкырдылар. Сакчылар, билгеле, беркемне дә кертмәделәр — тимер күгәнле имән капкаларны шундук эчтән бикләп куйдылар.

Атлылар, җәяүлеләр капка алдына килә тордылар. Шау-шу көчәйгәннән-көчәя барды. Акколакка атланып, Күрән би капка янына килде. Шаулашкан кешеләр арасында ул еракган ук Утташ камны күреп алды. «Үләксә козгыны! Кан исен әллә каян сизгән», дип уйлады ул кам турында.

— Сөекле туганым, бабам, син тагын коткы таратасыңмыни? — дип кычкырды би капка аша Утташ камга.— Ни булды, сөйлә.

— Монда чык, монда, кияү! — дип кычкырды Утташ кам, чәрелдәп, кулын бутап.

— Анда чыксам, мин синең тиле башыңны чабып кулыңа тоттырырмын! — диде Күрән би.— Синең коткы таратып йөрүеңне бөтен ыру белә — тагын ни уйлап таптың?

— Угры углың кая? Күрсәт углыңны? — дип кычкырды Утташ кам капка аша.

— Таралыгыз тизрәк! Күземә күренмәгез! — дип кычкырды би, ярсып.

Ул шундый каты кычкырды,— шаулашкан кешеләр чыннан да тынып калдылар, шүрли төштеләр. Бары Утташ кам гына, үз иярченнәрен өстерәп, туктаусыз чәрелдәвендә булды.

— Синең белексез Тотышың аркасында илдән тынычлык китте, җирдә чир-чор күбәйде, явыз ияләр азынды. Кичәгенәк балтачы Кылтимернең кызыл сыеры ярдан таеп аягын имгәткән; күнче Туктамышның ише икенче көн инде бала табалмый интегә; бүген таңда Котлыгыш аксакал үпкә чиреннән үлде; үзән төбендә эреп бетмәгән кар ята; әле булса яңгыр яумый... саный китсәң, тәлим яман эшләр тулып ята. Барысы да синең Тотышың аркасында!

— Барысы да синең коткың аркасында, Утташ кам! — дип кычкырды Күрән би, Утташ камның үзеннән дә яманрак итеп.— Килешәм: минем Тотыш углым усал, кыю... башсызлыгы да бар. Аның кебек чакта кем генә шулай булмаган! Күпме генә тинтәк, башсыз булмасын, шулай да балтачы Кылтимернең сыерын ярдан ул төртеп төшермәгәндер, күнче Туктамыш хатынының баласын да тумаска дип ул котыртмагандыр...

Төркем арасында, жылы җил булып, тыелып кына көлешү ишетелеп китте. Күрән бинең тавышы ышанычлырак яңгырый башлады.

— ...Котлыгыш аксакалның үпкә чире белән чирләвен кем белми! — диде ул, өзелгән сүзен ялгап.— Үлгән икән — урыны оҗмахта булсын! Яхшы, тыйнак кеше иде. Син, Утташ кам, аны да минем углым Тотыш үтергән, димәкче буласыңмы?

— Мин алай дип әйтмәдем! — дип кычкырды Утташ кам.

— Әнә, сүзеңнән тана да башладың! — диде Күрән би, җиңүче тәс белән.— Җирдә чыннан да яман эшләр тулып ята. Изге келәүдә буласы урында, изге эшләр белән мавыгасы урында, син, Утташ кам, юк-барны чокчып, ыру котыртып йөрисең. Чир-чорны бетерү, албасты-өрәкләрне качыру синең эш. Җирдә явызлык күп икән, димәк, син келәмисең, үз эшеңне тиешенчә башкармыйсың. Бер-ике көннән сабанга төшәргә кирәк, орлыкларны, коралны барларга кирәк — чураларны син эшләреннән аерасың, кешеләрнең тынычлыгын бозасың. Син языклы барысына да, Утташ кам!

— Чын шул!

— Би белеп сөйли! — диештеләр төркемдәгеләр, ачулы мыгырданып.

Кайберәүләр, исән-имин чакта китеп котылырга кирәк, диган сыман, шундук тарталарен кире бордылар. Утташ кам, бирешәсе килмичә, төкерекләрен чәчте, кулларын бутады. Шулай да инде төркемдәгеләр

аның сүзенә колак салмадылар. Тотышның кыланышларын да, Утташ камның ни өчен бигә ачулы икәнлеген дә алар чыннан да яхшы беләләр иде. Шуңа күрә, Утташ кам инде аларны тиешенчә кыздыра, ярсыта алмады. Әллә урлаган Тотыш кунак кызын, әллә урламаган — кем белә аны!..

Тора-бара кешеләр монда ни өчен килүләрен дә аңламый башладылар, Тотышны да исләреннән чыгардылар. Бөтен кызык би белән Утташ камның әйтешүенә кайтып калды. Үз тирәсендә кешеләр сирәгәйгәч, Утташ кам да тизрәк сыпыруны яхшы тапты. Би кешеләре аның артыннан көлеп, таш, балчык бәреп калдылар.

## XXII

Көн артыннан көн үтте, төн артыннан төн үтте — качакларны эзләргә киткән Котан белән Акбогадан бернинди яңалык ишетелмәде. Ул арада сабанга төшәр көн дә килеп җитте. Билгеләнгән көнне, кояш чыгу белән, игенчеләр үгезләрен, атларын җиктеләр, арбаларга сабан-тырмаларын, орлыкларын төяделәр дә басу-капка аша яланга агыла башладылар.

Язгы сабанда бөтен ыру, бөтен катау катнашты. Койма, капка сакчыларыннан кала, барлык ирләр, хатын-кызлар, бала-чагалар кырга чыктылар. Бераүләр җирне сөрә барды, икенчеләре арттан тырмалады. Өченче бераүләр, иңбашларына тубаллар асып, шунда ук чәчә бардылар. Басу белән катау арасында — зур юлда, сөрелгән җир буйларында, әрәмә башларында, яшел чирәмле үйдыкларда ыгы-зыгы, уен-көлке аз гына да тукталып тормады. Әле анда, әле монда күккә зәңгәр төтеннәр күтәрелде — пешекчеләр сабанчыларга ашарга пешерделәр, бала-чагалар иске салам, чүп-чар яктылар. Ераграк басулардан кешеләр кунарга өйләренә кайтмадылар — ак чатырлар корып, төне-көне шунда яттылар. Каралар гына түгел, би дә бөтен күче белән, туганнары, кунаклары белән бөтен көнен кырда-басуда үткәрде. Иген игү иң изге эшләрдән санала иде, шуңа күрә үз аягы белән йөри алган барлык кеше ничек тә язгы сабанга катнашырга тиеш иде. Үз аяклары белән йөри алмаганнар исә, борынгы ышану буенча, иске җирнең ертылуын, яңа җиргә орлык төшүен булса да үз күзләре белән күреп калырга тырышалар иде. Шунлыктан, бу көннәрдә басуда бөкшәеп беткән карт-корыларны да, моңарчы түшәгеннән башын калкыта алмаган каты авыруларны да күрергә була иде.

Шундый көннәрнең берсендә, кич караңгы төшкәч, Кызыл Яр катау турысына, ташлы ярга бер көймә килеп туктады. Көймәдән ике карачкы төште. Тавыш-тынсыз гына кыланып алар көймәләрен яр читенә тартып чыгардылар да, вак чуер ташларга сак кына басып, текә баскычка таба атладылар. Сабан көннәре булганга, яр буенда балыкчылар да, сакчылар да юк иде. Баскычның аскы башында да шулай ук бернинди сак күренми иде.

Көймәдән төшкән кешеләр, бер-берсенә тотынышып, текә баскыч буенча әкрен генә югары күтәрелделәр. Тиздән алар баскычның иң югары басмасына менеп җиттеләр, биек баганалар өстенә салынган, берни белән тоташмаган озынча күпер кырыенда туктап калдылар. Аларның артында, аста, бик тирәндә, төн карасында тагын да куркынычрак булып тоелган яр кырыенда беленер-беленмәс кенә кара су елкылдап ята. Аларның каршысында — очлы сырганнарын күккә сузып, биек кара койма калкып утыра. Аларның аяк астында, күпер янында, тирән бушлык барлыгы сизелә. Бар яктан да аларны төпсез упкын чолгап алган иде.

— Кайтып житүен життек — өйгә ничек керергә? — диде Тотыш, күпер кырыеннан артка чигенеп.

— Төнне шушында гына уздырыйк. Иртәгә ни булса да булыр,— диде Тәнкә.

— Ни булса да булыр дип көтеп ятсаң, булыр! — диде Тотыш.

Нишләргә дә белмичә, ул, Тәнкә белән кочаклашып, күпер кырыенда шактый озак басып торды. Ничек керергә катауга, ничек анасы, атасы янына барып житәргә? — аның күңелен уткер борау булып менә шундый сорау тынычсызлый иде. Кайтканда бу турыда ул артык борчылмады, кайтып житсәм, ничек тә жаен табармын әле, диде. Күпер баганасы буенча шуышып аска төшәргә, аннары шома яр битеннән үрмәләп өскә менәргә булыр иде — кызгылт ком-ташларда аның үзенә генә билгеле ярыклар, чокырчыклар бар иде. Тик аннан коймага ничек үрмәләп менәргә дә сакчыларга күренмичә генә ничек теге якка чыгарга? Үзе генә булса ул, билгеле, аптырап тормас иде. Икәү булгач, ул үзен тышаулаган кебек тойды.

Алар шулай аптырабрак торганда, капка турысында чыгырлар шыгырдаган тавышлар ишетелде. Шул ук мәлдә караңгы коймадан, тере булып, киң кара нәрсә аерылды. Күпер төшерәләр түгелме соң?! Каян сизгәннәр? Күреп торалар микәнни?

Тотыш Тәңкәне кысып тотты да артка чигенде, баскыч буенча ашыгып аска төшә башлады. Тик ике-өч басма төшкәч дә ул туктап калды. Ник кача соң әле ул? Кая кача? Өенә кайтып житкән икән, ни булса да барыбер керергә кирәк түгелмени?

Асылмалы күпер, көчсез генә дөпелдәгән тавыш чыгарып, баганалар өстенә төште. Качаклар янадан өскә менделәр, куркып-калтыранып, күпергә керделәр, бер-берсенә нык тотынып, упкын аша караңгы капкага таба атладылар.

Ярым ачык капка төбендә аларны сакчы туктатты.

— Тотыш, сезме? — диде ул әкрен генә, эчке бер сагаю белән.

— Мамыш! — диде качак егет, куанып.— Син күзәтеп тордыңмыни? Бай бул, Мамыш! Изгелегеңне мәңге онытмам!

— Мин генә түгел, бөтен яр-капка сезне күзәтеп торды,— диде Мамыш.— Бинең боерыгы шундый.

— Ачулымы миңа атай? — диде Тотыш.

— Юк,— диде Мамыш.

Тотышның кинәт өстеннән тау-таш ишелеп төшкәндәй булды. Күңелендә калыккан куаныч тойгысыннан, атасын-анасын кызгану тойгысыннан аның аяк буыннары йомшап калды. Ах, күпме кайгы-борчу салды ул аларга! Моннан соң инде беркайчан да ул аларның сүзеннән чыкмас, моннан соң инде ул аларның иң күндәм, иң игелекле угыллары булыр! Аны бары кичерсеннәр генә дә Тәңкәне алуына каршы гына килмәсеннәр.

— Бар, тизрәк йөгер, сөенче алырсың! — диде ул Мамышка.

— Сөенче — уртак! — диде аларны тыңлап торган икенче бер сакчы.

Алар ашыгыбрак алдан киттеләр, Тәнкә белән житәкләшеп, Тотыш алар артыннан атлады.

Басудан арып-алжып кайткан би каты йокыга талган иде. Аны уятып урыныннан торгыздылар. Шулай ук Койтым бикә белән Ямгырчы бине дә йокыларыннан уяттылар.

— Үзләре кайтыр дип әйттемме! — диде Койтым бикә, куанычыннан нишләргә белмичә.

— Мин дә кайтмаслар димәдем,— диде Ямгырчы би коры гына.

Әйе, кайттылар. Үзләре кайттылар. Әнә икәүләшеп аталары алдында тезләнеп торалар. Бераз гына ябыгып калганнар, бераз гына үсеп киткәндәй, үзгәргәндәй булганнар. Тотышның иңбашлары, кыска тунына сыймыйча, тертелеп тора сыман. Муены нечкәргәндәй булган, чәчләре үскән,— күзенә, мангаена төшеп тора. Тәнкә тартылган, сулыккан; күз төпләре зураеп калган.

Кайттылар... Алар Биар ханына тикле барып җитә алмадылар. Катаудан ике көн ераклыктагы балыкчы Карынчык өендә тукталып калдылар. Карынчык аларга Биар ханында болгарларга каршы яу чыгу кайгысы юклыгын әйтте. Быел тагын боз тиңгезе ягыннан аларга каеклы юлбасарлар төшкән. Көчләре артык күп булмаган, биарлар аларны бик тиз җиңә алганнар. Шулай да юлбасарлар Биар иленә шактый күп талау китергәннәр. Карынчык әйтте, анда йөреп юлыгыз уңмас, диде, Биарның Алмыш ханда эше юк, ул сиңа берни бирмәс, диде. Аннары өстәп куйды: теләгәнчә үземдә кунак булыгыз — би углына кайда да урын табылыр, диде.

Тотыш Карынчыкның сүзен тыңларга булды. Яр буенда, урман эчендә балыкчы аларга ялгыз тирмә корып бирде, көн дә аларны яңа тотылган балык, яңа суелган ит белән, сычук белән сыйлады. Тотыш Таңкә белән бергә тора башлагач, үзенең барлык кайгыларын, барлык үпкәләрен онытты. Чынында аның инде үзенең дә беркая яу белән дә чыгасы килмәде, кемнәндер, ни өчендер үч тә аласы килмәде. Таңкә белән икәүдән-икәү генә ул шул ялгыз тирмәдә, гүзәл Чулман буенда мәңге торып калуга да каршы килмәс иде. Тик аларга анда мәңге торып калырга туры килмәде. Аларны эзләп, көтмәгәндә атасының кешеләре килеп җитте. Ярый әле: балыкчы аларны алдап җибәрде: күрмәдем, белмәдем, монда беркем булмады, диде. Эзләүчеләр киткәч исә Карынчык качакларга әйтте: без капчыкта ятмый, болай булгач сезне барыбер табарлар, диде. Мине кызганыгыз, углан, диде, катауга кайтып китсәгез, иң яхшысы шул булыр, диде.

Менә алар кайттылар...

— Атам, анам, мин ир булдым,— диде ул, идәннән күзен алмыйча.— Моңарчы мин бала булганмын. Барысы өчен дә кичерегез мине! Кичер мине, Ямгырчы би! Миңа аерым өй салып бир, эш бир, атам. Минем дә башкалар кебек яшисем килә.

— Ата-ана өеннән качып китеп ир булмыйлар,— диде Күрән би, шактый тынлыктан соң, нык берекккән иреннәрен бер-берсеннән көчкә аерып.— Таңре каршында, түрә каршында син ир түгел, син — угры, син...

Яшь егет калтыранып китте, иңбашлары салынып төште, күз карашы томаланып калды.

— Угрылык өчен сезнең аяк-кулларыгызны чабып өзәчәкләр...

— Атай! — диде Тотыш, коты алынып.— Языклы мин! Ярлыкагыз мине, атам, анам!

— Чабып өзәчәкләр! — диде ата кеше, кабатлап, караңгы йөз белән.— Сезнең әллә икешәр башыгыз, дүртәр аяк-кулыгыз бармы?

Моңарчы бер сүз әйтми читтә басып торган Ямгырчы би телгә килде.

— Мин кызымның аяк-куллары агач башында асылынып торуын теләмим. Таң атканчы мин кузгалып китәргә тиешмен. Капканны ачарга боерык бирүеңне үтенәм, би,— диде ул.

— Мине ирем белән бергә ассыннар! Мин беркая китмим! — диде Таңкә, Тотышка сыенып.

Ямгырчы би усал гына көлеп куйды.

— Мин үз сүземне әйттем,— диде ул, Акбүре ыруының башына карап.— Үз углыңны син теләсә нишләтә аласың. Кызымны мин калдырмаячакмын.

Таңкә кинәт чыркылдап җибәрде, тынсыз калган, күңеле сынган иренең авыр башын күкрәгенә кысып, тыела алмыйча, кычкырып җыларга тотынды.

— Бирмим! Бирмим! Асыгыз... мине дә асыгыз! Минем дә үләсем килә! — диде ул, такмаклап.

*(Дәвамы бар.)*

## Әнвәр Давыдов

# Иптәш секретарь

Маруся, Маруся,
Онытмам сине!
Чәчәкләп чигелгән
Блузкаң җине.

Синең истәлегең
Мәңгегә китәр,
Беренче остазым,
Иптәш секретарь!

Чаткыланып караган
Кара күзләрең,
Бүлмәне яктырткан
Утлы сүзләрең:

— Иптәш, мә сиңа,
Изге бу билет.
Күрәмен, күзеңдә
Балкый зур өмет.

Тик бел син, алда бар
Йокысыз төннәр,
Чокырлы юллар һәм
Төтенле көннәр...

Каты сугышлар да
Булырлар алда,
Бел син, комсомолец —
Алгы сафларда!

Матур сүз өчен ул
Түгел комсомол,
Батырлар данында
Туган семья ул.

Мин үттем күп юллар,
Сугыш кырларын,
Бик якын ишеттем
Үлем җырларын.

Атака алдыннан
Кайнар ант биреп,
Кулыма алдым мин
Кызыл партбилет.

Тик синең истәлегең
Мәңгегә китәр,
Беренче остазым,
Иптәш секретарь.

Чәчәкләп чигелгән
Блузкаң җине.
Маруся, Маруся,
Онытмам сине.

1945

●

Бик борчылган чак була.
Тормыш юллары бит тигезсез.
Нинди үтерү хак була?
Нинди ачу була нигезсез?
Тормышымның ерак танында
булган бер вакыйга алдында
әле дә мин торам аптырап.
Законмы хак, хәтеремме хаклырак?
Утызынчы еллар. Авыл казаны кайный,
өстә җыелышлар күбеге,
аста сыйнфый ачу уты.

Җырлар сайлый-сайлый
без — пионерлар — урамнардан үтәбез,
кулакларны котыртып.
Бөек бәйрәм көне иде,
кырпак карлар иде урамда.
Без уенга бирелдек
күзгә беренче мамык буранда.
Кинәт якында гына
нидер гөрселдәде, шартлады.
Дустым пионер Марат
агарынып алга атлады
һәм егылды, шунда кырпак карга
җәелеп сеңә-сеңә акты кан...
Ни булганын без балалар
аңладык тик актыктан.
Бәйрәм җыры урынына «Матәм» җырлап,
Күмдек аны...
Бездә һәркемдә
үтерүчегә шундый ачу,
без Зимныйны алырга баручылардай
ачу белән бардык хөкемгә.
Әйе, ул бик нык кеше күренә иде,
һич каушау юк,
имеш, ул кызгана:
имеш, ялгыш кулы таеп киткән,
йортта ау мылтыгы чистартканда.
Аңа утлы корал белән
саксыз кыланган өчен
алты айны шунда
төрмә диде хөкем.
Ә безнең дус Маратны
салкын гүргә
хөкем иткән иде бит ул мәңгегә.
Эх, кайнады ачу, эх, кайнады,
без елаштык, кычкырыштык.
Аңлаттылар — закон шулай куша,
бу бит үтерү түгел, бу ялгышлык.
Әле һаман минем аптыраган чак була.
Тормыш юллары, ай, тигезсез.
Нинди үтерү хак була?
Нинди ачу була нигезсез?

1967

●

Совет халкым син нинди даһи,
нинди даһи син! Һәм... Нинди гади!
Патшалыкны җирдән себердең син,
искелекне бәрдең, җимердең син.
Ямау сала-сала күлмәгенә,
читән илен металл илләренә
әвереледерден.
Кара болыт кебек,
бар дөньяга кара дәһшәт китереп,
чыккач җиргә фашист ордалары,
нинди батыр каршы тора алды?

Тик син генә,
халкым — халык-даһи.
Нинди даһи син һәм... нинди гади!
Һәркем өчен ачык синең күңелең,
әзер дуслык кулың, әзер түрең
ачык ният белән килүчегә,
үз шатлыгын ачык бүлүчегә,
ә бер афәт, бәла кичерүчегә,
зур кайгысын әйтеп килүчегә
һәр мохтаҗга әзер ярдәм кулың!
Тик кисмәсең инде дошман юлың!
Белсен бу дөньяда, җирдә юк һич
сине юлдан кире борырлык көч.
Якты киләчәккә карап яну
бирә күңеленә зур ышану.
Максатына кыю син барасың,
сайламыйсың җиңел юл арасын.
Хәзер инде ул көн ерак түгел,
кояшыннан нурлар ала күзең.
Аны эзләп талмый күз карашы:
бүгенге иртә — ул зур көннең башы!
Совет халкым! Даһи син һәм гади,
Даһига күрә гади, гадигә күрә даһи!

1962

●

Без бу урамнарны
Икәү үткән идек.
Күпме хыялларны
Урап сүткән идек.

И син, ялгыз талым,
Моңсусың нигәдер,
Мин дә ялгыз калдым,
Мин дә моңсу хәзер.

Туа моңсуланып
Минем яшьлек иртәм.
Еракларда егылып
Калды минем иркәм.

1939—1945.

●

Мәхәббәтнең тәмуг газапларын
Кем күбрәк миннән татыган?
Йөрәгемнең ал кан тамчылары
Эземә тамып килде артымнан.

Әллә хәзер бөтенесен онытып,
Посаргамы тынрак почмакка?
Юк шул. Әле дә ташланырга әзер
Йөрәк янып торган учакка.

Ут күрдеме, шунда омтыла ул.
Ә белә бит янып бетәсен.
Там син, тамчы каным, ян син, йөрәк.
Шул бит тормыш! Нихәл итәсең.

1959

●

Уздылар байтак гомерләр...
Аш ашап, тамак кырып,
Карасаң узган юлыңа,
Бик тыныч була торып:

Кеше күк эшләп йөрелгән,
Аз түгел язган шигырь.
Көннәрдән елларны эрләп,
Әйләнеп торган чыгыр.

Тик күңел тынмый һаман да,
Юк канәгатьлек аңа —
Салкын сүзләргә сыймаган
Ялкыннар анда яна.

1962

●

Бу дөньяның чиксезлеген беләсезме?
Күпме анда хәрәкәт бар, күрәсезме?
Шатлык, кайгы, үлү, туу, газаплану
Һәм кояшлы көндә күңел канатлану,
Сөю, көнләү, ышану һәм өмет өзелү,
Зәңгәр күктә болыт куерып яшен сызылу...
Шагыйрь сыйдыра йөрәгенә мең дөньяны.
Шуңа, дуслар, гаепләмәгез сез аны
Алмаштырса шатлык җырын кайгы моңы,
Уйламагыз, шагыйрьнең дип тайпылуы,
Ничек юлдан тайпылсын ди ул дөньяда,
Дөнья үзе булгач аның йөрәгендә?!

1957

●

Бөтен язган җырларымны
Килә утка саласым.
Яндырсын ут китапларның
Кәгазен һәм карасын:
Калса шунда берничә җыр
Кыздырган корыч кебек,
Дошманнар тигәч алардан
Чигенсә пешеп-көеп,
Ә дуслар кылыч койсалар
Алдагы көрәш өчен,
Яки кыл итеп куйсалар —
Көйләргә бәйрәм хисен,
Шунда гына җырларымнан
Канәгатьлек аласым...
Хәзергә минем аларны
Килә утка саласым.

1966

**Вакыйф Нуруллин**

# КҮПЕР ЧЫККАНДА

ПОВЕСТЬ[1]

## 14



Тәки үзенекен итте Галим абзый. Икенче көнне төш авышуга ук, ит төяп килеп җитте. Ит исен сизгәч, печәнчеләрнең ничек куанышканын күрсәң иде син, туган! Ура кычкырып, һавага чөя-чөя, кочаклап үбә-үбә рәхмәт укыдылар үзенә. Әле кичә генә үләр чиккә җитеп авырып кайтып китүе турында бөтенләй искә алучы да булмады. Бары тик кичен, ит ашап кикереп куйганнан соң, чая телле Маһисәрвәр апа гына, кинәт бик зур ачыш ясаган кешедәй итеп:

— Бу ничек болай булды соң әле, Галим, пәрәми: син кичә бик борсаланып, больнискә барам дип кайтып киткән иең ләбаса, безгә ит китерәселәрен сизгәч, эчең төзәлде дәмени? — дип сорап куйды. Әмма Әйтсә эшли бу юлы да югалып калмады:

— Сиңа көлке, тишек борын! — диде ул, бик җитди итеп.— Сиңа кызык. Ә Галим кордашың чүт кенә теге дөньяга китми калды кичә. Клизма ясап, эчне юдыртып чыгармасалар — беткән буласы икән баш. Врач әйтә: тагын биш минут соңга калсаң, бу якты дөнья белән хушлашасы икәнсең, абзыкаем, запур булган сиңа, эчәкләрең шартлыйсы булган тагын биш минуттан, ди. Ярый әле, кайтышлый ук район больнисенә кагылырга башым җитте. Сразы рәхәтләнеп киттем шуннан ары. Кеше печән чапканда ничек итеп сәламәт башым белән өйдә ятыйм ди инде мин? Килдем менә... Ә син авыз җырып көлгән буласың тагы!

Маһисәрвәр апа:

— Әйттем исә кайттым, Галим кордаш, ачуланма, мин алай ук булганын белмәдем бит! Үземнең миңгерәү башым белән, әллә хатынын бик сагынган да, шуңа авыруга салышып кайтып килде микән дип

---

[1] Ахыры. Башы 7 санда.

уйлаганыем,— дигәч, барысы да рәхәтләнеп бер көлешеп алдылар да шунын белән бетте.

Табын яныннан купкач, Галим абзый мине култыклап алды да:

— Әйдәле, Өлфәт, идарәдән әйтеп җибәргән амәнәтләрне тапшырасым бар сиңа,— дип Кама буена алып китте. Икебез дә яр буена утырышкач, түбәтәен кыңгыр салды да, хәйләкәр елмаеп:

— Син миңа ачуланма инде, прсидәтел,— диде.— И бернәрсәдән дә хафаланма. Бөтенесен наять итеп, ничек әйткән — шулай эшләдем. Кичтән бажайга барып, көтүне иртәнге эңгер-меңгердә үк алып чыгарга куштым. Ә үзем, әйбәт кенә бер кусәк белән нык кына бау алып, таң тишегеннән купер төбенә барып утырдым. Көтү куперга килеп керүгә йомылып кына сикереп чыктым да матур гына бер чуар тананы мөгезеннән ялт — эләктереп тә алдым! Ә көтү үтеп киткәч, прәме купер өстендә бәйләп җыктым да суйдым үзен. Бичара тана җан биргәч кенә теге кусәк белән аягын сындырдым да, бажайга көтүен шул тирәдәрәк тотып торырга кушып, авылга барып заффирмы Рәдиф белән завхузны алып килдем. Аннары прәме шунда купер өстендә тунадык та ит булды менә. Рәдиф раюн сталаваена илтеп тапшырыйк дип маташканые маташуын, ну мин авыз да ачтырмадым тегеңә.

— Шушындый алла үзе китереп тоттырган нигъмәтне анда илтәләрме соң инде, Рәдиф энем! Ит ашамыйча печән чапкан кешеләрне кайда күргәнең бар? Печәнчеләргә алып барабыз и бетте-китте! — дигәч, артык карыша алмады. Карышырые да, миннән өркә ул. Прсидәтел булган чагындагы махинатсияләрен байтак беләм мин аның. Шуңа исәпләшә ул минем белән. Ә запур булган диюем болай гына анысы. Пычак булсынмыни миңа? Бүлнискә кагылуым хак. Теге безгә азык китергән кыз шикләнмәсен дип кереп чыктым мин анда. Брачка да, чуртка да күрсәтеп тормадым. Ишек төпләрендәге эскәмиядә биш-ун минут утырдым да чыктым. Менә шулай, энем Өлфәт, әйтсәм — эшлим инде мин!

Нишләтәсең инде аны? Вакытында тыеп кала алмагач, хәзер сүз озайтып торуның файдасы юк иде.

— Ярый, Галим абзый, булган — беткән инде. Ләкин бүтән вакытта мондый эшең кабатланса, яхшылык көтмә! — дию белән генә чикләндем.

Ә тана ите ярап куйды! Бөтенләй бүтәнчә эшли башлады печәнчеләр. «Коры» аш ашаган көннәрдә, кайбер печәнчеләрнең покосны я бик тар алып, яисә, күрер күзгә киң алып та, астын чи калдырып чабуларына эчем пошып, кисәтү ясагач:

— Теләсә ни әйт, прсидәтел, әмма үтерсәң дә шушыннан әйбәтрәк итеп чаба алмыйм! — дип әрепләшүчеләр дә бетте, эчем йомшады дип, атлаган саен тал арасына йөгерүчеләр дә күренми башлады.

Бәхеткә каршы, көннәр бик матур торды. Чапкан чакта яугалап китеп шиккә салса да, печәнне җыйган көннәрдә ник бер генә янгыр төшеп карасын. Тотынуыбызга унтугызынчы көн дигәндә төшке ашка соңгы богылны коеп кайттык. Шул ук көнне авылга кайтып китәрбез дип тә ниятләп тора идем, ләкин әлеге шул Әйтсә эшли Галим абзый:

— Син алай борчак урынына куырма инде, энем Өлфәт! Адәм баласына гел эшләп кенә торырга димәгән, вакыты белән әз генә булса да ял да кирәк ана! Давай, ашыкмыйк алай. Хатын-кызлар Иделдә бер рәхәтләнеп өс-башларын юсыннар, без, ирләр, сакал-мыекларыбызны кырыйк. Керле кием белән кайту килешми, безнең татар андыйны яратмый ул! — дигәч, башкалар да аның фикерен куәтләгәч, каршы килмәдем.

Шулай да күңелем тыныч булмады ул көнне. Су да коенып карадым. Җәйрәп тын гына агып яткан Кама суларының матурлыгына сокланып, әледән-әле чалт та чолт сикергәләп куйган балыкларны күзәтә-

күзәтә әллә кайлардан урап та кайттым. Тик барыбер нидер җитми, нигәдер эчем поша. Хәтта җәяүләп үзем генә кайтып китимме әллә дип тә уйлаган идем. Әмма, председатель паром мәшәкатьләреннән куркып, безне ташлап кайтып китте дип үпкәләрләр дип, ул уемнан кире түндем. Ә тәвәккәлләп кайтып китсәм,— бик шәп буласы икән, туган! Их, әйбәт буласы икән кайтып китсәм!..

Галим абзый сүзендә торды. Көндез үк безнең болыннан ерак булмаган землянкада яшәүче маякчы карттан зур гына көймә алып килеп куйды да кичке аштан соң (ул көнне кичке ашны да гадәттәгедән иртәрәк әзерләгәннәр иде) теләгән печәнчеләрне төяп, Камада йөздереп, җырлатып йөртте. Тавышы әллә ни моңлы булмаса да, үзе дә кушылып җырлады. Аларның җыры бөтен кич буе су өстен тутырып, әллә кайларга яңгырап торды.

Ни кыстап карасалар да, мин алар белән бармадым. Күңелем әллә нишләп боек иде. Акылым белән бик тыныч булырга тырышам. Нигә болай ашкынасың, нигә моңланасың күңел дип, үземне-үзем орышып та карыйм. Юк, булмагач — булмый инде!

Нәрсә турында уйлый башласам да, уйларым шул Сәкинәгә, улым Ирекка барып тоташа. Гел Сәкинәм күз алдыма килә. Ул — кыз, мин — егет чакта сирәк-мирәк кенә күрешүләрне, сабан туйларында урманда чәчәк, җиләк җыеп йөрүләрне исәпкә алмаганда, җәмгысе атна-ун көн генә торып калдым бит мин аның белән. Ай күрде — кояш алды гына булды. Ә онытып булмый менә! Һаман шулай мине сугышка озаткандагыча чибәр булып, тыйнак, мөлаем һәм сабыр булып каршыма килә дә баса. Күзне йомудан мәгънә юк. Маңгай күземнән тыш, адәм баласының күңел күзе дә бар бит әле. Аны берничек йомып та, каплап та булмый! Өстенә яшел сатин күлмәген, аягына зәңгәр брезент туфлиен кигән, башына зәңгәр җирлеккә ак бизәк төшерелгән ефәк косынкасын бәйләгән дә, эх, Өлфәт, нишләдең син, мин сине шуның өчен сөйгән идеммени дип, шомырт кара күзләрен текәп, тилмереп каршымда тора да тора...

Көндез, эш белән мәшгуль чакларда, ул кадәр читен түгел әле. Ә менә буш вакытларда, бигрәк тә кичләрен йокларга яткач!.. Әйтепсөйләп кенә анлата торган түгел инде ул сагышны... Шул ук вакытта Янтыкка барып, сөйләшеп-аңлашып карарга да көчем җитми, үҗәтлегем ирек бирми. Хафиз карт сүзләре исемә төшә дә йөрәгем тагын жу итеп китә.

Ә Галим абзый әйтә, ашыкмадың микән, энекәем, Сәкинәннең бер дә андый-мондый кырын эше сизелгән шикелле түгелие, алай-болай булса, авыл җирендә андый нәрсә сизелми калмый торгание ул, ди. Бүтәннәр сизмәсә дә мин абайламый калырга тиеш түгелием, мин белмәгән нәрсә юк безнең авылда. Ну мин бер дә андый-мондый хәлен сизмәдем Сәкинәннең. Хафиз, карт шайтан, ялганнарга да мужыт ул, ди... Аптырадым инде. Кемнәргә, кайсына ышанырга да белгән хәл юк...

Мин яр буенда шулай уйланып-өзгәләнеп утырган вакытта, кинәт безнең печәнчеләрнең шалашлары тирәсендә шау-шу башланды. Нигә болай ду куптылар икән, әллә берәрсенең шалашына елан-фәлән керде микән дип, яннарына йөгереп барсам, кайберләре күз яше белән еларга ук тотынган.

— Ни булды, иптәшләр, нигә болай дөнья шаулатасыз?

Гадәттәгечә, бу юлы да Мәһисәрвәр апа чәчрәп чыкты.

— Нигә буламени, пәрәми! Күрмисеңме әллә, яна бит! — диде ул, күктәге кызыл яктылыкны күрсәтеп.

— Шәфәкъ балкышы түгелме соң, Сәрвәр апа? — дидем мин, әле һаман үз уйларымнан арынып җитә алмыйча.

— Бу кадәр дә сантый булырсың икән, Өлфәт энем! Нинди шәфәкъ яктысы булсын ди ул сиңа? Шәфәкъ шул якта була димени? Кояш баешында була бит ул шәфәкъ. Ә бу ут кыйбла ягында лабаса!

Йөрәгем дерт итеп китте. Яктылык, чыннан да, кыйбла ягында, ераклыгы да шул безнең авыл тирәсендәрәк иде! Әгәр ут шунда булса— харап! Янгын сүндерердәй кеше юк анда хәзер. Буйдан-буйга өтеп чыгачак ул ут авылны. Җиле алай зыянлы түгел түгелен. Ләкин ут үзе җил чыгара бит ул! Җитмәсә, өнәре дә бик эссе торды бу арада. Суыбыз да ерак!..

— Җә инде, әйт ичмаса берәр сүз, нигә өннән чыгып калдың! Болай карап торып булмый ич! — диде Сәрвәр апа, утка баскандай сырпаланып.— Җигик атларны да китик кайтып тизрәк. Бетә бит ату авыл янып! Сүндерер кеше юк бит анда!

— Ничек кайтып китәсең ди? Төнлә паром эшләми, Мәһисәрвәр апа! Паромчы өенә, авылларына кайтып куна ич ул!

— Чукынып кына китсен инде, алай булса! Өем янса да җәл түгел, кадалсын анысы. Страхование бар. Андый гына өй салырлык акчасы чыгарые әле. Ну кәҗәм янса — бетте инде баш! Кәҗәм кәҗә ише генә түгел, сыерына алыштыргысызые, билләһи. Кәшифәм кәҗәмне генә чыгарып калса ярарые, ходаем-бер аллам! Булмас, чыгара алмас ул йокы чүлмәге! Итәгенә ут капканчы гыр-гыр йоклар да, итәге яна башлагач чыгып чабар, тавык мие капкан нәрсә! Кемгә ошап шулай ваемсыз булгандыр инде! Бер дә кыз балага ошамаган бит!.. Ичмаса, йөзә белмим. Йөзә белсәм, ике дә уйламасыем: Идел тармагын йөзеп чыгарыем да кайтып китәрием!

Әйбәтрәк өйле, сыерлы-сарыклы кешеләр, кайгырышсалар да, артык аһ ормыйча гына торганда Мәһисәрвәр апаның шушылай үрле-кырлы сикеренүе, бер караганда, шактый мәзәк тоела иде, әлбәттә. Тик аңар да ачуланып булмый шул. Күз карасы кебек бердәнбер кәҗәсеннән дә коры калса — нишләр ул? Шулай да паникага юл куярга ярамый иде.

— Ярар, җәмәгать, тынычланыгыз, ул кадәр борчылыр урын юк әле! Син дә алай бик үрсәләнмә, Мәһисәрвәр апа! Моннан торып кына бер эш тә чыгарып булмый. Кызың Кәшифә өйдә ич синең, ул-бу булса, кәҗәгезне чыгармый калмас! Минемчә, ул янгын безнең авылда булырга тиеш түгел. Безнең авыл үндарак, әнә тегендәрәк бит! — дигән булдым мин халыкны да, үземне дә шуңа ышандырырга омтылып.

Бер дә пошынмаган атлы булып, үз шалашыма кереп киттем. Ә үземнең йөрәк менә чыгам, менә ярылам дип, дөп-дөп тибә, өстемә салкын су койгандай, бөтен тәнем калтырый иде. Йоклау түгел, керфек тә какмадым мин ул төнне. Мин генә түгел, башкаларның да күзен йокы алмады: төне буе борчылып, мыдыр-мыдыр сөйләшеп чыктылар.

Таң сызыла башлау белән торып, атларны җиктек, әйберләрне төядек тә кайтырга чыктык.

Кичә тикмәгә генә пошынмаган, юкка гына кайтып китәргә ашкынмаган икән ул! Төнге янгынның безнең авылда булганлыгын паромчы рус картыннан ук ишеттек. Начар хәбәр бик тиз йөри диләр шул, яхшысы гына көттереп килә аның.

Безнең авыл янганын һәм бер генә йортның көле күккә очуын әйтсә дә, кем йорты икәнен белми иде паромчы карт. Анысын, кайтып житәргә унбиш чакрым калгач, Анаташ авылында ишеттек.

— Артык кайгырышмагыз, туганнар, бер генә өй, прсидәтелегезнеке генә янган. Ярый әле өе читтәрәк булган, бүтән йортларны саклап кала алганнар. Ничава, прсидәтел кешенеке булгач, зыянлы түгел, тагын салып керер әле! — дип «юатты» безне шул авылның бер карты.

Без авылга кайтып кергәндә, минем өйнең миче дә кара күмергә әйләнгән баганалары гына утырып калган иде.

Өен нилектән янган, ут кайдан чыккан диярсең инде син, туган. Мин мичәнгә киткәннән бирле ни мичәнә, ни казан астына ягылмаган йорт үзеннән-үзе генә кабынып китмәгәндер, билгеле. Берәрсе миңа үч итеп эшләгән эш икәнлеге көн кебек ачык иде. Ә менә кем эше икәнлеген мин бүгенгә хәтле тәгаен белмим әле. Ихтимал, моннан соң да шулай сер булып калыр инде бу мәсьәлә. Хәер, мин аны ачыкларга тырышмыйм да. Хәзер, инде күп еллар узгач кына түгел, элек, кешедә өйдәш торган чакта да төпченеп йөрмәдем. Гомумән йортсыз калуыма әллә ни зурлап хафаланмадым мин. Өйне аны, теләсәм, шул ук җәйдә салып керергә мөмкин: халык булышачак иде. Бурәнәләрен генә тап, мамиыт салып бирәбез без сиңа өй, дип тә әйтеп карадылар. Ә өй җиткереп чыкканчы безгә кереп тор, дип печәннән кайтып төшкән көнне үк җидесигез кеше үзләре килеп әйтте. Алты почмаклы йортта ирле-хатынлы гына торучылары да бар иде. Әмма мин аларга бармадым. Үзем теләп, дүрт балалы, кечерәк кенә өйле, ире сугышта вафат булып калган Әминә апаларда тора башладым. Ялгызлык куркытты мине. Шуңа Әминә апаларга, шау-шулы өйгә кучтем...

Әйе, йорт салу кайгысы юк иде миндә, туган. Йорты кадалып киткән иде, тик мин печән чабып йөргән көннәрдә Сәкинә Чиләбегә китеп барган булып чыкты. Көткәндер-көткәндер дә, мин бер тапкыр да Янтыкка янәрына барып карамагач, ачуланып чыгып киткәндер, күрәсең. Малайны да алып киткән. Калдырган булса, үземнең яныма алып кайтыр идем дә бер иптәш булыр иде ичмаса. Киткәннәренә дүрт айдан артык гомер узды, ә мин бер генә тапкыр булса да, хәлләрен сорашып кайта белмәдем шул! Минем ишеләрнең шул инде ул: дуамаллык алдан, акыл арттанрак йөри... Хәзер бик сөйләшәсе иде дә — Сәкинә юк!

Мин шулай мең төрле уйларга чумып, аптырап-алҗып йөргәндә райком секретаре Гадел абый килеп төште. Бик кызып урак урган көннәр иде бу. Килеп төшү белән үк машинасына утыртып, ул мине кырга, уракчылар янына алып китте.

Кул белән уручылар да, мангай тирен агызгычыбыз да (лобогрейканы бездә шулай дип йөриләр) әйбәт, чиста уралар иде. Ул яктан минем йөзгә кызыллык килмәде. Уракчылар эшеннән канәгать булып кайтты Гадел абый.

Аннары дәүләткә икмәк тапшыруның ничек барышын сораштырды. Дөресен әйтергә кирәк, ул мәсьәләдә эшләр бик шәптән түгел иде безнең. Районда иң артта ук булмасак та, мактанырлык эш юк иде. Тагын да дөресрәк итеп әйткәндә, ул эшне мин үзем бик ашыктырмый идем. Башта, яңгырлар башланганчы, урып-җыеп калырга кирәк, калганы үз җае белән барыр әле, дип уйлый идем һәм шул фикеремне Гадел абыйга да әйттем. Ләкин ялгыш уйлаганмын икән.

— Миңа синең күпме уруың гына түгел, күпме икмәк тапшыруың да кирәк! — диде ул, шактый кырыс итеп һәм нык кына орышып алды.

Сүз юк, ул да үзенчә хаклы, чөнки беренче җавапны ул бирә.

Әмма мин дә үземчә хаклы идем. Хикмәт шунда, әлеге дә баягы, колхозыбыз кечкенә булганлыктан, үзебезнең автомашинабыз юк, район автоколоннасыннан да машина артмады. Бөтен кырыбыздагы игеннең ашлыгын уру да, сугу да, дәүләткә илтеп тапшыру да гел шул егерме сигез баш ат җилкәсендә. Шуңлыктан сугылган ашлыкны вакытында тапшырып өлгертә алмыйбыз.

Менә шуларны сөйләп биргәч, Гадел абый шушы араларда ук автоколоннадан бер машина җибәртергә вәгъдә бирде. Аннары папиросын кабызып алды да:

— Я, хәзер үз тормышың хакында сөйлә инде? Нишләргә, ничек яшәргә уйлыйсын? Йорт салырга җыенасыңмы? Исәбең булса — сузма. Хәзер үк хастәренә кереш! Без дә мөмкин кадәр ярдәм итәрбез,— диде. Аталарча якын итеп, үз итеп, иңемә кулын куйды.

— Йортны салырга булыр ла аңысы, Гадел Салихович. Колхозчылар да булышабыз дип тора. Ләкин бер хикмәте бар бит аның: салып куйгач тагын яндырмаслармы икән соң?

— Да, сорарга да онытып торам икән: үзең кемнән шикләнәсең? Кем эшедер дип уйлыйсын?

Атап бирәүне дә әйтә алмыйм. Бер дә алай үчләшкән кешем юк иде шикелле.

— Әйдә, йортыңны яндырганнар бит. Димәк, кемгә дә булса ошамагансын.

— Күрәсең, шулайдыр инде.

— Әйдә болай сөйләшик алайса, иптәш Хәкимов: алай күңелең тартмый икән, йорт җиткерергә ашыкма син. Ләкин борыныңны төшермә! Каш ярылып, күз чыкмаган. Дөнья булгач, төрле хәлләр була.

— Яхшы сүзегез өчен рәхмәт, Гадел Салихович!

Инде хушлашып кайтып китәргә җыенгач:

— Ә хатының белән арагыз ничек? Күрешкәнең, сөйләшкәнең бармы? — дип сорады.

— Башта күрергә теләмәдем, үҗәтлегем җиңеп килде. Хәзер сөйләшеп карар идем дә — соң инде: мин болында печән чабып яткан вакытта, малайны ияртеп, читкә — Чиләбегә чыгып киткән.

— Да-а! — диде Гадел абый, борчавым уйланып торгач.— Шәптән түгел икән хәлләрең. Ашыгычлык, дуамаллык харап итә шул сез яшьләрне. Алдын-артын уйлап тормыйсыз, бер кизәнүдә дөньяны җимермәкче буласыз!.. Шулай да уйла әле син, энем, тагын бер кат бик нык-лап уйлап кара! Ахыр чиктә, Чиләбе җәһәннәм астында түгел ул. Телəгән кешегә анда барып кайту берни тормый. Аңысын да хәтереңә алып куй!

## 16

Уйландым мин, бик күп уйландым ул көннәрдә. Ахырында шундый нәтиҗәгә килдем: Сәкинәнең кылларын тарткалап карамыйча, Чиләбегә чыгып китәргә ярамый. Башта хат язарга кирәк. Янтыкка барып, әби күзенә күренеп йөрисем килмәде. Сәкинәнең адресын кеше аркылы гына соратып алдырдым да кичерүен сорап, гафу үтенеп түгел, ә болай гына, улыбыз Ирекнең хәлен сорашып, үзең ничек яшисең, нинди эштә эшлисен, дип кенә хат яздым.

Атна узды, ай үтте — җавап бирмәде бу. Ә минем эч поша. Күңелгә корт керде хәзер. «Менә Өлфәт,— дим үз-үземә,— җавап язарга да теләми хатының. Димәк, кирәгең шул чама гына инде синең! Йөр инде менә хәзер авызыңны ачып!..»

Мин әнә шулай ни эшләргә белмичә, ике күземне дүрт итеп Сәкинәдән хат көтеп йөргән чакта, шул форсаттан файдаланып калырга теләгән кешедәй, теге Гөлүсә дигән укытучы тагын калкып чыкты бит, туган. Шул кызыкай белән тагын бер тапкыр очрашырга туры килде миңа.

Безнең урман — җиләк һәм чикләвек оясы, дип әйткән идем инде мин сиңа. Дөресе шулай аның, туган. Үзебезнең авыл халкы гына түгел, унар-унбишәр километрдагы авыллардан да килеп җыялар безнең урман җимешләрен. Август ахырларында, чикләвекнең иң әйбәт өлгергән чагында, Гөлүсә дә безнең урманга чикләвеккә килгән дә кайтышлый минә чикләвек калдырып китәргә ниятләгән. Мин колхозчыларның кенәгәләренә хезмәт көннәрен утыртып торганда бик батыр кыяфәт белән идарәгә килеп керде бу:

— Кая, фуражкагызны салыгыз әле, Өлфәт абый, иң әйбәтләрен генә, үзегез шикелле сап-сарыларын гына калдырып китим әле шушы чикләвекләрнең. Сезнең өчен дип, боларын баштан ук аеры җыйган идем! — ди.

Шулай диде дә, минем ай-ваема һич карамастан, алдыма ун-унбиш стакан сыешлы бер янчык чикләвек китереп куйды.

— Нигә болай юмартланасыз, Гөлүсә, теге чакта юлда калдырып киткән өченме әллә? — дидем мин, уенын-чынын бергә кушып.

— Ярар инде, Өлфәт абый,— диде ул, колакларына кадәр кызарып.— Ул вакытны искә алмыйк инде! Без хатын-кызларның шулай икәнен беләсездер ич инде, һич тә юкка үпкәләдем мин ул чакта. Ә бу чикләвекне бер дә күпсенмәгез, рәхәтләнеп ашагыз! Сезнең өчен дип җыйдым мин аны. Уф, үләм, тамагым кипте, кая, бер стакан суыгызны эчим әле.

Мин ана су салып бирдем һәм ул авыз очы белән генә, вак-вак йотып кына эчкәндә калкып-калкып киткән күкрәкләренә, ялтыравыклы кара пута белән кысып буган нечкә биленә, нәфис аякларына сокланып карап тордым. Чибәр иде ул, шайтан кызы, бер дә килмәгән җире юк иде. Әллә инде... Шул чак тагын Сәкинәм күз алдыма килеп басты һәм мин үз уйларымнан үзем оялып киттем.

— Суларына хәтле эчеп туйгысыз шушы «Чулпан»ның! — диде ул, ә үзе стакандагы суның яртысын да эчмичә өстәлгә куйды.

— Тәмле булса, эчеп бетерегез сез аны.

— Тукта, ял итим азрак. Монысын бетергәч, тагын берне эчәм әле мин, Өлфәт абый. Булгач — пар булсын. Гомер буе ялгыз яшәргә димәгәндер бит миңа!

Аның тел төбе тагын минем өчен хәтәр якны каера башлавын сизеп, сүзне икенчегә борырга ашыктым.

— Сез теге вакытта укулар бетү белән үк үз ягыгызга кайтып китәргә җыена идегез шикелле. Кире уйладыгызмы әллә, Гөлүсә?

— Ә сез минем китүемне теләгән идегез инде, әйе?

— Аннан әйтүем түгел. Миңа берниндн дә зыяныгыз тигәне юк бит. Болай искә төште дә кызыксынып соравым гына.

— Их, Өлфәт абый! — диде ул, мәгънәле итеп көрсенеп. Аннары кинәт ниндидер бер кискенлек һәм горурлык белән башын күтәреп, түшәмгә текәлде дә, үз-үзенә сөйләгәндәй итеп, ярсып сөйләргә тотынды:

— Беләм, Өлфәт абый, сезнең миңа равнодушный булып кылануыгызны яхшы беләм. Ләкин асылда алай ук битараф түгел бит сез миңа. Сез минем сезне яратуымны сизәсез, шуңа күрә генә шулай кыланган буласыз. Ә мин сезне аның саен ныграк ярата барам. Әйе, Көрнәледән китмәскә булдым мин. Сез өйләнгәнче беркая да китмәскә ант иттем! Миңа шул! Ярый, кәефегезне кырган булсам, гафу итегез!

Шулай диде дә, үзенә дип җыйган капчыктагы чикләвеген дә алырга онытып, йөгереп чыгып китте. Мин бер сүз дә әйтә алмыйча калдым. Аңыма килеп, капчыгын бирим дип артыннан чыкканда, ул инде байтак җир киткән иде.

Тәмам хәйранга калдырып китте ул кыз мине! Чынлап ук ярата дыр инде, күрәсең. Яратмаса, кыз баланың болай ачыктан-ачык сөйләшергә йөрәге җитмәс иде.

Ләкин мин аны нишләтим соң? Ничек ярдәм итим аңа? Сүз дә юк, чибәр ул, акыллыдыр да, мөгаен. Ләкин мин Сәкинәмне оныта алмаячагымны сизеп торам. Шулай булгач, болай гына, вакытлыча гына мавыгудан безгә ни мәгънә? Юк, булмый бу болай, тагын берәр тапкыр шулай «бәйләнә» башласа, туп-туры, гафу ит, Гөлүсә, безнең ике арабызда берниндн мәхәббәт була алмый, чөнки минем яраткан кешем

бар дип, дөресен әйтеп бирергә кирәк булыр. Башта авыр кичерсә дә, үзен-үзе алдап йөрмәс, миңа да җиңелрәк булыр аннары.

Ләкин мин аңа бу турыда әйтә алмадым. Шуңа әйтә алмадым, чөнки идарәдә булган әлеге сөйләшүдән соң Гөлүсә ул хакта бүтән сүз катмады. Мин эш белән авыл Советына — Көрнәлегә барган чакларда урамда очраштыргаласа да, тыйнак кына исәнләшеп, ягымлы елмаеп, горур гына атлап үтеп китә торган иде...

Ә мин һаман Сәкинә турында уйлыйм, аннан җавап көтә идем. Көтеп-көтеп тә беренче хатыма җавап бирмәгәч: «Нигә дәшмисең, Сәкинә, нигә тилмертәсең? Аерым яшәсәк тә, ир белән хатын ич әле без, аерылышканыбыз юк лабаса? Нигә ике-өч сүз белән генә булса да, үзеңнең һәм улыбыз Ирекнең хәлләрен әйтеп язмыйсың? Әллә эшең бик кыенмы, ярдәм кирәкме әллә? Кирәк икән — әйтеп яз, кулдан килгәнчә булышырмын», дип гаебемне танып ук булмаса да, шактый җылы итеп, икенче тапкыр да язып карадым. Әмма... юк, анысына да җавап бирмәде.

Шуннан соң тәмам боегып калдым мин, туган. Бер уйлаганда менә хәзер тотам да янына китеп бармакчы булам. Инде җыена гына башлыйм дигәндә, башка тагын икенче төрле уй килә: «Ә Сәкинә чынлап торып миңа хыянәт иткән булса? Галим абзый андый-мондый эше сизелгәне булмады дип әйтә әйтүен... Ләкин дөньяда ул сизмичә калган эшләр дә булырга мөмкин ич? Әнә, Хафиз карт бүтәнчә раслап тора лабаса!..»

Менә шул уй килә дә кинәт тагын ярсып, алдагы фикерләремнән кире кайтам, күңелем суынып куйгандай була. Әмма бу хәл озакка бармый, мин тагын сагышка бирелэм, тагын Сәкинәмне тарта башлый күңел... Үзем шул ук вакытта күзгә күренмәгән, әмма мине тоткарлап тора торган киртәне дә ничектер атлап үтә алмыйм...

Тагын дүрт-биш ай көтеп тә икенче хатыма да җавап булмагач, ниһаять, кирелегемне җиңеп: «Синсез һәм улыбыз Ирексез яши алмыйм мин, Сәкинә бәгырем. Шуның өчен барысын да гафу итәргә әзер торам, тик син дә мине гафу ит? Гафу итәр булсаң, тиз генә хат язып сал. Хатың килгән көнне үк юлга чыгармын да икегезне дә барып алып кайтырмын»,— дип тә язып карадым.

Ләкин ул хатыма да җавап килмәде. Өзелеп-өзелеп юксынсам да, күрәсең, гаебе булгандыр, шуңа җавап бирмидер, шикләнә торгандыр, дип шуннан соң мин аны бүтән борчымадым. Бөтен сагышымны эш белән басарга тырышып, эчтән генә сызып яши башладым.

## 17

Ә вакыт һаман үтә торды.

Безнең аерым яши башлаганга да өч ел гомер узып китте. Колхозның чираттагы отчет-сайлау җыелышына әзерләнеп йөргән көннәрдә мине райкомга чакырттылар. Гадел абый үзе дәштергән икән.

— Я, сөйлә, иптәш Хәкимов, эшләрең ничек? — диде ул, кул биреп исәнләшкәннән соң.

— Әлегә ярыйсы шикелле, Гадел Салихович,— дидем, аны нәрсә кызыксындырганын тәгаен генә белә алмыйча. Аннары колхоздагы хәлләрнең торышыннан башлап киттем: — Ашлыкны сугып бетердек. Үзегезгә мәгълүм, икмәк заданиесен йөз дә егерме җиде процент итеп үтәдек. Чәчүлек орлыкларыбыз да әзер: чистартып амбарга салып куелган. Ел ахырында колхозчыларга да хезмәт көненә кило өч йөздән исәп-хисап ясадык. Ә хәзер утраудагы болыннан печән ташыйбыз. Аны да алып кайтып бетерсәк, алай зур эшебез калмый да кебек.

— Яхшы, аларың бик әйбәт булган, иптәш Хәкимов. Сводкалар карагандa ук шулай дигән идек. Инде хәзер син миңа шуны әйт: үз хәлләр-

рең ничек? Хатының белән сөйләшеп карадыңмы? Янына барып кайттыңмы?

— Янына бармадым, әмма хатлар язгалап караган идем, Гадел Салихович.

— Я, шуннан?

— Хатларыма җавап язмады.

— Хатны төрлечә язарга була аны, Өлфәт энем!

— Мин дә төрлечә язып караган идем, тик берсенә дә җавап булмады. Аннары мин дә язмый башладым. Күрәсең, үз хәлен үзе белә торгандыр инде. Гаебе булмаса, күптән дөньяның астын-өскә китерер, акланырга тырышыр иде ул. Хатын-кыз андыйга хирес бит, сәбәбе генә булсын!

— Ә нигә син бөтен хатын-кыз да шулайдыр дип уйлыйсың әле? — диде секретарь, җитди тонга күчеп.— Син уйлаганның киресенчә булуы да мөмкин түгелмени? Бәлки, хатыныңның гаебе юктыр, шуңа җавап бирми торгандыр ул. Синең, үзең килеп, гафу үтенүеңне көтәдер, бәлки. Синдә булган горурлык белән синдә булган мин-минлек нигә анда булмаска тиеш әле? Менә шул хакта да уйланырга кирәк! Өченче ел бер әйткән идем инде, тагын шул сүзне кабатлыйм: минемчә, янына барып, үзе белән сөйләшеп карарга иде сиңа! Бәлки, тезләнеп алдында гафу үтенергә дә кирәктер әле!

— Нишләргә дә белгән юк инде, Гадел Салихович. Оныта да алмыйм үзен, шул ук вакытта янына барып гафу үтенеп карарга да күңелем тартмый. Рәдиф белән чуалганын белүче бар бит!

— Ну-у! — диде Гадел абый, аптырыйрак төшеп.— Кем күргән, мин беләмме икән ул кешене?

— Аның үзен, ихтимал, белмисездер, ә малаен беләсез: районның культура бүлегендә эшләүче Мәлик Хафизов ул.

— Димәк, Мәликнең этисе Хафиз карт белә?

— Әйе, Гадел Салихович. Сез аны да беләсезмени?

— Аз-маз беләм. Минем янга кергәне бар аның бер-ике тапкыр. Бер-ике күрүдә генә кешене яхшылап аңлавы, әлбәттә, кыен, хәтта мөмкин дә түгел. Ну шулай да... Бик үк чиста күңелле сыман тоелмады ул карт миңа.

— Элек алай ялган сөйли торган кеше түгел иде ул, Гадел Салихович.

— Элек, элек. Элекне куйганнар шул аны әлеп! — диде Гадел абый, ничектер минем белән килешергә теләмәгән сыман итеп. Тәрәзә буена барып, бераз уйланып торды да кисәк кенә миңа борылды:

— Хәер, мондый чакта кеше киңәше белән генә йөреп булмый инде ул. Үзең кара, Хәкимов. Бала-чага түгел син. Мин сиңе акыл өйрәтергә чакырмадым монда. Моңысы сүз җаеннан гына килеп чыккан нәрсә. Башка мәсьәлә буенча дәштергән идем мин сине.

Секретарь кинәт рәсми төскә керде дә:

— Эш менә болай, иптәш Хәкимов: без сине «Ватан»га күчермәкче идек, син үзең шуңа ничек карыйсың? — диде.

Мин бик нык борчуга калдым. Шулай булмый хәле дә юк: «Ватан», бердән, зур колхоз, икенчедән, экономик яктан бик артта калган. Өченчедән, кешеләре авыррак холыклы. Шабашниклыкта йөреп көн күрүчеләрне әйтәм. Дүртенче сәбәбе дә бар: минем председатель булып эшли башлавыма нибары өч ел гына бит әле, шулай булгач, күпме генә тәҗрибәм бар да, андый зур колхозны ничек җитәкләрмен ди мин?

— Әгәр чынлап әйтүегез булса, мин категорически каршы моңа, Гадел Салихович!

— Сәбәбе?

Әлеге дүрт сәбәбемне санап бирдем һәм, шуларга өстәп:

— «Чулпан»да эшләр җайланып кына килгәндә, халыкның да, хуҗалыкның да рәтенә төшенеп бетеп кенә барганда башка җиргә күчеп китәргә һич тә теләгем юк! — дидем.

— Бүтән сәбәпләрең бармы? — диде ул, боларына бер дә алай исе китмичә.

— Бар: «Ватан»га күчеп, тагын бер шелтә алырга теләмим. Теге елдагысы да өстемдә кара тап булып тора әле!

Райком секретаре мәгънәле генә итеп елмаеп куйды. Аннары блокнотына нидер язды да:

— Ярый, анысы безнең гаеп. Киләсе бюрода карарбыз ул мәсьәләне. Кадрларны мактарга онытканлыйбыз да икән шул кайчакта! — диде һәм шундук җитдиләнеп сүзне тагын үз җаена борды.— Ә «Ватан»га барырга теләмәвеннең сәбәпләре җитди түгел, иптәш Хәкимов. Үзебезгә генә ошаган җирдә эшли торган вакытлар да җитәр, әлбәттә. Әмма хәзергә андый чак түгел әле. Иртәрәк әле ана. Һәркайсыбыздан сәлатенчә таләп ителә әле хәзергә! Һәркайсыбыз булдыра алганча эшләргә һәм мөмкин кадәр күбрәк эшләргә тиеш... Ә синең «Ватан»да эшләрлек сәләтең барына мин ышанам. «Чулпан»да калдыра алмыйбыз без сине. «Ватан» штурвалын тоттырмакчы булабыз. Бүген генә уйланган нәрсә түгел бу. Өең янганнан соң, йорт салырга ашыкма дию ем дә шул максатны күздә тотып әйтелгән сүз иде.

— Миннән башка кеше юкмыни соң, Гадел Салихович?

— Кешесе күп лә аның! Хәзерге председатель Мосафировны калдырырга ярамавын сизенеп, аның урынына төпләнеп калырга теләп, үзләре ымсынып йөрүчеләр дә бар. Әмма безгә андыйлар кирәк түгел. Эш майтарырдай, «Ватан»да тәртип урнаштырырдай кеше кирәк безгә! Сер түгел, «Ватан» — районда иң артта килүче хуҗалык... Кыскасы шул: бар, кайт та «Чулпан»ның отчет-сайлау җыелышын әзерли башла. Көнен билгеләгәч, хәбәр итәрсең, мин үзем барырмын җыелышыгызга.

Мәсьәлә әнә шулай кабыргасы белән китереп куелса да, мин ризалык бирергә ашыкмадым:

— Хәзер генә өзеп берни дә әйтә алмыйм, Гадел Салихович. Халык сайлап куйган бит мине «Чулпан»га. Алар нәрсә дияр бит әле,— дип, эшне бөтенләй үк өзеп бетермичә кайтып киттем.

## 18

Көн шундый суык — авызыңны ачсаң, сулуга каба. Теләсәң, шул зәңгәр суыкны пычкы белән турап, әрдәнәләп өеп куеп булыр төсле. Тере җан ияләре ничек түзә торгандыр, хәтта авыл йортларының капкаларына тикле «тим-ә-ә-ә!», «үлә-ә-эм!» дип, елап-сыкрап кына ачыла. Кояш үзе дә туңган, ахрысы — «колакларын» тырпайтып тора, яктылыгы да кими төшкән. Ярый әле, җиле юк. Җиле дә булса, капкаңнан баш тыгып, урамга карый алмас идең!

Ә Гадел абый иртәнге унга ук килеп җитте. Җыелыш көндезге сәгать икедә башланды.

Тиене тиенгә туры килсә, кереме чыгымыннан артмаса, ягъни, кересенчә, чыгымы кеременнән артып китмәсә, колхоз отчет-сайлау җыелышы әллә ни кызыклы да, тавыш-гаугалы да булмый. Бездә андый чатаклыклар юк иде. Шуңа күрә җыелышның отчет өлеше шома гына барды дияргә була. Дөрес, Рәдиф:

— Менә өч ел инде Хәкимов ел саен печән өстендә печәнчеләргә я тана, я сыер суйдырып, бушлай ашатып килә. Минемчә, узган елгы сыер итен печәнчеләрдән түләттерергә кирәк,— дип тәкъдим кертергә азаплана башлаган иде башлавын. Әмма халык ана: «Ниткән түләү ди ул?!» — дип, авыз ачарга да ирек бирмәгәч, Гадел абый да ул мәсьәләне күтәреп алмагач, шундук тотлыгып калды да:

— Мин болай гына, колхоз милке өчен эчем пошып кына әйткән идем, түләтмисез икән — кирәк түгел! — дип мыгырданып, урынына утырырга мәҗбүр булды. Ишек катында торучы Галим абзый:

— Беләбез инде, олан, синең колхоз өчен ничек тырышканыңны, сөйләп тору кирәк түгел! — дип иплəп кенә әйтеп куйгач, бөтенләй кечерәеп, халык арасына сенеп калды.

Ә менә сайлау өлеше башланып, Гадел Салихович мине председательлектән азат итүләрен үтенгәч исә җыелыш бик нык кызып китте. Ин әлек теге вакытта кәҗәсе өчен кайгырып, нишләргә белмичә сырпаланып йөргән Маһисәрвәр апа сүз алды:

— Бу ниткән тамаша була инде, иптәш сиклитар? — диде ул, урта рәттә утырган җиреннән сикереп торып.— Калхузны аякка бастырып килгәндә генә нигә алай алып китмәкче буласыз безнең Өлфәтне? Без бүтәннәрдән киммени? «Ватан»да кеше беткәнмени? Алты йөз йортлы авыл бит ул! Үзләреннән сайлап куйсыннар прсидәтел. Юк-юк, Хәкимов Өлфәтне беркая да җибәрмибез без! Адәмчә яши башладык дип торганда гына эшме соң инде шулай? Башкалар ничек дияр, мин үзем каршы бу эшкә! Менә шул!

Маһисәрвәр апа артыннан сүз алган Галим абзый да шул рәвешле рәк сөйләде. Тагын биш-алты кеше аларның фикерен куәтләп чыкты.

Болай булса, үзебезнең «Чулпан»да калам, ахрысы, дип куанып утырган идем мин. Аннары Гадел абый сүз алды:

— Беренчедән,— диде ул,— безнең өчен «Чулпан» да, «Ватан» да, башка колхоз да барысы да бер үк дәрәҗәдә якын! Берсен дә аерып карамыйбыз. Иптәш Хәкимовны да сезне кимсетеп караганнан күчерергә җыенмыйбыз. Аның сезгә кирәкле кеше булуын да, сезнең аны хөрмәт итүегезне дә бик әйбәт белеп торабыз. Ләкин сез дә мине аңларга тырышыгыз, иптәшләр: халык белән уртак тел табып, бар көчен куеп, чын күңеленнән тырышып эшли торган җитәкче буларак, намуслы партия члены буларак, Хәкимов Өлфәт «Ватан»га аеручa кирәк грәк. Яшерен-батырын түгел, «Ватан»ның хәле кыен. Моны сез үзегез дә беләсез. Аннан килеп, тагын шунысын да искә алыгыз, иптәшләр: әллә кая китми бит Хәкимов, үзегезнең авыл советы урнашкан күрше авылга гына күчәчәк. Киңәш-табыш итәргә кирәк булган очракларда сез дә аның янына баргаларсыз, ул да сезне бөтенләй үк онытып бетермәс дип уйлыйм. Әйдәгез, алай карышмагыз инде сез. Бушатыгыз Хәкимовны эшеннән?

— Туктале, ул тикле куырма әле син безне,— дип, янә Маһисәрвәр апа сикереп торды.— Уйларга ирек бир әле әзрәк, пәрәми! Үзеннән дә сорап карыйк әле Өлфәтнең, ул үзе нәрсә дияр икән?

Нишләргә инде? Китәсем килми дисәм, алар мине җибәрмәскә дә мөмкин. Минем, чыннан да, китәсем килми, үз авылның халкы белән эшләү,— бер, чит авылда — бөтенләй икенче нәрсә бит ул. Үзебезнең авыл кешеләренең һәркайсының холкын-гадәтен өйрәнеп бетә язган идем бит мин! Ә Көрнәледә бөтенләй таныш булмаган кешеләр белән, бөтенесен яңа баштан башларга туры киләчәк. Ярый ла җайларын табып булса... Шул ук вакытта Гадел абыйны уңайсыз хәлдә калдыру да читен. Райком секретаре булганы өчен генә түгел, кеше буларак, акыллы җитәкче буларак хөрмәт итәм ич мин аны.

— Мине азат итүегезне үтенәм, иптәшләр! — дидем мин, беркавым уйланып торганнан ары.— Яхшы гына эшләдек. Хөрмәтегез өчен рәхмәт! Әмма азат итүегезне үтенәм. Семьям да җимерелде, йортым да янды, шуңа күрә монда эшләргә күңелем тартмый. Анысын да искә алыгыз, иптәшләр!

— Рас үзе шулай дип әйтә икән — көчләп булмый инде алайса,— диде Сәрвәр апа.— Я, әйтеп кара алай булгач, Өлфәт энем: урынына кемне куйыйк соң?

— Бәлки, яңадан Рәдифне куярсыз,— дидем мин, аны үз урынымда калдырырга теләүдән бигрәк, халыкның фикерен беләсем килеп.— Белеме дә бар, тәҗрибәсе дә. Аннары хәзер салу белән дә мавыкмый.

Шул сүзем өчен ул җыелышта миңа бик нык үпкәләде халык. Аны кую түгел, исемен иштергә дә теләмибез, син нәрсә, үзең киткәч, колхоз да тәмам эштән чыксын дисеңме әллә, сугыш елларындагысына да үкенеп бетә алмыйбыз әле. Прсидәтел генә ит — шул кенне үк эчә башлый ул...

Кыскасы, пыр тузынды халык. Аннары, халыкны да, крәстиән эшенең рәтен-чиратын да белә дип, Галим абзыйны сайлап куйдылар.

## 19

Берәр атнадан «Ватан»да да отчет-сайлау җыелышы булды. Инде әйткәнемчә, хәле мактарлык түгел иде «Ватан»ның. Шуның өстенә, тиене тиенгә генә түгел, меңе меңгә туры килеп бетмәгән очраклары да шактый булып чыкты. Кыскасы, моңарчы председатель булган агайны — юантык гәүдәле, кара тут чибәр йөзле бер кеше иде ул — яңадан үз урынында калдыру турында сүз дә булмады. Ә менә кемне сайлау мәсьәләсендә тавыш зурдан купты. Иң элек өстенә тышлы яңа тун, башына яхшы бүрек кигән ир уртасы бер агай сүз алды.

— Үзебезнең авыл кешесен сайларга кирәк, ничу монда читтән килгәнне куярга! — диде ул, минем кандидатура тәкъдим ителгәч.— Читтән килеп эшләп караучылар, шөкер, булгалады инде. Тик берсе дә колхозны алга җибәрә алмады. И һәм җибәрмәячәкләр дә! Чит кешегә нәрсә аңа: бүген монда ул, ошамады икән — иртәгә койрык сыртта аның. Булсын дип йөрми алар. Ә хезмәт хакын каера беләләр: акчалата кирәк аларга!..

Аның артыннан тагын өч ир, ике хатын-кыз шулайрак сөйләп, мине сайлауга каршы чыктылар.

— Я, тагын кемнәрдә нинди фикерләр бар, иптәшләр? — диде Гадел абый, тыныч кына. Бер-ике минут халыкка карап, көтеп торды. Бүтән сөйләргә теләүче күренмәде.

— Яхшы! — диде ул аннары. Сәламәт кулы белән чәчен сыпырып куйды да иң алдан сөйләгән яңа тунлы абзыйга мөрәҗәгать итте: —Әйтегез әле, иптәш, нинди эштә эшлисез сез?

— Кая кушсалар — шунда! — диде Галләмов.

— Ә узган ел күпме хезмәт көне эшләдегез?

— Син нәрсә пркарур шикелле дупруслый башладың әле мине?

— Сез алай кызмагыз әле, иптәш! Прокурор булып түгел, җыелыш исеменнән үтенәм бит мин: күпме хезмәт көне эшләдегез?

— Ну, сиксән җиде булсын, ди. Шуннан?

— Ә ел буена барлыгы ничә көн эшкә чыктыгыз?

— Менә анысын санамаган идем шул, иптәш сиклитар. Кирәк буласын белмәдем. Иренмәүчеләр хезмәт кенәгәсен алсын да санасын... Ә миңа бушны чутлап ни файда?

Гадел абый аның сүзләрен сабыр гына тыңлап утырды. Аннары Галләмовның хезмәт кенәгәсен алып килергә кушты да минем кандидатурага каршы чыккан башка кешеләрдән дә, кайда эшлисез, күпме хезмәт көнегез бар, дип сораштыра башлады.

Әмма алары да батырып эшләүчеләр түгел, колхоз белән бәйләнешләре бик чамалы кешеләр булып чыкты. Теге өч ирнең икесе балта остасы, берсе мич чыгаручы — гомерләрен күбрәк тирә-як районнарда, хәтта чит өлкәләргә чыгып та эшләп үткәрүчеләр икән. Әлеге ике хатынның ирләре дә шулай ук колхозны куандырырлык эш күрсәтмиләр: кышын вак-төяк эштә эшләп йөрсәләр дә, җәйгә чыккач, колхоз эшенең иң кызу

чагында, бер кешене унга бүләрдәй вакытта Урал ягына китеп, печән чабып, утын кисеп акча сугып йөриләр икән.

Хезмәт кенәгәсен карап, Галләмовның да колхоз эшенә нибары илле бер көн генә чыкканын, аның да җәен шабашниклыкта йөрүен ачыклаганнан соң, Гадел абый иплән кенә трибуна янына барып басты да, өстенә иске сырма кигән, башына уңып беткән калын шәл япкан кечкенә генә бер хатын-кызга мөрәҗәгать итеп:

— Әйтегез әле, менә сез кайда эшлисез? — дип сорады.

Кечкенә ханым башта сискәнеп-каушап китте. Аннары ялт итеп урыныннан купты да:

— Дуңгызлар карыйм, иптәш сиклитар, дуңгызлар! Безнең ише ирсез-атсыз хатын-кыз кайда эшләсен инде бүтән? — диде.

— Узган ел күпме хезмәт көне эшләдегез?

— Һей, миннән сорасаң! Көненә ике труддин язабыз дип әйткәннәр ие эшкә куйганда. Өченче елымны эшлим инде. Үткән ел күпме труддинем булгандыр, үтер — әйтә алмыйм. Бер дә ул хакта сорашканым булмады.

— Җиде йөз дә унтугыз да җитмеш биш сутый хезмәт көне бар Хәдичә апаның! — дип кычкырды берсе мич артыннан. Күрәсең, бригадир яки ферма мөдире кычкыргандыр, югыйсә алай төгәл әйтеп бирә алмас иде.

— Алай икән! — диде секретарь, мәгънәле генә итеп.— Кызык, бик кызык килеп чыга бит, иптәшләр! Кечкенә генә Хәдичә апа җиде йөз унтугыз хезмәт көне эшләгән, ә чиртсәң битләреннән кан чыгарга торган тап-таза дүрт ирнең дүртесенекен бергә кушсаң да Хәдичә апаныкы хәтле хезмәт көне юк! Бу нәрсә була инде, иптәшләр? Бу килештән ул колхоз ничек алга китсен инде? Җитмәсә колхозда иң аз эшләүче шул кешеләр, оялмыйча, авыз күтәреп сөйләп торган булалар бит әле! Аларның нигә алай йон кабартулары аңлашыла, әлбәттә: Хәкимов Өлфәт председатель булса, тезгенне нык тотачагын бик яхшы белә алар. Элекке елларда «Чулпан»да да бар иде андый берничә кеше. Ләкин Хәкимов аларга бик тиз чик куйды. Күрше авыл гына бит, ул турыда сезнең авыл шабашниклары да ишеткәннәрдер, билгеле. Галләмов агай да белә булса кирәк ул хакта. Ләкин, иптәшләр, мин сезгә шушы җыелышта авторитетлы рәвештә әйтеп куям: моннан соң шабашникларның юлын ябачакбыз! Сугыш китергән авырлыкларны сылтау итеп, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып йөрүчеләр булырга тиеш түгел киләчәктә!

— Әмма дә дөресен әйттең инде, иптәш сиклитар! — дип, кинәт тәрәзә буенда утыручы бер апа торып сөйли башлады.— Нәкъ өстенә генә китереп бастың инде менә! Бер бүген генә түгел, сугыш башланган елдан бирле шулай килә бездә: җыелыш булса — Галләмов ишеләр бугаз киереп акыра, эшкә килгәндә, анысын безнең ише тол хатыннар эшли. Беркемгә бер сүз әйттерми ул Галләмовлар! Гел алар сүзе өстен чыга. Чыкмасые да, җә өркетеп, җә майлап, прсидәтельне үз якларына аударалар! Син бик дөресен әйтәсең, иптәш сиклитар: Хәкимов Өлфәтне прсидәтел итеп куйсак, аның белән бутказары пешмәсен, аны ярты эчертеп кенә үз якларына аудара алмаслыкларын сизенә алар, шуңа шушылай тыпырчыналар. Әмма дә ләкин алар сүзенә карамаска кирәк! Минем фикерем шул: Галләмов ише шабашникларның сүзен колакка алмыйча, шуларга юри үч итеп, тотарга да Хәкимов Өлфәтне сайлап куярга кирәк. Кертсә ул кертә безнең халыкны денгә. Үткән ел «Чулпан»да килә да өч йөздән бүлеп бирде ул! Без шуның чиреге белән калдык. Ул да атхуттан... Ә җирләребез бертөсле үк. Безнең җир тигезрәк, яхшырак та әле. Сугышка хәтле без һәр җылны «Чулпан»нан күбрәк бүлә торганыек!

Ул апа урынына утырган гына иде:

— Мина да мөнкинме берничә сүз әйтергә? — дип, алгы рәттән брезент кожанлы, йөзен сап-сары сакал-мыек баскан бер абзый торып басты да, рөхсәт иткәнне дә көтмәстән, сөйли үк башлады:

— Төптәнрәк уйлаганда, чыннан да, шулай ич, җәмәгать! Нуржамал хак сүз әйтте бит! Галләмефе дә, Хәмитофы, Сираефы да — берсе дә колхозны кинәндерүчеләр түгел ич, үзегез дә күреп торасыз. Читтә, шабашниклыкта акча эшләп йөри бит алар. Менә минем киемне карагыз да, Галләмеф Закирныкын карагыз: ул өр-яңа җылы тун кигән, мин җыртык бишмәт тә иске кажан киеп йөрим. Ә бит минем кулым да балта тота белә. Мин дә башка авылларга барып йорт салып йөрергә магу. Ну минем алай итәсем килми, сәвисем бар минем. Бөтенебез дә шулай йөри башласак — кем алып барсын колхуз эшен? Минем фикерем шул: Хәкимовны куярга кирәк прсидәтел итеп. Булдыра торган егет ул. Вәт шул! Минем сүзем бетте. Кирәк булса, язып куй, иптәш сиклитар: Сафин Вафа дигән кеше мин.

Вафа абзыйдан соң тагын унлап колхозчы кызып-кызып мине яклап сөйләде. Аннары Гадел абый торып басты да:

— Хәзер, иптәшләр, мәсьәләне тавышка куябыз: кем дә кем Хәкимов Өлфәтне...

— Гафу итегез, Гадел Салихович, минем дә бер-ике сүзем бар иде,— дип мин үзем трибуна янына чыктым.

— Мәсьәләне тавышка куйганчы мин сезгә шуны әйтмәкче булам, иптәшләр,— дидем мин.— Зинһар, мине үзе теләп килгән икән дип уйлый күрмәгез! Сезгә килергә һич тә җыенмаган идем. Хәзер дә председателегез булырга атлыгып тормыйм. Сайламасагыз — рәхмәттән башка сүз әйтмәячәкмен. Әгәр сайлыйсыз икән, әйдәгез, алдан ук килешеп куйыйк, соңыннан үпкәләшү булмасын. Сездә эшләмәсәм дә, беләм мин: сукранырга яратучылар күп, ә эшләргә теләүчеләр азрак бирелә. Ул нәрсәне бетерергә кирәк булыр! Иң элек яхшылап эшләргә туры килер. Аннары, рәхим итеп, сорый да аласыз. Бөтенебез бер семья булып, колхозныкы дип түгел, минеке дип, күңел биреп эшләмәсәк, читтән килеп беркем дә алга җибәрмәячәк бу колхозны. Монысы — бер! Икенчедән, читкә китеп, шабашниклыкта йөрүчеләр иртәгәдән үк ул эшне туктатырга тиеш! Өченчедән, һәркайсыгызга бригадир кая эшләргә куша — шунда барырга кирәк булыр. Сәбәпсез-нисез эштән калучылар рәхим-шәфкать көтмәсен! Инде килеп, әгәр минем ялгыш эшләрем була икән — шулай ук күземә терәп әйтүегезне үтенәм. Чыш-пыш арттан гайбәт сату кирәк түгел! Менә шул, иптәшләр. Мәсьәләне тавышка куйганчы боларны искә алыгыз. Әле соң түгел. Соңыннан тегеләй дә болай, фәлән дә фәсмәтән дип йөрерлек булмасын! Минем таләпләргә риза булган кешеләр генә кулын күтәрсен. Тагы шунысын да әйтеп куям. Кайсыдыр, Галләмов Закир агай иде, ахрысы: «Читтән килгән председательләрне күп күрдек инде, юньләп эшләмиләр, әмма хезмәт хакын акчалата каералар»,— диде. Курыкма, Закир агай, мин акчалата алмаячакмын. Барлык колхозчылар кебек үк, мин дә хезмәт көненә эшләячәкмен. Сезгә ни — миңа да шул булыр.

Аннары Гадел абый мәсьәләне тавышка куйды. Җыелыштагы биш йөз алтмыш өч колхозчының уналтысы каршы булды, башкалары, ризалык белдереп, кул күтәрде...

Шулай итеп, мин «Чулпан»нан «Ватан»га күчәргә тиеш булдым, туган. Ләкин сайлап куйган көннәрдә үк анда эшли башламадым. Ни өчен дисәң, алдагы елда мин Казан авыл хуҗалыгы институтында читтән торып укырга имтихан биреп кайткан идем. Нәкъ шул көннәрдә кышкы сессиягә барырга кирәк иде. Шуңа күрә, элекке председатель белән алыш-бирешне кайткач ясарга булып, Казанга кышкы имтиханнарны тапшырырга китеп бардым.

Менэ шунда теге укытучы кыз Гөлүсә белән янә очраштык без. Ул да читтән торып Казан педагогия институтында укый һәм ул да, минем кебек, кышкы сессиягә килгән иде. Беренче имтиханымны тапшырып чыккан көнне үк ялт итеп институтка килеп керде бу.

— Хәлегезне белергә килдем, Өлфәт абый,— ди.— Авылдаш итеп үзегез килерсезме дип көттем-көттем дә, сез килмәгәч, үзем килдем менә!

— Мин сезнең Казанда икәнлегегезне белми идем бит,— дидем мин, аның сессиягә киткәнлеген ишеткән булсам да, белмәгәнгә салышып.

Ул минем бу сүзләремне колагына да алмады:

— Я, нинди билге белән котлыйм сезне, «отлично» беләнме? — дип, һаман үзенекен тәтелди бирде.

— Юк, «яхшы»сы бик житкән минем ише читтән торып укыган кешегә.

Өмете акланмаганга борынын жыерып, ризасызлык белдерде дә шундук тагын кояштай балкып китте.

— Котлыйм, Өлфәт абый! — диде аннары, кулымны кысып һәм серле итеп елмайды да өстәп куйды: — Имтихан алучы урынында булсам, мин сезгә, һичшиксез, «отлично» куйган булыр идем!

— Яхшы ниятегез өчен рәхмәт, Гөлүсә! Ә үзегезнең эшләр ничек соң? Ничә имтихан тапшырдыгыз әле?

— Уф, үләм! — диде ул, һуштан яза башлаган кешедәй башын тотып, чытлыкланып.— Ниһаять, сез дә минем хәлем белән бер кызыксынырсыз икән? — Аннары кинәт башын күтәрде дә: — Минем хәлләр болай ярыйсы, Өлфәт абый: өч имтиханымны тапшырдым инде, тагын берәү генә калды. Анысы ничек булыр — әйтә алмыйм, ә өчесен гел «отлично»га тапшырдым.

— Молодец, котлыйм үзегезне, Гөлүсә! Мин әле дүрт имтиханның бары тик берен генә тапшырдым.

— Шулаймыни? Ә мин тагы эшләре бетеп килә торгандыр, әллә бергә кайтырбызмы дип килүем иде. Булмый икән инде алайса,— диде ул, сөмсерен коеп.

— Нишләтәсең бит, Гөлүсә.

— Беләсезме нәрсә, Өлфәт абый! — диде ул, тагын рухланып китеп.— Әйдә, киного барыйк әле бүген. Сезнең дә куанычлы көнегез икән, мин дә имтихан тапшырып чыктым. Әйдәгез, шуны отмечать итеп кайтыйк әле!..

— Бик барыр идем дә, әмма мине бүген кичкә фронтта бергә хезмәт иткән бер иптәшем чакырган иде шул, Гөлүсә,— дип мин аның үтенечен кире кактым.

Әмма Гөлүсә тиз генә бирешергә теләмәде.

— Ә ул дустың янына икәү барырга ярамыймы соң, Өлфәт абый? — диде, һаман шулай матур, серле итеп елмаеп.— Карамаган кино түгел, анысына бүтән вакытта да өлгерербез әле!

— Алдан сөйләшеп куймагач, икәүләп килеп керү бик үк килешеп бетмәс шул, Гөлүсә. Аннары ул минем өйләнгән кеше икәнлегемне дә белә бит.

— Белсә — бик шәп! Сез мине хатыныгыз дип әйтерсез.

Нишләргә инде бу кызый белән? Мин беркавымга аптырабрак калдым. Аннары, әйдә, ялганларга булгач, ялганларга инде дип уйладым да:

— Ул кеше минем Сәкинәне таный шул, Гөлүсә. Сугышта вакытта рәсемнәрен күргәне булды аның,— дидем.

— Ну хәйләкәр дә кеше инде сез, Өлфәт абый! — диде ул, ачыктанагык үпкәләп.— Нигә юкны уйлап чыгарып маташырга инде! Алдашканыгызны күзләрегездән үк күреп торам бит! Ичмаса, дөресен әйтегез аны: синең белән күрешәсем дә, сөйләшәсем дә килми диегез!

Мин җинаять өстендә тотылган кеше сыман телсез-өнсез калып торган арада, күрәсең, бу кыен хәлдән коткарырга теләп булса кирәк, Гөлүсә мине юатырга ашыкты:

— Ярый, Өлфәт абый, хафаланмагыз. Теләмисез икән — кирәкми, алып бармагыз. Алай атлыгып торудан әйтмәгән идем мин сезгә. Риза булсам, киносына да, театрына да, тагын әллә кайларга да алып барырга җан атып йөрүчеләр дә бетәсе түгел. Тәмам туйдырып бетерделәр инде. Ну әкәмәт тә икән бу ир-ат халкы! Барысына да матур кыз булсын. Хәтта инде чәчләренә чал төшкән һәм, мөгаен, кимендә ике бала атасы булганнарына тикле сүз кушып азапланган була бит. Әнә шул ач күзләрдән котылып тору өчен кинога чакырган идем мин сезне, Өлфәт абый. Аннары минем өчен бик мөһим, бик зур бер мәсьәлә турында киңәш-табыш итеп карамакчы идем.

— Нинди мәсьәлә ул, Гөлүсә? — дидем мин, ниһаять, тел тибрәтеп сүз әйтергә җай чыгуына куанып.

— Улмы?...— Шулай диде дә, әйтергәме-юкмы дип булса кирәк, беркавым уйланып, аска карап торды. Аннары кинәт башын күтәреп күзләремә текәлде дә тиз-тиз сөйләп китте.— Эш менә болай, Өлфәт абый. Сүз әлеге шул яшь, чибәр кызлар артыннан куган ач күзләрнең берсе турында булачак. Ләкин монысы гади генә түгел, ә особый ач күз. Үземне укыта торган бер доцентның күңеле төшкән миңа. Мин үзем дә сизенеп йөри идем аның шулай икәнен. Әмма моңарчы ул миңа бу турыда сүз белән әйткәне юк иде. Мин тоже берни белмәгәнгә салышып йөри бирә идем. Ә менә кичә ул мине фатирыма кадәр озата кайтты һәм кулымны сорады. Риза булсаң, хәзер үк алып калам, әгәр инде уйлашырга кирәк дип әйтәсең икән, көтәргә дә була, диде. Киңәш ит әле, Өлфәт абый, нишлим икән?

— Ниндирәк кеше соң ул, Гөлүсә? Өйләнеп аерылышканмы, әллә егет кешеме? — дидем мин, нинди киңәш бирергә дә белмичә.

— Улмы? Ул егет кеше түгел инде, Өлфәт абый. Бала атасы икән инде. Ләкин баласы үзе белән түгел, аерган хатынында калган. Яшькә дә бик яшь түгел — миннән унсигез яшькә олы. Төскә-биткә, буйга-сынга болай симпатичный гына үзе. Институтта да шактый авторитетлы сизелә. Моннан алты ел элек үк инде кандидатлык диссертациясен яклаган. Хәзер докторлыкны язып ятам, озакламый анысын да төгәлләячәкмен, ди. Әйт әле, Өлфәт абый, нишлим икән, ә?

— Кешегә киңәш ит, үзең теләгәнчә эш ит, диләр бугай мондый чакта.

Ул миннән мондый җавап көтмәгән иде, ахрысы — йөзе кинәт карангыланды, күзендәге нурлар юып алгандай юкка чыкты. Беравык идәнгә карап торды. Бары тик шуннан ары гына гадәтенчә ялт итеп башын күтәреп миңа текәлде дә:

— Димәк, сезгә ничек итсәм дә ярый, шулаймы! — диде.— Руслар әйтмешли, сезгә не жарко и не холодно, эйе?

— Соң мин тормыш итәсе түгел бит ул симпатичный белән,— дидем мин, аның кирәгеннән артык төпченә башлавына эчем пошып.— Әгәр аңа кияүгә чыгасыз икән, сез яшәргә тиеш буласыз. Шулай булгач, үзегез карагыз инде, Гөлүсә. Йөрәгегез ничек куша — шулай эшләгез! Башкача мин берни дә әйтә алмыйм. Кешегә киңәш бирү түгел, үземнең семья тормышымны да шушыңарчы рәткә сала алганым юк әле.

Бу җавабымның кискенрәк булганын сизенеп, мин аңа: «Хәер, мондый зур эшкә алынып өчен бер-береңне яратышу да кирәк диләр бугай бит, анысы бармы соң ике арагызда? — дип әйтмәкче булып авыз ачкан идем, ләкин Гөлүсә мине тыңлап тормады.

— Рәхмәт, Өлфәт абый! — диде дә институт коридорын яңгыратып, тек-тек басып, китеп барды.

## 20

Сессиядән кайтып, «Ватан»да эшли башлагач та җиңел булмады, туган, минем хәлләр. Аеруча беренче айларда, халык мине, мин халыкны яхшылап белмәгән чорда кыенга туры килде. Үз якларына аудару өчен ниләр генә эшләп карамады ул шабашниклар! Мең төрле хәйлә табып, өйләренә алып кереп сыйларга да тырыштылар, төрле «бүләкләр» төртергә азапланучылар да булды. Минем әле һаман бүйдак булып йөрүемне сәбәп итеп, гайбәтен дә туйганчы тараттылар...

Һей, туган, ул көннәрдәге хәлләрне искә алганда хәзер дә аркалар чымырдап китә әле!..

Әлеге шул «Ватан»да эшли башлаган көннәрдә килеп чыккан кайбер хәлләрнең бер-икесен сөйләп үтмичә тәки булдыра алмам, ахрысы. Март аеның урталары, аяз, җылы көн иде. Икенче бригададан алты ирне кырга салам көрәргә җибәрдек. Тукта әле, нишләп яталар икән дип, төшкә таба яннарына барып карап кайтырга булдым мин боларны. Килсәм, алтысына алтышар метр кар да көрәмәгәннәр. Үзләренә кирәк кадәр урынны гына чистартканнар да, көрәкләрен карга кадап куеп, дөньяларын онытып, карта сугып утыралар! Шулкадәр бирелеп уйныйлар — яннарына килеп басканымны да сизмәделәр хәтта.

Акыра, сүгенә башлаудан үземне чак-чак кына тыеп калдым. Ачуын килмәслек тә түгел бит: иртәгә шушы эскерттән ферма терлекләренә салам ташый башларга тиешләр, ә болар әле ул эскертне көрәргә тотынмаган!

— Кая, миңа да карта өләшегез әле, җәмәгать? — дидем мин, ачуымны бик зур кыенлык белән генә басып, юри исем китмәгән атлы булып күренергә тырышып.

Алтысы да дерт итеп киттеләр. Ә мине сайлаган җыелышта райком секретаре белән әрепләшеп азапланган Галләмов Закир агай исә карталарын салам өстенә ташлап, сикереп үк торды. Башкалары да карталарын ташладылар. Берсенең дә алып кесәсенә салырга йөрәге җитмәде: нишләргә белмичә, аптырашып тик торалар.

— Нигә авызларыгызны чөйгә элеп, шаккатып калдыгыз? Мине уенга алырга теләмисезмени?

Берсе дә бер сүз дәшмәде.

— Синекеләрме болар, Закир абзый? — дидем мин, чәчелеп яткан карталарны җыеп алып.— Мә, кесәңә салып куй!

Закир абзый кымшанып та карамады.

— Синеке түгел, димәк. Кемнеке соң болар?

Берсе дә минеке димәде.

— Ярый, хуҗасы юк алайса, бик шәп булды әле бу! — дип, куанган сыман итеп, карталарны кесәмә салып куйдым да сәгатемә карадым: уникенче киткән иде.

Кыш көне безнең якларда мондый эштән төшке ашка кайтып тору гадәте юк. Иртәдән алып, көндезге икеләргә кадәр эшлиләр дә шуннан соң барып йөрмиләр. Димәк, бу алты ирнең нибары ике-ике сәгать ярым эш вакытлары калган. Нәрсә генә майтара ала инде алар бу килештән?

— Теләсә нишләгез, иптәшләр,— дидем мин, кискен итеп,— кайтып төшке ашны ашап киләсезме яки кайтып тормыйсызмы — анысы сезнең ихтыярда. Ләкин кичкә шушы салам эскертенең һич югында яртысы көрәлгән булырга тиеш! Иртәгә моннан салам ташый башлаячакбыз. Әгәр эскерт көрәлмәгән булса, җавабын үзегез бирерсез!

Башкалары, көрәкләрен алып, эшкә керештe. Тик Галләмов Закир агай гына урыныннан кузгалмады. Миңа карап, мыскыллы итеп елмайды да:

— Без тырышып караганыек та, барып чыгар төсле тоелмады шул, прсидәтел, кары бик калын булып чыкты,— диде.— Шуңа кәрт сугарга

тотындык. Әйдә, алай бик оста булсаң, мә, минем күрәкне ал да үзең күрәп күрсәт әзрәк. Бәлки, син булдыра алырсың, бәлки, мин җаен белми торганмын!

Шулай диде дә күрәген сузды. Мин бер мәлгә аптырап калдым. Белеп торам: эш авыр булганнан әйтми ул моны. Шабашниклыкта йөрүеннән тыеп, төшемле эшеннән мәхрүм иткәнгә шушылай кылана. Минем ачуны китерергә, мине кычкырта башларга маташа. Әгәр мин хәзер дулап китеп, кычкыра-сүгенә башласам, ул миннән дә катырак тузыначак. Аннары артымнан көлеп калачак, үзен җиңүче санап, күңеленнән тантана итәчәк... «Юк инде, Закир абзый алай гына мәтәштерә алмассың син мине»,— дип уйладым да, ялт итеп кулыннан күрәген тартып алып:

— Бар, хәзер үк, менә шушы минутта ук кайтып кит моннан, корткыч! Үзең эшләмәвең генә җитмәгән, башкаларны да оскыртып ятма! Ахмакка санама син мине, карталарның синеке икәнлеген белми икән дип уйлама! Бар, шушы секундта ук югал күз алдымнан! Калганын кичен, идарәдә сөйләшербез! — дип куа башладым тегене.

Күрәсең, минем сүзне уенга алырга ниятләде булса кирәк, Закир агай башта:

— Җә инде, ул тикле чәпчемә, уйнап әйткәнгә дә кызып китмә алай,— дип карышып маташты.

Бәлки миңа, чыннан да, шунда үземне кулга алып, тыелып калырга кирәк булгандыр. Әмма бер кызгач туктала алмадым:

— Бар, ычкын яхшы чакта, югыйсә ахыры өчен мин җавап бирмим!— дип, күрәк белән өстенә бара башладым. Закир абзый да эшнең уен түгел икәнлеген сизенде, ахры, үз алдына сүгенә-сүгенә шыпырт кына кайтып китте.

Ә мин, җан ачуым белән тегеләр янына барып, кар күри башладым. Минем дуамаллык аларга да күчте булса кирәк, тегеләр дә кызыпкызып эшләргә тотындылар. Дүрт сәгать буена беркем бер авыз сүз әйтмичә, пыр тузып эшләдек без. Бары шуннан ары гына, ниһаять, алтмышка җитеп килгән Саттар абзый телгә килеп:

— Әйдә, Өлфәт туган, бер пыскытып алыйк булмаса! Хәйран каты эшләп ташладык бит,— диде. Бүреге белән маңгай тирен сөртеп алды.

Дөресен генә әйткәндә, мин үзем дә аны кызгана башлаган идем инде, тик башлап сүз әйтергә уңайсызланганнан гына дәшми тора идем. Шунлыктан бу тәкъдимен бик рәхәтләнеп элеп алдым:

— Әйдә, Саттар абзый, тартып җибәрегез, булмаса!

— Ну усаллык та бар икән үзегездә, Өлфәт туган! — диде Саттар абзый, тәмәкесен төреп тарта башлагач.— Ну кызык иттең син безне бүген! Эт итеп кыйнап киткәннән дә болайрак булды инде бу!

— Ачуны китердегез бит, Саттар абзый! Минем урында булсаң, син дә карта уйнап утырган өчен рәхмәт әйтмәс идең. Миңа гына кирәк түгел ич бу салам, үзем өчен йөрмим ләбаса!

— Беләм, энем, бик әйбәт беләм. Шуңа күрә үпкәләмим дә миңа!..

Кичке сәгать алтыга кадәр эшләдек без ул көнне. Теге агайларның ник берсе сукранып карасын, ичмаса! Сукранырлар иде дә, мин дә шунда, алар белән бергә эшлим бит. Шуңа сер бирәселәре килми. Тагын берәр сәгать эшләсәк, эскертне бөтенләй күрәп үк бетерергә мөмкин булыр иде, күп калмаган иде ул. Ләкин һәр нәрсәнең бер чамасы була бит. Сүземне сүз итәм дип, әтием яшендәге ул өлкән агайларны да аяктан екканчы эшләтергә ярамый ич инде!..

Менә шулай, туган. Шул хәлдән соң Закир агай минем белән сүз көрәштерүдән туктады. Кая кушсалар да, майлаган шикелле эшләп йөри башлады. Әмма шуннан ары барысы да ал да гөл булып китте дигән сүз түгел әле. Соңыннан да байтак булгалады андый чәкәләшүләр.

Гомеремдә онытасым юк, Таифә исемле бер бик чая хатын бар иде Көрнәледә. Беркемгә сүз әйтергә ирек бирми, һичкем белән исәпләшми. Кайчан тели — чыга да китә авылдан. Ачулана башласаң, авызыннан утлар чәчеп:

— Сезнең ике-өч йөз грамм икмәгегез белән бер башым ул алты баламны ничек итеп туйдырыйм мин? Мине бик эшләтәсегез килсә, тәрбияләгез әнә шул балаларны: ашатыгыз да, өсләрен-башларын да карагыз! — дип, бөтен дөньяны сасытып, чәрелдәргә тотына.

— Нигә бер башың буласың, ди? Ирең бар бит синең, Таифә апа! — дисәң, тагын да ныграк тузына башлый:

— Аның ише ирнең булуыннан булмавы мең артык! Бала тудыртудан бүтәнне беләмени соң ул? Аңа ышанып ятсаң — ике ай да яши алачак түгел ул балалар!

Бер уйлаганда, Таифа апа да хаклы. Ире, үзе сау-сәламәт булса да, чыннан да, төнтек, пешмәгән бер бәндә аның. Йорт-җир эшен белми дә, белергә теләми дә. Тормыш итү өчен дә пошынмый. Хатыны тапканны ашап, хатыны юнәткәнне киеп тик йөри. Фермада төнге каравылчы булып эшли ул. Көннең көн буе буш, эшсез. Аның урынында башка берәү булса, һич югында чабата ясап сатар, я итек басарга өйрәнер иде. Инде аларың ук эшләмәсә дә, ичмаса, йорт-җирен, каралтысын ныгытыр иде. Ә бу аркылыны буйга да алып салмый. Каравылдан кайткач, шешенгәнче йоклый да торып ашаганнан соң пожарныйлар янына килеп, әкият сата, тәмәке пыскыта. Әйткәләп тә карадым инде үзенә, әмма файдасы булмады...

Ә хатыны Таифә апа — ут борчасы! Юньләп авылга кайтып та керми. Я район үзәгенә алып барып сөттер, каймактыр сата, яки авыл буйлап май, йомырка җыеп йөри дә Казанга чыгып китә. Авылда арзанрак алып, шәһәрдә кыйммәткәрәк сатадыр инде, күрәсең. Бару-кайтуына киткән расходларыннан соң күпме табышы каладыр,— анысын белгән кеше юк. Ләкин йөри. Бигрәк тә колхозларда кызу эш барган чорларда — печән, урак өстендә һәм бәрәнге алган вакытта бик еш югала ул. Шунысына бик эчем поша минем.

Бер тарыдан ботка пешереп булмый, билгеле. Таифә апа юньләп эшләмәгәнгә карап кына колхозга әллә ни зур зыян килмәс иде. Ләкин яман чир тиз йогучан бит ул. Андыйлар бер Таифә апа гына түгел авылда, байтак. Кызып урак урган көннәрдә тагын да күбәеп киттеләр. Берничәсенең өенә барып, ташлагыз бу эшегезне, соңгысы булсын, дип оялтмакчы, тәртипкә китермәкче булган идем, авыз ачарга да ирек бирмәделәр. Әйтерсең, алдан ук сүз берләшеп куйганнар — барысы да бертөрле сөйли:

— Нигә нәсел үгезе шикелле тап-таза ире булган Таифәгә сату итеп йөрергә ярый да, нигә безнең ише тол хатыннарга йөрергә ярамый? Аннан кай җиребез ким безнең? Тыясың икән, башта Таифәне тый, прсидәтел! — диләр.

Миңа шуңа күрә Таифә апаның «гастрольләренә» чик куярга булдым мин. Бер көнне Казаннан кайтып килешли очратып, идарәгә алып кердем дә:

— Соңыннан үпкәләштән булмасын, Таифә апа, әйтүем шушы: әгәр дә мәгәр урак беткәнче авылдан чыгып киткәнеңне сизсәм — тотам да, спекулянт итеп, милициягә озаттырам мин сине! — дип кисәтеп куйдым.

Ул үзе дә бу юлы алай карышып тормыйча, ризалашкан төслерәк итеп чыгып киткән иде. Шул сөйләшүдән соң өч-дүрт көн үтүгә, ни күзем белән күрим, чиләк-көянтәсен аскан да бакча артлатып кына таң тишегеннән тагын Казан каласы ягына китеп бара бит бу! Минем дә кан кызып китте хәзер. Тиз генә куып җиттем дә каршына бастым.

— Борыл, Таифә апа!

Башта каушабрак калды булса кирәк, күзләрен ялтыратып, сүз әйтә алмыйча торды. Аннары кинәт кызарып-бүртенеп чыкты. Гадәттәгечә, ни әйткәнен дә уйлап тормастан, чәрелдәргә тотынды.

— Чукынып кына китсәңие, энем Өлфәт! Алланың каһәре генә төшсәе үзеңә! Инде котылдым бугай дип кенә барадырыем, тәки күзеңне тәреләндереп килеп җиттең бит, ә! Нигә дип, кем өчен дип болай көнтөн чапкан буласың син? Әллә, чынлап торып, безнең калхузны алга җибәрәм дип йөргән буласыңмы? Йөрмә, наный, булмый ул, була торган нәрсә түгел ул бездә! Кая, тотма әле көянтә башын, кызлар түгел мин сиңа! Җибәр, тиз генә барып кайтыйм әле Казанга. Берсекөнгә иртүк кайтып җитәм мин, менә күрерсең, кайтып җитәм!

— Теләсәң ни әйт, Таифә апа, ләкин беркая да җибәрмим мин сине! Әйдә, борыл яхшы чакта!

— Нигә бу тикле каныгасың син миңа, Өлфәт — диде ул, күзләремә ялвару катыш нәфрәт белән карап.— Ни зыяным тигәне бар сиңа? Син борып кайтарганга карап кына барыбер калхузны кинәндерерлек эш майтармыйм бит инде мин! Төшмә лутчы аркылы, җибәр көянтәмне? Ике көндә дөнья харап булмас бит, кайткач тырышыбрак эшләрмен! Башка чакта болай кача-поса сораусыз йөрмәм, билләһи менә, йөрмәм!

Ихтимал, инде әзерләнеп юлга чыккан һәм шушылай ялварып үтенгән кешегә соңгы тапкыр юл куйганда да ярар иде. Ләкин Таифә апаның бу сүзләрне чынлап әйтмәвен белеп торам шул мин. Күп мәртәбәләр сүз биргәне бар инде аның. Ике-өч көннән тагын шушылай тотылса — тагын шушы ук сүзләрне кабатлаячак ул! Хикмәт анда гына да түгел иде әле. Иң ачу китергәне шул: соңыннан, эш узгач, Таифә апаның мактанып йөри торган гадәте бар. Өлфәт миңа бер сүз дә әйтә алмый, әйтсә дә тыңламыйм мин аның сүзен, имеш...

Менә шуңа күрә бүген үз сүземдә нык торырга булдым мин.

— Әйтмә дә, тыңламыйм да, Таифә апа! Борыласың да кайтасың хәзер — бетте-китте! Колхозның урагы урылып бетмичә торып, беркая бармыйсың! Җитте сиңа бүтәннәрне котыртып йөрергә! Әйдә, хәзер үк кайтып, чиләк-көянтәңне калдыр да, урагыңны алып — кырга!

Сүземнән кире кайтмаячагым кыяфәтемә үк чыккан иде, ахрысы, Таифә апа тәмам өметен өзеп, җан ачысы белән соңгы сүзләрен әйтергә кереште.

— Алланың әче каһәре генә төшсен, имансыз җан! Җир генә йотсыные үзеңне, сары тәре! Кансыз ук икәнсең! Юньле бәндә булсаң, багалмасы шикелле хатыныңны куып җибәрмәсиең син! Гомергә буйдак булып калсаңые, бер ходаем, гомергә хатын таба алмасаңые, тфү!

Лачкылдатып битемә төкерде дә җир акырып еларга тотынды. Минем урында син булсаң, белмим, нишләр идең икән, туган, әмма минем шуннан соң да түзеп торырлык хәлем калмады. Башкасына исем китмәгән иде минем, алары — көн дә ишетелеп тора торган сүзләр. Ә менә хатын мәсьәләсенә кагылгач, йөрәгемне нидер чәнчеп алды да, үземне үзем белештермичә:

— Ах, син әле шулаймы! — дип кычкырып җибәрдем һәм Таифә апаның бер чиләген йолкып алып, бакча киртәсенең казыгына китереп тә ордым. Яньчелеп үк китте чиләге. Аннары, туктале, эчендә нәрсә бар иде икән соң моның, дип чиләкнең авызын бәйләгән иске яулыкны чишеп карасам — йомырка икән! Бер чиләк йомырканың барысы да сытылып беткән иде. Оят та, кыен да булып китте миңа. Әмма нихәл итәсең соң инде? Бер секунд, бары тик бер секунд кына харап итте бөтен эшне!

Мин тилмереп, гафу үтенмәкче булып, башымны күтәреп карагандa Таифә апа, сыңар чиләген тотып, йөгереп дип әйтерлек тиз-тиз атлап, арт капкаларыннан кереп бара иде инде.

Нигә алай итүемнең сәбәбен үзем дә аңламыйча, бик мөһим эш башкаручы кешедәй, мин чиләктән йомырка кабыкларын санап читкә алып

атарга тотындым. Минем исәп буенча, туксан жиде йомырка булган булып чыкты. Димәк, мин Таифә апага йөзләп йомырка табып бирергә тиеш. Анысын гына ничек тә табарга булыр иде әле, иң хәтәре шул: бөтен авылга, авылга гына түгел, бөтен районга хәбәр таратачак бит ул хәзер! Их, үзем дә инде!.. Шул тикле булырга ярыймы соң?!.

Кабыкларын чүплəп бетергәннән соң ярты чиләккә якын йомырка эче калды. Моны кая куярга инде хәзер? Таифә апага илтүдән фәтва юк — барыбер алмаячак...

Уйладым-уйладым да йомырка тәбәсе пешертеп, механизаторларга илттерергә булдым. Урак өстендә төшке ашны аларга колхоз исәбеннән ашата идек. Көн дә аш та аш кына димәгән, йомырка да ашап карасыннар әле бер!

Шул фикер башыма килгәч, күңелем күтәрелеп китте. Чиләкне тоттым да механизаторларга аш пешерүче карчыкка алып барып бирдем.

Мин Хәерниса карчыклардан чыкканда, урагын иңенә салып, Таифә апа каршыма килә иде. «Ну була хәзер хәлләр! Бөтен авылны жыя инде бу!» дип котым да калмаган иде. Ләкин алай булып чыкмады. Таифә апа бер сүз дә дәшмичә генә аска карап, кырга урак урырга китте. Бу хәлне болай гына калдырыр дип һич тә көтмәгән идем мин. Ләкин ул шул көнне кич, уртанчы кызын жибәреп:

— Иртәгә кичкә йөз дә ун йомырканы табып китереп биргән булсын штубы! — дип кенә әйттерде дә, мин колхоздан тиешле йомыркаларын илттерткәч, бу хакта сүз кузгатып йөрмәде. Ә бит теләсә — бише белән түләттерә ала иде ул!

## 21

Шуннан соң мин бер дә алай дуамалланмаска, ничек кенә ачу килгән чакларда да сабыр булырга үз-үземә сүз биргән идем. Шактый гомер шул сүземнән чыкмыйча йөрдем дә. Әмма берсендә тәки тыелып кала алмадым. Әле дә бик еш уйланам ул турыда. Бер уйлаганда, үземне гаепләп, алай ук кызып китмәскә кирәк иде дип, үкенеп тә куям. Икенче уйлаганда исә, әле ярый шулай иткәнмен, минем урында булса, бүтән кеше дә нәкъ минемчә эшләр иде, дип үземне-үзем юаткан чакларым да күп була. Ләкин шул фикерләремнең кайсы дөрес икәнен бүген дә өзеп кенә әйтә алмыйм әле. Бик четерекле, бик зур эш булды ул, туган. Менә тыңлап кара әле, бәлки, син аерып бирерсең.

«Ватан»да икенче елымны эшли идем мин ул чакта. Урып-жыю эшләре тәгәлләнеп килә, көзгә чәчүгә чыгарга әзерләнеп йөри идек. Бер дә бер көнне, кырдан, тракторчылар яныннан кайтып килешли, минем туган авыл белән Көрнәле арасындагы Лашман күпере дип йөртелә торган күпердә, һич тә иста-оста юк чакта, Рәдиф очрады миңа. Күпер төбендә бит-кулын юып азаплана иде. Мин сүз катмыйча гына үтеп китмәкче булган идем дә барып чыкмады. Күпергә килеп кергәннән соң арба дыңгырдый башлагач, Рәдиф башын күтәрде дә, мине танып алып, кулы белән «туктап тор әле» дигәнне аңлата торган ишарә ясады. Мин атны туктаткач, күпергә алпан-тилпән менде дә янымa килеп басты.

— Них... нихҗәл, Өлфәт дус? — диде ул, телен чак әйләндереп.— К...аян кил...еш?

— Тракторчылар янына барган идем. Үзеңнең нишләп йөрү? Нигә шул тикле күп эчтең? Аягыңда басып торырлыгың да калмаган бит!

— Ниг-гә эчтемме? Ан-нысын мин үз... һык!.. үззем беләм аның! Дав-вай, син мин-не кай... һык! ...кай-тарып куй әле, яме!

Шулай диде дә арбага менеп утырды. Ул тагын нидер әйтергә талпынган иде дә, бик каты очкылык тота башлагач, туктап калды. Аннары

укшырга тотынды һәм тагын «торып тор» дип ишарә ясап, арбадан төшеп, читкәрәк китте.

— Х-хәзер бетә! — диде ул, байтак азапланганнан соң бераз рәткә керә башлап. Аннары, су буена төшеп, ярга сузылып ятып, су эчеп менде.

Мине үзләренә кунакка чакырган Рәдиф түгел иде инде ул хәзер. Әле утызга гына якынлашып килсә дә, илле яшьлек кешегә охшап, картаеп, ябыгып калган иде. Өстендә дә мин фронттан кайткан вакытта киеп йөри торган зәңгәр галифе чалбар белән зәңгәр гимнастерка түгел, иске граждански чалбар да бөләүләнеп беткән пинжәк. Аягына да әлекке ялтырап торган хром итекләр урынына кыршылып беткән кирза итек кигән. Ә башында бер нәрсәсе юк, чәчләре тузып, күзләренә төшеп тора. Бөтен өс-башы буялып, пычранып беткән.

— Әйдә, Өлфәт, авырсынмый гына авылга кайтарып куй инде син мине, малай! Үләм ату, аяк атлар хәлем дә юк! — диде ул, көн шактый эссе булса да, дер-дер калтыранып һәм хәйран айнып китеп.

— Кайта алмаслык булгач, эчмиләр аны. Теләсәң ни әйт, мин сине илтмим, Рәдиф!

— Дуслык хакына да тыңламыйсыңмы?

— Хатыныңа кул сузган кешене син дус итә алыр иденме соң?

Рәдиф беркавымга тотлыгып калды. Аннары башын аска иде дә:

— Мин нәкъ менә шул турыда сөйләшмәкче идем синең белән, Өлфәт,— диде.

— Нәрсәсен сөйләшәсең аның? Аңлашасын аңлаштык бугай бит инде.

Мин шулай дигәч, ул бөтенләй айнып киткәндәй булды. Җиңемнән тотып, тонган күзләрен мөлдерәтеп, йөземә текәлеп карады да, чын күңеленнән ялварып:

— Әгәр булдыра алсаң, кичер син мине, Өлфәт? — диде.— Зинһар, кичер минем бөҗәкне! Алдаштым бит мин теге чакта: Сәкинәң белән чуалдым дип юри әйттем.

— Соң нигә кирәк булды сиңа безнең тормышны бозу? Ни кызыгын таптың инде шуның?

Ул уңайсызлангандай булып, читкә бераз карап торды да:

— Шул минем урынга сине куясыларына ачуым килүдән булгандыр инде, Өлфәт. Аннары, якын җибәрмәгәнә өчен, Сәкинәңә дә хәтерем калган булгандыр,— диде.

Арбадан сикереп төштем дә каршына килеп бастым:

— Чынлап әйттеңме син бу сүзләреңне, Рәдиф?

— Шушы урынымда җир йотсын, әгәр ялганласам!

— Ә Хафиз карт нигә үзем күрдем диде икән соң?

— Анысы да минем эш иде, Өлфәт, мин котырттым аны ул чакта. Синең белән сөйләшкән кичнең иртәгесен иртүк районга бардым да Хафиз картны утыртып алып кайттым. Менә шунда, юлда кайтышлый, ялган шаһитлеккә күндердем мин аны. Ул чакта ул карт минем кулда иде әле, минем сүздән чыкмый иде.

Аның шушы сүзләреннән соң бөтен күңелем әллә нишләп айкалып китте дә, ни кылуымны үзем дә абайламыйча:

— Җитте, Рәдиф, артыгын сөйләмә! Булды, рәхмәт! Мә сиңа шуның өчен! — дип, башта авызына берне тондырдым, аннары күтәреп алып күпердән ыргыттым.

Ул лапылдап су читенә барып төште дә тынсыз калды, ә мин киләт өнемә килеп, куркып-аптырап киттем: «Нишләдем мин? Әллә бөтенләй харап иттем инде кешене!» дип хафаланып, йөгереп янына төшкәндә Рәдиф әле һаман һушсыз ята иде.

Ни эшләргә дә белмичә бераз торгач, мин аны күтәреп алып менәргә дип кузгалган идем, күпер өстеннән:

— Әй, Өлфәт, Өлфәт! Шулай ук ярыймы соң инде? Харап иттең бугай бит кешене! — дигән тавыш ишетелде.

Күтәрелеп карасам — Закир абзый. Теге вакытта сәлам күрәргә барган җиреннән мин куып кайтарган Галләмов Закир абзый! Күпер тирәсендә генә печән чабып йөрүе икән. Шуннан безнең бәйләнешкәнне карап-күреп торган!

Яшерен-батырын эш итәрлек ара да, чама да юк иде хәзер. Беткән баш — беткән инде, дип уйлап алдым да:

— Әйдә, анда остарып торганчы төш монда, алып менеп арбага салыйк әле үзен! — дидем мин аңа, бер дә исем китмәгәндәй күренергә тырышып.

Без ярты гәүдәсе суда яткан җиреннән тартып алып күтәрә башлагач, Рәдиф бик каты ыңгырашып куйды. Аннары, күкрәген тотып:

— Үләм, кузгатмагыз! Тимәгез миңа! — дип кычкырды.

— Тукта, Өлфәт, кая, куеп торыйк әле! — дип, Закир абзый башта Рәдифне иплэп кенә җиргә яткызды. Аннары тегенең күкрәген, ян-якларын капшарга тотынды. Уң як кабыргасын капшый башлагач, Рәдиф тагын җан өшеткеч итеп илереп куйды.

— Әһә! — диде Закир абзый, нинди дер нәтиҗәгә килеп.— Болай икән эшләр! Ә син алай ук борсаланма, энекәш! — диде ул аннары, Рәдифкә мөрәҗәгать итеп.— Әллә ни куркыныч нәрсә юк монда. Сынса — бер кабыргаң гына сынгандыр. Кабырга сынганнан берәүнең дә үлгәне юк әле. Тик кенә ят, тик ятсаң авыртмас ул! Кая, Өлфәт, су алып кил тиз генә, авыз-борыннарын юыйк, бу килеш адәм күзенә күрсәтә торган түгел бу.

Башымнан кепкамны йолкып алдым да шуңа тутырып су алып килдем.

Хәйран батыр йөрәкле кеше икән Закир абзый: Рәдифнең ыңгырашуына һич исе китмичә, битен ялт иттереп юып алды. Күрәсең, күпердән барып төшкәндә берәр ташка бәрелгән булгандыр, Рәдифнең маңгаенда да яра эзе бар иде. Үги ана яфрагы ябыштырып, аның да канын туктатты. Аннары әйтте:

— Әйдә, Өлфәт, иплэп кенә күтәреп алып меник инде! Җайлап кына арбаңа салыйк та өйләренә илтеп куй син моны!

Ул минутларда минем үз башым берни эшләми иде, Закир абзый кушканны гына үтәп йөрдем...

## 22

Мин Рәдифне алып кайтып, җитәкләп өйләренә керткәндә әнисе Мәсрүрә апа үзенә урын җәеп йөри иде. Күргәнем юкка, күп булса, бер ел үткәндер, әмма шул арада Мәсрүрә апа бик нык ябыгып, тамам карчыкка әйләнгән бичара: чәчләре дә агарып калган, яңакләры да эчкә баткан, сөйләшүенә хәтле бөтенләй үзгәргән. Элек чат-чат килеп, кеше бер сүз әйткәнче унны әйтеп ала торган иде ул. Ә хәзер сабыр гына, теләр-теләмәс кенә әйтә сүзен. Мин Рәдифне алып кергәч тә бер дә алай күтәрелеп бәрелмәде. Хәтта нишләгән, кайда булган, дип тә сорашып тормады.

— Эчеп исерү генә түгел, егылып муены сынса да сүзем юк, олан! — гына диде дә, бүтән бер сүз дә дәшмичә, урынын җәюен дәвам итте. Аннары, үз алдына сөйләнгәндәй генә итеп:

— Пычак та булмас әле! Күзен-башын тондырып, иртәгә ук баш төзәтергә акча сорый башлар! Озаграк ятса, әзрәк иркен сулыш алырыем, ичмаса, ятмас шул! — диде.

Урынын җәеп бетергәч тә, Рәдифкә бөтенләй игътибар итмичә, каршыма килеп:

— Әй, Өлфәт наный, тамам бозылды бит бу малай! Бөтенләй кешелектән чыгып бара инде! Зәфирмылыктан да шул эчкән өчен алып

ташладылар аны.— диде. Рәдиф аерып җибәргән киленен сагынып искә алды.— Бер генә дә килмәгән җире җугые балакайның, бөтен авыл жаратадырые үзен, минем өчен дә, әнкәй дип, үлеп торадырые. Үкенечкә генә булган икән, менә шушы хәерсезнең әчүенә түзә алмыйча ташлап китте,— диде.

Әйе, мин үзем дә бер-ике тапкыр күреп калган идем Рәдифнең ул хатынын. Узган ел педучилище бетереп кенә килгән бер укытучы кызга өйләнде. Буй-сыны да дисеңме, төсе-битеме — бөтенесе бик килгән иде. Балаларны да яхшы укыта дип мактадылар... Күрәсең, түзәр чамасы калмагандыр, шуңа киткәндер Рәдифне ташлап.

Киленен сагынып елап алганнан соң, Мәсрүрә апа миннән: «Өйләндеңме әле?» дип сорады да, мин «юк» дигәч:

— Җөрмә, наный, болай ялгыз, ал да кайт Сәкинәңне! — дип мине үгетләргә тотынды.

Ләкин мин аның үгет-нәсихәтләрен тыңлап торыр хәлдә түгел, башымда мең төрле уйлар кайный иде. Тиз генә саубуллаштым да Хафиз картларга киттем.

Өйләренә кереп тормадым, ишекләрен шакып, оялдына гына чакырып чыгардым:

— Әйт әле, сөннәт бабай, теге чакта күпмегә сатылдың син Рәдифкә? — дидем. Һәм, шырпы сызып, йөзен яктыртып карадым. Башка вакытта бернәрсәгә дә алай шаккатмый торган Хафиз карт бу юлы каушап калды, башта ни әйтергә дә белмичә, ык-мык килеп торды.

— Нигә җавап бирмисең: «Зелпе җыеп йөргәндә күрдем», дип нигә ялганладың? — дидем мин, ярсып.

— Туктале, олан, иплэп кенә әйт әле син: кем әйтте сиңа мин нахак сөйләгән дип? — диде Хафиз карт, ниһаять, үзен кулга алып, батыраеп китеп.

— Кем әйттеме? Рәдиф үзе әйтте! Давай, боргаланмыйча гына сөйләп бир тизрәк: нигә ялганладың син миңа ул чакта? Нигә минем тормышны боздың?

— Сәбәбе шул тамак инде аның, олан,— диде ул, калтыранып.— Тамак тәмугка кертә ул! Үзең дә беләсең, бик авыр заманаларые бит ул чакта. Ә Рәдиф кулында ризык барые.

Синдә генәмени ул тамак, башкаларда юк иде микәнни, дип әйтергә һәм ипи шүрлегенә бер менеп төшәргә бик кыҗрап торсам да, Рәдиф белән бүген генә булган хәлне искә алып, мин үземне тыеп калдым һәм:

— Ярый, урының җәннәттә булыр инде болай булгач! — дидем дә ул кабахәт картның йортыннан чыгып, атыма утырып кайтып киттем.

Гаҗәеп тын, айлы кич иде. Һава саф, салкынча. Сулап туймалы түгел. Ат, ара-тирә пошкыргалап, үз көенә генә атлап кайта. Мин, арбага сузылып ятып, күктәге йолдызларга карап уйланып барам. Кемнәр генә йөрмәгәндер инде бу йолдызлар астында? Нинди генә хәлләргә шаһит булмагандыр инде алар? Хәзер менә мине, мин ахмакны күреп торалар. Мондый да кешене күргәннәре бар идеме икән әле аларның?.. Юктыр, булса да, бик сирәктер...

Нишләргә соң инде миңа? Кая барырга? Рәдиф айныганны көтеп, аның белән үзара мөнәсәбәтне ачыклаганчы шушылай тыныч кына, берни дә дәшмичә генә торып торыргамы? Әллә иртәгә үк улым Ирек белән Сәкинәм янына чыгып китәргәме?.. Вакытының шундый мәшәкатьле чагы туры килүен әйт әле син аның! Бүген-иртәгә көзге чәчү башланырга тора бит! Андый чакта үзең көн-төн карап-тикшереп торсаң да таманга гына килә әле ул. Узган көз, әнә, чәчүлек орлык ташучының бирсен җавапка тарттырмыйча тәки булмады. Үз күзең белән карап эшләтүгә җитми инде ул. Ышан, әмма тикшереп тор, дип тикмәгә генә әйтмәгән инде Макаренко!..

Анысы шулаен шулай да, ә мин чәчү чәчтереп йөргән арада Радиф эшне судка бирсә? Кабыргасы сынган диде бит анда Закир абзый... Хәер, сынмаган булса да, рәхәтләнеп рәшәткә артына тыктыра ала ул мине. Гаепләр өчен маңгаендагы ярасы да бик житкән!.. Шаһит эзләп йөрисе юк: Закир абзый барысын да күреп торган бит! Аның да миңа үпкәсе бар... Юк, сузарга ярамый бу эшне! Үзләрен үк алып кайтып булмаса да, һич югында, Сәкинә белән Ирекне күреп, алларына тезләнеп гафу үтенергә кирәк...

Уйладым-уйладым да болай итәргә булдым, туган: Оренбургта минем әнинең бертуган абыйсы яши иде. Житмешкә житеп килә торган ул ялгыз карт әле быел жәй генә минем янга кайтып, айга якын торып китте. Менә шул абый бик авыр хәлдә икән, тиз генә килеп житәргә кушып, телеграмма суккан дип, үз урыныма беренче бригада бригадирын калдырдым да, иртән иртүк торып, Сәкинәм белән улым Ирек янына юл тоттым.

## 23

Казанга барып, поездга утырганнан соң бик нык пошына, борчыла башладым. Билгесезлек өзгәли иде күңелне. Кем белә анда — Чиләбедә нәрсә буласын? Бәлки, Сәкинә инде күптән башка кешегә кияүгә чыккандыр. Яисә, кияүгә үк чыкмаса да, берәрсен яратып йөридер. Андый чибәр, яшь һәм акыллы хатынга берәрсенең күзе төшмәгәндер дип кем әйтә ала?.. Әгәр мин барып кергәндә ул ире яки яратып йөри торган кешесе белән утыра торган булса?.. Яки фатирында улым Ирек белән икәве генә булып та мине күрергә теләмәсә?.. Алай итәргә дә тулы хакы бар ич аның: үз иркендә яшәүче ләбаса ул хәзер! Дүрт ел ярымнан артык бит инде безнең күрешкәнебез юкка. Ул арада ниләр генә булмагандыр дисең?..

Әгерҗене узганда «әллә барып та йөрмим микән?» дип борылып кайтып китмәкче дә булган идем. Ләкин анинары кире түндем. Юк инде, бер кизәнгән икәнсең, әйдә сук, гомер буе саргаеп, берни белмичә яшәгәнче, ичмаса үз күзләрең белән барысын да күреп-белеп кайтырсың...

Кулымдагы адрес буенча сорашып килеп кергәндә, мине шактый өлкән яшьләрдә булса да әле нык, житез һәм ягымлы гына бер карт каршылады. Башта чак кына сәерсенебрәк торса да, кем икәнлегемне, нишләп йөрүемне белешеп алганнан ары, Фәхретдин абзый кинәт яктырып, ачылып китте:

— Кияү тиешле кеше буласың икән алайса! Әйдә, ишек катында гына торма! — дип, шундук түр якка алып керде.

Өйдә ул ялгызы гына иде. Карчыгының Казанда яшәүче малайларына кунакка киткәнлеген, Сәкинәнең эштә булуын, ә Ирекнең урамга уйнарга чыкканлыгын әйткәч:

— Зыян юк, энекәш, үз вакытлары белән бар да кайтырлар. Ә менә килеп чыгуың яраган, бик әйбәт булган анысы! — диде.

Ике бүлмәле квартирада бер дә житешмәгән нәрсә юк кебек. Аяклы машиналары да, зур гына радиоалгычлары да бар. Стеналарында ике бүлмәдә ике зур-зур келәм. Зал идәнендә дә бик әйбәт берсе бар — өстенә басарга аяк тартмый. «Мондый кешеләрдә яшәгәч, Сәкинә, шәт, азып-тузып йөрмәгәндер әле. Алай булса, Фәхретдин абзый үзләрендә тотмас иде»,— дип бераз тынычланып куйдым мин, аларның өй эчен күздән кичергәч.

— Кунакның ризыгы үзе белән йөрер дип бик дөрес әйткәннәр икән. Какрас чәй өлгертеп тора идем, әйдәле, чәй янында сөйләшеп утырыйк! — дип Фәхретдин абзый мине кухняларына алып керде.

Чәе генә түгел, мәе дә бар икән картның.

— Син, энекәш, миңа үпкәләмә, мин үзем булдыра алмыйм аны. Яшь чагында тоткалый торган идем дә, хәзер ярамый ул миңа. Син үзең чамала инде, яме! — дип сөйләнгәләп, анысын да китереп куйды.

Мин инде байтактан эчмәвемне әйткәч, мине дә кыстап тормады. Гаҗәпләнеп телен шартлатып кына куйды да аерылышуыбызның сәбәбен сорый башлады.

— Ала-а-ай! — диде ул, мин бөтенесен аңлатып биргәннән соң, чалара башлаган мыегын сыпырып. — Алай икән! Ашыгыбрак типкәнсең икән шул тәртәгә, энекәш. Сез, яшьләр, кайчакта ашыгычрак кыланучан шул. — Беркавым тынып торды да дәвам итте. — Туганы булганга болай сайрый инде бу дип уйлама, мин сиңа дөресен әйтәм: бик уңган хатын ул Сәкинә! Кадерен белеп кенә тотарга кирәк булган аны сиңа. Авылдан малаен иртеп килеп кергәннән бирле бездә яши, ник бер әндый-мөндый кыек эше сизелеп карасын ичмаса! Кемнәр генә килмәде инде үзен сорап, берсенә дә әйләнеп карамый. Минемчә, сине оныта алмый бугай ул, энекәш. Үзе сездерергә дә теләми теләвен. Әнә шул искитмәгән атлы булып күренергә тырышуы үзе үк сине яратуының бер билгесе инде ул.

Шунда туктап, икебезгә дә тагын берәр чынаяк чәй ясады да янә сөйләргә кереште:

— Безгә килеп кергәндә йөзенә карарга куркыныч иде Сәкинәнең. Саргаеп, ябыгып беткән иде. Килеп эшкә урнашкач та берничә ай бик боек йөрде. Шәһәр тормышына күнегә алмыйча интекте бугай. Хәзер ияләште инде. Ә малаең тач үзеңә охшаган инде менә! Синеке төсле үк зәп-зәңгәр күз, бакыр чәч, шундый ук калын каш. Хәтта сипкеленә тикле шушылай синеке төсле үк куе, чуп-чуар. Шуңа тиз танып алдым мин сине. Килеп кергәч дигәнем.

— Минем дөньяда барлыгымны беләме икән соң ул малай, Фәхретдин абзый? Әтисе барын беләме, кайда дип сорыймы?

— Сорамыймы соң инде, энекәш! — диде ул, тирән итеп көрсенеп.

— Нәрсә дисез соң аңа? Сәкинә ни дип җавап бирә?

— Ирек өчен — солдат син, энекәш! Әле һаман армиядә хезмәт итә дип белә ул сине. Барыбыз да аңа шулай дип аңлатабыз. Сәкинәдә синең сугыш елларында җибәргән бер рәсемең бар. Шул рәсемне күрсәтәбез Иреккә. Башта әтием безне фашистлардан саклый дип куанып, мактанып йөри иде. Ә хәзер инде, ник кайтмый соң ул, нигә бик озак тора анда, дип аптырата.

Мин ни әйтергә дә белмичә аптырап утырганда, Фәхретдин абзый кинәт кенә урыныннан купты да:

— Әй, бу карт кешенең башкайлары: бер генә дә юньләп эшли белми бит! Үзем сиңа шул малай турысында кайчаннан сөйләп утырам, ә үземнең шуны чыгып апкерергә уема килмәгән. Әйдәле, апкайтыйк әле үзен! — дип мине иртеп алып китте.

Әллә ни ерак та булмаган икән Ирек: күрше йорт ишек алдында иптәшләре белән пыр тузып туп тибеп йөриләр иде. Фәхретдин абзыйны күреп алуга очып кына килде дә картның муенына менеп асылды.

Уф!.. Ул минутлардагы кичерешләремне сөйләп кенә аңлата торган түгел, туган. Уйлап кына кара: малайга инде тугыз тулып килә, ул инде тәмам үсеп беткән, ә мин аны нибары атна-ун көн генә күреп калган кеше бит. Миннән башка, мин юләр атасыннан башка, үскән ләбаса ул! Минем хәлгә калуны дуска дип әйтмим, дошманга да күрсәтмәсен...

Фәхретдин абзый дөрес әйткән: Ирегем бетеп үземә охшаган икән! Күзе-кашы гына түгел, авыз-борыннарына тикле, колакларына тикле нәкъ минеке. Буй-сынга да үзем шикелле үк эре булырсы...

Мин аның атасы, ул миңа әйләнеп тә карамый ичмаса. Тырнак очы кадәрле дә игътибары юк.

— Нишләп йөрисең, бабай, ник килдең монда? Әни эштән кайтмадымы әле? — дип Фәхретдин абзый белән мәш килә. Ә минем аның белән сүз башларга йөрәгем житми. Урынлы-урынсыз сүз ычкындырып, өркетеп, үпкәләтермен дип куркам.

Күрәсең, һаман артларыннан ияреп килүемә сәерсенеп булса кирәк, подъездга кереп баскычтан күтәрелә башлагач кына, Фәхретдин абзый-га елышты да:

— Бу абый ник гел безгә ияреп килә, бабай? — дип сорап куйды.

Җавабы әзер түгел иде булса кирәк, Фәхретдин абзый бер мәлгә тотлыгыбрак калды. Аннары Ирекне мина таба борды да:

— Яхшылабрак кара әле, улым, кемгә охшаган бу абыең? — диде.

— Мин каян белим аның кемгә охшаганын? — диде Ирек, һич тә исе китмичә генә.

— Бу синең әтиең була инде, улым!

Ирек пырхылдап көлеп җибәрде дә, шундук җитди төс алып:

— Ялганлап торма әле, бабай! Нинди минем әти булсын ди бу кеше? Минем әти солдат бит ул! — диде.

— Әтиең инде, улым, алдамыйм мин сине. Солдаттан башта авылдагы әбиеңнәргә кайткан ул. Солдат киемнәрен шунда калдырып килгән. Чын әйтәм, әтиең бу, улым! Көргәч рәсемен алып карарсың әле менә.

— Карап тормыйча да бик яхшы беләм мин: минем әти түгел бу!

Сизеп торам, инде миңа да сүзгә катнашырга, ничек булса да, Ирекнең күңелен табарга, үз ягыма тартып карарга кирәк. Ләкин ул сабыйда үземә хөрмәт уятыр өчен ни әйтергә, әшне нәрсәдән башларга соң? Гадәттә, кеше белән беренче очрашу һәм шул вакытта аның әйткән сүзләре гомер буена сакланып кала бит!

— Әйдә әле, Ирек, берәр уенчык кибетенә алып бар әле син бабаң белән мине! Беләсеңме уенчык кибетен? — дидем мин, ни газапланып та шуннан да юньлерәк сүз дә, тәкъдим дә таба алмыйча.

Үзенә ошаган берәр уенчык алып бирү әллә нинди матур сүзләрдән дә әйбәтрәк булыр, дип уйлаган идем. Дөрес фикер йөрткәнмен икән: шундук күзләре очкынланды малайның:

— Беләм, абый, безнең йорт янында гына ул! Әйдә алып барам! — дип, Ирек мине җитәкләп дип әйтерлек уенчык кибетенә алып керде. Ә инде, үз теләге буенча, башта уенчык машина, аннары кием-салым кибетеннән әйбәт кенә костюм-чалбар алып биргәч исә бөтенләй үз итеп, күптәнге танышыдай, ияләшеп китте. Әй, бу гөнаһсыз сабыйлык!..

Шулай да үз әтисе булуыма Ирек бөтенләй үк ышанмаган иде әле. Әйләнеп кайткач та, әнисенең альбомындагы минем рәсемне алып, байтак кына бер миңа, бер рәсемгә карап торды. Аннары:

— Чыннан да минем әтиме бу, бабай? — дип сорады. Бары тик Фәхретдин абзый тагын бер кат:

— Чынлап та әтиең бит инде, улым! Куркып торма инде, бар, кочаклап ал үзен! Бик сагынып кайткан бит ул сине! — дигәч кенә, кыяр-кыймасрак килеп, алдыма менеп кунаклады.

— Ә син китмисеңме инде, әти? Бөтенләйгә кайттыңмы син? — диде ул, мин куанычымнан тәмам телерер чиккә җитеп, аны озаклап сөйгәннән-үпкәннән соң.

— Минме?.. Китәргә туры килә шул, китәбез, улым. Сине дә, әниеңне дә авылга алып кайтырга килдем. Бик рәхәт безнең авылда! Синең шикелле малайлар да күп. Шулар белән уйнарсың, урманга йөрерсең. Безнең бакча артында гына — урман. Кайткач мин сиңа гармун да алып бирермен әле, яме!

Ләкин Ирек алай тиз генә ризалашырга ашыкмады.

— Ә бабайны алып кайтмыйбызмыни? — диде ул, гаҗәпсенеп.

— Кайтса, аны да алып кайтырбыз, балам!

— Кайтасыңмы, бабай? Кайтабызмы эти белән? — диде Ирек. Ялт итеп, Фәхретдин абзый каршына барып басты.

— Бик кайтыр идем дә, өйдә кеше калмый бит, улым. Мин дә синең белән кайтып китсәм, мәчебез ялгыз кала ич, аны кем карар?

— Әйе шул, бабай, мәче бар бит әле безнең! — Аннары малай кинәт миңа мөрәҗәгать итеп: — Юк, кайтмыйм мин авылга! Әгармунны кайткач посылка белән...

Шунда кисәк кенә ишек кыңгыравы чылтырап куйды. Каян сизенгәндер Ирек:

— Ура! Әнием кайтты! — дип кычкырды да ишеккә атылды.

— Әнием, этием кайтты! — диде ул, ишекне ачканны да көтмичә куанычын белдерергә ашыгып.

## 24

Сәкинә килеп кергәндә үле дә, тере дә түгел идем. Ул да мине күргәч тукталып калды. Минем дә сүз башларга йөрәгем җитми, аның да башлап сүз катасы килми иде, ахрысы. Ярабби! Ул хәзер элеккегә караганда да чибәрләнеп, яшәреп киткән ләбаса! Әй, килешә дә икән соң үзенә шәһәр киеме! Аягында биек үкчәле ялтыравыклы кара туфли, өстендә зәңгәрсу костюм. Чәчләрен кистергән, бөдрәләтеп җибәргән...

Коточкыч кыен хәлдән мине улым Ирек коткарды. Әйтергә көч таба алмыйча торган арада әле Сәкинәгә, әле миңа карангалап алды да, гаҗәпсенеп һәм куанып:

— Әллә танымыйсыңмы, эти? — диде.— Безнең әни бит инде бу! Нигә күрешмисең?

— Шулаймыни, улым? — дигән булып, мин Сәкинә янына бардым һәм ояла-курка гына кулымны суздым:

— Нихәл, Сәкинә? Әйдә, күрешик инде.

Ул озын керфекләрен сирпеп, сагышлы күзләрен күтәреп карады да:

— Әйдә, күрешик алай булгач,— дип йомшак, җылы кулын бирде. Күрешмәгәнебезгә инде күпме гомер узган, эмма шундый таныш, шундый якын, шундый үз кул иде ул! Күңелем шундый тулган, нечкәргән, дулкынлану катыш шатлыгым шундый дәрәҗәгә җиткән иде — авыз ачып бер сүз дә әйтә алмадым. Күзләремнән тәгәрәп чыккан яшь бөртекләрен Ирекка күрсәтмәс өчен, аннан да бигрәк Сәкинә белән сөйләшә башларга сүз таба алмыйча, тиз генә икенче бүлмәгә кереп киттем. Сизми дә калганмын, без Сәкинә белән бер-беребезгә карашып, күрешеп торганда Фәхретдин абзый да шунда кереп утырган булган икән. Мин килеп керүгә:

— Тукта, мин башта үзем сөйләшим әле Сәкинә белән,— дип зал якка чыкты да:— Бар әле, улым, этиең янына кереп тор әле! — дип, Ирекне минем янга кертеп җибәрде.

Ун-унбиш минутлап мыдыр-мыдыр сөйләшкәннән соң, Фәхретдин абзый минем янга керде. Кыяфәте бик җитди иде аның.

— Бик каты тора әлегә, энекәш,— диде.— Ләкин син егет бул! Әгәр иплэп кенә, җаен белеп, егетләрчә сөйләшсәң, алай бик үк этеп җыкмас дип уйлыйм.— Аннары Ирекне җитәкләде дә:— Әйдәле, улым, без синең белән кибетләргә чыгып керик. Атаңның иртәдән бирле ашаганы юк икән, бик ашыйсы килгән, аңа тәмле әйберләр алып кайтыйк әле! — дип сөйләнә-сөйләнә урамга алып чыгып китте.

Күкрәгемнән сикереп чыгардай булып гөрселдәп типкән йөрәгемне тотып, өч мәртәбә тирән итеп суладым да, ниһаять, тәвәккәлләп, олы якка, Сәкинә янына чыктым. Ул өстәлгә таянып, башын ике кулы белән тотып, уйга чумган килеш, аска карап утыра иде. Мин янына килеп баскач та күтәрелеп карамады.

Шунда аны кысып кочаклап, күтәреп аласым һәм, теге чакта сабан туеннан соң озата баргандагы шикелле итеп, онытылып үбә-үбә, зыр-зыр әйләндерәсем килде. Ләкин йөрәгем житмәде. Кочып алырга түгел, чәчләреннән сыйпарга да курыктым. Үпкәләтермен, ачуланыр кебек тоелды. Шул ук вакытта болай багана шикелле басып тору да читен иде.

— Яңагыма чап әле минем, Сәкинә! — дидем мин, уйлап-уйлап та шуннан бүтән әйбәтрәк сүз таба алмыйча.

Ул бөтенләй игътибар итмәде.

— Мин ялгышканмын, Сәкинә!

Күтәрелеп тә карамады.

— Кичерә алырсыңмы икән син мине, Сәкинә? Улыбыз Ирек хакына булса да, кичерүеңне үтенәм мин синнән!

Әллә ташка әйттем, әллә аңа: һаман шулай тик кенә утыра бирде.

— Мин сезне алып кайтырга дип килдем. Бер дә юкка рәнжеткәнмен мин сине. Рәдиф үзе шуны әйтте: «Сәкинәңә ачу итеп, сине минем урынга куясы булганга үч итеп кенә алдаштым мин», ди. Хафиз картны да шаһитлеккә ул яллаган булган икән... Я, әйт инде берәр сүз?

Бары шуннан соң гына башын күтәрде Сәкинә. Мөлдерәп аккан яшьле күзләре белән шактый гомер аптырап, гаҗәпләнеп һәм үпкәләп карап торды да, ниһаять, телгә килде.

— Шулаймыни? Рәдиф шулай дип әйттеме? Шул ук сүзләрне мин үзем дә сиңа әйтмәгән идеммени, Өлфәт?

— Әйтүен әйткән идең дә бит... Үзем ялганлый белмәгәч, мин аңа ышандым тагын... Беләм, кадерлем, авыр сиңа. Авыр булса да, кичер син мине? Улыбыз Ирек хакына кичер! Яратасың бит син мине! Яратмасаң, башта мин сугыштан кайтканчы дүрт ел ярым, аннары минә шушылай тилереп йөргәндә янә дүрт елдан артык ялгыз яшәр идеңмени?

— Кайдан беләсең? Бәлки, мин монда Чиләбедә...

Йөрәк энә кадагандай чәнчеп, авыртып китте.

— Юк, Сәкинә...

— Ярый,— диде Сәкинә, әле һаман агып торган күз яшьләрен сөртеп.— Сине оныта алмавым да хак! Ярый, мин сиңа ияреп кайттым да, ди. Ләкин я сиңа, я миңа ачу итеп, берәрсе тагын берәр нәрсә ялганласа? Ул чакта нишләрсең? Тагын шулай, күземә күренмә, диярсеңме?

— Беркем дә бутый алмас хәзер безнең араны, Сәкинә!

— Дөнья бит ул, Өлфәт. Председатель бит син хәзер. Ә председатель хатыннары турында чәйнәүчеләр күп була ул. Әйдә, үзеңә дә бәла алып, минем дә йөрәгемне бозып йөрмә инде син! Бер кискән ипине ябыштырып торма! Барыбер ныклап ябыштыра алмассың син аны.

— Бернинди кискән икмәк юк, Сәкинә! Рәдифнең вак җанлыгы аркасында килеп чыккан аңлашылмау гына лабаса бу! Аерым яшәсәк тә, күңелем белән гел синең янда, гел улыбыз Ирек янында булдым мин.

— Әллә син мин уйламаган дип беләсеңме, Өлфәт? Яратмаган булсам, сугышка китәренә дүрт-биш сәгать вакыт калганда үзем ияреп кайткан булыр идеммени? Биш елга якын көтәр идеммени, син сугыштан кайтып куып җибәргәч тә көттем мин сине. Көн дә минә килеп җитәр, минә килеп керер дип көттем. Ләкин бу сугыш вакытындагы төсле көтү түгел иде инде. Кавышырга өметләнеп, бергә яшәрбез дип көтү булмады монысы... Сүз катып караучылар да булды миңа. Тик берсенә дә ризалашмадым. Әгәр кияүгә чыгып куйсам, син гаебе булган икән моның, Рәдиф белән типтергән икән бу, дип уйларсың төсле тоелды. Минә ни өчен генә көттем мин сине, Өлфәт!

Мин бу дөрес сүзләргә шаккатып, аңа каршы куярлык бернинди дәлил таба алмыйча башымны иеп, өнсез булып утырдым. Ә ул иләп кенә, ашыкмыйча гына сөйли бирде:

— Инде менә минем турылыклы булуыма, ниһаять, ышангансың икән. Хәзер минем җаным тыныч. Ирекле тол мин хәзер. Нәрсә телим — шуны эшли алам, кем белән телим — шуның белән сөйләшә алам! Ә сиңа кайтасым килми. Куркам! Дуамал син, Өлфәт!

— Туктале син, алай кызма әле, Сәкинә! — дидем мин, җайлы гына башланып киткән сүзнең шушылай куркыныч якка борыла башлавына аптырап.— Ну, булган инде, зур хата эшләнгән... Үз гаебемне танып, алдыңа тезләнеп гафу үтенәм бит менә! Шуңа килдем. Синсез, улым Ирексез яши алмаганга килдем!

— Ничава, яшәрсең әле! Мин дә башта шулай дип уйлаган идем. Син куып кайтарып җибәргәч, әллә батып үлимме икән дип, өч көн рәттән бәке буена төштем. Әни генә тыеп калды: өченчесендә дә, артымнан төшеп, борып алып менде.

— Барысын да бик яхшы аңлыйм! Ләкин мин ул чактагы Өлфәт түгел инде хәзер! Зинһар, кичер син мине? Алдагы матур тормышыбыз хакына кичер! Беләм бит, яратасың син мине! Әйт әле, яратасың бит?

— Шул яратуым аркасында шушылай сызланам да инде мин, Өлфәт... Мин тегү фабрикасында эшлим. Анда безнең барысы да хатын-кызлар. Кай чакта ял вакытларында үзара сөйләшәбез шулай. Беренче мәхәббәте белән, яраткан кешесе белән бәхетле яшәүчеләр сирәк икән. Ә менә үзелеп яратмаган кешеләре белән яшәүчеләр һәм бик әйбәт яшәүчеләр шактый.

— Мәхәббәтсез, болай просто үзең хөрмәт иткән кешең белән яшәү — чын яшәү буламы икән соң, Сәкинә?

— Анысын әйтә алмыйм, Өлфәт. Һәрхәлдә, адәм баласына җан тынычлыгы да кирәк бит. Яратам дип, кимсетелеп яшәгәнче, үзең чын-лап торып яратмасаң да, сине ярата торган, сине кеше итеп саный торган ир белән яшәү артыграктыр, бәлки.

— Нигә һаман шул бер сүзне тукыйсың, Сәкинә? Әйтеп торам бит инде: элеккесе-ахырысы шул!.. Аннары улыбыз Ирекне дә чуттан чыга-рып ташларга ярамый иң.

— Җитәр, Өлфәт, әйдә, туктатыйк бу хактагы сүзне. Никтер күңелем ышанмый төсле минем сиңа.

— Димәк, минем белән кайтмыйсың?

— Юк, кайта алмыйм, Өлфәт!

— Бәлки, син торыр урыныбыз юклыктан, өебез булмаудан курка-сындыр, Сәкинә? Әгәр шулай булса, һич тә аптырама! Бер ай эчендә өй салдырып куям. Тик кайтыгыз гына!

— Әйтәм бит: ышанып җитмим мин сиңа. Холкың дуамал, бер дә юкка көнләшәсең, шуңа шикләнәм.

— Бу юлы кайтмасаң, өй салдыру белән тагын алмага киләм мин сине!

— Йөрмә, Өлфәт. Килмә бүтән!

— Алайса улыбыз Ирекне алып китәргә рөхсәт ит? Ялгызың гына калгач, иркенләбрәк йөрерсең. Сиңа мәшәкате кимрәк булыр! — дидем, болай әйтүемнең һич урынлы булмавын белсәм дә, тыела алмыйча.

— Юк, Өлфәт,— диде ул, һаман шулай тыныч кына,— анысы булмас инде! Аны бик яхшы тәрбияли алам мин. Сугышның иң кыен елларында да артык булмады! Ә хәзер беркемгә дә бирмим мин аны!
Моннан ары да сүз озайтып торуның мәгънәсе юк иде инде.

— Әйтүем шушы, Сәкинә,— дидем мин аңа, кискен итеп.— Синсез яши алмыйм мин. Белеп тор: тагын алмага киләчәкмен!

Шулай дидем дә, Сәкинәмне кинәт кенә күтәреп алып суырып үптем һәм, ул үзенә килергә өлгергәнче тиз генә чыгып китеп, туп-туры вокзал-га юнәлдем.

25

Шулай итеп, йомшак җәйсә дә, шактый катыга утыртып җибәрде мине Сәкинә. Шуның өстенә алда ни булачагы, авылда мине ниләр көткәнлеге ачык түгел иде. Кем белә бит кайткач нәрсә буласын? Бәлки, Рәдиф мине инде күптән судка биргәндер дә мине хөкем итү өчен көтеп кенә торалардыр. Шәһит эзләп тә йөрисе юк — Закир абзый бар. Ике арабызда булган хәлләрдән соң миңа ачу саклап йөрмидер дисеңме аллә аны?.. Колхозда эшләр ничек бара икән? Мин юкта берәр мөгез чыгып куймаса ярый инде...

Чиләбедән әнә шулай уйлап, бик аптырап-алҗып кайттым. Ә кайтып төшкәннән соң мәсьәләнең мин уйлаганнан да четреклерәк һәм куркынычрак икәнлеге мәгълүм булды: Рәдифнең ике кабыргасы ук сынган һәм ул больницада ята булып чыкты!

Башта мин, аллә янына барып, сөйләшеп-аңлашып, гафу үтенеп карыйммы икән, дип уйлаган идем. Ләкин соңыннан, барыбер гафу итмәс, андый кеше түгел ул, тәмле теленне әрәм итеп йөрүдән башка нәтиҗәсе булмас дип, уемнан кире кайттым. Ни булса — шул дип, көтә башладым...

Ә колхоз эше өчен юкка борчылганмын икән. Бер дә андый-мондый хәл булмаган. Барысы да үз җае белән бара. Трактор чәчкечләре дә, атлы чәчкечләр дә әйбәт кенә эшлиләр иде.

Кызык та инде бу тормыш! Сәкинәм белән улым Ирекне тәки алып кайта алмадым. Больницадан чыккач, Рәдифнең ни кылачагы шулай ук мәгълүм түгел. Ләкин мене шундый хәлдә дә кешенең өмете, ышанычы югалмый икән. Чиләбедән кайтып төшкәннән ары ике-өч көн үтүгә үк, райбашкармага барып, өй салдыру өчен агач юллап кайттым. Аннары аны лесхоз эшчеләрен яллап кистердем, үзебезнең колхозда эшләүче автоколонна шоферлары белән сөйләшеп, бер төн эчендә ташытып куйдым да идарә эшеннән бушаган араларда шул өйгә дигән бүрәнәләрнең кабыкларын каезлый башладым. Әйтерсең, минем бүтән хәсрәтем юк, әйтерсең, дөньяда иң мөһим эшем — йорт салу!..

Беркөнне шулай идарәдә иртәнге эшләрне бетергәч, йорт саласы урынга барып, тагын шул бүрәнәләрне каезларга тотынган гына идем, бер ә ү:

— Куеп тор әле, яшти, балтаңны! — дип эндәште.

Әйләнеп карасам — Рәдиф! Кулымнан балтам төшеп китә язды.

— Син икәнсең әле, әйдә, утыр!

Балтамны бүрәнәгә чабып куйдым да, нинди ниятләр белән килде икән инде бу, нәрсә әйтмәк була икән, дип көтә башладым.

Ул бүрәнәгә килеп утыргач:

— Ни хәлләрең бар соң, Рәдиф, нишләп йөрү? — дидем.

— Менә килдем әле,— диде ул. Янчыгын чыгарып, тәмәке төрергә кереште.— Күптәннән күрешкән юк бит, сөйләшәсе сүзләр бар иде синең белән.

— Әйдә, сөйләшик алайса,— дип мин дә аның янына барып утырдым.

Больницадан чыкканнан бирле кырынмый йөргән, ахры, сакал-мыеклары бик җиткән иде аның. Үзе исерек булмаса да, аракы исе аллә кайдан бөркелеп тора, куллары калтырап-калтырап куя. Күрәсең, кичә эчкәнлектән махмырлый иде.

— Син минем больниста ятып чыкканны ишеткәнсеңдер бит? — диде ул, ниһаять, тәмәке төреп кабызгач.

— Андый эш ишетелми калмый инде ул.

— Кабыргаларым сынганын да беләсеңме?

— Анысын да әйттеләр.

— Кайда сынганы да мәгълүммe сиңа ул кабыргаларның?

— Барысы да мәгълүм, Рәдиф.

— Нишләтим икән соң инде мин сине? Таш капчыкка яптырыйммы? Бик ансат яптыра алам бит, теләсәм.

— Әйе, яптыра аласың, әлбәттә. Ләкин сиңа аннан нинди җиңеллек һәм ни файда булыр? Дәүләт судыннан башка кешенең үз суды, үз хөкеме, үз вөҗданы да булырга тиеш ич! Шул хәлгә үзең җиткердең бит син мине. Аннан тыш та байтак этлекләрең бар. Хәтта өемне дә син яндырдың бит!

Инде әйтеп киткәнемчә, өйгә кем ут төрткәнен мин әлегә кадәр төгәен генә белмим. Рәдифкә дә «син яндырдың» дип белеп әйтү түгел, ачу килгәннән генә әйттем. Шунда ул бик аз гына вакытка каушап калды да:

— Ә син күрдеңме мин икәнен? — диде.

— Бөтен хикмәт тә шунда шул — күрмәдем. Күрсәм, шул утның иң кызу янган җиренә тотып аткан булыр идем мин сине!

— Күрмәгәч, сөйләнеп йөрмә!

— Ә минем сөйләнгәнем дә юк, сүз җаеннан үзеңә генә әйтүем.

— Һи! — диде ул, бер-ике минут чамасы уйланып утыргач.— Димәк, куркасың төрмәдән, ә?

— Эш куркуда түгел. Гаиләмнән, җан сөйгән кешеләрдән аерды син мине.

— Ә мин сине шулай да утырттырып куйсам?

— Анысы ихтыярың. Без бер-беребезгә бурычлы түгел инде. Алыш-бирешебез беткән, арабыз өзелгән! Син мине аңларга тиеш, Рәдиф. Үзеңне дә хатының ташлап киткән бит. Шуның хәсрәтеннән тагын да күбрәк эчә башлагансың, шулай ич?

— Эчүен күптәннән эчәм инде мин,— диде ул, тәмәке төпчеген бүрәнәгә басып сүндерә-сүндерә.— Шуңа түзә алмыйча китте дә ул. Акылга керергә бик вакыт иде инде миңа да... Белеп торам, эчүемне ташласам, кире кайтачак минем хатын. Ә менә тыела алмыйм!

Кызганыч иде ул бу минутларда. Йөзе ап-ак, иреннәре кипкән һәм дер-дер калтырана иде. Гаҗәп бит, ә: кеше үзенең ялгыш эшләвен дә белә, әмма шуны төзәтергә көч таба алмый!

— Алайса менә болай итик без,— диде ул, кинәт урыныннан кубып.— Ярый, калдырам мин сине иректә. Үзең өчен түгел, хатының белән балаң өчен калдырам! Давай, син миңа бер литрлык бир дә — син мине белмисең, мин сине белмим. Шуның белән бетсен! Үзең күреп торасың, кәеф шәптән түгел минем, баш бик авырта.

«Шунда да кимсетеп китмәкче буласың, ә, шул көнгә төштеңмени, Рәдиф?» — дип әйтүдән чак кына тыелып калдым да, тагын ачуым чыгып, кесәләремне актара башладым. Кызганычка каршы, янымда бер тиен дә акчам юк иде...

Рәдиф, аксак булса да хәйран тиз атлап, бата-калка барыбер кибет янына китеп барды.

## 26

Ә шул көнне кич мине, бригадирларга наряд биреп, идарәдән кайтырга чыккач, Закир абзый артымнан җитеп туктатты.

— Тыңларга вакытың булса, бер-ике сүзем барые сиңа, прсидәтел,— диде ул.

— Әйтеп кара, Закир абзый.

Ул, нидәндер шикләнгәндәй, як-ягына каранып алды.

— Юк, Өлфәт, урамда сөйләшә торган сүз түгел ул, бик важный мәсьәлә. Бүлмәндә кеше калмадымы анда синең?

— Юк, бикләп чыктым.

— Әйдә, алайса, шунда кереп утырыйк әле.

— Бик мөһим эшмени соң ул, Закир абзый, иртәгә калдырырга ярамыймыни?

— Ярамый, Өлфәт туган. Бүген үк, хәзер үк хәл итә торган эш!

— Мәсьәлә менә болай тора,— дип башлады ул, идарәгә кереп утыргач.— Сезнең авылның теге син кабыргасын сындырган Рәдиф бездә ята. Бик исерек. Авызында теле дә юк. Хатын әйтә, төшкә хәтле үк килеп кергәнне инде, ди. Кергәндә үк салмышые, ди. Үзе белән бер бутилкә аракы алып кергән булган, анысын да эчеп бетерә язган инде. Закир абый кирәк миңа, аны күрмичә китмим, дип әйтә, ди. Председателегез Өлфәтне төрмәгә тыктырырга йөрим, шуңа кирәк миңа Закир абзый, дип әйтә, ди. Мин бүген МТСка гәрүчи алып кайтырга барганыем, әле яңарак кына кайттым да, хатын шушы сүзләрне әйткәч, синең янга йөгердем. Рәдиф йоклап калды. Нишләмәк була икән соң ул, Өлфәт энем? Әллә теге күпердән ташлаган өчен тавыш куптармакчымы икән? Ул хакта ике арагызда сүз булдымы соң?

— Сөйләшкән идек, Закир абзый,— дидем мин, Рәдифнең шулай итенеп йөрүен башыма сыйдыра алмыйча.— Бүген иртән генә сөйләшкән идек.

— Ничек-ничек килеп чыкты соң ул чакта сезнең чәкәләшү?

Мин аңа барысын да әйтеп бирдем.

— Алай икән эшләр! — диде ул, мине тыңлап торганнан соң уйга калып.

— Әйт әле, Закир абзый, ул көнне минем урында булсаң, син ни эшләр идең? — дидем мин, аның фикерен беләсем килүдән бигрәк, авыр тынлыктан котылыр өчен.

— Минме? — ул чигәсен кашыган булып, тула эшләпәсен маңгаена ук төшереп куйды.— Мин синең урында булсаммы?

— Әйе.

— Туктале, башта бер тарих сөйлим әле мин сиңа, наный. Сугыш елларында булган хәл ул. Синең сүзләрне тыңлап утырганда искә төште. Кырык беренче елда, сугыш башланган айларда ук немесләргә әсирлеккә эләктем мин. Кырык өчнең башына тикле алар кулында яшәдем. Бары шуннан ары гына, ничек кирәк алай качып, үзебезнекеләр ягына чыктым. Ишетеп беләсеңдер, әсирнең бөтен тормышы сак астында үтә аның. Эшкә барганда да сак астында, эшләгәндә дә сак астында, кайтканда да сак, кайткач та сак. Бүтәне турында әйткән дә юк инде, дажы бәдрәфкә барганыңны да карап-күзәтеп торалар. Әмма сакчыларның да төрлесе барые. Кайсылары, без-әсирләргә ярдәм итмәсә дә, тәк торганда зыян да эшләми. Кушканың үтәсәң, шул җитә. Ә кайберләре фашисның да фашисы инде. Ничек итеп синең җаныңа тию, кимсетү, мыскыллау турында гына уйлый. Бер көнне шундый кабахәтләрнең берсе безне, биш әсирне, урманга агач кисәргә алып барды. Кышкы салкын көнне. Башта без эшләгәнне карап, ашыктырып, әрле-бирле сызгыргалап йөрде бу. Аннары туңа башлады булса кирәк, мине чакырып учак яктыртты да шуның каршында җылынып утыра башлады. Ә үзенең күзе һаман бездә, «шнель! шнель!» дип туктаусыз өреп тора. Әз генә туктап, тын алырга да ирек бирми. Үзе бик шат, үзләренчә нидер мыгырдана, тинтәк кеше сыман, тик торганда кычкырып-кычкырып көлгәләп куя. Тора-бара учак җылысы да туйдырды булса кирәк, берәр аршын буе саллы гына агач ботагы кисеп алды да шуны безгә атып уйнарга тотынды бу. Ул томыргач, кайсыбызга килеп тисә, агачны шул кешедән китерттерә. Үзе шашып-шашып көлә. Миңа да өч тапкыр эләктерде. Бер сүз дә әйтмәдем, агач килеп тигән җирем бик каты авыртса да, өчесендә дә тыныч кына илтеп бирдем. Бәлки, тынар, кызганыр дип өметләнгәннем. Юк, малай, кая ул сиңа туктау! Әле беребезгә, әле икенчебезгә тондырып кына тора. Шуннан соң дүртенче тапкыр бәрде бу миңа. Бу юлы маңгаема ук туры китерде, күземне чак кына чыгармый калды.

Мин, авыртуга түзә алмыйча, маңгаемнан аккан канны җиңем белән каплап туктатырга азапланган арада, агачын китерергә кушып, автоматы белән янап, тагын акырырга тотынды бит бу. Шуннан мин нишләде дисең? Я тәки атып җыгар, ике дә уйлап тормас, дидем дә дүртенче тапкыр илтергә киттем таягын. Бер кулым белән ярык маңгайны тотканыем, берсендә — тегенең агачы. Мин килеп җиткәч, тинтәк алаша шикелле кешнәп көлә-көлә, башта агачын тартып алды, аннары, кулымны сугып төшереп, маңгайдагы яраны карады да «гуд!» дип кычкырып, яңакка чапты. Ант итеп әйтәм, шуңарчы ул фашиска кул күтәрү турында күңелемә дә килмәгәние. Әмма яңакка чапкач, секунд эчендә әллә нишләп киттем дә, алдын-артын уйлап тормастан, мин дә авызына берне менеп төштем моның! Минем ише коры сөяккә калган, чыкмаган җаны гына булган кешенең сугуы андый эзмәвердәй фашиска нәрсә инде ул? Чебен тешләгән шикелле дә булмагандыр. Ну миңа шуның өчен эләкте! Шундый каты типкәләп кыйнады — ничек исән калганыма әле дә шаккатам. Белмим, ничек атып үтермәгәндер инде. Менә шундый хәлләр... Ну мин шул вакытта бер тамчы да үкенмәдем! Хәзер дә үкенмим. «Вчүтки бер иң әшәке фашисның яңагына чаптым бит әле!» дип, ул заманнар искә төшкән саен, куанып куям.

Чак кына тынып, уйланып торды да Закир абзый тагын дәвам итте.

— Әсирлектән котылганнан соң, үзебезнекеләргә кушылып сугыша башлагач, әй бирдем инде үзләренең дә кирәкләрен: очраган бер немесне пүдрәт кырып бардым. Ник дисәң, үзләре бинават, үзләре җиткерделәр мине шул хәлгә... Инде килеп, син теге аксак малайны тәвәккәлләгәнсең икән. Минем урында булсаң, нишләриең, дип сорыйсың. Кистереп кенә әйтүе кыен, кәнишне. Бер караганда, синең дә сәбәбең җитди. Шулай да күпердән үк тотып атарга кирәк булдымы икән?

— Соң ул Рәдифнең әле генә үзең сөйләп үткән фашисттан кай җире ким, Закир абзый? Бары тик көнчелек аркасында гына минем бөтен тормышымны бозып, туздырып ташлады бит ул.

— Ул яктан караганда, аермасы, ихтимал, әллә ни зур түгелдер. Әмма синең хәл белән минем ул чактагы хәлем арасындагы аерма — җир белән күк арасы бит! Миңа нәрсә: мин тоткындаем ул чакта. Берниндн бүтән чарам да югые минем. Бүген үтерәләрме, иртәгәме — аның анысы әллә ни әһәмиятле түгелие миңа. Ә син бит иректәге кеше! Сиңа башкачарак эшли алырга да булырые... Әй, Өлфәт, турысын әйткәнгә хәтерең калмасын, кызурак канлы кеше шул син, олан! Башың да хәйран яхшы эшли, гаделлегең дә зур, ну кайчакта кирәгеннән артыграк кыланып ташлыйсың. Исендәме, сәлам күрергә барган җирдән мине ничек итеп куып кайтарганыең?

— Ул заманнарны искә алмыйк инде, Закир абзый,— дидем мин, оятымнан нишләргә белмичә.— Атта да, тәртәдә дә булды инде ул чакта.

— Анысы шулай, узган эш. Әмма андый хәлләрне дә искә төшереп алу зыян итми кайчакта. Әйтик, син ул вакытта тузынганда минем дә кызып китүем барые бит. Шулаймы?

— Соң сез, эш эшлисе урында, карта суга идегез ләбаса!

— Анысы хак сүз. Ну бит син әле яңа кеше иең. Нинди эш майтара алачагыңны белмидериек ич әле без.

— Бөтенесен дә бер калыпка сапларга ярамый, Закир абзый. Үз районыбызда да хезмәт көненә әйбәт кенә биреп килүче колхозлар бар иде ләбаса ул чакта да.

— Авызымнан тартып алып әйттең бу сүзләрне! — диде Закир абзый.— Имыннны шулай шул менә. Хәйран хәлле генә колхозлар барые. Ә син аның нилектән алай булуын беләсеңме? Әйтимме сиңа аның галәмәтен?

— Әйтеп кара.

— Хикмәт колхозның дилбегәсе кем кулында булуда, энекәш. Ә без-

дә сугыш башланганнан бирле юньле прсидәтел булмады. Балык башыннан бозыла ул. Рәдиф тә шундый черек булды. Салу белән булышты. Әшнәлек, кода-кодагыйлык хөкем сөрде. Менә шуңа каршы иде халык. Ә хәзер, син ничава гына бүлеп бирә башлагач, тагын эшләргә тотындык бит.— Ул бераз нидер уйланып утыргач кинәт урыныннан купты да сүзне бөтенләй икенчегә борып җибәрде: — Ә син Рәдиф алай-болай эшне зурга илтер дип бер дә шикләнмә. Пычагымны да эшләтә алмый ул! Гаеп үзендә булган ич аның. Шулай булгач, яклый алмыйм мин аны. Бәлки, ул мине шаһит итеп, гаепләүче итеп чакырттырмакчы буладыр. Тотсын менә... Иртән торгач, айныгач бик хәтәр итеп сүгәм әле мин аны!

## 27

Закир абзый белән шушы сөйләшүнең икенче көнендә үк, балта осталары яллап, мин өйне бурата башладым. Рәдиф эшне зурга җибәрсә, бүленеп калуы да мөмкин икәнен дә беләә идем. Шулай булса да, үземә бертөрле үҗәтлек белән, тизрәк йорт җиткерергә ашыктым. Чиләбедән кайту белән Сәкинәгә дә хат яздым. «Кайтырсыңмы икән, Сәкинә? Кайтыр булсагыз, ым гына как — шундук барып алам мин сезне»,— дидем.

Бу юлы озак көттермәде ул. Ун көн эчендә җавап килде: «Әйбәт кенә яшибез, тик син киткәннән бирле Ирек кенә: «Әти кая китте, ник безне калдырып китте, алып кайтам дип әйткән иде бит ул безне, нигә алдалады икән?» — дип аптырата башлады. Ләкин мин һаман шул элекке уемда калам. Юләрләнеп килеп йөрмә! Әгәр кайтырга уйласам, үзебез дә кайта алабыз ла без»,— дип язган иде.

Әнә шуннан соң канатланып йөри башладым мин. «Кайта алабыз» дигән бит! Кем белә, бәлки, шушы араларда ук тып итеп кайтып та төшәрләр дип, көн дә аларны көтеп яши башладым...

Йорт та салынып бетте. Колхоз эше дә ярыйсы бара. Закир абзый җитәкчелегендә арба ясау эшен дә көйләп җибәргән идек. Әйтергә онытып торам икән, сугышка хәтле «Ватан» колхозында арба ясау бик нык алга киткән иде. Көрнәле арбаларын районыбызда гына түгел, күрше районнарда да яхшы беләләр һәм бик теләп сатып алып китәләр иде. Сугыш башлангач, ул эш тукталып кала. Бу ел җәй менә шул хәйран табышлы эшне җайга салып җибәрдек...

Вакыт һаман су урынына ага да тора. Кыш та үтеп китте, яз да килеп җитте. Ә менә Сәкинәнең һаман кайтам дип өзеп әйткәне юк әле. Көтә торгач, сагына торгач, ниһаять, түзә алмадым: килергә кушмаса да, язгы чәчүне әйбәт кенә башкарып чыгып, колхозда бераз эшләр җиңеләйгәч, ял көненә барып керерлек итеп, тагын Чиләбегә улым Ирек белән Сәкинәм янына киттем.

Мин килеп кергәндә Фәхретдин абый карчыгы белән танышларына кунакка киткән, ә Сәкинә белән Ирек өйдә иделәр. Бу юлы Сәкинә дә мине күргәч артык шаккатмады, мин дә беренче баргандагы шикелле телсез-өнсез калып тормадым. Ә Ирек шундук танып алып:

— О-о! Әтием килде. Безне апкайтырга килдеңме, әтием? — дип алдыма ук менеп утырды.

— Әйе, улым, сезне алып китәргә килдем! — дип башта аны кочаклап үбә-үбә сөйдем дә: — Теләсәң нишлә, Сәкинә, ләкин бу юлы сездән башка кайтмыйм мин! — дидем.

Ул көнне тагын нләр сөйләшүебезне тәфсилләп торуның кирәге юктыр, туган. Билгеле, мин әйтү белән үк ризалык бирмәде Сәкинә. Байтак уйланып, икеләнеп утырды. Бары тик Фәхретдин абзый да кайтып:

— Җитәр, сеңелем, һәр нәрсәнең чамасы була! Үзеңне дә, Өлфәтне дә җәберләп, Сак белән Сок шикелле икегез ике якта яшәүгә чик куярга

кирәк инде. Гомер ике килми ул, чәчәктәй вакытыгызны заяга үткәрмәгез! — дип мине яклап бик нык үгетләгәннән соң гына, ниһаять, риза булды.

Шулай итеп, минем дә, ниһаять, дөньям түгәрәкләнде һәм без, чын кешеләрчә, матур гына яши башлаган идек. Әмма...

## 28

Бу урында мин сиңа шактый сәер булган һәм минем чәчләрне агарткан хәлләрне сөйләп китәргә мәҗбүрмен, туган.

Берсе сиңа инде билгеле Гөлүсә аркасында булды. Сәкинәмнән шул шашкын хисле чәчбикә тагын колак кактыра язды.

Теге чакта институтка килеп сөйләшүдән соң, ул мине аңлаган сыман булган иде. Йомышы төшеп, идарәгә килгәндә, урамда очраган вакытларында, гадәтенчә үтә ягымлы, үтә ачык сөйләшсә дә, күз карашы белән һаман әле мине яратуын сиздерсә дә, тел белән әйтеп, әрсезләнеп йөрмәде. Мин үзем дә мөмкин кадәр җитди, рәсми булырга тырыштым һәм бер дә алай икеле-микеле уйланырга урын калдырмаган шикелле идем. Әмма ул өметен өзмәгән, һаман мине көтеп, ышанып йөргән икән. Ә өмете өзелгәч...

Инде әйткәнемчә, Сәкинә белән Ирекне алып кайтып, куанып-шатланып эшләп йөри башлаган чагым иде ул. Август ае ахырларында бер көнне районга барырга дип ат җигеп тора идем, шул укытучы Гөлүсә яныма килде дә:

— Сезне районга бара икән дип әйткәннәр иде, зинһар, мине дә утыртып алып барыгыз әле? — диде.

— Йомышыгыз бармы, әллә теге чактагы шикелле болай гына барырга уйладыгызмы? — дидем мин, шактый кырыс итеп.

— Ә сезгә барыбер түгелмени, Өлфәт абый?

— Юк, барыбер түгел, Гөлүсә! Йомышыгыз булса гына алып барам мин сезне.

— Йомышым бар иде шул, Өлфәт абый! — диде ул зәп-зәңгәр күзләрен очкынландырып.

— Барырсыз инде алай булгач, авыл мөгаллимәсен калдырып китү ярамас. Кайтыгыз да әзерләнеп, көтеп торыгыз. Китешли ала китәрмен.

Ул кинәт яктырып:

— Ә мин инде әзер! — диде дә башта кулындагы портфелен тарантаска китереп куйды, аннары үзе менеп утырды.

Киттек без моның белән. Башта ул да ничектер уйчанланып, моңланып, миңа сүз катмыйча гына барды. Мин дә көннең матурлыгына, җылылыгына рәхәтләнеп, кырдагы игеннәребезнең инде җыелып бетеп баруына куанып килә идем. Үзебезнең «Ватан» межасын үтеп, Качкалак урманы дип аталган кечерәк кенә урманга барып кергәч, Гөлүсә кинәт миңа сыенарак төште дә, күзләрен майландырып:

— Беләсеңме, Өлфәт абый, бу юлы да бер йомышсыз килəм бит мин синең белән! — диде.

Мин эсселе-суыклы булып киттем. Атны туктаттым да, ачуланып:

— Нигә болай юләрләнеп йөрисез сез, Гөлүсә? Әйдә, төшегез тарантастан! — дидем.

— Ә син тыңлап бетер, Өлфәт абый! — диде ул, кырыслыгыма һич тә исе китмичә.— Әйе, минем районда бүген дә бер йомышым да юк. Ләкин минем синең белән бергә, бер тарантаска утырып барып кайтасым килде. Соңгы мәртәбә синең белән бергә утырып каласым килде минем, аңлыйсыңмы син шуны, Өлфәт абый, соңгы мәртәбә дип әйтәм мин сиңа!

— Аңлавым ни дә, аңламавым ни...

— Аңласаң, мине кума, Өлфәт абый, яме! Хәтерендәдер, кырык

алтынчы елның кышында синә утырып кайтканда, «син өйләнмичә шушы Көрнәледән китмим», дигән идем мин сиңа. Менә мин сүземдә тордым: син Сәкинәңне алып кайтмыйча китмәдем. Ә хәзер китәм! Ронодан расчет алдым инде мин. Хәзер миңа монда яшәүнең бер кызыгы да юк. Әйдә, туктатма атыңны, йомышым булмаса да, үзең белән алып барып кайт инде син мине бүген. Биш-алты ел үзеңне яратып йөргәнем өчен, бер кечкенә генә теләгемне үтә әле, ичмасам.

— Зинһар, җыен юк-барны сөйләмәгез әле, Гөлүсә! — дидем мин, тәмам аптырашка калып.— Безнең ике арада берниндн гыйшык-мишык та була алмаячагын аңларга күптән вакыт иде бит инде сезгә!

— Акыл белән мин үзем дә шулай уйлый идем,— диде ул, сабырлана төшеп.— Үземне шуңа ышандырырга тырышып та карадым. Ләкин, акылдан тыш, йөрәге дә бар бит әле адәм баласының. Аны берничек тә акылга буйсындырып булмады шул. Нигә шулай каршылыклы икән бу кеше тормышы? Син яраткан кеше нигә сине яратмый икән? Нигә син үзең күрергә дә теләмәгән кешеләр синең өчен саргаеп-кибеп йөри икән? Шушы Көрнәледә генә дә ничә егет йөрде артымнан! Ә мин аларга әйләнеп тә карамадым. Неужели шулай үзем яратмаган кеше белән гомер итәргә туры килер миңа да?

Мин, хәтта инде нигә бүген районга барырга чыгуыма үкенеп, үземне-үзем тиргәштереп бара идем. Гөлүсә иңнәремнән тотып, илереп күзләремә текәлгәч, башта әллә тарантастан куып төшеримме дип тә уйладым. Ләкин аның йөзендәге сагышны, үкенүне һәм газапны күргәч, ул уемнан кире кайттым да, юатырга тырыштым:

— Борчылмагыз, Гөлүсә, нигә алай булсын ди! Сез дә яратырсыз әле, миннән йөз мәртәбә акыллырак, шәбрәк кешене яратырсыз! — дидем.

Ул күзләрен мөлдерәтеп тагын бераз миңа текәлеп карап барды да:

— Мин үз хәлемне үзем беләм, Өлфәт абый, син миңа акыл биреп азапланма инде, яме! — диде.

Юатыр сүз таба алмаганлыктан, мин дәшмәдем. Аны ишетмәгәнгә салынып, атның дилбегәсен кагып куйган булдым. Ат җиңел генә юртып китте. Чокыр-чакырлы урман юлы тарантасны шактый нык чайкый башлагач, Гөлүсә тураебрак утырды. Мин, үзен кулга алды, ахры, бу кызыкай дип, җиңел сулап куйдым. Ләкин шул чак һич тә көтелмәгән бер нәрсә булды. Гөлүсә кинәт минем кулдан дилбегәне тартып алды да, атны шып туктатып, йөрәк тавышы белән:

— Их, Өлфәт абый! — дип куйды. Аннары ниндидер бер кыргый көч белән кочып алып, яшькә чыланган озын керфекләрен битемә тидерә-тидерә, мине үпте.

Кайнар иреннәре биткә тигәч, мин дә аны кочып үпми калалмадым... Акыл белән түгел, ничектер үзем дә сизмәстән...

Нәкъ шул чакны якында гына:

— Алла куәт бирсен, Өлфәт абый! — дип кычкырып көлешә башлаган малайлар тавышын ишеттем һәм, ни әйткәнемне үзем дә абайламыйча:

— Рәхмәт! — дип куйдым. Корт чаккандай сискәнеп, тарантастан сикереп төштем дә тавыш килгән якка бара башладым. Ләкин көлешүчеләрнең берсен дә яхшылап күрә алмый калдым: алар куелыкка йөгерешеп кереп киттеләр, артларыннан куак ботаклары гына селкенеп калды. Миңа шунысы гына ап-ачык иде: ул малайлар — чикләвек җыярга килгәннәр һәм мине белә торган малайлар...

Мин юлымны дәвам иттем, ә оялуыннан мәк чәчәге төсле кызарган Гөлүсә исә:

— Кичер, Өлфәт абый, мин юләрне, минем аркада килеп чыкты бу,— диде дә авылга кайтып китте.

Кичен мин районнан әйләнеп кайтканда Сәкинә өйдә юк иде. Мине

ташлап, Янтыкка, үз авылларына кайтып киткән иде ул. Теге безне урманда күргән малайлар арасында минем Ирек тә булган икән һәм ул кайткач әнисенә барысын да сөйләп биргән. Башка чакта шундый сабыр Сәкинәм бу юлы түзә алмаган, Ирекка: «Әтиең минем арттан килеп йөрмәсен», дип әйтеп китеп үк барган.

Гөлүсә дә урманнан борылып кайтып, әйберләрен жыештырган да үз якларына кайтып киткән булып чыкты.

Шулай итеп, тагын Сәкинәсез калдым мин. Шул ук кичне артыннан барсам да, кайтырга түгел, сөйләшергә дә теләмәде Сәкинәм. Мин күргән ишек ябылганчы ук өйләреннән чыгып китте.

Көн саен диярлек Янтыкка барып, кайтырга айдан артык өндәвемә дә карамастан, Сәкинәнең һич тә кайтыр исәбе юк, һаман шулай бик нык хәтере калган килеш тора, йомшар чамасы күренми иде. Хәтта ул Янтыкка инде үзенең яраткан эшенә дә урнашкан, үзебезнең «Ватан»дагы шикелле үк, сыерлар сава башлаган иде.

Белмим, мондый аяныч хәл тагын күпмегә сузылыр иде икән, ләкин үз башы житептерме, кеше киңәше буенчадырмы, Гөлүсә үзе бозган эшне үзе жайлады бит, туган. Күрәсең, Көрнәледә калган дусларыннан берәрсе безнең аерылышуны һәм аның сәбәбен хәбәр иткән булгандыр инде, бер дә бер көнне яңа урнашкан эш урыныннан — Актаныш ягыннан минем Сәкинәгә хат язган бу. Ул хатның кайбер юлларын хәзер дә бик яхшы хәтерлим әле мин: «...Ишетүемә караганда, син Өлфәтне миннән көнләшеп ташлап киткәнсең икән, Сәкинә,— дип язган иде ул.— Син мине яхшы беләсең бит, Сәкинә, алдаша торган гадәтем юк минем. Ышан миңа: Өлфәтнең энә очы кадәр дә гөнаһсы булмады ул чакта. Мин, бары тик мин генә гаепле бу эшкә. Яшермим, синең Өлфәтеңне ул сугыштан кайтканнан бирле чын-чынлап яратып йөрдем. Арагыз бозылышып, син аерылып киткәннән соң ятратуымны аңа ачыктан-ачык әйткәләп тә карадым хәтта. Ләкин ул сиңа, бары тик сиңа турылыклы булып калды...

Ә урманда мин аны үзем кочаклап, үзем үптем. Син теләсәң ни әйт, Сәкинә, ләкин, минемчә, алай зурлап шаккатырлык нәрсә юк монда. Ул мине яратмаса да, мин аны алты ел буена сөеп йөргән һәм, дөресен әйтим, син кайтмасаң бәлки үземә булыр дип тә өметләнгән кеше бит... Шул өметем дә өзелгәннән соң сезнең авылдан бөтенләй китеп барырга карар кылгач, күңелем алгысып, хискә бирелеп киткәнмен икән — аннан гына дөнья жимерелмәгәндер бит. Син дә азрак мине аңларга тырыш инде, Сәкинә. Хатын-кыз лабаса син, безнең затның хыялга һәм хискә кайчакта кирәгеннән артыграк бирелеп китүчән булуын үзең дә беләсеңдер... Сүз дә юк, ул чактагы тилелегем өчен соңыннан минем үземә дә бик читен булды. Шуңа күрә, синең күзеңә күренергә кыенсынып, шул ук көнне жыенып, Көрнәледән чыгып киттем дә мин...»

Шушы хатны алып укыганнан соң гына, ниһаять, игә килде Сәкинәм. Шуннан соң гына без, ниһаять, яңадан кавыштык.

Кавышуын кавыштык, әмма ул арада минем чәчләрнең яртысы агарырга өлгергән иде инде.

## 29

Кайбер кешеләр яртылаш агарган чәч белән дә шактый гомер йөриләр. Ә кайберәүләрнеке тәмам соңгы көннәренә тикле шулай яртылаш агарган килеш кенә кала. Әгәр тыныч кына, борчылмыйча, пошынмыйча, янмый-көйми генә яшәгән булсам, ихтимал, мин дә шул яртылаш агарган чәч белән хәзергәчә йөргән булыр идем. Ләкин алай йөри торган кеше түгел шул мин. Алай йөри дә алмыйм.

Сәкинә белән кавышып, матур гына яши башлагач та, үземнең әлеге кыбырсык холкым аркасында, байтак кына читен хәлләрдә калгаларга туры килде. Хәтерлисең булыр, илленче елларның азагында авыл хужа-

лыгын алга җибәрү өчен кукурузны күбрәк чәчәргә кирәк дип аңлата башладылар. Һәр колхозга аерым-аерым план җиткерелде. Безнең «Ватан» да ике йөз гектар чәчәргә тиеш булды аны. Шуннан соң бик нык пошаманга калдым мин. Чәчүен чәчәрбез дә, унбиш мең пот бодай үсәчәк җир әрәм булып калмасмы?..

Шикләнергә урын да бар иде. Сугыш елларында Михайло исемле бер украин егете белән бергә хезмәт иткән идем мин. Шунда без бик нык дуслашып киттек һәм соңыннан да хат язышып тора башладык. Ул инде сугышка кадәр үк институт тәмамлаган кеше иде. Сугыштан соң үз авылларында агроном булып эшли башлады һәм хатларында кукуруздан бик зур уңыш алуларын әйтеп яза иде. Шуннан кызыксынып китеп, мин аннан бер гектарлык кукуруз орлыгы соратып алдырып, үзебезнең кырга чәчеп карадык. Ләкин ул безне көткәнчә үк куандыра алмады, ни тырышып тәрбияләсәк тә, телгә алып әйтерлек уңыш бирмәде.

Менә шуңа күрә башта илле гектар гына кукуруз чәчтек без. Ихтимал, юл буена сузып, үткән-барган кешегә биш йөз гектар булып күренерлек итеп чәчелгән булгангадыр инде, районнан килеп карап киткәләсәләр дә, башта аны-моны әйтүче булмады. Әмма кырын эш кырык елдан соң да беленер дип бер дә юкка гына әйтмәгәннәр шул. Көзләр җитеп, уңыш җыю көннәре башлангач, шул эш өчен мине шактый нык итеп башта «пешекләделәр», аннары шелтә элэкте.

Анысыннан арынып күп тә эшләмәдем, тагын бер шелтә — бу юлы инде катысы ук. Бер вакыт безнең хуҗалыкка да тавык һәм үрдәк үрчетә башларга кушылды: тавыгы ике меңнән артык, үрдәк мең ярым булырга тиеш иде. Шул чак тагын аптырабрак калдым, туган. «Тавык-чебеш» кенә булсалар да, аларга да тәрбия кирәк лабаса. Үсеп җиткәннән соң итләре бик тәмле дә соң, ләкин үсеп җиткәнче ярты картайта бит әле алар сине. Колхозчының йортында күп дигәндә ун-унбиш баш чебеше була һәм аларны бала-чагасы, карчык-корчыгы туктаусыз ашатып-эчертеп, кош-корт күзеннән саклап тора, ләкин шулай да әлеге ун-унбиш чебешнең барысын да исән-сау килеш үстереп җиткерә алучылар бик сирәк ич... Ә монда, мә сиңа, меңләгән тавык-үрдәк үстерергә кирәк!..

Ярый, тавыкларын ничек кирәк алай үстерергә дә булыр ди инде. Нәни чакларында тилгән-козгыннардан, исәя төшкәч төлке һәм сасы көзәннәрдән саклап кала алсак, тавык планын ничек тә үтәрбез. Ә менә үрдәкләр мәсьәләсен ничек хәл итәргә?.. Ник дигәндә, су юк бездә. Кечкенә-кечкенә өч бөртек чишмәдән агып чыккан су күпме генә инде ул? Буып куйганнан ары да мең ярым үрдәк берьюлы сыярлык булмаячак!..

Шулай да тавык чебиләрен дә, үрдәк бәбкәләрен дә алып кайттык без һәм кулдан килгәнчә тәрбия итә башладык, туган. Күпме тары ярмасы, күпме он ашаттык, тик файдасы гына булмады. Үрдәк бәбкәләреннән элек тавык чебиләребез кырыла башлады. Аннары канат чыгып, тәмам исәеп килә башлагач, ниндидер чир йогып, үрдәкләребез үләргә тотынды. Ветврачлары да ул чирнең серенә төшенә алмады. Без үзебез аны иркенләп йөзәрлек су булмаганнан күрдек.

Әллә соң кошчылар юньләп тәрбияләмиләр микән дип, аптырагач, сыер савудан алып, бер сукранырак йөри торган хатын урынына үземнең Сәкинәне дә куеп караган идем. Барыбер нәтиҗәсе булмады.

Икенче елны, әле кар бетәр-бетмәс борын ук, инкубатордан үрдәк бәбкәләре килеп алырга шалтыраттылар. Аннары, без барып җиткәнне дә көтмичә, МТС тракторына арба тагып, үзләре китерделәр үрдәк бәбкәләрен. Ә без тоттык та хәл иттек: тукта, ни булса ул, озатыйк әле боларны Казанга.

Казан безгә ерак түгел, ни бары туксан километр гына. Икенче көн-

не кичкә үк әйләнеп тә кайтты сатарга барган кешеләр. Үрдәк бәбкәләрен талашып алып бетергәннәр иде.

Ә көз җитеп колхозлар кош-корт тапшыра башлагач, идарә членнарын җыеп киңәштем дә, колхозчылардан бодайга алмаштырып үрдәк, тавык җыярга карар чыгардык. Ышансаң — ышан, ышанмасаң — юк, туган: өч көн эчендә план буенча тиешле тавык һәм үрдәкне җыеп алдык без. Үзебезнең авылдан гына түгел, күрше авыллардан да китерделәр. «Ватан» үрдәк планын йөз дә бер процентка үтәде дип, район газетасында хәбәр дә чыкты.

Ләкин кайчакта мактауның орышудан битәр нәтиҗәгә китергән очраклары була икән, агай-эне. Ул елны минем белән дә шундыйрак хәл булды. Газетада теге хәбәр басылганнан соң, миңа район күләмендә үткәреләчәк авыл хуҗалыгы алдынгылары киңәшмәсендә ничек итеп кошчылык өлкәсендә шушылай зур уңышка ирешүебез турында сөйләргә, ягъни тәҗрибә уртаклашырга тәкъдим иттеләр. Ялганларга теләмәдем, чынын сөйләп көлкегә каласым килмәде һәм мин, начальствога шалтыратып, ул җыелышта сөйли алмаячагымны әйтеп, сәбәбен аңлатып бирдем. Бая әйткән каты шелтә миңа әнә шул эшем өчен эләкте...

Бер кирегә китсә китә икән ул эшләр, туган. Өстемдә кара тап булып, күңелемне сызлатып торган теге шелтәдән котылырга да өлгермәдем, аннан да яманрак хәлгә дучар булдым. Һаман да шул үземнең тынгысызлыгым аркасында инде...

Колхозчылар сыер, сарык асрап, аларга печән җыеп, тиресләрен түгеп мәшәкатьләнергә тиеш түгел, бәлки, шәһәрдәгечә, сөтен дә, маен да, итен дә әзер килеш, колхоздан гына сатып алып торырга тиеш, дигән фикер алга сөрелә башлады. Ялгыш аңлауга урын калмасын өчен, алдан ук әйтеп куям: эшче белән колхозчы тормышы арасындагы аерманы бетерүгә мин дә каршы түгел идем. Хәзер дә хуплыйм мин ул нәрсәне. Ахыр чиктә, ниһаять, шулай булырга тиеш тә ул. Эшләр шуңа таба бара. Әйтик, безнең фермада эшләүчеләр, нәкъ шәһәрдәгечә, атнага биш көн һәм көненә сигез сәгать алмашынып эшли хәзер. Бәйрәм көннәрендә эшләүчеләргә, шулай ук шәһәрдәгечә, хезмәт хакын икеләтә түлибез. Ә колхоз буенча һәр колхозчының эш көненә уртача хезмәт хакы өч сумнан да артыграк туры килә. Ул яктан эшче белән колхозчы арасында хәзер үк инде аерма юк дип әйтергә була...

Ләкин бит бу хәзер шулай. Ә ул елларда эшләр әле башкача иде: көненә өчәр сум түгел, атнасына да ул хәтле эләкми иде колхозчыга...

Башка якларда, белмим, ничек булгандыр, әмма безнең тирәләрдә корылык булды ул елны. Игеннәр дә, печән дә начар иде.

Бүтән елларда халык ничек тә җаен таба: колхоз кырыннан бер сыер һәм өч-дүрт баш сарыкны кыш чыгарырлык печән әзерли торган иде. Әмма ул елны иген дә, печән дә уңмагач, шуның өстенә, колхозчыга сыер тоту артык мәшәкать ул дип тә әйтеп торганда, тирә-як авыллар сыерларын я суеп сатарга, яки дәүләткә тереләтә тапшырырга керештеләр. Сатучы күбәйгәч, сыерларның бәһасе бик арзанайды. Әйтик, башка елны башмактан бозаулаган һәм җиленнәре кәҗә җилене хәтле генә булган сыер кисәген дә юлың уңса гына сатып алырга мөмкин булган акчага ул елны егермешәр литр сөт бирә торган бурадай сыер алу берни тормый иде.

Сыер — чебеш түгел: ел саен үсеп, өлгереп тормый. Димәк, быел ике йөз илле сум торган сыерны киләсе елга биш йөзгә дә табып булмавы мөмкин...

Исәпли-уйлый торгач менә мондый фикергә килдем: колхозга сыер җыя башласак ничек булыр икән?

Шул ук көнне идарә членнарын чакыртып киңәштек тә колхозга савым сыерлар җыярга булдык. Азык запасын исәпләп караганнан соң, туксан биш баш сыер алырга мөмкин, диде зоотехник.

Азык булмагач, сез ни белән туйдырмак булып җыярга ниятләдегез ул сыерларны, диярсең инде син, туган. Хикмәте менә болай аның: күпьеллык үләннәр ул чорда инде тәнкыйтькә дучар ителсәләр дә, әлеге дә баягы, үҗәтлегем белән, люцерна җирен сөрдермәгән идем. Күрәсең, язгы дым белән ныгып калган булгандыр, иген белән печән уңмаса да, люцерна бик шәп иде безнең ул елны.

Сыерларны карап, яхшыларын, күп сөт бирә торганнарын гына кабул итү өчен, бер күз салу белән хайванның нинди икәнен белеп ала торган әлеге шул Галим абзыйны билгеләдек. Колхозларны берләштергәндә безнең «Чулпан» да «Ватан»га кушылган һәм Галим абзый хәзер ферма мөдире булып эшли иде.

Терлекләр инде кулга кергән, суясы яки сатасы хайванны бер көн ашату да крестьян өчен бик исәпле чак булганлыктан, нәтиҗә без көткәннән дә әйбәтрәк килеп чыкты. Ун көн эчендә тирә-як авыллардан сиксән өч баш сыер китерделәр. Сатарга теләүчеләр әле һаман күп иде. Әмма дәүләткә терлек кабул итү пункты мөдире, бу хәлне сизеп алып, Хәкимов миңа аяк чала дип, районга барып тавыш куптарган. Шуннан соң мине чакыртып алдылар да башта сыер җыюны туктаттылар, аннары, җитәр инде, күп чиләндек без синең белән дип, мине җавапка тарту турында мәсьәлә куйдылар. Мин берни дә эшли алмадым. Чөнки формаль яктан мин, чыннан да, хаклы түгел идем. Эш шунда, без сыерларның һәр килосын дәүләт бәясеннән биш тиенгә кыйммәтрәк алдык. Бу, бер яктан, закон бозу сыманрак хәл, икенчедән, тирә-як авыл халкы, сыерларын дәүләткә тапшырудан туктап, безнең колхозга ябырылган иде. Биш тиенгә кыйммәтрәк җыйган өчен түгел, әлбәттә. Дөрес, анысы да җирдә аунап ятмый. Дүрт йөз килолы сыер тапшырган кешегә — егерме сум дигән сүз ул...

Мине шунда бер буйдан эшемнән алырга да ниятләре юк түгел, Гадел абый урынына килгән секретарь шуны үземә дә сиздереп куйган иде. Әмма эш аңа ук барып җитми калды.



## 30

Тормыш гел бер килеш кенә бармый икән, туган.

Тора-бара авыл хуҗалыгында эшләүче кешеләргә мөнәсәбәт тә, шул җәһәттән авыл халкының хәле дә бик нык үзгәреп китте. Эштә инициатива, эшне яңача оештыру аеруча хуплана башлады. Аннары килеп, хезмәт хакына түләү шартлары да колхозчылар файдасына авышып һәм тотрыклыланып калгач, колхоз эшеннән читләшеп йөрүчеләр дә эшне үзләре сорап алып эшли башладылар. Халык белән эшләү бик нык җайланды, күңеллеләнде...

Ләкин, шул ук вакытта, бик зур борчуым да бар иде минем, туган. Җәзага эләккәнемә күңелем сыза, шуңа йөрәгем әрни, шуңа үз-үземне тирги идем.

Мең төрле уйларга батып, бик күп тынгысыз көннәр, йокысыз төннәр кичергәннән ары, ниһаять тәвәккәлләп, кичерүне үтенеп шикаять язган идем. Бәхетемә каршы, озак көттермәделәр. Бөтенесе мин дигәнчә булып бетте.

Ә аннан соң ике-өч ел вакыт үткәч минем өчен көтелмәгән бик зур яңалык булды: мең дә тугыз йөз алтмыш җиденче елда миңа Социалистик Хезмәт Герое исеме бирделәр. Анысы ни өчен икәнен тәфсилләп торасым килми. Башкаларга ни өчен биргән булсалар — миңа да шуның өчен, Указдагыча итеп әйткәндә, авыл хуҗалыгы продуктларын җитештерүдә ирешелгән уңышлар өчен бирделәр.

Бу хәлгә мин шатландым да, офтандым да. Шатландым, чөнки ул исемне бер минем генә хезмәтемә түгел, бәлки безнең «Ватан» колхозчыларының барысының да тырышлыгын искә алып бирелгән дип сана-

дым. Дөресе дә шулай бит, туган. Әгәр Галим абыйлар, Таифә, Мәһисәрвәр апалар, Закир абыйлар һәм алар кебек үк башка бик күп колхозчылар чын-чынлап тырышмаган булса, ничек кенә әйбәт эшләмим, мин бер үзем берни дә майтара алмас идем...

Офтандым, чөнки минем дә, ниһаять, макталып телгә алына башлавымны Сәкинәм-җан кисәгем күрә алмыйча калды. Сыерлар савуда яхшы гына эшләп йөри торган җиреннән кинәт авырый башлады һәм җиде ай түшәктә ятканнан соң дөнья куйды. Казанга гына түгел, Мәскәүгә үк алып барып, профессорларга да күрсәтеп караган идем үзен, әмма: «Хәзер соң инде, берни дә эшләп булмый — рактан терелтә торган ышанычлы дару әлегә табылмаган», диделәр.

Хәсрәтемнән үземне үзем кая куярга, нишләргә белмичә өнсезләнеп йөрдем. Искиткеч акыллы, сабыр, тыйнак, ягымлы кеше иде бит минем Сәкинәм. Ирне зур иткән дә — хатын, хур иткән дә — хатын, дип бик дөрес әйткән борынгылар. Председательнең эше болай да бик тынгысыз. Кояштан алда торырга, кояштан соң ятарга туры килә аңа. Яткач та иркенләп йокларга бирмиләр әле. Тугыз йөз илле йортлы хуҗалыкта («Ватан» хәзер биш авылны берләштерә) еш кына төннәрен дә кичектергесез мәсьәләләр килеп чыга. Озынга сузмыйча гына әйткәндә, тәүлек буе эшли председатель. Фәлән сәгатькә кайтам, дип хатынга әйтеп китеп тә вакытында кайта алмый калган чаклар турында әйткән дә юк инде. Ә бит хатын, бичара, менә кайтыр, менә кайтыр дип, ике күзен дүрт итеп, көтеп тора. Әмма мин Сәкинәнең шундый чакларда беркайчан да үпкәләгәнен хәтерләмим.

Ярый әле, ул елны улым Ирек укуын тәмамлап кайткан иде. Укыган елларында ул, эшкә башка авылга китәм, үзем укыган мәктәптә, үземне укыткан укытучылар белән бергә эшләргә кыенсынам, дип йөргән иде. Инде менә эшләр болайга киткәч, мине ялгыз калдырма, улым, дип мин үзем дә аның авылга кайтуын үтенгәч, үзебезнең Көрнәле мәктәбенә кайтып математика укыта башлады. Шулай аталы-уллы икәү кыш чыктык. Ә язын, Ирекнең укытуы беткәч, мин аны өйләнергә кыстый башладым. Малай каршы килмәде. Институтта укыганда яраткан кызы булган, укып бетергәч ул кыз да безнең күрше районга эшкә кайткан икән. Җәйге каникулында шул кызны алып кайтты да шуннан бирле матур гына яшәп яталар. Өлфәт абзаң хәзер бабай булды инде — оныгыбыз бар.

Үземнең сәламәтлек тә әйбәт әле. Тиз генә бирешергә исәп юк. Тик менә Сәкинәмнең вакытсыз үлеп китүе генә аяныч. Ул вафат булганга да ике елдан артты инде. Әмма мин аны һаман да шулай тере, чибәр һәм акыллы итеп күз алдымда тотам. Күнелемнән һәрвакыт аның белән сөйләшәм, киңәшләшәм...

Инде шушында сүзне туктатырга да мөмкин булыр иде. Ләкин...

## 31

Заманында Көрнәледә укыткан теге Гөлүсә белән тагын бер мәртәбә очрашуымны әйтми калдырсам, хикәям тулы булмас төсле.

Узган ел декабрь аенда Казанга барырга туры килде шулай. Килгәнкилгән, берәр спектакль дә карап китим әле дип, үзебезнең татар театрына барган идем. Театрның күргәзмә залында артистларның рәсемнәрен карап йөри идем, иреннәрен, кашларын бик хәтәр итеп буяган бер хатын кояштай балкып яныма килде дә:

— Үзегез танып күрешмәссезме дип көттем-көттем дә, таныр чамагыз булмагач, үзем башлап сүз кушарга булдым. Нихәл, Өлфәт абый?— дип, күрешергә кулын сузды.

Мин аны тавышыннан танып алдым һәм аптырап калудан аркан авып китә яздым. Үзгәрсә дә үзгәрә икән адәм баласы! Тал чыбыгыдай нечкә билле, зифа буйлы, озынча чибәр йөзле элекке Гөлүсәгә тамчы

да охшамаган иде ул. Битләре тулган-түгәрәкләнгән, биле колач җитмәслек булып юанайган, элек беленер-беленмәс кенә тәртеп торган түшләре зурайган, хәтта заманында кап-кара булган чәчләренә тикле аксыл-сарыга әйләнеп калган иде. Хәер, аңысын буяткан булгандыр инде..

Мин каршымда торган шул симез ханым белән элек бездә укыткан чибәр кыз арасында ниндидер охшашлык табарга теләп, әмма һичнинди охшашлык таба алмыйча шаккатып торган арада ул, сүзләрен пулеметтан аткандай сиптереп, үзегез һаман шул «Ватан»да эшлисезме әле, һаман председательме, улыгыз кайда, Сәкинәнең ни хәлләре бар, дип сораштыра башлады. Мин барысын сөйләп биргәч, көрсенеп куйды да:

— Ә теге сез кабыргасын сындырган Рәдиф кайда хәзер, гел шулай эчәме? — дип сорады.

Мин сиңа әйтеп китәргә онытып җибәргәнмен икән, туган. Рәдиф шулай ук гүр иясе булган иде инде. Алтмыш җиденче елның кышында, буранлап торган ачы салкын көнне күрше авылга барып, бик каты эчкән дә шуннан кайтып килешли туңып үлгән иде ул.

Шул хәлне сөйләп биргәч, Гөлүсә әллә ни гаҗәпләнмәде:

— Тәки барып чыккан икән! — генә диде дә кемнәндер шикләнгән сыманрак итеп, як-ягына каранып алды. Аннары туп-туры күземә карап:

— Теге вакытта Качкалак урманындагы тыйнаксызлыгым өчен сез миңа үпкәләгәнсез инде, Өлфәт абый, әйеме? — дип сорады.

— Ул көннәрне искә төшереп тормыйк инде,— дидем мин, нык кына итеп үзен ачуланып ташларга телем кычытып торса да, сүз озайтырга теләмичә.

— Әйтегез әле, Гөлүсә, үзегез ничек тормыш итәсез, кайда яшисез? — дип сорадым.

— Казанда мин хәзер, Өлфәт абый. Беркайда да эшләмим,— диде ул, соравын җавапсыз калдыруыма игътибар итмичә.— Хәтерегездәдер, сез икенче курс өчен кышкы сессиягә имтиханга килгәндә мин, институтыгызга барып, сезне киного чакырган идем. Шунда мин сезгә бер доцент артымнан йөрүен дә әйттем. Исегездәме?

— Исемдә.

— Исегездә булса, менә шуның белән яшим инде мин. Сезнең белән булган хәлдән соң, үз ягыбызга кайтып бераз укыттым да, бөтен дөньясына үч итеп, Казанга киттем һәм туп-туры шул доцентның квартирына барып кердем. Ул мине бик куанып каршы алды һәм без аның белән тора башладык. Хәзер ул зур кеше булды инде — профессор. Профессор хатыны мин, Өлфәт абый! Шуңа беркайда да эшләмим.

— Профессор хатыннарына эшләргә ярамыймыни соң?

Ул авыр сулап алды да, кинәт уйчанланып китеп:

— Ярый, нишләп ярамасын! — диде.— Бик эшләр идем дә, профессорым рөхсәт итми. Бик көнче ул, хәтта колхоз базарына ит алырга да үземне генә җибәрми.

— Ярата торгандыр. Шуңа алай көнләшәдер.

— Һей! — диде Гөлүсә, кычкырып көлеп җибәреп.— Аның коры яратуы миңа пычагымамыни? Их, Өлфәт абый, белсәң иде син минем хәлләремне. Мин бит...

Ул сүзен әйтеп бетерми калды, янибызга ябык кына, кечкенә генә гәүдәле һәм пеләш башлы бер кеше килде дә, миңа бөтенләй әһәмият бирмәстән, Гөлүсәнең җиңеннән тотып:

— Әйдә тизрәк, чиратым үтә юкса,— дип, театр буфеты ягына ымлады.

Гөлүсә, менә шушы инде ул профессор, дигән мәгънәне аңлатып, ризасызлык белдереп, миңа күз сирпеп алды да теләр-теләмәс кенә ияреп китте.

## Соңгы сүз

Менә мин вәгъдәмне үтәдем, туган. Үз башымнан кичкән һәм әле дә минем күңелне борчып торган, төнлә төшләремә кереп йөдәткән нәрсәләрне бер дә арттырмыйча-киметмичә сөйләп бирдем. Калганын син үзең кара инде, нәтиҗәсен үзең чыгар. Мин үз эшләремә үзем бәя бирергә теләмим. Теләсәм дә, дөрес бәяли алмас идем. Мин бары тик шуны гына әйтә алам: барлык эшләремне дә, үземчә, яхшы ният белән, кешеләргә кулымнан килгәнчә изгелек итү максаты белән эшләдем. Хәтта минем өчен җанын бирергә әзер торган һәм мин үзем дә аны өзелеп яраткан Сәкинәмне аерып җибәргәндә дә дөрес эшлим дип уйлаган идем. Ә соңыннан, үзеңә мәгълүм, әнә нинди хәлләр килеп чыкты... Күрәсең, адәм баласының табигате шундыйдыр инде: нинди генә эш кылырга тотынса да, башта үзен хаклы саныйдыр, шуңа ианып тотына торгандыр.

Хәер, алай дип кистереп әйтү дә бик үк дөрес булмас. Андый хәлләр мәсьәләне һәрьяклап уйлап җиткермәү, кызулык аркасында килеп чыга бит алар. Ә нәтиҗәләре йөрәккә уелып кала да гомер буе җанны әрнетеп, чәнчеп тора.

Әлбәттә, фәлсәфәгә бирелеп, уйлана-эзләнә башласаң, минем ул вакытта юләрләнеп китеп бер гөнаһсызга Сәкинәмне җәберләвемне дә, Рәдифнең, Хафиз картның әшәкелекләрен дә, Гөлүсәнең хикмәтләрен дә аңларга һәм билгеле бер дәрәҗәдә акларга мөмкин. Фашистлар китергән аяусыз сугыш нәтиҗәләре дип санарга була аларны. Бер карагайда, чыннан да шулай бу. Егерме яшем дә тулар-тулмас фронтка китеп, дүрт ел буена көнен дә, төнен дә пуля астында йөреп кайту бер дә эзсез генә калгандыр дисезме әллә? Авылның менә дигән ир-егетләрен сугышка алып китеп бетермәгән булсалар, Рәдиф тә ул тикле азына алмаган булыр иде, билгеле. Гөлүсә дә алай ук әрсезләнеп йөрмәс, аңа да үз тиңе, күңеленә ошаган бүтән егет табылыр иде... Ниһаять, колхозлар һәм колхозчылар тормышы да ул тикле үк кытлыкка калмас, гөрләп барган булыр иде...

Әйе, алары шулай. Ләкин, шул ук вакытта, бар гаепне сугыш кыенлыкларына гына кайтарып калдыру да дөрес булып бетмәс, чөнки сугыш мәхшәрләреннән әйләнеп кайтып менә дигән итеп яши һәм эшли башлаучылар меңнәр, миллионнар булды! Димәк, хикмәт сугышта гына түгел монда...

Атом көчен һәм коралын уйлап таптылар. Унбиш-егерме ел элек кенә акыл җитмәстәй эш булып тоелган Айның да серләрен ача башладылар. Ә менә кеше холкының, кеше психикасының серләренә ахырынача төшенү, аны бары тик яхшы психика гына итү өчен бик күп тырышасы бар әле. Бер минутлык дуамаллык аркасында бер гомерлек фаҗига эшләп ташлаучылар бер мин генә түгел, бар бит әле алар, туган, бар. Һаман шулай булырга тиеш түгел ич инде бу. Космосны өйрәнүгә генә түгел, үз холыклары белән идарә итү чараларын өйрәнүгә дә ныграк игътибар итсен иде кешеләр. Әгәр шуның серләренә төшенсәләр, минем кебек ише шырпысыз кабынып китүчеләр дә, үз хисләрен үзләре йөгәнли алмау аркасында, бүтәннәргә дә бәхетсезлек китереп, үзләре дә бәхетсез калган Гөлүсә кебек кыбырсык җаннар да, башта башкаларның тормышын бозып, соңыннан үз башларына үзләре җиткән Рәдиф ише яман бәндәләр дә булмас иде.

*1968—1969*

## Галимҗан Латыйп

# Ленинизм таңы

Офыкларның киңлекләре өчен,
Биеклеге өчен күкләрнең,
Азатлыкның якты идеалларын
Кояш итеп күккә күтәрдең.

Рус патшалыгы тарафыннан
Кимсетелгән барлык җаннарга
Тигез хокук бүләк иттең, Ленин,
Тигез яшәп, тигез янарга.

Сораштың син татарның да хәлен,
Чувашның да хәлен сораштың.
Милләтләрнең бердәмлеге өчен,
Күркәмлеге өчен юл ачтың.

Үзең бүләк иткән гәүһәрләрне
Бездән беркем тартып алалмас.
Мең ел үтәр, ленинизм таңы
Гел яктыра барыр,
    Гел яктыра барыр,
        каралмас!

●

Россиянең урта бер җирендә,
урта һава,
урта Иделдә;
һәйкәл салабыз без
гаҗәп итеп,
матур итеп бөек Ленинга.

Бу дөньяның барлык осталары
соклансыннар карап анарга.
Айга, елга түгел,
гасырларга,
заманнарга, миллион елларга.

Яраткан ул безнең бу якларны,
туган ягы итеп яраткан.
Хыялларны чынга әйләндергән,
кайгыларын илнең тараткан.

Давыл алды хәбәрчесе булып
кергән Казан аның җанына.
Сходкада очкан очкыннардан
Октябрьда ялкын кабына.

Чырай күрми,
чыра яктысында
гомер иткән иске Россия,
җир-суларның киңлекләре өчен,
ут-суларны кичкән Россия!

Бабаларның күргән михнәтләрен
бәхилләә син,
кайтар барысын.
Каргыш-рәнҗү белән киткәннәр дә
торып чыгып,
сине танысын.

Мәйданнарның уртасында бит син,
мәҗлесләрдә түрдә урының.
Бүгенгесе гүзәл,
иртәгәсе,
тагын да шәп барыр юлыңның!

●

Килдем мин Урал ягыннан,
Әй, нурлы Казан, диеп.
Шушында Тукай, Такташлар
Җырларын язган, диеп.

Мондадыр Ильич эзләре
Һәм Сәйдәш маршлары.
Горькийның егет чаклары,
Шишкинның арышлары.

Әй, яңа Казан, Иделнең
Ярлары таштан икән.
Хыялы иске Казанның
Тормышка ашкан икән.

Килдем Кремелең янына
Бераз соңгарак калып.
Остазым Муса алдында
Торам мин башым салып.

Янында тере чәчәкләр,
Янында гөлләр генә.
Карыйсың мәрмәр тавыңнан
Менәчәк үрләреңә.

## Чехов каены

Сихәт эзләп Ялта якларына
Килеп төшкән җирән пар аттан.
Бик яраткан шул ул Россияне,
Җаны-тәне белән яраткан.

Йортын күрдем,
Йөргән сукмакларын,
Ак каенын күрдем мин аның.
Туктадым да
Җырын тыңлап тордым
Ташлар ярып аккан елганың.

Чабыш аты кебек
Тау елгасы
Сикереп лә, уйнап ага ул.

Синдә-миндә аның ни эше
бар,
Гел дингезгә таба бара ул.

Алып килеп Кырым җирләренә
Россиянең ап-ак каенын,
Бер сөенгән Чехов,
Бер көенгән:
— Мин бит аны
Туган туфрагыннан,
Туган якларыннан аердым...

Нишлисең бит,
Каеннардан башка
Яши алмам кебек дигән ул.
Россияне юкәләре белән,
Каеннары белән сөйгән ул.

Кипарислар уртасында каен
Тернәкләнгән, үскән, ныгыган.
Хәзер инде бар, аерып кара,
Алып китеп кара Кырымнан.

Анда әле дә Чехов учларының
Җылылыгы бардыр, исәндер.
Шул каенны сыйпамыйча
китмә,
Кырым якларына килсәң бер!

●

Аргы очка таба
Гармонь уйнап,
Үтеп бара яшьләр урамнан.
Бабайлар да үткән,
Әтиләр дә
Моң калдырып
Шушы юллардан.

Бау тутырып кызлар,
Кибәргә дип,
Ап-ак керләр юып элгәннәр.
Егетләрнең алар
Бу тирәдән
Үтәселәренме белгәннәр.

Хәерле юл сезгә, дигән кебек,
Җилферди дә керләр
Җилферди.
Мондый чакта күңел,
Беләсездер,
Мондый чакта ниләр кичерми!

Киттеләр дә,
Күпләр кайтмадылар,
Тагын шулай була күрмәсен.
Киткән җырлар
Кире урап кайтсын,
Сагыш булып төшкә кермәсен.

Жыр йөресен сабан
туйларында,
Буразналар буйлап йөресен.
Усал җилләр ала күрмәсеннәр
Кер чайкаучы кызлар өлешен.

## Шуларның берсе мин булырмын

*Рәсүл Гамзатовтан*

Әгәр дә, мин сине сөям, дип,
Мең егет,
Мең җирдән,
Мең кода җибәрсә;
Шул меңнең
Берсе мин булырмын,
Тик аны
Син кире җибәрмә.

Әгәр дә, янында бөтерелеп,
Әйләнсә йөз гашыйк,
Йөз егет.
Шуларның берсе мин
булырмын,
Сөюче гел сине өзелеп.

Әгәр дә, эч серен яшерми,
Әйтсәләр, гашыйк, дип,
Ун кеше.
Шул унның берсе мин
булырмын —
Иң чыны,
Кайнары,
Көчлесе.

Әгәр дә дөньяда бары тик —
Бер генә ир булса,
Гел сине өзелеп сөюче.
Әйе мин,
Үл үзем булырмын,
Җанашым,
Бәгырем дию че.

Әгәр дә бу олы Җиһанда —
Янына килмәсә бер ир дә,
Гафу ит син мине,
Ярлыка!
Күмелгән булырмын мин
җиргә.

Мәҗит Рафиков

# ИШГИЛДЕ

*Этюдлар*

## I

Бу кеше дигәнен әйт тә, тормыш, дөнья дигәнен әйт...

Син үз күңелеңнән уйлыйсың: имеш, син берәр авылда күпмедер вакыт торып, яшәп киткәнсең икән, ул җирдә инде тормыш синсез дә гел шулай бер килеш кенә торырга тиеш, чөнки ул җирләр синең күңелеңә шул бер күргән килеш мәңгегә сеңгән, урнашкан инде...

Ләкин син бу авылдан киткәнсең, күп вакытлар буе бу җирләрне күргәнең юк... Менә бер көнне, шактый гомерләр узгач, күптән таныш җирләреңә бер кайтып әйләнәсең. Әйләнсәң... Бәрәкәт! Сәлам бирер бер генә танышыңны күрмисең, атылып килеп битеңне ялап алыр бер эт тә юк... Ә бит дөньясы һаман шул ук: кояшы — кояш, җилләре — җил, кырлары, сыртлары, су буйлары — бары да үз урынында, бер якка да күчеп китмәгән, чыпчык-карлыгачлары да, сукмак буендагы кычытканнары, суындагы маймычлары әле дә шулар... Тик калкулыклар бераз кечерәйгән, чүккән сыман, елга ярлары сөзәкләнгән, күреп өйрәнгән карт тирәкләр урынында сирәк-мирәк кенә яшь тал куаклары күренә, син белгән сәләмә агач күпер ташка, цементка әйләнгән, юлда ат тоягы, арба тәгәрмәче эзләрен машина көпчәге сырлары басып, күмеп киткән... Өйләр элеккеге салам «малахай» урынына кызыл калай яки аксыл-соры шифер «эшләпәләр» кигәннәр, үзләре калкурак, иркенрәк күренәләр, киң тәрәзәләре белән ничектер һавалырак карап утыралар. Авылның очларында, арт якларында син күреп өйрәнмәгән кызыл яки соры кирпеч корылмалар, яңа биналар күзеңә ташлана, җиңел рәшәткә эчендәге яшь агачлар тәртипле генә тезелешеп ничектер шәһәрдәгечәрәк үсеп утыралар... Галиҗәнап Тормыш синең биредә барлыгыңа-юклыгыңа карап тормаган, иркенләп үзенекен итә биргән. Язгы ташулар, җәйге яңгырлар, кышкы бураннар син юк дип бер дә туктап тормаганнар, кешеләр игәсен иккән, төзисен төзегән, йөрисен йөргән. Ә син инде хәзер бүтән бер җир кешесе, сине биредә әллә кидә бер

яхшы сүз белән телгә алсалар, яхшы теләк белән исләренә төшерсәләр, шул инде сиңа бик-бик җиткән.

Ә син белгән өйләр урынында өйләр булмаса, син уйнаган җирләрдә уйнап йөрүче балалар күренмәсә нишләрсең?..

## II

Башкорт илендә Ишгилде дигән бер авылны белә идем. Башкортстанның көньяк төбәгендә, Урал тавының ерак тармаклары арасында, маяклы шәрә түбәсен күккә калкытып торган Олы тауга сыенып кына, шул тау астыннан агып яткан инеш аркылы ике урында күпер ташлап, бер-берсенә ялганып киткән озын урамнары белән дугаланып сузылган ул. Бу авылның тирә-як җирләре күлле-чишмәле, урман-куаклы, җимеш-җиләкле. Иген игәргә дисәң, менә дигән кара туфраклы кырлары бар, терлек асрарга дисәң — калын үләнле болыннары, Калку башлы, калку сыртлы Олы тау бу юмартлык-гүзәллек дөньясын төньяк җилләрдән саклап тора. Олы тауның «муены», сырт буйлары куе кара урманнар белән каплана барып, башка таулар белән бергә борыла-сырыла көнбатышка, Урал тавының олы сыртларына таба китә-китә күздән югала. Бу якларда элек-электән кош-киекнең исәбе-хисабы булмаган. Бу Олы тау ышыгында элек бер заманнарны ике исем белән йөргән кечкенә-кечкенә ике башкорт кышлавы булганга охшый. Кайчандыр, Россиянең кайсы почмакларыннандыр, ниндидер җилләр шушы Олы тау артына бер төркем русларны китереп ташлаган. Берәр рус алпавыты ак патшага күрсәткән хезмәтләре өчен «кыргый башкорт» илендәге «иркен җирләр»дән бер өлеш бүләккә лаек булып, крепостной авылларының берсен нигезеннән куптарып, тоташы белән бирегә, Урал тавы итәгенә күчереп китергәндерме, әллә бу руслар, дәүләт крестьяннары буларак, «наян нугайларга каршы чик тоту» максаты белән күчерелгәннәрдерме, әллә кан эчкеч крепостниклардан эз югалта-югалта килеп бу тау ышыгына поскан качаклар булганмы алар,— кем белсен инде хәзер. Әмма Ишгилде руслары Смоляков, Бондарев, Конев, Драбазанов, Катаевлар арасында Топорковлар да бар иде. Ә бу Топорковларны авылча «мупрмцы» дип тә йөртәләр иде. Белмәссең, бәлки бу кушамат Топорковларның еракта калып күптән онытылган туган якларына ишарә булгандыр...

Кайлардан килсәләр дә килгәннәрдер, әмма ике авыл башкортлары бу русларны, үзләре эчкән су буеннан урын биреп, ике арага алганнар. Соңрак — күрәсең, шул җиргә кысанлыктандыр инде,— Идел буеннан Ишгилдегә берничә гаилә чувашлар килеп чыккан. Боларга да үрге авыл башкортлары белән руслар арасына сыенырлык урын табылган.

Беренче күрүемдә Ишгилденең урам тәртибе болай иде: Олы тауның иң текә янтавыннан түбәндәрәк, инешнең калку ярындагы мәчетле бер олы урам авылның түбәнге оч башкорт урамы була. Бу урам озын гына, бик үк төз түгел, өйләре шактый тарау утырган иде. Аларның да күбесе кечкенә, мунча сыманрак, тәрәзәләре дә тыштан килеп ике уч белән капларлык кына иде. Колхоз чорына чыккач салынган алты почмаклы иркен яңа өйләр күп түгел иде әле. Урамда бердәнбер калай түбәле мәһабәт бина — урамга ни аркылы, ни буй куелган мәчет иде. Бу челтәр манаралы мәчет күптән инде мәктәп ителгән иде. Эче тулы парта. Җыр дәресендә башкорт балалары: «...Дошманыңды кыр да һал, һал, һал!..» дип Салават маршын җырлыйлар иде.

Түбәнге оч урамыннан үрли килгән ат юлы, тау текәсенә килеп җитү белән, бакча читәне буеннан гына уңга төшә дә, чыбык күпердән чыккан уңайдан авыл кибете алдындагы такыр мәйданны бер әйләнеп, рус урамына кереп китә...

Рус урамының югары очында, калку җирдә, хөрмәтле урында бага-налар утыртып, киртә белән уратып алынган мәктәп бинасы тора: таш нигез, зур гына тәрәзәләр; бина үзе биек, кызыл калай түбәле, урамның уртасынарак, юл өстенәрәк чыгарып салынган.

Мәктәп яныннан узгач, юл чуваш урамына керә. Сул кулда гына кызыл балчык белән сыланган өйләр утыра. Уң кулда исә буш җир, арырак — сирәгәя төшкән каенлык уртасында — саф яшькелт сулы озынча түгәрәк күл (бу күлгә язларын кыр үрдәкләре төшә, авыл сунарчылары куян мылтыклары белән куак арасына посып үрдәк сагалый торганнар иде), ә күлле каенлык артында бик күп тәреле зират — руслар белән чувашлар зираты. Күл турысын узгач, чуваш урамы да куш урамга әйләнә: уң кулда да бер алты-җиде йорт-кура күрәсең. Бирегә ике өй бүтәннәреннән аерылып тора: икесе дә алты почмаклы, калку, иркен, түбәләре яшел калай; киң, якты тәрәзә төпләрендә гөлләр чәчәк атып утыра. Бу — күп балалы бертуган Василий Иванович белән Егор Иванович Захаровларның яңа өйләре.

Бу урамны узгач, юл сулга борылып түбән төшә, кичүдән чыга (җәяүле кешегә, аяк чишенеп тормаска, сыртларын юнып, басма итеп ике усак бүрәнә дә салынган), аннары үрге оч башкорт урамыннан китә. Монда да ике рәт булып утырганнар, ләкин бу урам мәчетле урам кебек үк озын түгел.

Менә шушы бер үк су буена тезелеп, бер-берсенә кул бирешеп, бер үк Олы тау ышыгына сыенган дүрт урам — бер үк Ишгилде авылы, бер үк колхоз иделәр. Кайсы гына базарда булмасын — Йомаголдамы, Троицкидамы, Янчурадамы — «Син кайсы авыл кешесе?» дисәләр, бу авылның башкорты да, русы да, чувашы да: «Ишгилденеке» дип җавап бирә иде. Колхозның исеме «Интернационал» иде.

Ишгилде минем күңелгә бик якын авыл. 1919 елны, Колчак куылгач, күрше татар авылы Куштирәктән Джигитировский кантоны мәгариф бүлегенең эшкә юллау кәгазе белән килеп, минем әти белән әни Ишгилденең башкорт балаларын беренче булып советча укыта башлаганнар. Ишгилденең башкорт агайлары-апалары арасында әле дә, битен-күзен нурландырып, үзләренең укытучыларын: «Мөгаллим, мөгаллимә... Һары мыек Миңгалим, Сәхибә һылыу абыстай...» — дип искә алучылар бар.

Ә мин Бөек Ватан сугышыннан бер өч-дүрт кенә ел элек Ишгилдегә барып русча укып киткәнмен. Әти белән әни, күрәсең, мине чит авылда бер үзе укый алмас, сагыныр, боегыр дип уйлаганнардыр — әти аръяк Әхмәдулла абзый белән сөйләшеп, аның улы белән икебезне бергә җибәрмәкче булганнар...

Үз авылыбыз Куштирәктәге дүртенчене бетереп, бишенче класска йөри башлаган көннәрем иде. Бер көнне шулай, су өстеннән яссы ташлар җибәреп «коймаклар пешерә-пешерә» мәктәптән соңлабрак кайтып керсәм, ишек алдында да, өй артында да зур-зур өем яңа арыш саламы күрәм. Үзе җылымса кояшта алтынланып ялтырап ята, үзеннән кырлар исе, башак исе килеп тора. Сикереп мин дә рәхәтләнеп мәтәлчекләр ата-ата уйна! Бу әти кайчан үзенең өченче классын укытып кайткан да, ни арада бригададан атын-арбасын алып, бу кадәр салам кайтарып аударган! Әнә үзе өй түбәсеннән иске саламны төшереп йөри. «Эх, иртәрәк кайтсам, мин дә әти белән саламга барган булыр идем бит»,— дип үкенеп өлгермәдем, әти мине күреп алды да:

— Улым, ашап-эч тә, әнә Фәрит дустың килер, Ишгилдегә барырсыз,— диде.— Русча укырсыз, менә шәп булыр! Өченче класска керерсез. Укытучыгыз Тарас Иваныч сезне көтәдер инде. Квартирыгыз рус урамының түбән очында булыр. Конев Дмитрий Иваныч дигән картта. Ак өй, кибеткә каршы гына...

Авызны ачып тыңлап торганмындыр, каршы сүз әйтмәдем. Уйга кал-

дым. Фәрит белән минем моңарчы бергә уйнап, дус булып йөргәнем юк иде юклыгын. Әти әйткәч, дустым булыр инде... Безнең әти иң акыллы кеше ул, аның сүзе — минем өчен иң олы сүз. Ул үзенең башкорт, рус, чуваш иптәшләрен еш кына ашка-чәйгә алып кайта. Алар да һәркайсы көләч йөзле әйбәт кешеләр. Тарас Иваныч дигәненең дә бездә булганы бар бугай әле... Безнең әти үзе дә яшьли бик укырга тырышкан. Ишле, ярлы гаилә баласы, унөч яшендә авыл агайларына ияреп калага киткән — укырга, белем алырга, русча өйрәнергә. Барган. Кичтән, кала мәдрәсәсенең менә дигән алгыр шәкерте булырмын, дип хыялланып ятып йоклаган, иртә белән җиләк-җимеш сатучы бер байның малае булып уянган... Соңрак, рус телен өйрәним дип, бер рус сәүдәгәренә хезмәткә күчкән, сатып алган китапларын урын-җиренә төреп, яшереп тоткан... Үзлегеннән укып-өйрәнүе белән генә укытучы булып күтәрелгән ул. Фәрит дус белән миңа Олы тау артында гына торган Ишгилдегә бару — әллә кайдагы калага китү түгел эле ул. Бармый ни!

Фәрит дус килде. Җилкәсенә ике яклап бау тагылган капчыгын аскан, үзе ялан аяк, ботинкаларын, бәйләвечләреннән төйнәп, бармагына эләктереп тоткан. Мин дә үземнең агач сумкага яңа дәфтәр-каләмнәр салып иңбашка элеп алдым. Әни әзерләгән биштәрне аркага астым. Калды, калды ялтырап яткан алтын салам өемнәре... Тапталмаган, изелмәгән килеш калды...

Фәрит дус белән без шыгырдавык сиртмәле, зур улаклы кое янынан узып, ялан аяк тәпили бирдек.

## III

Авылдан чыктык, сыртка мендек. Юл уңга-сулга аерыла башлады. «Чыкрык-чыкрык» саесканнан, кызыл койрык төлкедән юл сорашасораша, ташландык бер арба юлы белән Олы тау итәге буйлап барабыз да барабыз. Менә бер вакытны без бара торган юл тауның астында да, битләвендә дә күпләп куелган печән кибәннәре арасында юкка чыкты да куйды. Ләкин тиздән ниндидер икенче бер юлга — тояк-тәгәрмәч эзләрен аермачык танырлык ниндидер бер «тере» юлга тап булдык. Бу юл түбәннән килеп, уңга, туп-туры Олы тау сыртына менә иде... Фәрит белән без алай куркып-каушап калмадык. Олы юл булгач, кая булса да алып чыгар әле! Моңарчы күрмәгән-белмәгән якынлы-ераклы тауларны-үзәннәрне әйләнеп карый-карый үргә менеп киттек.

Безгә әти: «Олы юл уңга китә, Моратшага алып бара, кече юл сулга, Ишгилдегә илтә», дигән иде. Ә без «кече юл»дан янә кечерәк юлга — печәнчеләр юлына кереп киткәнбез. Ә бу аркылы юл — башкорт Дәүләтбае белән чуваш Дәүләтбаеннан Ишгилдегә тау аша туры чыга торган юл икән лә!

Тауның ак кылганлы сыртына да мендек, саргаеп, шәмдәй янып утырган каеннар арасыннан түбән дә төштек. Төшсәк без инде хәзер әллә кайда — Ишгилде дигән авылның үрге үк очында икәнбез! Чуер ташлы кичүне чыгып, биткә берәр уч салкын су сирпеп, аяк-кулларны юып алдык. Менә каршыбызга ярдан бер чуваш бабай төшеп килә. Үзе кечкенә, үзенең киң коңгырт сакалы биленә җиткән, сакал-мыек арасыннан борыны белән ике күзе генә күренә. Курка-курка гына Конев карт өен сораштык. Үзе бик яхшы бабай булып чыкты бу. Без: «Геди? Геди?» — дип торабыз, ул менә дигән иттереп саф татарча диярлек әйтте дә бирде. Безгә озын урам буйлап түбәнгә күпер төбенә кадәр янә бер ике-өч километр кире төшәргә туры килде. Менә кызык: юлыбыз ялгыш булса да, килүебез дөрес булып чыкты бит!

Карт-карчык, кыз-кияү, ак чәчле, ак керфекле, зәңгәр күзле өч тиктормас бала-чага — өй тулы халык безнең килүне белеп, көтеп торганнар. Руслар белән беренче күрешүебез иде, әчке каушауны җиңеп:

«Драстуй! Драстуй!» — дидек, таныштык. Кәрәк сакаллы җирән бабай кулларын җәеп елмайды да бер-ике сүз әйтте. Шул минуттан бу картлар өчен Фәрит — Федя, мин — Миша булып та киттек.

Ак чәчле, зәңгәр күзле Петька, Кланька, Маруськалар белән аерым табын ясап идәнгә утырыштык та рус ипиен зур-зур каба-каба, дәү табактан «похлебка хлебать» итәргә керештек.

Баш өстемдә хуҗа хатын тавышы ишетелде:

— Ешьте, ешьте...

Тавышы ирләр тавышына тартым калын булса да, болай ягымлы гына тоелды. Хуҗа хатын үл үзе дә таза, калын гәүдәле, түгәрәк иңбашлары ак кофтасына чак сыешып тора. Бите киң, якты чырайлы. Зур, итләч кулларыннан ипи исе килеп тора сыман. Фәрит белән мин аңа хәзер «бабушка» дип, аның кәрәк сакаллы картына «дедушка» дип дәшәргә тиешбез инде: танышканда алар үзләрен шулай дип атадылар.

Петька яшькә безнең белән бер чама иде. Гаҗәп тә шук, гаҗәп тә үз егет булып чыкты ул. Без табыннан торып өлгермәдек, Петя инде әле Фәритнең кабыргасына төртеп, әле минем иңбашка шапылдатып суккалап ала башлады. Үзе елмая, көлә, безне үчекләгән сыман итенә. Менә бүлмәдән чыкты да, чолан ишеге артына поскан булып, бармагы белән безне чакырды. Ишек алдына чыккач: «Айдате бороться! Пошли бороться!» — дип ябышты. Ул теге безнең ише татар малайларының ишек алды саен сабан туе ясап, батыр булырга маташып йөрүләрен белмәгән, ахрысы. Бакча артына чыгып алмаш-тилмәш бил алыштык. Читән буендагы үлән шактый изелде, хуҗа картның батыр оныгы авызын бик алай турсайтмады, кызулык күрсәтмәде, ихтирам белән карады: караңгы төшә башлауга да карамастан, безне келәт артына ияртеп алып китте.

Келәт артында аның үз «хуҗалыгы», үз «мастерское» бар икән. Иркен генә кабык куыш, куыш эчендә, кечкенә бүрәнә өеме шикелле итеп, җиткән көнбагыш сабаклары өеп куелган. Таяк-таяк итеп тигез генә киселгән бу сабаклар тигез генә өелгән. Һәр таякның ике очы астан да, өстән дә үткен пәке белән киртләнгән. Аларны дүрт чатлап очын очка китереп, киртләреннән тишеп дүрт тал чыбыгына тезеп утырта барсаң, менә дигән «бура» килеп чыга икән лабаса! «Бура»ның төбенә катыргы яки фанер кисәге куйсаң, «идәне» була, ә көнбагыш таякларын өч-очларыннан ике чыбык үткәреп тезсәң — менә сиңа әзер капкач. Аны, ачылмалы-ябылмалы итеп, ике чатыннан бурага бәйләргә генә кала. Бу бит читлек була лабаса! Аның эченә ялган басма итеп такта кисәге эләктереп кенә куясың да, басмадан җеп сузып, ачык капкачны терәп куя торган чыбык кисәгенә тоташтырып бәйлисең. Читлекне капка баганасына, я читән башына мендереп утыртасың да ялган басмасына җим саласың. Сары түшле песнәк кыздырган бөртек исен әллә кайдан сизеп ала ул. Ялган басмага кагылып та өлгерми, өстәге капкачның шапылдап ябылганын сизми дә кала... Әнә капка баганасы башында бер читлек тора, эчендә бер песнәк пырылдапмы пырылдый. Петя аларны читлектә озак тотмый, кулын тыгып, яман пырылдаган кошчыкны сак кына учына ала, җылы, йомшак кошчыкны сенелләренә, аннары безгә тотып карарга бирә, соңыннан, киртә башына менеп, үз кулы белән чөеп, очырып җибәрә. Шуннан соң янә аулый — кызык өчен генә, ничек, нәрсә эшләп була икән дип кенә...

Поклар урынны әби, бишебез бергә тәгәрәшеп ятарлык итеп, алгы өйнең мич башына җәйде. Бирегә квас, киез итек исләре дә, җәйге кояшта кызган елга буе комы исе дә килә иде бугай.

Иртә белән Петя, Фәрит, мин мич башыннан төшкәндә кызчыклар уянмый да калдылар. Без кызгылт касмаклы рус катыгына мана-мана кайнар белен капкалап тамак ялгадык та, сумкаларны эләктереп, Петя белән бергә урамга чыктык.

IV

Бу кояшлы салкынча иртәдә урам кичәгегә караганда да ямьлерәк күренде. Сул рәттәге өйләрнең аклыгы күзне чагылдыра, урам як тәрәзәләре ялтырый. Этләр исә бүген инде Фәрит дус белән мине дә үз итәләр сыман тоелды.

Менә мәктәп. Дүрт баскыч, такта чолан. Бина эче икегә бүленгән: сул як бүлмәдә беренче класс, унда — өченче. Урта стена ишеккә ук җитми, тавышлар класстан класска ишетелә. Ике класска бер укытучы. Бер үк класста укучы бертуганнар да бар икән, чөнки беренче класс ике елга бер генә ачыла. Ике баланың яшь аермасы яшь-яшь ярым гына булса, ник аларны бер класска йөртмәскә? Китаплары да уртак була, дәресләрен дә узыша-узыша әзерләшәләр... Шулай итеп, киләсе елны бу мәктәптә икенче класс белән без күчәсе дүртенче класс булачак, аның киләсе елында янә беренче класс ачыла да өченче класс була...

Мәктәптә бу авылның ике очыннан килеп русча укучы башкорт малайлары да бар иде. Берсе — бик шук бер башкисәр, бик оста көрәшче, Карагужин Иргали дигән башкорт малае — арифметикадан теләсә нинди мәсьәләләрне күңеленнән чишә, ә диктантта хата өстенә хата җибәрә иде. Ә Тимербулат Йомабаев атлысы (бик көттереп-сагындырып туган ир бала булгач, ата-аналары, авыру-сырхау белмәсен дип, шундый исем кушканнар аңа) үзе гел эчтән генә нидер көйләп, моңланып йөри, үзе сулагай, гаҗәп оста художник иде, стена газетасын бизәүчебез шул Тимербулат иде. Аскы авылыннан килеп йөрүче мишәр малае кызыл чәчле Али Асанов бүтәннәрдән көнләшә-көнләшә тырышып укый, бер генә тапкыр бишле ала алмаса, үртәлүеннән хәтта елар хәлгә җитә иде.

Дәрестә бер карашып алудан — иптәш, тәнәфестә бер йөгерешеп китүдән дус булышкан чаклар... Фәрит белән без үзебезне биредә тиз арада ук үз авылыбыз мәктәбендә, үзебезнең Куштирәк малайлары арасында кебек хис итә башладык. Инде икенче көнне үк арифметика дәресендә без дә, тыңлап кына утыра белмичә, кул күтәрә башлагач, беребез «сиксән сигез»не: «гүчимдичәт гүчим» дип, бар классны шаулатып бер көлдереп хур булды. Мондый көлдерүләр-кызарулар әүвәлен булгалый торды инде ул. Әмма алтын кеше — Тарас Иваныч, сүз ялгышына, сүзне әйтү ялгышына турыдан-туры игътибар итмәстән, хатабызны бик шома гына төзәтеп җибәрә, кыюлыкны тизрәк күрә, ачык елмаеп әйткән сүзләре белән күңелне үсендерә белә иде.

Безне ул, рус балалары белән аралаштырып, алгы парталарга утыртты: күрәсең, әйткән сүзен ачыграк ишетсеннәр, тактага язганын якыннанрак күрсеннәр, тактага чыгучыларның язган-сөйләгәннәрен дә яхшырак үзләштерә барсыннар, дигәндер...

Ул Тарас Ивановичның бит-күзләре, буй-сыннары һәм бигрәк тә күзгә карап елмаеп сөйләшүләре хәзер дә күз алдымда. Озынча какчарак бит, ачык ак чырай, киң маңгай, дулкынлатып артка таралган коңгырт чәчләре, төз генә борын, ачык карашлы зур-зур күк күзләр, юмарт елмаючан нечкәрәк иреннәр, зур, көчле, чиста куллары, бераз гына юкарак төз гәүдә, җиңел хәрәкәтләре... Бу мәктәптә: «Их, зурайгач Тарас Иванович кебек булсам иде!..» — дип йөрүче малайлар бер мин генә түгел идем.

Нинди яхшы күңелле, нинди сизгер кеше булган ул, Тарас Иванович! Ул чын-чыннан безгә тигән бәхет булган бит!

Минемчә, Тарас Ивановичның укучылар белән сөйләшкәндәге күз карашына багышлап поэмалар язарга мөмкин. Менә ул синнән дәрес сорый. Синә карый. Карашы җылы, юмарт, сабыр. Синең дәресне бел-

мәвенә, ялгышуларына ул ачуланмый, үчләшми,— боларга аның игътибары да юк сыман. Ул белә: бу соңгы дәрес түгел, син әле бик күп тапкыр җавап бирәчәксең. Ул синең күңелеңдәгеп бөтенесен күреп, аңлап тора, ул синең бөтенләй үз кешең, чын теләктәшең, ул сиңа карата бик-бик яхшы теләктә, ул синең бөтен ялгышларың, гөнаһларыңны кичерергә әзер, тик син бер дә курыкма, әйдә, кыю бул, укы, тырыш кына,— шулай итсәң, барысы да менә дигән шәп булачак... Малай чакларында күңелеңдәге иң матур хыял-ниятләреңне үсендереп, үзеңне дәртләндереп, канатландырып җибәрүче шушындый җылы караштан да кадерлерәк нәрсә бардыр бу дөньяда, мин белмим...

Аның безнең белән бергә ерак урманга чыгулары, төрле чәчәкләрнең таҗчыкларын, таҗ яфракчыкларын, серкәчләрен күрсәтеп йөрүләре, талның тамырдан, имәннең орлыктан үсүен аңлатулары, каен, карлыган үсентеләре казып алып кайтып, безнең белән бергә мәктәп бакчасына утыртып йөрүләре, юл уңаенда ак аюлар, пальмалар, арсланнар, жирафлар, филләр турында сөйләгәннәре, кышларын, дәресләр беткәч, класста арабызга утырып укыган әкиятләре, хикәяләре — бары да, бары да күңелдә...

Ул ак битле юантык малай Вася Топорков, гел әчтән нидер көйләп йөрүче Тимербулат Йомабаевлар белән бергә мәктәптә теш порошогы изеп, кызыл полотноларга лозунглар язып элгәндә, бәйрәм кичәләрендә (әйтергә кирәк, безнең мәктәп, кирәк чакта, клубка да әверелеп китә иде: парталарны тезеп, өстән калын такта җәяләр дә — менә сиңа сәхнә!) кызыл галстуклы малайлар-кызлар сәхнәгә чыгып зурлар алдында шигырьләр сөйләгәндә, «По долинам и по взгорьям», «Конная Буденного» кебек җырлар җырлаганда, хезмәт дәресләрендә тырыша-тырыша кечкенә агач көрәк, тырма, арба кебек әйберләр ясаганда — без бит һәр эшне Тарас Ивановичның шул җылы, мәхәббәтле карашына шатланып эшләгәнбез лә!..

Мәктәптән беренче кайтканда ук карчыга борын Сенька Катаев (аның куллары озын, таш атудан аннан да уздыручы юк иде) безне үзләренең абзар артларына алып кереп китте. Аларның эте балалаган икән, шуны карадык: каралы-аклы ябык зур бер ала кәнтәй, ачулы күзләре белән безгә карап, ырылдап ята, көчекләре — ала-кола туп корсаклар — күзләрен дә алмыйча аналарының бүртенгән алсу корсагына капланганнар, койрык очлары гына кыймылдый...

Һавада озын-озын пәрәвез җепләре ялтырый иде. Без арткы бакча аша туры Андрюша Топорковлар ягына уздык. Бирелә безне хәйран калдырырлык, күңелләрне әсир итәрлек гаҗәп бер нәрсәгә тап булдык...

Андрюша Топорков турында алдан ук шуны әйтергә кирәк: ул тегe ак битле, юантык малай, гел тыныч, сабыр, гел бишлегә генә укучы, плакат хәрефләрен бик матур итеп яза белүче Вася Топорковның туганнан туганы иде. Ни сәбәптәндер, Андрюшаның әтисе юк иде, әнисе — купшы, чибәр, әмма каты бәгырьле хатын — көне-төне тау буендагы сөтчелек фермасында үзенең сыерлары янында була, иркен, буш өй эчләре кайчан керсәң дә җыештырылмаган, ә кышын ягылмаган, салкын, караңгы, җан өшеткеч шыксыз була иде. Андрюша өенә кайтса да, карыны бик ачканнан гына йөгереп кайтып керә дә, ватылып, уалып торган иске ипине зур-зур тешләп, юылмаган кашык белән куерып, әчкелтем тәм кергән каймак сыпыра башлый. Ул каймак цинк чиләк белән шәрә, шыгырдавык өстәл астында гына тора иде. Андрюша ютәлли-төчкерә ашый, үзенең күзләре кызарып яшьләнеп тора. Кайвакытны аның бу зур, матур соры күзләрендә моңсулык, ниндидер тирән сагыш та чагыла иде. Андрюша, тәмәке тартса да, алдашу, урлашу кебек гөнаһлары сизелми. Талашырга-сугышырга яратмый иде ул. Тик бер тапкыр гына күрдем: бер олы малай үзен оятсыз сүзләр әйтә-әйтә үрти торгач,

Андрей кинэт кыргый тавыш белэн үкереп жибэрде, нелэ төшеп, очып барып теге күсэкне бэреп екты да, аяклары-йодрыклары белэн бэрэ-бэрэ, кырык тэүбэсен эйттергэнче сабагын укытты. Үзенең эт талаган зур пальтосын ул җилбэгэй җибэреп йөри иде; төймэлэре булмый торган иде; бүлтэеп чыккан кесэлэрендэ гел болт, гайка кебек тимер-томыр булыр иде. Андрюшаның яраткан бер эше, бөтен җанын-хыялларын билэгэн бер дэрте бар иде, менэ шул ягы белэн ул мине беренче танышуда хэйран калдырды да... Андрюшага ияреп, аларның тишек-тошык буш читэн абзарларына кергэч без шуны күрдек: җирдэ яткан киң тактаның бер очында тэгэрмэчле-торбалы кечкенэ трактор тора иде. Чын трактор диярсең! Андрюша очраган бер тимер кисэген җыеп йөри икэн. Абзардагы тактасына эреле-ваклы винтларын, болтларын, чарыкларын һэм эллэ нинди тишек-тошык тимер кисэклэрен тезеп куйган, шулардан ни тели — шуны корыштырып ясый. Комбайн дисенме, молотилкамы анда, чэчү агрегаты таккан тракторамы...

Фэрит белэн без яңа иптэшлэргэ баш бармакны белэзеккэ тидереп күрсэттек, тик аларның моңа бер дэ исләре китмэде. Соңрак, атна узып ялга кайткач, Куштирэктэн мин үземнең өчтэн ишеп җэй буе бик шэп шартлатып йөргэн кыл очлы чыбыркымны, Фэрит исэ үзе ясаган бэлэкэй арбасын Ишгилдегэ алып килдек... Яңа дусларыбызга...

Тамак туйдырып чыккач (бу шул беренче көнне мэктэптэн кайткан уңайда була инде), бакчалар башыннан су буена йөгерештек. Чуер ташлы үзэннэн дерелдэп агып яткан су читеннэн вак балык көтүе агым уртасына атылып юк булды. Менэ бер вакытны безнең ак чэчле Петябыз башкортча:

— Һэтэү! Һэтэү! Кара һин уны! — дип балыклар белэн сөйлэшэ-сөйлэшэ, ыштан балагын күтэрэ төшеп, салкын суга кереп бара.

Фэрит белэн без аптырап калдык: Петя башкортча сөйлэшэ лэбаса! Күзенне йомып торсаң, бу нинди башкорт малае диярсең! Бу Ишгилде руслары арасында башкортча белү бер дэ гаҗэп нэрсэ түгел икэн лэ! Озын буйлы, кара тут йөзле Костя Смоляков Петяга шунда ук:

— Тот койорогын! — дип салды.

Күрэсең, башкорт малайлары ташбашны «һэтэү» дип тэ йөртэлэр... Э Петя моңарчы безнең белэн гел русча гына сөйлэште. Ул, мөгаен, без татарлар булгач, башкортча белмибез дип уйлаган... Болай булгач, безгэ белмэгэн рус сүзлэрен сорарга тылмач та булды!

Кичке эңгердэ без инде, куак артларына посына-посына, яр астыннан барып, кемнендер бакчасына төштек. Юлэрлэр! Кэбестэсен йолкабыз да, башын кисеп ташлап, күчэнен юнып кетердэтэбез. Үзебез шат: без кыю, янэсе...

Кар төшкэч урамның бүре басардай Полканнары, кэкре койрык йонлач Жучка, Рыжиклары белэн авыл артына чыгып, эскерт, кибэн төплэреннэн куяннар өркетеп тэ йөрдек. Бу бэлэкэй йонлач этлэр кызык! Атылып-атылып качкан аксыл сырлы сизмез куянны куып барганда, чокырлырак җирлэрдэ баш аркылы мэтэлеп китэлэр, аннары инде җан ачулары белэн эллэ нэрсэгэ өрэ-өрэ чабалар. Э куян элдертэ генэ! Билгеле инде, Ташлы сырт үрендэге челек куаклары арасында ул бездэн качып югала...

Э су аръягында Бондаревлар бакчасы турында Түгэрэк маңгайдан чана шуулар нинди күңелле була иде! Җил битеңне кисэ, сулуын каплана — очасың гына!.. Тик безнең Куштирэктэ һэрбер малайның оста кул Вэлихан абзый ясап биргэн бэлэкэй чанасы бар, э бирелэ, күрэм, чанасыз да бик шэп шуып була икэн. Юкэсе сыдырылмаган кабык кисэге булса, шома ягы белэн карга салып, үкчэсенэ басасың да, алгы очын күтэреп тотып, бер аягың белэн этенэ биреп, шуып төшэсен дэ китэсен. Яман кыштырдап, кабыкның ике кыры белэн ике якка кар сиптереп барасың, мин сиңа эйтим! Шул ук рэвештэ ике юанрак тал

чыбыгына басып та шуарга мөмкин. Тау бозланган да булса, тал чыбыкларының каерысын өйгә алып кереп яхшылап чистарткан да булсаң, очырта гына! Болардан тыш әле «боз чана» ясап алырга да була. Берәр түгәрәк савытка — кечерәк таскамы анда, коштабаккамы— берәр чиләк су алып кайтып саласың, салам салып бутыйсың да, берәр бау очы төшереп, шул килеш кышкы салкында бер генә төнгә ишек алдында калдырасың, иртән торуыңа Кыш бабай сиңа «боз чана»ның менә дигәнен ясап куйган була. Бусы да бик шәп шудыра. Тик аңа бер аягыңны гына бөкләп утырып шуарга кирәк, икенче аягыңны артка ташлап, тауны тырнатып төшәсең, югыйсә бу боз чана чокыр-чакырда сине унга, я сулга әйләндереп, шундый җилле очыртып җибәрә, әллә нихәтле җир тәгәрәп барасың...

Ул бригаданың печән абзарларына кереп, кыек асларыннан күгәрчен тотулар, ул биек кар сырынтысында бер үзең «батыр» булып торыр өчен, бер-береңне сөйрәп, я этеп төшерә-төшерә мәш килүләр, ул язын җир ачылгач ялан аяктан тезеп-тезеп ашык бәрүләр, чыр-чу килеп туплы уеннар уйнау дисеңме... Кая калды ул, дөньяның гел шатлык кына, гел рәхәт кенә көннәре, ул укуың да, эшнең дә гел уен гына чаклары?!.



## V

Дүртенче класска Фәрит Ишгилдегә бармады, мин генә бардым. Баруыма әти миңа фатирны чуваш урамыннан килешеп кайткан иде. Анна исемле ялгыз бер әбидә кыш чыктым. Әбинең өй эче ап-ак итеп акшарланган, ак стеналарына газетадан төрле-төрле өлгеләр буенча челтәрләп киселгән, аллы-гөлле төсләргә буялган зур-зур түгәрәк «чәчәкләр» ябыштырылган. Бу «чәчәкләр»нең үзәгендә кызыл кояш бар, ә тирәләре — төрле төсле нурлар сыман. Әбинең аягындагы оеклары, кулына кигән бияләйләре я күкле-сарылы, аллы-зәңгәрле бизәкләр төшереп бәйләнгән, я бәйләгәндә шул ук төсләр бер-бер артлы беләзек-беләзек итеп тезелгән була иде.

Гаҗәп бер әби иде ул. Үзе бик карт инде, туксанны узган. Озынча ак бите әз генә җилсенгән сыман. Ирләрнекедәй озын калын борын; бик йомшак, ягымлы карачы зәңгәр күзләре кысыкланып, яшьләнеп тора; зур авыз, авыз читләреннән өстән аска сызылган ике тирән җыерчык. Тавышы калынча, гыжылдабрак чыга торган булса да күңелгә ятышлы, җылы. Кул аркалары тиресе юкарган, ялтырап тора, күк гамырлары калкып чыккан, колагы шактый томаланган, әмма шушы кадәр картлыгына карамастан, ул үз көнен үзе күрә, үз хуҗалыгын үзе алып бара иде. Җиңел сөякле, юка гәүдәле, ирену-ару белмәс бу әби инәсен үзе саплый, киясен — борынгы өлгеләр буенча — завык белән — үзе кисеп, үзе тегә иде. Аның озын, киң итәкле күлмәкләренең тирән-тирән ике кесәсе, сүс җептән үргән нык биллеге була иде. Әби шул биллегенә бәйләп алъяпкыч астында гына үзенең иске сандык ачкычын йөртә: әбинең «кара көнемә» дип, аз-азлап җыя килгән акчасы бар...

Уналты бала тапканнан соң тол калып, үз көнен үзе күрергә өйрәнгән бу әби көрәк-сәнәк, балта, чалгы тоту, ат җигеп тегермәнгә, урманга йөрү кебек эшләрдә дә кешегә салынмаган. Хәтта атын да асраган, җирен дә сөргән ул. Ярдәмчеләре булмаудан түгел, үз алдына яшәргә теләүдән... Кер уамы ул, ишек алды себерәме — нинди эшкә тотынмасын, уңга-сулга карамыйча, буш хыялга бирелмичә, һәр эшкә дәртен-күңелен биреп, эшнең тәмен белеп эшли иде. Бер көнне шулай иртән мин мәктәпкә киткәндә, әбием җиңел сәнәген тоткан, лапас ягына узышлый, үз-үзенә әйткәндәй: «Эшләренне эшли алган көнең — якты көнең, эшли алмасаң, караңгы көнең шул булыр»,— дип сөйләнеп калды...

Ашарга да ул, икебезгә ничек тә ярар әле, дип тормады, итле бәлешләрен, пилмәннәрен, кәбестәле-йомыркалы сумсаларын бәйрәм ашыдай, кунак сыедай тәмле иттереп, килгән-кергән кешеләрне сыйларлык, кучтәнәчкә бирерлек мул иттереп әзерли иде. Йокы белән, ял белән түгел, эш белән саклый иде ул үзенең сәламәтлеген.

Үзе ялгыз торса да, ишеге бик тиз ачыла иде әбинең, сәлам сүзе еш яңгырый иде аның өендә. Ишгилдедә, аның үз күршесендә үк диярлек, әлеге яшел түбәле өйләрдә ике кече улы яши иде, икесенең гаиләсендә барысы унҗиде бала булып, аларның алты-җидесе мәктәпкә барысы бергә йөрделәр. Барысы да аксыл чәчле, кысылып, көлеп торган зәңгәр күзле, гәүдәгә зур түгелләр, чандырлар, әмма күпләр. Аларга шулай күп килеш исән-сау үсеп, кеше булыр өчен дәүләт ел саен зур-зур акчалар бирә иде. Аларга әти-әниләре ел саен яхшы киемнәр алалар, аларның балалайка, гармоньнары да бар... Бу онык-оныкалар Анна әбиләренең учагында һәртөрле ризыкның бик тәмле булып пешкәнен, әбинең сөякчел кытыршы кулы бик юмарт икәнен белеп торалар...

Оныкларының зурлары арасында иң чибәре Матрена иде. Түгәрәкләнеп, матурланып җиткән кыз иде ул, зур зәңгәр күзләрендә хисләр кайнарлыгы мөлдерәп ташып тора. Дус кызлары белән әбиләренә кич утыра керсәләр, Матрена армиядәге Петругын сагынып: «Чиру чирап, чиру чирап...»[1]— дип, йомшак кына тавыш белән җырлый башлый. Әйтерсең, шулай әкрен генә, йомшак кына итеп җырласа, аның җырын әллә кайдагы бер генә кеше ишетә дә, бүтән беркем дә ишетми, ә үзе егетенә атап чигеп, бизәкләп теккән тәмәке янчыгына чуклы бәйләвеч җеп үткәрә... Ә инде егетләр дә килеп керсә, аксак Гришук Портнов, идән уртасына утырып ала да, кара күзләрен яман уйната-уйната, куллары белән артистларча төрле ишарәләр ясый-ясый, беренче әтәчләр кычкырганчы коточкыч әкиятләр сөйли...

Кызыл Ярдан да, Дәүләтбай хуторыннан да әбинең олы кызларының онык-оныкалары бу өйдән өзелеп тормадылар. Мин кышкы каникулда өйдә чакта әбинең Дәүләтбайдан килгән укучы оныклары атна буе кунак булып ятканнар. Әллә кайдан, Бердяуш дигән бер җирдән килгән бер оныкасы — сазан кыз, юан кара Варвара — әбидә айдан артык ятты. Ул бәлки Ишгилдедә берәр егеткә кияүгә чыгарга да өмет иткәндер дә, ялкау, акрын кыймылдаучан иде шул. Кичләрен кызлар моңланып җырлый-җырлый чигү чигеп, егетләренә челтәрләп-бизәкләп перчаткалар бәйләгәндә, ул бичара утырган җиреннән йоклый да китә, йоклый да китә иде.

Таныш-белешләре дә күп иде ул әбинең. Шатлыклы, ачык елмаюы белән елмаеп, авызын чәпелдәтә-чәпелдәтә, башкорты белән башкортча, русы белән русча, татары белән татарча рәхәтләнеп сөйләшә иде әбкәең. Һәркем белә иде: әбигә сүзне бик үк кычкырып әйтмәсәң дә, сул колагынарак әйтергә кирәк.

Әби үзе кешене рәхәтләнеп бер сыйламыйча өеннән чыгармый иде. Таныш-белешләре дә — кайсы пима басучы, кайсысы тун тегүче, кайсысы әбинең арышын-бодаен тегермәндә тарттырып китерүче — берсе дә әбигә берәр төргәк шикәрсез, берәр савыт балсыз килми иделәр.

Язын, җир ачыла башлагач, әби сабырсызлана, өй эчендә йөренгәндә: «Минә җәй дә җитә инде... Оныкларым ни хәлләрдә икән?.. Барам, барам, күреп кайтам...» дип үз алдына сөйләнә башлый. Җәйгә чыккач ул, чыннан да, авылдан авылга барлык балаларын — олыларын, кечеләрен һәм иң кечеләрен — күреп йөрде. Иңбашында зур гына бер төенә, кулында озын гына таягы. Адымы җиңел. Артыннан килгән атлы кеше атын туктатып:

— Әйдә, әби, утыр! — ди.

Әби утырмый.

[1] «Хатлар язам, хатлар язам...» (чув.).

— Аякларым юлны ярата, рәхмәт! — дип атлый бирә.

Әби белә ул: «Үз аякларың белән йөргән көнең — якты көнең, йөри алмасаң — мәнә шул булыр кара көнең...» Арыса, су янында туктап, биткулларын чылатып ала, чабаталарын чишеп аяк юа, чирәмгә утырып, күзләрен кыса-кыса, зәңгәр күктәге тургайларны эзли. Тапкач, озак карап тора — сайрауларын ишетә, диярсең...

Кышын, бал коеп, пилмәннәр пешереп, өендә Матрена белән аның дуслары — чуваш, рус, башкорт кызлары җыелган кичләрдә, күңелләр җилкенгән бер сәгатьтә әби дә, идән уртасына чыгып, ике кулын ике якка чөеп: «Ах!» дип кызыллы-зәңгәрле оегы белән идән сайгагына «тып» иттереп китереп бер басар иде...

Анна әбинең тагын бик хикмәтле бер ягын әйтми уза алмыйм. Аның иң күңел биреп эшләгән эше — сүс эрләү дә киндер сугу иде. Кичләрен әби гадәттә үзенең зур тәгәрмәчле кабасын алып утыра да аягы белән аны зыр-зыр әйләндерә-әйләндерә сүс эрли: көмешсу тәрәшеннән тигез генә, нечкә генә җебен сава да сава. Мин аның кабасы зырылдавын тыңлый-тыңлый йоклап китәм. Уянсам, минем әбием һаман эрли! Үзе йокымсыраган, калгып-калгып куя, хәтта төшләр дә күрәдер сыман, үзе һаман эрләвен белә.

Кышкы чиллә узып, көнне язга сындырдымы, әби зур киндер сугу станын өйгә кертеп урнаштыра да мин өйдә юкта, җеп шүресен уңга-сулга уздыра-уздыра, киндер суга да киндер суга.

— Үземә кәфенлек киндер сугам,— ди ул кешегә. Бик аек акыл, тыныч күңел белән әйтә ул моны. Аның өчен гүя җан биру дә, чүмеч белән алып су эчкән кебек, гади генә бер хәл буласы. Шунысы кызык, аның суккан киндерләре инде сандык тулы. Аның ул ак калай коршау сугылган көрән сандыгы зур, биек караватт астына чак сыя. Әби килгән бер кешегә шул сандыгын ачып, үзенең киндер кисәкләрен төргәге-төргәге белән алып күрсәтергә ярата. Аның ул киндер төргәкләре үзләре зур, һәркайсысы әбинең өй нигезен тыштан бер урап сузарлык, үзләре күп, барын да чыгарып өеп салсаң, Олы тау хәтле булыр. Алар бары да чиста итеп юылган, кояшка, ак карга чыгарып җәеп-җәеп агартылган. Миңа калса, бу төргәкләрне ни төсләре, ни зурлыклары белән бер-берсеннән һич аерырлык түгел, әмма әби аларны сандык төбенә төшеп җиткәнче һәркайсысын ялгышмыйча исемнәре белән атап-атап кулына ала... Ахырдан ер-яңа сукканнарын алып күрсәткәндә сүзләрен тәмләп-тәмләп:

— Монысы Зинушкама, мәнә тотып кара, нинди йомшак! Ә мәнә бусы Любашама...— ди.

Ә аның Зинушкасы белән Любашасы — берсе кайдадыр Кызыл Ярда, икенчесе Дәүләтбай хуторында сыгылмалы каен сиртмәгә эленгән бишектә тирбәләләр....

Әбинең оныклары-оныкалары бер-бер артлы дөньяга килә торалар, әби аларның һәркайсына озын гомер, ак бәхетләр теләп, киндер җепләрен эрләпме-эрли, киндерләрен сугыпмы-суга, ә үзенә кәфенлек сугарга чират җитми дә җитми...

Ватан сугышыннан кайткач ишеттем: Анна әби йөзгә якынлап yлгән. Төрле фронтлардагы улларына-оныкларына чәчәкләп-сырлап оекбашлар, аеры бармаклы бияләйләр бәйләп утырган җиреннән тыныч кына, йокыга талган кебек кенә, киткән дә барган...

Әйтергә кирәк, бу дүртенче класста укыганда гел чуваш малайлары белән йөреп, гел алар белән уйнап, мин чувашча сөйләшергә дә өйрәнеп киттем. Бала күңелем белән бу чәчәкле-бизәкле, ягымлы, йомшак телдә туган телемә борын-борыннан килгән ниндидер якынлык, тугандашлык барлыгын сиздем мин.

## VI

Мин инде күптән шәһәр кешесе. Семья белән әллә нидә бер Куштирәккә кайткалыйбыз, башкорт авыллары Саньяргә, Моратшага да барып чыгабыз. Саньярда укытучы абыем бар, башкорт җиңгәм белән җиде бала үстерәләр; Моратшада укытучы сеңелем белән башкорт киявем бар.

Былтыр шулай бер көнне кичкә таба Моратша больницасының баш врачы башкорт киявем Килсенбайның җиңел машинасына утырдык та совхоз умарталыгына чыгып киттек. Врачлар, дәва ясыйбыз, прополис табыйк, дип кубынганнар иде. Июль ахырының аяз матур көне, машинасы да булгач, ник миңа да дөнья күреп әйләнмәскә, дип мин дә әләгеп киттем.

Әйтергә кирәк, бу борынгы башкорт авылы — легендалар оясы Моратша — хәзер зур бер совхоз үзәге булып киткән. Бик зур ремонт мастерское, зур-зур гаражлары бар; монда кызыл кирпечтән типовой проект буенча урта мәктәп, мунча, ашханәләр салынган, сырт ягында сигезәр квартиралы ике катлы торак йортлар тезелеп киткән — шәһәрнең бер микрорайоны диярсең; көнкүреш комбинаты осталары, теләгән бер кешене өр-яңадан киендереп, сакал-мыегын төзәтеп, яки толымнарны һәм чәчне теләсә ничек кыландырып, одеколонлап тарап, битен сыйпап, рәсемен алып күрсәтү белән хатынны үз иренә, ирне үз хатыннарына яңадан гашыйк иттерә алалар... Саньяр, Имәнле, Һыербай, Морзакай, Дәүләтбай башкортлары, Александровка, Имбирское руслары, Аркат мордвалары, Кызыл Яр, Дәүләтбай чувашлары, безнең Куштирәк татарлары, Аскы Акташ мишәрләре — хәзер бары да шушы бер Моратша совхозының бүлекчәләре. Ишгилде авылы да шушы ук Моратша совхозының бер бүлекчәсе булып чыкты. Совхозның директоры — ир уртасы бер башкорт егете — Хезмәт Герое Асылгужин. Бүлекчәләр белән Моратша арасында машиналар, юкә чәчәк аткан чактагы бал кортлары кебек, йөреп кенә торалар.

Моратшаның аның хәзер атларына караганда төрле машинасы күбрәк, агач өйләренә караганда таш йортлар күбәя бара, киртә казыкларына караганда өй түбәләрендәге антенналар саны арта... Юк, хәзер Моратша кечкенә башкорт авылы түгел инде. Нинди генә милләт кешеләре биредә эшләми дә, нинди генә милләт кешеләре биредә яшәми! Урта мәктәбен генә ал. Директоры — безнең Куштирәк татары, завучы — университет тәмамлап кайткан башкорт егете, укытучылары арасында руслары да, чувашлары да, мордвалары да бар.

Шулай кичкә таба, баш врач эштән бушагач, кызыл хачлы җиңел машина белән Моратшадан чыгып киттек. Каршыбызга шоссе буйлап, үкерә-үкерә, машиналар килә, машиналар килә. Яңа арыш төягәннәр.

Аркат авылын узгач, шоссейдан төштек, бер инеш буйлап унга юл тоттык. Барабыз. Уң кулда, су артында, ниндидер кызыл башня, терлек фермасының зур-зур корылмалары калды. Су буйлап куе таллык, зирекләкләр китә. Юлның сул ягын тоташ алып арыш басуы җәелгән. Җиңел генә искән җил алтынсу башакларны йомшак кына сыйпап, дулкынландырып йөри. Еракта, басуның югары очыннан, бер-бер артлы өч комбайн килә. Аларга йөк машиналары ияргән. Берсе төялеп китсә, аның урынына шунда ук икенчесе килеп тагыла...

Бу юл миңа таныш түгел. Безнең өскә әкрен генә йөзеп килгән киң итәкле, биек бер тауның сызым-чалымнары ят күренә. Тик биләп торган урыны, шәрәлеге, саргылт-соры төсе һәм еракларга киткән урманлы сырты белән генә мин аның Олы тау икәнен ялгышусыз беләм.

Машинабыз бер үр менеп, бер түбәнли төшеп бара бирде. Бу гади авыл арасы юлында да яна иген төяп Моратшага чапкан машиналар

бер дә үзгәрмәгән икән. Шоферлары, йөк тәяүчеләре баш врачка елмаеп, кул селкеп узалар: күрәсең, ярата**лар**...

Менә бер вакытны юл икегә аерылды, машинабыз инешне кичте дә, озын, күбесе яңа өйләрдән торган матур бер урамны сулда, калку якта калдырып, түбән ярдан куак артларыннан китте. Бу ак рәшәткә ихаталар, телевизор антенналары, яңа өйләр Ишгилденең түбән оч урамы микәнни инде, дип карап бардым...

Куе шомырт агачлары һәм рәшәткәләп алынган ниндидер зур гына җимеш бакчасы артыннан көтмәгәндә, кинәт борылып, авылга килеп кердек. Күрсәк... нинди якын, үз минә бу җир, һәм инде таныш та түгел бу җир миңа!..

Бу каршыдагы Олы тауга, су буйларына, еракта**гы** зәңгәрсу урманнарга күз шул кадәр өйрәнеп беткән — алар минем күңелгә сыенып, бөтенләй үз булып бик күп еллар буе яшәп килгәннәр икән лә!.. Тик су буенда карт тирәкләр күренми (беләм, ул тирәкләрне сугыш елларында кисеп якканнар...), салам түбәле таныш өйләр, таныш куралар, капкалар юк. Теге чак булса, бу машина янына ялан аяк, ялан баш ак чәчле, ак керфекле Петя («Пошли бороться!..») сеңелләрен нәртеп атылып чыкмас идемени, тракторлар ясаучы Андрюша Топорков, озын куллы Сенька Катаевлар җыелырлар иде!.. Безнең машина нәкъ Фәрит белән минем әлеге ялгыш йөреп, дөрес килгән җирдә туктаган лабаса! Магазин да нәкъ үз урынында. Тик ул зурайган, бераз әйләнә төшеп, киң ишегеп кыйблага, кояшлы якка ачкан. Ә каршыдагы миңа бик таныш алты почмаклы ак өй, аның күрше өйләре, абзар-куралар юк. Аларның урынын тоташы белән миңа бөтенләй таныш түгел зур, якты бер бина билап алган. Ул әле яңа, нараттан салынган. Алтынсуланып, зур бакча яшеллеге эченнән калкып, кояшта күзне чагылдырып утыра.

— Мәктәп буладыр бу? — дидем мин.

— Әйе, был беззең һигезъеллык мәктәп,— диде миңа шома битле, кысык күзле сатучы хатын.— Унда хәзер беркем дә юк... Директормы?.. Директоры үзебезнең Ишгилденеке, Тимербулат дигән кеше, Помабаев. Акһак, һугыштан шулай...

«— Һай, сулагай художник, менә кайда икәнсең син!» — дип кычкырып җибәрә яздым.

— Кайда тора ул? — дип сораганымны үзем дә сизми калдым.

Минем дулкынлануым сатучы хатынга да күчте булса кирәк, ул шунда ук тәрәзә каршына килеп:

— Әнә генә... Күпер артында гына... Олы урамда, верандалы өй... Ә-әй, өйдә юк бит әле ул! Кисловодскида ялда...

Машинага утырып ары киттек. Мин комсызланып, күреп туймастай булып, бер уңга, бер сулга карыйм... Карасам, мин белгән урам юк... Бу яңа мәктәп рәтендә верандалары белән урамга буй салынган ике өй бар да, каршы рәттә, сулда өч өй... Берсенең зәңгәр капкачлы ачык тәрәзәсеннән «Өфе һөйләй...»

Ә алда... алда инде урам бөтенләй өзелә. Ни йорт-ихаталар, ни киң урам, ни келәтләр... Кая монда мин фатир торган, мин малайлар белән кереп йөргән өйләр, таныш кешеләр?.. Бушлык!.. Хәер, бушлык түгел: саргылт төс ала башлаган бодай басуы, уң яктагы нигез урыннарын тоташ күмеп, машина юлы өстенә үк чыгып дулкын кагып ята. Ә сул якта — юлның буеннан-буена тыгыз кирпә белән киртәләп алынган җимеш бакчасы: рәт-рәт утыртылган яшь алмагачлар үсеп утыра. Бакчаның югаргы очында гына ялгыз бер йорт күзгә ташланды. Алты почмаклы, кызыл калай түбәле. Телевизор антеннасы биек... Тәрәзәләрендә ак пәрдәләр, тюль... Абзар-келәтләре толь белән ябулы... Кара, Тарас Ивановичларның өе нәкъ шушы урында тора иде түгелме соң? Тик аларның өе кечкенә, салам түбәле, ап-ак кына иде... Ә элеккеге мәктәп урыны буш. Үлән үскән...

Мәктәп артыннан башланып киткән чуваш урамы да юк.

Уң кулдагы чөгендер, сул кулдагы бәрәңге басуларын буеннан-буена күреп уздык...

Ике якка ике су пәрдәсе чөереп, югаргы оч кичүен чыктык, югаргы оч башкорт урамына кереп, аны узып та киттек. Яңа нарат өйләр, өем-өем нарат бүрәнәләр кояшта күз явын алып калдылар. Машина йомшак кына тирбәлә-тирбәлә кара урманлы, чишмәле үзәннәр аша бара бирде, мин — юл буе төрле авылларның төрле яңалыкларын сораша-сораша килгән кеше — кинәт тотлыккандай, телсез-өнсез калдым, уңны-сулны күрмәс булдым, үз күңелемә, үз кичерешләремә чумдым.

Гаҗәп! Ниндидер тирән, тыенкы, якты бер шатлык хисе дә мөлдерәмә тулган минем күңелгә, шул ук вакытта бәгырьнең әллә кайсы бер җирен өзеп алгандай, бәһасез бер югалту тойгысы да бар иде минем күңелдә...

Ишгилде!.. Ул бүген кайчандыр мин күргән, мин белгән хәлендә түгел. Тормыш аны, мин оныткан кебек, онытып калдырмаган, ташландык итеп, читтән урап узмаган. Ишгилде бөтен ил белән бергә үскән, күтәрелгән. Җитешсез ярлы түгел, ким-хур түгел. Куллары эштә, күңелләр үсештә, күзе-колагы ил хәлләрендә, дөнья хәлләрендә... Олы тау артындагы Ишгилдедә дә олы тормыш кайный...

Ә минем үзем генә белгән Ишгилдем, ике генә класс башлангыч мәктәпле, чабаталы-киндерле Ишгилде юк... Эзе дә, билгесе дә юк. Әйтерсең, Фәрит дускай белән без икәү, адаша-адаша, авылыбыздан килеп, биредә, Тарас Иванович мәктәбендә укып та йөрмәгәнбез, биредәге яңа дусларыбызга Куштирәктән кадерле уенчыкларыбызны да алып килмәгәнбез, Ташлы сыртка кадәр, чыр-чу килеп, куяннар өркетеп тә чабышып йөрмәгәнбез, әйтерсең, мин Анна әби өендә «Ворона и лисица»ларны укымаганмын, ә кояшлы, җылы бер көнне, барлык малай-кызлар бер булып, дүртенчене бетердек, дип шатланып таралышмаганбыз...

Барысы да үткән, барысы да эзсез югалган. Шаһитлар да калмаган... Хәер, бар ул шаһитлар. Олы тау бар... Кояш бар... Кайдадыр Кисловодскида кордашым Тимербулат Йомабаев бар...

Ә ник бу Ишгилде сине шул хәтле уйландырып, дулкынландырып җибәрде соң әле? Ник син аңа кул гына изәп уза алмыйсың? Күпмедер вакыт шушында укып яткан өчен генәме? Соң бит тормыш биредә син белгәннән бирле, бөтен нәрсәне бер ботарлап, яңабаштан корып өлгергән инде, монда бит хәзер җирләр дә үзгәргән, тормыш та бүтән җайларга куелган, һәм син үзең дә күптән инде сабый бала түгелсең... Ник син әллә кайчан биредә кичереп үткәргән, көндәгечә вак кына, әһәмиятсез генә хәлләр һәм вакыйгалар бүген синең үзеңә кинәт бу тикле кадерле булып киттеләр әле? Син ул көннәреңнең вак кына, гади генә шатлыкларын-рәхәтләрен яңадан бер кичерергә дә һич каршы килмәс идең бугай?..

Ә менә хәзер, инде бераз дөнья күргән, акыл-гыйбрәт җыйган башың белән, көндәгечә гади һәм вак хәлләрнең кабатланмас гаҗәеп олылыгын һәм гүзәллеген күрә-тоя беләсеңме син?

Врач кемнеңдер югалган сәламәтлеген кайтарып өчен прополис табарга чыккан. Син, үзең дә абайламастан, яшәвеңнең үзең онытып йөргән чишмә башларына килеп чыккансың һәм шул чишмәләрнең сафлыгы, гүзәллеге белән бәхетлесең...

## VII

Умарталыктан кайтышлый, Ишгилденең югары очында машинаны туктатып, бүрәнә өстендә утырган киң битле, фетр эшләпәле бер башкорт агай янына килдем.

— Агай, теге Тарас Иванович мәктәбе урыныннан түбәнрәк бер зур өй бар, кем тора анда?

— Тарас Ивановичның тол бисәһе инде, Нәстәсья.

Тарас Ивановичның Ватан сугышында, Берлин юнәлешендә һәлак булуын мин күптән ишеткән идем инде.

— Ялгыз түгелдер бит?

— Юк, кесе улы менән.

— Олы улы кайда?

Тарас Ивановичның зур улы Коля — өч-дүрт яшьлек кенә, туп кебек малай — дәресләр бетүгә әтисен каршыларга килә торган иде. Әтисен зур кулыннан эләктереп алып, «Муха-муха, цокотуха»ны такмаклый-такмаклый, икәүләп кайтып китәләр иде.

— Олоһы Өфелә тора, Черниковскийлә. Шофер...

— Кечесе монда нинди эштә?

— Кесеһеме? Тракторга утырһа — тракторсы, комбайнга утырһа — комбайнсы, баксага инһә — баксасы, мылтык тотып сыкһа — һунарсы. Төлкеһен түгел, бүреһен дә ала... Әнә теге һары буйда ике комбайн йөрейме? Тарас Иванычның Алексейе менән беззең Мәсәлим икеһе шулар булыр.

Бераз тынып торгач, мин авыр көрсенеп сорап куйдым:

— Агай, бу уртадагы ике урамга нинди хәлләр булды соң?

— Һе! Ниндәй хәлләр булһын тей?! Эстерлелә химкомбинат һалдылармы? Салават калаһы юктан бар булдымы? Күмертау калаһы юктан бар булдымы? Әллә кайзардан китереп Түлгәнгә тиклем пуйыз юлы һуззылармы? Был хәтле дөньяны әкейәттәге шайтандар корһынмы? Китүселәр улар, беззең остан да, түбән остан да күп булды. Иәштәр бигерәк тә. Кунакка тип кайталар да эштәрен, тормыштарын мактап, тагын ияртеп китәләр. Ә кайберәүзәр Моратшага күсте... Ә беззең Ишгилде һаман кәмемәй. Ишәя. Был ике ос бергә кушыла әле ул. Кешенең хәзер гумере озая бит... Әнә, яңа буралык бүрәнәләр!.. Яшьтәр кайда оя корыр тиһең? Билгеле, мәктәп урамында!..

## VIII

Анастасия Ивановнаның ярым ачык капкасы алдында ук миңе бүре буардай зур бер саргылт-соры эт абалап алды, артыннан йөгереп кеше чыкмады. Мин каушап калдым. Басып торам... Менә өе, менә капкасы, эт җибәрми генә! Торган саен гарьләнүем, ачынуым артты, бу бүре басар эт алдында мин чынлап ук курка башладым. Ул ни яхшы сүзенне, ни ым-ишарәнне белми, күңелеңдә ниләр барын ул каян аңласын!.. Аның түгәрәкләнгән соры күзләрендә котырган ачу очкыннары уйный сыман. Бәреп егып өзгәләп тә ташлый ала бит ул... Ә мин бу өйгә сәлам бирми китә алмыйм... Эт исә шуны да белми, мин аның өчен бу йортка бөтенләй ят кеше. Ул үз йортын, үз хуҗаларын миннән иң яхшы этләрчә тугры саклый... Бу капка алдына ул, әйтерсең, мине, Ишгилдемә күп еллар буе килмәвем, хәл белеп сәлам бирмәвем өчен аяусыз, гадел көч белән җәзаларга чыккан...

Инде тәкатьсез калдым. Әллә машинаны чакырып алып, кабинага житез генә кереп утырырга да китеп барыргамы?.. Алай итү бөтенләй килешмәс инде...

Кинәт арткы бакча капкасы ачылып, бер яшь кенә хатын күренде. Кулында чиләге. Күрәсең, ул тау асты бакчаларында яңа бәрәңге алып йөргән. Ул ашыга иде. Башына ак панама кигән юантык кына улы арттарак калган. Хатын алсу җиңел күлмәк, ак яулыктан, зифа буйлы, житез хәрәкәтле, чибәр. Битендәге кара тут аша да алсулык бәреп тора, ялтырап торган дымлы кара күзләре ачык, ягымлы карыйлар.

Таныштык. Мария Никитична Алексей Тарасовичның хатыны булып чыкты, Дәүләтбай хуторыннан килен булып төшкән чуваш кызы икән, Иомабаев мәктәбендә башкорт балаларын рус теле, рус әдәбиятыннан укыта.

Эчке өйгә керү белән, түр стенада Тарас Ивановичның зурайтылган портретын күреп алдым... Элек Ишгилде русларында иконасыз өй юк иде. Бу өйдә икона юк, Тарас Ивановичның портреты гына... Безнең укытучыбыз... Исән булса, менә хәзер шатланыр иде...

Стенада рамы-рамы белән фоторәсемнәр тезелгән. Рәсемнән рәсемгә күчә-күчә Тарас Ивановичны эзлим. Менә ул саргайган бер рәсемдә этисе белән әнисе артында тора. Егет чагы. Кепкасын артка таба чөереп кигән, шат елмаеп тора ул... Менә ялгызы... Укыткан еллары булыр. Шул ук киң маңгай, ачык чырай, сабыр, акыллы караш. Пакь кеше, пөхтә кеше... Менә ул Анастасия Ивановна белән икәү утыра. Әтисе белән әнисе арасында бер ялан аяклы малай — Коля тора. («Муха-муха, цокотуха...»), әнисенең тезендә, чиккән ак башлыктан, кечкенә Алеша — әллә кая читкә карап утыра. Нәрсә күргән булгандыр?..

Тышта кинәт эт тагын, чылбырын өзәрдәй булып, шашына башлады. Капка төбенә машина килеп туктады, ишектән минем оныткан юлдашларымны иңртеп Анастасия Ивановна үзе йөгереп килеп керде. Бит очларына алсулык йөгергән. Үзе ачык елмая. Хәтеремдә, ул элек тә күз карашы белән дә, елмайганда да ничектер Тарас Ивановичка охшап киткәндәй була иде... Бер мизгел ни диярга белми карап тордым... Күңелемдә кинәт бу өлкәнәя баручы, ләкин якты, нурлы карашлы апага моңарчы үзем белмәгән олылау, анадай якын күрү тойгысы уянды, мин: «Анастасия Ивановна!» дип ташланып, аны кочаклап алдым, башымны аның иңбашына салдым.

Үзем генә белгән Ишгилде белән күрешүем иде бу минем.

Анастасия Ивановна йортыннан без тиз генә чыгып китә алмадык.

## IX

Куе зәңгәр күктә йолдызларның иң яктыларыннан башлап, күзгә чалыныр-чалынмас иң вак кыналарына кадәр барысы да күзләрен ачканнар, һәркайсысы хәленнән килгәнчә тырышып нур чәчә. Тулы айның да, бу йолдызларның анасы булып, югарыга ук менгән сәгате. Ул үзенең йомшак яктылыгы белән бу йолдызлы куе зәңгәр күк фонынннан Олы тауның кабырга тармакларын, түбәләрен, буйларын яктырткан, уйсу-уйпат култыкларына кисәк-кисәк кара күләгәләр ташлаган. Сулда, сыртка таба кинәя киткән басу башакларын салындырып тынган, тигез генә, тонык кына яктырып ята. Менә бер як стеналары белән кордашым сулагай Тимербулат салдырган яңа мәктәп калды. Агач ябалдашларына яфрак саен көмешсу яктылык кунган. Агач төпләре — тоташ кап-кара күләгә.

Түбән очтан урап, Ишгилдедән кайту ягына чыктык. Су буендагы ялтыр яфраклы куаклар безгә каршы йөгереп киләләр дә кинәт артта калалар. Машинаның ян-як пыялалары төшерелгән. Салкынча саф һава белән аралаш, биткә дулкын-дулкын көндезге жылылык та килеп бәрелә. Хезмәт көненең бу әле эреп бетмәгән кайнарлыгында — колшта жылынган туфрак исе, тәмле ипи исләре аңкый. Машина әле бераз гына үргә менеп, әле бераз гына түбән төшеп, майда йөзгәндәй шома гына бара да бара...

Минем күз алдымда — кинәт алсуланып киткән ачык чырайлы Анастасия Ивановна, аның юмарт карашы тора, колагымда — аның әле сабыр гына, тыныч кына, әле ачынып, әле шатланып, әле авыр сулап агылган жылы-йомшак тавышы яңгырый, ә күңелемдә — мин үзем генә белгән, бик үз күргән Ишгилдем...

Гажәп бу Анастасия Ивановна! Тарас Ивановичта укып йөргән бөтен иптәшләремне хәтерли, язмышларын белә. Әйтерсең, үз балалары.

«...— Ак чәчле, ак керфекле Петямы? Разведчик булган ул... Фронттан әниләренә бер фоторәсемен дә җибәргән иде... Медальләре түш тулы

иде... Допроста эсэсчылар анын кукрэгенэ йолдыз кискэннэр, сүз ала алмагач, атканнар...»

«...— Андрюша Топорков чолганышта эсирлеккэ элэккэн, тиф белэн ятып үлемнэн чак калган... Качкан, партизан булып йөргэн... Хэзер Күмертауда тора. Бульдозерда эшли, ди. Әле былтыр гына семьясы белэн кайтып, бер башкорт дусларында — теге түбэн очтагы Вэли Баязитовны хэтерлисендер, хэзер агроном ул — менэ шунда атна буе ятып китте. Хатынына, балаларына урамнарны, су буйларын күрсэтеп йөрде... Туган җирлэре бит...»

«— Иргэли? Ә-э, теге башкисэр Карагужинмы? Советлар Союзы Герое ул, полковник... Кайткалый... энисен, туганнарын күреп киткэли...

«— Гоша Яковлев Күмертауда, тимер юлчы ул. Газетада рэсеме дэ бар иде эле...»

«— Костя Смоляков?... Октябрьскида, нефтьче, оператор, диме...»

«— Кызыл чэч Али Асанов Уфада, фэннэр кандидаты, доцент...»

«— Сеня Катаев сугышта үлгэн ул...»

«— Анна эбинең Матренасымы? Кияүгэ чыккан иде. Ире сугышта үлде... Улы Моратшада шофер, өйлэнгэн... Матрена биредэ торды, сыерлар сава иде. Былтыр гына өен сатып Кызыл Ярга китте эле. Кияүгэ. Дүрт бала өстеннэн...»

«— Колялармы? Ел саен кайталар. Ел саен бүлэк ташыйлар. Әле июль башында гына монда иделэр. Миңа — күлмэк тэ купшы итеклэр, Алешага — энэ, яңа мылтык... Бу Ишгилдедэн берсе дэ аерылып бетэ алмый шул. Әле Салаваттан, эле Нефтекамскидан, эле күмэклэп төрле җирдэн берьюлы кайтып төшэлэр. Я туп-туры безгэ кайталар, я башкорт дусларында яталар! Дачадагы кебек! Кайткан саен безгэ килэлэр. Тарас Иванычны искэ алалар...»

* * *

Тормыш туктаусыз агыла, тормыш үзенекен итэ. Ә син Ишгилденең болай үзгэрүлэрен, яңалыкларын күрми йөргэнсең...

Киткэннэр, таралганнар...

Син аларга хэерле юл телэмэс идеңмени?

Шоферлар, бульдозерчылар, нефтьчелэр, хэрбилэр, элемтэче, тимер юлчылар... Барысының да артларыннан житеп бер генэ сүз эйтэсе иде:

— Эшлэрегез уң булсын, язмышларыгыз якты булсын, иптэшкэйлэр!..

* * *

— Һавалар матур тора,— дип куя шоферыбыз, ай яктысында басу уртасыннан килгэн комбайннар ягына баш кагып.— Сменщиклары, күрэсең, эшне туктатмыйча ук алмашыналар...

Әбрар Шәмин

# АЛТЫН МЕДАЛЬОН

хикәя

## I



уктале, кайтуларына гөмбә шулпасы әзерләп куйыйм, исләре китсен,— диде Әминә апа үз-үзенә һәм өстендәге макинтошын салып чөйгә элде дә кухняга керде, ак алъяпкыч бәйләде, поварларча ак калфак киде. Аннары кухняның тәрәзәсен ачып җибәрде.

Август ае иде. Тәрәзә аша эчке якка саф һава бәреп керде. Ул да түгел, коридорда телефон шалтырый башлады. Моны ишетеп, Әминә апа кухнядан чыкты һәм телефон янына килде.

— Тыңлыйм!

Җиңел генә ак трубкадан Әминә апаның оныгы Эльвира тавышы ишетелде:

— Кайттыңмыни, дәү әни? Сөенче бар, бик зур сөенче! Мин хәзер кайтып җитәм.

— Ярый, кызым, ярый,— диде Әминә апа һәм телефон трубкасын акрын гына куеп, яңадан кухняга керде. «Сөенче, нинди сөенеч булыр икән?» — диде ул эченнән генә һәм кулына пычак алып, гөмбәләрне чистартырга керешге.

Әминә апа кунакта булып кайтты. Аерылганнан бирле күп еллар үтеп китсә дә, дуслык хисләре сакланган икән әле: Әминә апа үзенең яшьлек дусты һәм ерак туганы, хәзер инде пенсиягә чыгып, Аккош күле ягында яшәүче Мәрфугасы янында булды. Мәрфуга гынамыни? Әй, ул якларның нарат һәм каен урманнары... Читләренә таллар үскән аксыл күлләре... Гөмбәле чокырлары һәм чәчәкле аланнары... Ләкин, нишлисең бит, гомернең үтеп киткәнен сизми дә каласың икән...

Мәрфугалар дачасында ул бер атна торды һәм үзен мәшәкатьсез кеше кебек хис итте. Хәер, аның мәшәкатьләре үз өендә дә күп түгел хәзер. Бер уйлаганда, шулай булмый хәле юк: гомер буе диярлек карап үстергән бердәнбер кызы Нәгыймә ханым — танылган врач, ә кияве Солтан Дәүлиев — күренекле инженер. Оныгы Эльвира исә дүртенче ел инде чит телләр факультетында укый.

«Ни дисән дә, үз йортында яхшырак»,— дип уйланды Әминә апа, болын кебек иркен квартирага кайтып, өч бүлмәнең өчесенә дә күз салып чыккач.

Өй тын, бераү дә юк. Ләкин карчык моңа күптәннән ияләшкән инде. Аның кияве белән кызы көне буе эштә була, ә Эльвира укудан кайтмаган иде әле.

Ниһаять, Эльвира кайтып керде һәм күбәләктәй очынып:

— Сөенче, дәү әни, сөенче! — дип кычкырды. Ул да түгел, әбисенең битеннән үбеп алды да күрше бүлмәгә чыгып китте. Түзмәде, кыз артыннан әбисе дә иярде.

— Беләсеңме, дәү әни? — диде Эльвира.— Кичә бездә бер кунак булды. Чит ил туристы! Кызганыч, өйдә ялгызым гына идем. Әни дә күрми калды, әти командировкада. Кызык бит. Инглизчә сөйләштем! Ә үзе нинди зур шатлык китергән. Менә хәзер хәйран буласың...

Эльвира язу өстәленең тартмасын ачып ниндидер күз ияләшмәгән конвертлы хат чыгарды һәм әбисенә бирде.

— Менә, дәү әни,— диде ул.— Кичәге турист китерде бу шатлыкны. Әнием белә, бергә укыдык.

Карчык аптырап калды: бу нинди хат? Кемнән? Кемгә ул? Эльвирагамы? Әллә Солтанга яки Нагыймәгәме? Мөгаен, Солтангадыр: ул үзе дә кайлардадыр турист булып йөрде ич. Ә шулай да нинди шатлык икән ул?

Карчык ашыкмый гына күзлеген киде һәм хатны укый башлады.

«Әни һәм Нагыймә! Бәлки сезнең берәрегез исәндер әле? Бу хатны җир шарында иң бәхетсез кеше — Галимҗан яза...»

Галимҗан... Карчыкның шундук йөзе яктырып китте һәм җыерчык төшкән юка гына иреннәре тибрәнеп куйды. Ул да түгел, күзләренә шатлык яшьләре килде.

— Исән икән ләбаса, исән икән! — диде ул, хатны күкрәгенә кысып һәм рәхәтләнеп елый башлады.

Бер уйлаганда акылга сыймас: карчыкның кырыгынчы елда хәрби хезмәткә китеп, сугыш башлангач та юкка чыккан һәм күптән инде фронтта үлде дип исәпләнгән улы язган иде бу хатны.

— Тынычлан, дәү әни, тынычлан! — диде Эльвира, карчыкны кочып.

Карчык әллә нинди ләззәтле бер төштән уянып киткәндәй булды һәм янә хатка текәлде.

«Сез инде мине сугышта үлде дип уйлагансыз. Юк, кызганычка каршы, мин исән әле. Авыр әсирлек һәм рәхимсез язмыш чит илләргә ташлады мине. Менә инде сездән аерылганга ничаклы еллар үтте! Бу хатны мин сезнең якларга турист булып баручы дустым Чарль Ричард белән җибәрәм. Әгәр ул сезне тапса, аның аша җавап языгыз әле! Дөньядамы сез? Хәзер кайда, ничек яшисез? Сеңлем Нагыймә ирдәдер инде. Тагын нинди үзгәрешләр бар? Ни булса да, кайтырга телим... Кайтам! Әгәр дә мин көтмәгәндә кайтып килсәм, кабул итәрсез микән? Нишлим соң? Сезнең якларда минем өчен дә бер кадерлек җир табылыр дип уйлыйм. Аңлыйм, бу хатны алгач, «Нигә ул шушы көнгәчә кайтырга теләмәгән?» — дип шикләнерсез. Дөрес, мин гаепле. Ләкин биредә мин ялгызым гына түгел, семья белән яшәдем. Ике балам да булды. Берсе үлде, берсе — Көньяк Вьетнамда хәзер... Үткән елны хатыным вафат булды.

Ярый, ни булса да кичер инде, әни. Бик үтенәм, бик! Менә сезнең якка кунак булып баручы Ричард — минем иң якын кешем. Мине ничек күрсәгез, Ричардны да шулай кабул итегез, яме? Хатымны дөрес аңлагыз инде. Мин үземне акламыйм: гаебем зур, әлегрәк илемә кайтсам, яхшы буласы икән.

Ричард аша сездән хат көтәм. Күнел сизә, күрәсең, өметем зур! Сезне сагынып, шушы хатны язучы — Галимҗаныгыз».

Хат шулай беткән иде. Аны укыганда да, укып чыккач та карчык Галимне берничә тапкыр күз алдына китерде. Әнә ул! Ул чакларда нибары унтугыз яшьлек малай... Чандыр гына урта буй... Житен сыман саргылт чәч, коңгырт күз... Өстендә кыска пальто... Хәрби хезмәткә китүчеләр сафында бара. Аннары: вокзал, кызыл вагоннар. Гармун тавышы. Ниһаять, китте, күздән югалды... Озакламый әтисе дә югалды. Заманында армиядән кече командир булып кайткан иде ул. Эш арасында ауга йөрүне, балык тотуны ярата иде. Аннары, сугыш... Нишлисең бит, шул сугыштан кайтмады, мәрхүм... Менә инде Галимҗанның исәнлеге турында ул да ишетсә иде хәзер. Әй ишетсә иде! Ни дисәң дә, әтисен күбрәк ярата иде Галимҗан... Ир белән хатын арасында сүз чыкмый буламыни? Шундый чакларда, өйрәтеп куйган кебек, гел атасы ягында иде...

Карчыкның уй-фикерләре куерганнан-куера барды: «Әйе, бик күп еллар һәм кайгы-хәсрәтләр үтү белән бергә, йөрәктәге авыр яра да төзәлә башлаган кебек иде. Юк, төзәлмәгән икән әле... Менә ул, тоз сипкән сыман, тагы ачылды, тагы сызлый башлады! Йа хода, Галимҗан исән икән. Ләкин кайчан, ничек кайтыр ул?»

— Аһ, дөнья! — диде карчык һәм тәрәзә каршына килеп туктады. Аның чал сибелгән чәчләре һәм ябык иңнәре дер-дер калтырый иде.

— Дәү әни, әйдә, абыйга хат языйк, тизрәк кайтсын,— диде Эльвира, әбисе янына килеп.

Карчык дәшмәде. Бераздан стена буенда торган шкаф янына килде, аның аскы тартмасын ачты, юка гына иске сумка чыгарды һәм аннан саргаеп беткән кәгазьләр алды.

«Хөрмәтле Әминә ханым Шакирова!

Сезнең ирегез Мөхәммәтҗан иптәш Шакиров 1941 елның өченче октябрь көнне фашистларга каршы каты көрәштә каһарманнарча һәлак булды һәм Новгород өлкәсенең Тын күл авылы янына күмелде. Кайгыгызны уртаклашып, хәрби часть командиры —

Петров.

4. 10. 1941 ел».

Менә янә бер хәбәр:

«Кадерле ана!

Сезнең улыгыз Шакиров Галимҗан Мөхәммәтҗанович Бөек Ватан сугышының Псков участогында булган авыр сугышта билгесез юкка чыкты.

Район хәрби комиссары Гафаров.

30 октябрь, 1941 ел».

Ике хәбәр... Берсе — һәлак булды, икенчесе — югалды... Нишлисең бит, ана йөрәген аз тетте менә алар?! Ә шулай да күңел көткән, бик көткән, бик озак көткән иде. Ялгышмаган, күрәсең: әнә Галимҗан исән икән! Ничек килде бу шатлык, ничек?!

Әминә апа кәгазьләрне яңадан урынына куйды һәм аның бөтен дөньяны яңгыратып: «Кайт, улым, тизрәк кайт!» — дип кычкырасы килде. Шул арада карчыкның кызы Нәгыймә кайтып керде.

— Ай-һай, әни, сагындырып бетердең,— диде ул елмаеп һәм әнисен шатландырырга ашыкты.— Эльвира әйтмәдемени? Абый исән икән бит, әни!

Ананың күзләре янә яшь белән тулды.

— Беләм кызым, беләм,— диде ул.— Әле генә хатын укыдым.

— Әни, абыйны әйтәм әле, ничек инде ул?..— диде Нәгыймә.

Нәгыймә абыйсы турында кичәдән бирле уйланып йөри иде. Чандыр гәүдәле, җитен чәчле, сәер холыклы усал малай итеп хәтерли ул абыйсын. Нәгыймәгә әле алты-җиде тирәсе генә иде. Ә Галимҗанга, күп

булса уникелэр булгандыр. Шулай да Нэгыймэнең эле дэ күз алдында: аның абыйсы Галимҗан үзе укый торган мэктэпне һэм өйне ташлап, кемнэргэдер ияреп, каядыр качып китте. Аннары аны милиционер алып килде... Дөрес, Галимҗанның мондый эшлэре кабатланмады бугай... Ниһаять, аны армиягэ алдылар. Эйе, моңа инде күп еллар үтеп китте. Ул елларның давыллы минутлары хэтергэ сыямыни? Буталды, барысы да буталды... Хэзер инде Нэгыймэгэ абыйсы белэн бэйлэнеше булган күп вакыйгалар бик ерактан, эллэ нинди куе томаннар арасыннан гына күренэ сыман.

— Ярый,— диде ул күңеленнэн генэ.— Күптэн инде дөньяда юк дип саналган абый кеше табылды, ди. Э нигэ соң ул шушы көнгэчэ иленэ кайтырга телэмэгэн? Ни көткэн ул, ни көткэн? Андыйларга илгэ кайту өчен рөхсэт бирелде ич! Чит илдэн кайтып килүчелэр дэ булмады түгел, булды. Э ул нэрсэ уйлаган? Нигэ соң ул тол энисен, туган илен һэм үксез сеңлесен онытып йөргэн? Нинди хэл бу, нинди хэл? Ни өчен ул элегрэк кайтырга тырышмаган? Кем ул хэзер, кем?

Нэгыймэ мондый шиклэрне энисенэ дэ эйтмэкче иде, лэкин эйтмэде, тыелды: карчыкның хэтерен калдырасы килмэде.

Кухняга Эльвира килеп керде.

— Дэү эни! — диде ул.— Абыйга инглизчэлэп хат языйм һэм кайтырга чакырыйм, яме? Югыйсэ, берсекөнгэ турист килер, «килэм» диде ул.

Бу вакытны Эминэ апа кайларгадыр таралып киткэн уй-фикерлэрен бер йомгакка җыя алмыйча аптырый иде.

— Нэрсэ? — диде ул Эльвирага. Тик аннан соң гына: — Эйе шул, эйе. Лэкин атагыз белэн киңэш итэсе иде, ул нинди киңэш бирер тагы,— диде һэм Нэгыймэгэ карады.

— Дөрес, эни,— диде Нэгыймэ.— Э Солтан: «Иртэнге поезд белэн кайтып җитэрмен», дигэн иде. Кайтыр: Мэскэү белэн безнең ара ерак түгел бит...

Шундый карарга килеп һэм кичке чэйне эчеп йокларга яткач, Эминэ апа тынычлана төшкэндэй булган иде, лэкин бик озак йоклый алмады, эле мэрхүм ире Мөхэммэт, эле улы Галимҗан белэн бэйлэнеше булган эллэ кайчангы минутларны күңеленнэн кичерде...

Ул вакытта Эминэ апа, бөтен семьясы белэн бергэ, туган авылы Башбалыкчыда яши иде эле. Энэ алтыны гына тотырган Галимҗан... Өстендэ сарыга манган киндер штан һэм киндер күлмэк. Өй каршындагы чирэмлектэ тавык чебешлэрен саклый ул. Кулында таяк. Ата каз таламасын, янэсе. Шул вакытны көтмэгэндэ һава бозылып, көчле җил күтэрелде һэм урам буенча соры өермэ уйный башлады. Ул да түгел, коточкыч зур кара тилгэн һавадан атылып төшеп, бер чебешне элэктереп алды да, канатларын ашыкмый гына кага-кага, китеп тэ барды. Э Галимҗан елый, эй елый, мескен, эйтерсең лэ, ни кадерле уенчыгын алып киткэннэр. Галимҗанны көйлэргэ кирэк иде. Энисе исэ, йөгереп килеп, суккаларга тотынды аны. Ник суккан ул аңа, ник суккан?! Сабый баланың нинди гаебе булган?!

Аннары, ничэ еллар үткэндер инде — хэтердэ сакланмаган, шулай да, шэһэргэ күчеп килеп, тэрэзэсе җиргэ үелып кергэн кечкенэ генэ таш бүлмэдэ торган чаклары исэ калган. Мэрхүм Мөхэммэт Галимҗанның дэреслэрен тикшереп утыра.

— Матуррак язарга тырыш! — ди ул.— Хэлфэн соклансын! Ярыймы?

— Ярый,— ди малай.

Азмы-күпме укымышы булган энисе дэ сүзгэ кушыла:

— Бу нэрсэ бу?! Мондый ямьсез хэреф өчен, безнең остабикэбез булса, колагыңа тондырыр иде!

Галимҗан дэшми. Тик лышт-лышт итеп борынын гына тарткалап куя.

Әминә апа улының кәкре-бөкре хәрефләрен күз алдына китерде.

Карчык урыныннан торды, утны кабызды, күзлеген киде, өстәл тартмасын ачты һәм аннан улының хатын алып укый башлады.

«Әни һәм Нәгыймә!

Бәлки сезнең берәрегез исәндер әле? Бу хатны...»

— Әйе, Галимҗан язган моны, Галимҗан кулы,— диде карчык эченнән генә.— Мәктәптә укыганда да, солдаттан җибәргән хатларында да нәкъ шулай яза иде. Дөрес, кайбер хәрефләре Галим кулына охшамый охшавын... Хәер, ул еллардан бирле үзе дә нык үзгәргәндер инде. Илле белән бара бит. Ә менә теле — нигәдер ят. Ярабби, нигә ул элеккедәй күңелгә якын түгел? Нигә коры, нигә салкын? Әллә чит илләрдә, чит җирләрдә үксез булып яшәгәнгәме?

Әминә апа, улы белән сөйләшергә теләгәндәй, хатны берничә тапкыр укып чыкты.

Бу вакытны Эльвира шул ук бүлмәдә тын гына йоклый иде. Бер генә дә хәсрәте юк, күрәсең: бүлмәдә янып торган ут яктысы да комачауламый аңа. «Их, гамьсез яшьлек! Нишлисең бит, булмады, мондый яшьлек туры килмәде безгә», дип уйлады карчык...

## II

Иртәгесен ял көне иде. Эльвира иртәнге ашны ашык-пошык кына капкалады да каядыр чыгып китәргә җыенды. Һәм коридорда торган зур көзге каршына килеп, төзәнә-бизәнә башлады. Шул вакытны ишектә кинәт зәгыйфь кенә тавыш чыгарып, кыңгырау чыңлап куйды. «Әти кайтты»,— диде Эльвира күңеленнән һәм тиз генә ишекне ачты. Әмма ни күзе белән күрсен: ишектә әтисе түгел, ә теге турист иде.

— Гуд монинг! [1]— диде турист, шактый ягымлы тавыш белән.

Кыска буйлы, чандыр гәүдәле, зәңгәр күзле, урта яшьләрдәге кеше иде ул. Өстендә гади генә соры костюм, кулында портфель.

Сүз инглиз телендә барды.

— Рәхим итегез! — диде Эльвира, баладай куанып һәм кунакны залга чакырды. Шул арада, кухняга борылып, әниләренә: «Турист килде», дигән ишарә ясап алды.

Турист залга үтте, кулындагы портфелен диванга куйды һәм өстәл янында торган йомшак урындыкка утырып, Эльвирага текәлде.

— Каядыр ашыгасыз бугай, туташ?

Кыз чиксез шат иде.

— Юк, сэр, юк, вакытым сезнең ихтыярда.

Эльвира, кыска күлмәге астыннан күренеп торган тулы тезләрен бөгеп, турист каршына килеп утырды һәм:

— Мин шат, сэр, менә сез килүгә әби дә кайтты,— диде, елмаеп.

Турист бер мәлне нигәдер дәшми утырды.

— Мине бик кызыксындыра, сөйләгезче, сэр! — диде Эльвира.— Безнең абый инглиз телен яхшы беләме?

Турист елмаеп куйды һәм:

— Бик яхшы белә,— диде.— Бирегә кайткач, сезнең белән ярышмый калмас, ләкин...

Турист тагы нәрсәдер әйтмәкче иде, ләкин әйтмәде, сүзне башкага борды.

— Әбиегезне күрәсе иде, туташ, дустыма хат язмады микән?

— Әх, юктыр әле, сэр, чөнки без сезне иртәгә көтә идек,— диде Эльвира һәм урыныннан тиз генә торып, кухняга чыгып китте.

Карчык белән Нәгыймә, плау пеширергә дип, дөге чистартып утыралар иде. Туристның килеп керүен ишеткәч, икесе дә каушап калдылар:

---

[1] Хәерле иртә.

«Нишләргә? Галимҗанга нинди җавап язарга? Солтан да кайтып житмәде ичмаса!»

— Әйдәгез, туристның сезне күрәсе килә,— диде Эльвира, кухняга кереп.— Бүген ул никтер күнелсезрәк кебек...

— Нәрсә, әллә китәргә җыенамы? — Нәгыймәнең күз алдына янә абыйсы килеп басты.

— Җыенадыр, конечно,— диде Эльвира.— «Әбиең Галим дустыма хат язмады микән», ди.

Нәгыймә әнисенә карады.

— Язарбыз,— диде карчык.

Нәгыймә әнисен аңлый һәм ул үзе дә Галимҗанны кызгана иде. Ни дисәң дә, абый кеше бит, бер туган абый! Өстәвенә, бер уйлаганда, гаебе дә юк кебек аның. Чит илләрдә калып семьялы булгач, яңадан кайту ансат эшмени? Язмыш аны туганнарыннан читтә — ят илдә калырга мәҗбүр иткән! Әгәр дә гаепсез булып һәм Мәскәүнең рөхсәтен алып өйгә кайтып күренсә, хатына җавап язмаган өчен вөҗданың ничек чыдар?

— Әйдәгез залга, бу нинди культурасызлык?! — диде Эльвира һәм турист янына чыгып китте.

Карчык алъяпкычын салып буфет янына элде һәм өс-башын төзәтергә кереште.

— Әйдә, кызым, чыгыйк, сөйләшик әле, Галимҗан турында кунак ни белә икән?

— Ярый,— диде Нәгыймә һәм, өс-башымны рәтлим дип, күрше бүлмәгә чыгып китте.

Күпмедер вакыттан соң алар залга керделәр. Карчык, залга кереп туристны күргәч, үзенең улын күргәндәй булды һәм аның күзләренә яшьләр килде.

Болар керүгә, турист кинәт урыныннан торды һәм әүвәл карчыкка, аннары Нәгыймәгә баш иде.

— Һау ду йоуду[1]. Турист Чарль Ричард.

Әминә апа һәм Нәгыймә ханым турист белән кул биреп күрештеләр дә диванга килеп утырдылар. Турист исә диван каршында торган йомшак креслога утырды.

— Эльвира! — диде карчык, залда урнашып барган авыр тынлыкны бозып.— Сорале, кызым, Галимҗан абыең хакында нәрсәләр белә икән ул?

Эльвира сорауны тәрҗемә иткәч, турист Галимҗан турында сөйли башлады. Карчык өчен бик ят һәм сәер иде кунакның теле. Ярый әле: Эльвира мондый телләрне юкка гына өйрәнми икән.

Галимҗан әсирлеккә сугышның башында ук эләккән, ди турист. Шул көннән башлап, өч елдан артык вакыт эчендә нинди генә лагерьларда булмаган ди ул. Ә сугыш туктагач: «Илеңә кайтсаң, атып үтерергә хөкем итәләр сине», дигәннәр аңа. Галимҗан ышанган моңа һәм лагерьдан исән-сау котылса да, илгә кайтырга тырышмаган. Ниһаять, ул Фленбург портына килеп туктаган сәүдә пароходына эшкә урнашып, әллә нинди диңгезләр һәм океаннар аша, бөтен дөньяны гизгән, рәхәт тормыш эзләгән. Ахырында ниндидер бер ятим кызга өйләнеп, семьялы булган.

Турист шулай дип сөйләде, ә карчык, күзләрендә хәсрәт чагылдырып, дәшми утырды. Аннары ул, акрын гына урыныннан торып, кухняга чыгып китте. Бераздан Нәгыймә дә кузгалды.

— Эльвира, кунакка чәй әзерлик микән? — диде ул, бер кызына, бер туристка карап.

---

[1] Исәнмесез.

— Әзерләгез, конечно,— диде кыз, туристтан сорамый гына,— холодильниктагы коньякны да ачыгыз, яме!

Залда Эльвира белән турист икәү генә калдылар.

Нәгыймә кухняга килеп кергәндә Әминә апа, тәрәзә янагына сөялгән килеш, урамга карап тора иде.

— Әни, әйдә кунакка чәй әзерлик! — диде Нәгыймә.

Карчык сискәнеп китте һәм:

— Күңелем көтә, кызым, менә хәзер Галимҗан кайтып килер шикелле,— диде.

— Кайтып килсә, бик әйбәт булыр,— диде Нәгыймә.

Алар, һаман әле Галимҗан турында бергәләшеп көенеп, табын әзерли башладылар...

Ничек башланып киткәндер, ләкин бу вакыт турист залда Эльвираны фоторәсемгә төшереп маташа иде.

Яшьлек дәрте кайный, күрәсең: Эльвира арлы-бирле очынып әле тәрәзә янына килеп басты, әле почмакта торган телевизорга барып таянды, әле пианино каршына үтте, ә турист аны төшерде дә төшерде.

Аннары матур гына елмаеп:

— Рәсемнәрегез безнең ил кызларын таңга калдырмый булмас, туташ,— диде.— Мин аларны өлгерткәч, хат белән җибәрермен, ә берсен, рөхсәт итсәгез, үземә калдырырмын, ватаныгызның матур истәлеге булып сакланыр. Ярыймы?

— Ярый, сэр, рәхмәт,— диде кыз, җем-җем итеп торган ак тешләрен күрсәтеп.

Турист фотоаппаратын портфельгә салып диванга килеп утырды. Шул вакытны зал ишегеннән Нәгыймә ханым һәм карчык килеп керде.

Ашъяулык ябылган түгәрәк өстәл минут эчендә эре-эре кисәкләргә туралган тавык ите, куырылган йомырка, алма, чия һәм апельсин белән тулды. Ул да түгел, өч йолдызлы коньяк та килде.

— Рәхим итегез! — диде Нәгыймә, сабыр гына елмаеп.

Утырдылар.

Берәр рюмкадан соң, һәммәсенә дә ничектер күңелле булып китте. Тик карчык кына коньякка кагылмады.

— Сыйла, кызым, сыйла, туйганчы ашасын! — диде ул, үзен Галимҗаны белән утыргандай хис итеп.

Кунак исә кыстатып тормый һәм шул арада үз тормышы, үз язмышы турында сөйли иде.

Шунысы гаҗәп: Чарль Ричард — үз иленең сәүдә пароходында күп еллар буе Галимҗан белән бергә йөреп, бергә ашап, бер каютада яшәгән кеше икән. Ричард да, Галимҗан да капитанның ярдәмчеләре булып хезмәт иткәннәр, ди. Ә моннан биш-алты ел элек алар икесе дә пароходтан китеп, ниндидер фәнни институтка урнашканнар икән.

Әллә шуңа таянып инде, турист үз өендәге кебек рәхәтләнеп утырды. Аннары хуҗаларга зур хөрмәт белән рәхмәт белдерде.

Ниһаять, аш узды һәм карчык белән Нәгыймә өстәлдәге табак-кашыкны җыештырып, залдан чыгып киттеләр.

Ричард белән Эльвира янә икәү генә калдылар.

Эльвира, менә инде дүртенче ел, инглиз телен өйрәнә, буш араларда немец һәм поляк телләре белән дә мавыккалый. Табигый хәл, көтмәгәндә чит илдән килгән кеше белән очрашу һәм аның белән күзгә-күз карап, туйганчы бер сөйләшү Эльвира өчен бик кызык һәм рәхәт иде. Шуның өчен дә: «Кунакка да күңелле булсын әле», диде ул эченнән генә һәм аңа, пианино өстеннән алып, рәсем альбомнары күрсәтергә кереште. Менә шәһәр альбомы... Бусы — Сочи күренешләре... Ә менә монысы — кием модаларыныкы. Модалар альбомының барлык битләрен берәм-берәм күрсәтеп чыккач:

— Ничек соң, безнең модалар ошыймы сезгә? — диде кыз.

Турист елмаеп куйды.

— Ошый, туташ,— диде ул.— Ләкин хатын-кызлар өчен искерә төшмәгәннәрме? Минемчә...

Ричард тагын нәрсәдер әйтмәкче иде, аны Эльвира бүлде:

— Аңлашыла, сэр.— диде ул.— Модалар тиз үзгәрергә тиеш димәкче буласыздыр. Ә сездә тиз үзгәрәме?

— Атна саен! — диде турист һәм нигәдер шаркылдап көлеп җибәрде.

Кыз сагайды.

— Нигә, сэр, әллә сез модаларга каршымы?

— Юк, юк, киресенчә! — диде Ричард, җитди төс алып.

Шуның белән мода турындагы әңгәмә өзелеп калды.

Кич булып килә иде. Тәрәзәдән кергән шәфәкъ нурлары Эльвираның битендә уйный башлады.

— Кыз чибәр,— диде турист эченнән генә һәм аңа сокланып карап куйды. Кыз исә сокланырлык иде шул. Әнә күзләре нинди кара һәм саф. Аз гына күпереп торган җыйнак ирен, озын керфек, энҗе теш. Өстәвенә, искиткеч матур буй-сын. Кыскасы, сирәк очрый торган чибәрләрнең чибәре иде ул!

— Пианинода кем уйный, туташ, бәлки берәр көй уйнар идегез,— диде турист.

Кыз тиз генә пианино каршына күчеп утырды һәм аны ачып, испан серенадасын уйный башлады.

«Әйбәт уйный», дип уйлады Ричард, ә музыка туктагач:

— Браво, браво! — дип кычкырып куйды. Аннары, Эльвираның янына ук килеп утырып: — Минем татар көйләрен ишеткәнем юк, ә Галим җырламый иде, үзегезчә уйнагыз әле, туташ? — диде ул.

Эльвира «Таң йолдызы»н уйный башлады.

«Таң йолдызы»ның бер күтәрелеп, бер түбәнәеп, бер киң кырлар сыман киңәеп киткән салмак агышлы моңнары күңелләрдә әллә нинди нечкә хисләр уята иде.

Күп тә үтмәде, музыка тынды. Аннан соң турист берничә секунд дәшми утырды.

«Татар моңы турында чит ил кешесенең фикере ничек икән? Ул нигә дәшми?» Кыз туристка шундый сорау белән карады.

— Гаҗәп! — диде турист.— Сезнең моңыгыз рус моңына тартым.

Эльвира татар моңының үзенчәлекләре турында кунакка сөйләргә дә уйлаган иде, тик Ричард, бәхәскә керәсе килмәгәндәй, урыныннан торды.

«Бер карасаң кызык ич! Эльвира чит ил телләре белән мавыга, яңа модаларны да ярата кебек, ә менә бу асыл бүләк ничек тәэсир итәр соң аңа?» дип уйланды ул һәм диванда торган портфелен ачып, алтын медальон чыгарды һәм кызга биреп:

— Сезне хөрмәт итүемнең бер истәлеге булсын, туташ,— диде елмаеп.

Кыз да елмаеп куйды. Ләкин бу елмаюда ниндидер сагаю барлыгы сизелеп китте. Ул бүләкне әйләндергәләп карады, ләкин артык искиткеч тәләмәте күрсәтмәде. Шуның өчен дә: «Юк, шатланмый, шикләнә, күрәсең»,— диде турист эченнән генә һәм ярлы-бирле йөренә башлады.

Мондый бүләккә нинди генә кыз шатланмас икән! Ләкин чит-ят кеше алдында авыз ерып утырмассың бит.

— Рәхмәт, сэр,— диде кыз сабыр гына.

Беразга әңгәмә өзелеп торды. Аннары Ричард тагын хат турында искә төшерде. Эльвира әниләре янына чыкты.

...Солтан булмасе. Биредә Нәгыймә ханым Галимҗанга хат яза, ә карчык аңа әйтеп утыра иде.

«Кадерле балам!

Хатынны алдык. Рәхмәт. Бездән күп сәлам сиңа. Шөкер, без исән әле. Тормышыбыз да әйбәт. Нәгыймә — ирдә. Врач. Гомерләр үтә, кызы да үсеп җитте инде. Үзем пенсия алам. Тик менә атаң мәрхүм һәм синең өчен гомер буе кайгырдым. Ярый, исән икәнсең әле. Әмма мин сине, улым, чит илләрдә вәйран булып йөрер өчен үстермәгән идем ич. Акылга сыймый: нигә син мине ят илгә алыштырдың? Ә мин сине ничә еллар буе өзелеп көттем, көне-төне кан-яшь түгеп еладым. Ә син... Шулай да мин сине әле дә көтәм, әле дә бик сагынам һәм бик кызганам! Менә хәзер дә, бала чагыңдагыдай, күз алдымда басып торасың. Кайт, улым, кайт! Хәерле юл белән кайт! Яшьлектә булган адашуларыңны юарга тырыш!»

Хатның шушы урынына җитүгә, Эльвира килеп керде һәм керүе белән:

— Карагыз әле, карагыз,— диде шыпырт кына.— Менә турист нинди медальон бирде миңа. Алтын бит, билләһи алтын!

Һәммәсе дә гаҗәпләнеп, бүләкне карарга тотындылар. Сүз дә юк, моңа чаклы берәүдә дә күренмәгән искиткеч бүләк иде бу. Уртасында, салават күпере сыман, аллы-гөлле нур уйный һәм ул нурга караган саен карыйсы килә. Дөрес, алтын дигәч тә алтын ук түгел, ахры, тик шундый төскә генә буялгандыр ул, әмма көязрәк хатын-кызларны, һичшиксез, әсир итәрлек әйбер. Тасмасы да шәп: җем-җем итеп, гел җемелдәп тора.

Эльвира аны муенына тагып карады һәм әниләреннән: «Килешәме?!— дип сорады.

— Килешә,— диде Нәгыймә ханым, ә карчык үзенчә бәяләде:

— Килешә дә, зуррак, яна гына чәчәк аткан көнбагыш кебек.

Эльвира чыраен сытып куйды һәм, бүләкне калдырып, кунак янына чыгып китте.

Эльвира залга килеп кергәндә турист, тәрәзә аша урамга карап, уйланып тора иде.

— Ярый, туташ,— диде ул, китәргә ашыгып.— Юл кешесе юлда булырга тиеш, ләкин дустыма бирәр төрле хат булырмы икән?

— Була, сэр, була! — диде кыз һәм яңадан әниләре янына чыгып китте...

Ниһаять, туристны озаттылар һәм абыйга Галимҗанга язылган әлеге хатны да тапшырдылар.

— Ярабби,— диде карчык балконга чыгып һәм турист киткән якларга карап калды.

### III

Ричард, карчык өеннән чыгу белән, шәһәрнең зур кунакханәсенә, үзенең юлдашлары янына кайтып китте. Алар инде иртәгә үзләренең илләренә китәргә тиешләр иде.

Сәгать кичке җиде тирәләре генә иде әле. Киң урам буйлап, гадәттәгечә, якты троллейбуслар, җиңел машиналар сыргыла, ә тротуарларда — халык. Әгәр дә сынап һәм санап чыксаң, биредәге кешеләрнең уй-фикерләре ничәгә тулыр икән? Ричард исә әле карчык, әле Нәгыймә, әле Эльвира турында уйланып барды.

— Ышандылар, яхшы каршыладылар,— диде ул күңеленнән.— Ләкин кайсын гына алып карама, берсе дә алдан уйлаганча туры килми. Юк, таянырлык багана итеп булмый аларны... Хәтта Эльвираны да. Нишлисең бит, барысы да үз сукмагында нык басып тора! Әллә инде бу якларга юл киселдеме? Әйе, шулайга охшый! Мондый шартларда берәрсенә сүз салып кара әле? Нишләргә соң, нишләргә? Шулай итеп барлык мәшәкатьләр бушка булыр микәнни?

Ричард шулай уйланды. Уйланды да әле үткән айда гына үз илендә булган бер вакыйганы күз алдына китерде.

...Менә биредән бик еракта, дингез һәм океаннар артындагы зур шәһәрнең тар урамнары, биек йортлары, сәүдә, газета-журнал һәм дәүләт идарәләре... Ниһаять, тугызынчы каттагы аерым бүлмә... Йомшак диван, пыяла буфет һәм түгәрәк өстәл... Әнә, өстәл каршында урта яшьләрдәге ике кеше утыра. Берсе жыйнак кына кара сакаллы, кап-кара чәчле, өстендә — яңа костюм, икенчесенең чәче коелган, кашларына ак төшкән, өстәвенә сул кулы да юк. Өстендәге костюмы да бик иске анын.

Алларында ниндидер ширбәт тирбәлә һәм ике бокал.

— Менә без тагын бергә,— диде сакаллысы ширбәтне бокалларга коеп,— ә кичә кайда кундың?

— Урамда, агач төбендә,— диде чулак.

Сакал чыраен сытып куйды һәм:

— Белмәдем бит, мондый хәлгә калуыңны белмәдем, дускай,— диде.— Әйтергә генә ансат,— дип дәвам итте ул,— без күрешмәгәнгә ничә еллар үтеп китте инде! Исеңдәме теге вакытлар? Ярый, киләчәге күңелле булыр! Мин сәяхәттән кайтыйм әле. Аннан соң мин сине үземә алырмын. Ә син хатыңны яз, яз. Мин әниеңне табармын: хатыңны тапшырмый калмам.

Чулак, каләмне сау кулына тотып, ниндидер уйга калды.

— Нәрсә, нигә язмыйсың? — диде сакал.

Чулак яза башлады, ләкин шундук туктады һәм:

— Нигәдер башым эшләми,— диде.

Теге сагаеп куйды.

— Ярый, мин үзем әйтеп торам, булмаса,— диде ул бераздан һәм әйтергә кереште. Ә чулак яза барды.

«Әни һәм Нәгыймә!

Бәлки сезнең берәрегез исәндер әле. Бу хатны жир шарында иң бәхетсез кеше...»

Күпмедер вакыттан соң хат язылып бетте. Сакал аны кулына алды һәм, конвертка салып, түш кесәсенә куйды. Аннары, бокалларны янә бер тапкыр тутырды. Янә эчтеләр.

— Хуш!

— Хушыгыз!

Чулак бүлмәдән чыкты, ашыкмый гына беренче катка төште һәм ничәдер минуттан соң урамның аргы башындагы чәчәк мәйданына юнәлде.

Сакал исә аның артыннан күзәтеп калды...

Чәчәк мәйданы... Биредә атлаган саен диярлек утырып ял итә торган яшел эскәмияләр тора иде.

— Ай-һай, хәлләрем! — диде чулак шуларның берсенә килеп утыргач һәм сау кулы белән маңгаен кысып тотты. Аннары эченнән генә чәчәкләр белән сөйләшергә тотынды:

— Әй сез, гөнаһсыз чәчәкләр! Әйтегезче, нишлим мин, нишлим? Сездән башка беркемем дә юк бит... Кайчандыр мин дә, сезнең кебек үк, саф жир баласы идем... Хәзер инде пычрак, әшәке кеше мин. Ләкин сез миннән жирәнмәгез! Минем болай да күңелем кайный, жаным ачып йөрәгемнән кара кан тама. Кинәш бирегез, гүзәл чәчәкләр, гаебем зурмы минем? Дөресен әйтим: мин әсир идем... Аннары язмыш мине бу якларга ташлады. Сезнең хужаларыгызның берсендә батрак булдым мин. Үзе белгәч, хужа мине зур гаражга тапшырды. Автослесарь итеп. Мин анда, автокранга кысылып, бер кулсыз калдым. Уйларым башыма сыймый, аптырыйм, йөдим, бер телем икмәккә тилмереп йөрим. Шушы яшемә житеп өем дә, илем дә, хезмәтем дә, гаиләм дә юк минем! Әйтегезче, нәфис чәчәкләр! Әллә фронтта үлгән атамның яки илдә калган

анамның каргышы төште микән? Нигә мине тормыш шулай җәберли? Нигә мин шулай мыскыл ителдем? Күпме вакыт шулай яшәргә мөмкин? Кем гаепле моңа, сугышмы?! Сез гаепле түгел, әлбәттә. Сез һәр илдә үсәсез. Шуның өчен сезнең белән сөйләшәм дә мин. Кем белә, бәлки инде минем әнием каберендә дә сезнең кебек гөнаһсыз чәчәкләр үсә торгандыр...

Тыңлагызчы, матур чәчәкләр! Моннан өч тәүлек элек иске хуҗам очратты мине. Көтмәгәндә, урамда, шушы мәйдан янында. Мине элеге гаражга урнаштыручы. Без аның белән бүген, менә хәзер генә тагын очраштык. «Мин туристлар группасы белән Советлар иленә барам, әнкәңне эзләп табармын, хат яз», дип ул. Ул бик явыз җан. Юкка гына шулай юмартланмас ул. Анда кайтса, әниемә һәм сеңелемә, тагын әллә кемнәргә әллә нинди кара бәхетсезлекләр алып килер. Ә мин хатны яздым. Сагынуыма чик-чама юкка яздым. Бәлки чыннан да анам кулына эләгер, дип өметләндем. Нәрсә эшлим, чәчәкләр? Шул ук хуҗаның офицер булган чагында әйткән сүзләренә ышанып, бу якларга килеп чыгуым һәм шушындый көнгә калуым җитмәгәнмени? Юк, чәчәкләр, күрә торып, илемә мин шымчы җибәрмәм! «Иелгән башны кылыч кисмәс», дигәннәр. Менә хәзер, хәзер үк дәүләтемнең илчелегенә барам. Барысын да ачыктан-ачык сөйлим. Дөрес бит, сердәшләрем!

Чәчәкләр гүя:

— Дөрес эшлисең, дөрес! — дияләр иде.

Чулак урыныннан торды һәм каршы яктагы урам чатына, матур гына дүрт катлы йортка ашыкты. Биредә исә Совет Илчелеге урнашкан иде.

Дүрт катлы йортның подъездына килеп җитәргә аз гына калган иде инде, ләкин сакаллы кеше утырган җиңел машина Чулакны таптап китте...



*Туган җирем Түбән Кама районы Ташлык авылы мәктәбендә укытучы апа тырыша-тырыша миңе чиста язарга өйрәтте. Әби өстәл янында аяк селкеп утырмаска, бабай җәя белән ук атарга, абый мылтык тотарга өйрәтте. Шигырь язарга өйрәтмәсләрме, дип, Чаллы әдәби берләшмәсе утырышларына йөри башладым. Ләкин Чаллыда да, соңрак Казан университетында да, мене инде хәзер Горький исемендәге Мәскәү Әдәбият институтында укыганда да шигырь язарга өйрәтмәделәр. Бу эшкә мин, кулымнан килгән кадәр, халкыбыз җырларыннан, әниемнең такмак, бәетләреннән, яхшы шигырьләрдән өйрәнәм.*

## Рәзил Вәлиев

### Аппассионата

Үлә шагыйрь, үлә президентлар:
Һәр көн саен дошман төзрәк ата.
Илләр елый ятып буразнага...
Колагымда — аппассионата.

Күз нурлары белән күкне терәп,
Мылтык кысып күпме ирләр ята!
Җир ярасы — окопларда йөри
Ул яраткан аппассионата.

Күңелләрдә һаман олы өмет:
Кеше барыбер җирне бик ярата!
Йөрәкләрдән саркып җырлар туа...
Ленин тыңлый аппассионата.

Хыялларым илләр, җирләр кичеп
Әйләнә дә тагын сиңа кайта.
Дөнья шаулый, гөрли, әйтерсең лә
Миң авазлы аппассионата.

## Вакыт

Арыдым бүген.
Дөньядагы барлык сәгатьләрне
туктатып
бер йоклыйсы иде.
Әй, җир!
Үзең белән әйләндереп
тилмертмәче мине.
Әй, җир!
Бер минутка гына
Туктыйсы иде.
Әй, җир!
Арыдым бүген.
Кичтән бирле
үзем генә киләм.
Әй, җир!
Кирегә әйлән әле?!
Ул бит артта калды...
Әй, җир!!!
...Тыңламый җир.

## Мизгел

Җир шарына утырып тәмәке төрдем.
Җир шарына басып сүндердем,
җир шарында арлы-бирле атлап йөрдем,
санап чыктым барлык шатлыкларны,
кайгыларны,
карап чыктым:
кемнең күзе йомык, кемнең ачык
һәм ни өчен.
Бизмәнләдем күз яшьләрен, таң чыкларын,
барын, барын, барын.
Онытып тордым йолдызларның
тик төннәрен януларын.
Бер мизгелгә
уч төбенә куеп тордым бу җир шарын.
Әйе, әйе!
Мин бер мизгел шагыйрь булып алдым.

## Мәхәббәт

Монда кояш
океан төбеннән күтәрелә.
Монда
сукбай һәм буйдак өй —
кул сузымы җитә.
Монда давыл
дулкын биеклеге белән үлчәнә.
Монда
болытларның күз яшьләре
иш янына куш кына.
Монда бар йолдызлар,
ике пар күз караганда, ахры,
бик якыннар һәм бик тоныклар.
Монда юллар, сукмаклар юк.
Монда адашканнар —
өметсез өметлеләр.
Монда төн һәм көн бар,
кыш һәм җәй юк.
Монда
шигырь,
шигырь,
шигырь —
шагыйрьләр юк.

**УДМУРТ ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫНЫҢ ӘДӘБИ ЖУРНАЛЫ**




**Геннадий Красильников**

# ТУГАНДАШ ХАЛЫКЛАР СЕМЬЯСЫНДА



Бу ил Идел-ана белән чал Урал уртасына, Кама һәм аның кызы Вятка арасына урнашкан. Ул үзенең күләме белән Даниядән дә, Голландиядән дә зур, Бельгиягә тиң диярлек. Хәзергә ул туристларның зур юлыннан читтә тора. Шулай да әгәр яңа җирләрне, Урал буеның матурлыгын күрергә, чибәр Каманы башлап җибәргән чишмәнең чылтыравын тыңларга теләсәң икән, моны тормышка ашыруы бик җиңел: мәсәлән, син Мәскәүдән икән, Мәскәү—Ижевск поездына гына утырасың да диста ярым сәгатьтән соң максатыңа ирешәсең. Химки елга портыннан да юлга чыгарга була — теплоход сине зәңгәр су юлы буйлап Каманың су башына ук алып киләчәк. Хәер, мәскәүле тиз йөрешле «Ракета» теплоходына да утыра ала. Сәяхәтне Быково аэродромыннан да башларга була: журналда басылган кроссвордны чишеп өлгергәнче, самолет бирегә килеп җиткән дә була инде.

Кем нәрсәгә утырып килсә дә, Россия җиренең аерылгысыз өлеше — яшь, чәчәк атучы, иркен Удмуртия аны кунакчыл каршы алачак һәм охшашы булмаган матурлыгын аның алдына җәеп салачак.

...Удмуртия предприятиеләрендә һәм колхозларында төрле телдә сөйләшүче кешеләр иңгә-иң торып эшлиләр. Җир-анадан көч алып яшәгән мифик Антей кебек, Совет строеның көче һәм куәте дә халыкларның бөек туганлыгында. Менә шуңа күрә дә дуслык — безнең иң кыйммәтле байлыгыбыз.

Бөек Октябрь революциясенә кадәрге вакытлар удмурт халкы өчен тоташтан караңгы, күңелсез төн иде. Кама буе урманнарында урядниклар, приказчиклар баш-

баштаклыгы хөкем сөрде. Ярлылык, наданлык, авырулар — кешенең бу коточкыч юлдашлары — удмуртны туганнан алып соңгы сулышына кадәр җәфалады.

Халык физик һәм рухи сукырлыкка дучар ителгән иде: трахомадан сукырайган кешеләр дини китапларны (башка төрле әдәбият удмурт теленә тәрҗемә ителмәде, туган телдә язылган әдәби китаплар турында сүз дә булырга мөмкин түгел иде) иҗекләп укучыларга караганда күбрәк иде.

Удмуртия Автономияле республикасын оештыручыларның берсе, ленинчыл революционер Иосиф Наговицын утыз биш ел элек болай дип яза: «Удмуртлар арасыннан революциягә кадәр югары белем алган өч кешене генә беләм. Бөтен өлкәгә биш-алты больница, удмуртлар арасыннан ике-өч агроном, урта белемле иллеләп укытучы — Октябрь революциясенә кадәр удмурт халкы ирешә алган нәрсәләрнең бөтенесе шулар».

1920 елның ноябрендә Владимир Ильич Ленин һәм Бөтенсоюз старостасы Михаил Иванович Калинин Россия Федерациясе составында Удмуртия Автономияле өлкәсе төзү турында декретка кул куйдылар. 1934 елда өлкә Автономияле республика итеп үзгәртелде.

Башка тарихи үзгәрешләр белән бергә, бу акт кеше шәхесенең чәчәк атуы өчен зур этәргеч булды. Менә бер мисал: Октябрь революциясенә кадәр удмурт әлифбасы туып кына килә иде, белемле кешеләрне бармак белән генә санарлык иде. Сүз уңаенда әйткәндә, 1897 елда ике өяздәге 50 мең кешегә бер мең чамасы газета һәм журнал туры килә иде. Хәзер республикада халык ел саен миллион данәдән артык вакытлы матбугат алдыра.

Удмуртия турында сөйләгәндә, лекторлар еш кына гадәти фразаны кабатлыйлар: «Элек бу як патша Россиясенең артта калган окраинасы иде», диләр. Бу сүзләр турында уйланырга ярый. Чыннан да, унтугызынчы гасырда рус халкының иң яхшы уллары бирегә сөргәннәр. Чорыбызның ашкынулы адымы, ярты гасырда булып үткән үзгәрешләр шул кадәр гаҗәпләнерлек ки, Совет властеның өченче яки дүртенче унъеллыгында туып үскән яшьләр лекторның сүзләренә шикләнеп карыйлар: «Бу нинди окраина булсын! Бездә югары уку йортлары, театрлар бар, ун елдан артык инде үз телевидение үзәгебезнең тапшыруларын карыйбыз»,— диләр алар.

...Удмуртия чал Уралның итәгенә җәелеп урнашкан, урманнарның һәм болыннарның чуар келәмен Каманың елга башыннан алып уртасына кадәр җәйгән. Бүген Удмуртия, беркайчан да булмаганча, яшь һәм көчле, шатлыклы. Ул Хезмәт һәм Тормыш гимнын җырлый. Бу гимн электровозлар һәм заводлар гудогында ишетелә. Бу гимн Каманың ярларында, кеше кулы белән Воткинск шәһәре янында төзелгән яңа диңгез өстендә яңгырый.

Халыкның культура дәрәҗәсен билгеләү өчен төрле «билгеләр» бар. Мәсәлән, кеше башына тотылган сабын яки кәгазь күләме. Менә иң реаль билге: революциягә кадәр Сарапул шәһәрендә барлыгы... дүрт врач булган. Хәзер монда йөзләрчә медицина работниклары эшли, берничә дистә дәвалау учреждениесе бар. Шәһәрдә берничә техникум, махсус уку йортлары, драма театры, клублар, кинотеатрлар, стадионнар, китапханәләр, музей эшли. Хәзерге чордагы удмурт шәһәренең культура билгесе менә шулар!

Удмурт краеның иң гади бер авылын — Алнашины алып карыйк. Авыл зур, борынгы, ләкин башкалардан аерылмый. Иң гадәти авыл, күп урамлы һәм тыкрыклы район үзәге. Монда урта мәктәп, бик яхшы Культура йорты, балалар бакчалары, ясләләр, көнкүреш хезмәте күрсәтү комбинаты, хәзерге авылларга хас башка нәрсәләр бар. Моннан Мәскәүгә мең километрдан артык дип уйларлык та түгел: кешеләр Лужникидагы спорт сараеннан бирелә торган тапшыруларны карыйлар, һәр җирдәге кебек, футбол сөючеләр «Динамо» яки «Спартак» командалары өчен «авырыйлар».

Бу авылда руслар һәм удмуртлар, татарлар һәм марилар, украиннар һәм белоруслар бер туган кебек яшиләр. Удмуртның татар телен белүе, ә мариның удмуртча сөйләшүе беркемне дә гаҗәпләндерми. Әңгәмәдәшеңнең телен белмәсәң зарар юк: рус теле ярдәмгә килә, ә аны монда һәркем белә.

Район үзәге болай зур түгел, анда кырык меңләп кеше яши. Ләкин аның мисалында совет кешесенең үсуен бик ачык күрергә мөмкин. Җирле халык читтән килгәннәргә: «Районда бөтен союзга танылган Варзи-Ятчи курорты бар, районда миллионер колхоз-

лар бар, геология разведчиклары Алнаши җирендә ташкүмернең бик куәтле ятмаларын таптылар, бу урыннардан Пугачев отряды үткән, бөек рус художнигы И. Шишкин шушы урыннар тирәсендә үзенең атаклы «Арыш эчендәге агачлар» дигән картинасын язган»,— дип, зур горурлану белән сөйлиләр.

Ләкин иң мөһиме кешеләр, билгеле. Алнашилылар үзләренең якташлары — Советлар Союзы Герое, летчик Иван Клевцев, Социалистик Хезмәт Герое Иосиф Семенов, төрле орденнар һәм медальләр йөртүче йөзләрчә кешеләр белән хаклы рәвештә горурланалар. Тагын шунысы да бар: бу районнан республикада һәм башка өлкәләрдә танылган күп удмурт язучылары, артистлары, художниклары чыкканнар. Соңгы биш-алты елда гына да Алнашида туып-үскән язучылар республикада, Мәскәүдә һәм башка өлкәләрдә үзләренең егермедән артык китапларын бастырганнар.

Алнаши районында әле хәзер дә беренче удмурт шагыйрәсе Векшина Лина Григорьевна (Ашальчи Оки) яши. Күз врачы Векшина вакытында кешеләрне трахомадан дәвалаган, аларга сукыраерга ирек бирмәгән, ә шагыйрә Векшина үзенең тәэсирле шигырьләре белән кешеләрнең яңа дөньяга күзләрен ачкан. Аның көйгә салынган шигырьләрен профессиональ һәм үзешчән коллективлар бик теләп башкаралар.

Иҗатлары соңрак, утызынчы, дәһшәтле кырыгынчы, эшчән илленче елларда һәм безнең көннәрдә үскән һәм ныгыган шагыйрьләр һәм прозаиклар үзләренең көчләрен юкка сарыф итмәгәннәр: аларның китапларын укучылар зур игътибар һәм мәхәббәт белән кабул иттеләр. Октябрьның иң ачык билгеләренең берсе монда да чагылды: үзенең әлифбасы да булмаган, моңарчы гасырлар буе дәшми килгән халык бөтен тавышына сөйли башлады.

Совет властеның илле елында удмурт халкы культурасы искиткеч үсте, чәчәк атты! Тоташ наданлыктан сигезьеллык гомуми белемгә, әлифбасызлыктан хәзерге чорның милли матур әдәбияты белән тулган китапханәләргә, һәр яклап культурасызлыктан пьесаларга, опералрга, балетларга иреште. Иҗади интеллигенция: язучылар, композиторлар, художниклар, артистлар — халыкның чын вәкилләре — рус һәм совет культурасының иң яхшы үрнәкләрендә тәрбияләнделәр. Алар социалистик реализм традицияләрен үстерәләр, шул ук вакытта, үз халыкларының рухи ихтыяҗларына якынрак булырга омтылып, иҗатларында милли формаларны саклыйлар. Минә ни өчен удмурт язучылары Кедр Митрей, Михаил Коновалов, Григорий Медведев, Михаил Петров, Трофим Архипов, Михаил Лямин, Степан Широбоков әсәрләре, композиторлардан: Герман Корепанов, Геннадий Корепанов-Камский иҗатлары, артистлардан: Григорий Титов, Кузьма Ложкин, Васса Виноградова, Клавдия Гаврилова, Николай Зубков һәм башка бик күпләрнең башкару осталыгы укучыларда, тамашачыларда һәм тыңлаучыларда чын мәхәббәт казандылар һәм казаналар. Халык тормышы, аның омтылышлары һәм зәвыклары белән нык һәм тыгыз бәйләнеш — иҗади хезмәт кешеләренең уңышка ирешү сере менә шунда. Ринат Гамзин тәрҗемәсе

# БҮГЕНГЕ УДМУРТ ӘДӘБИЯТЫ

Удмурт әдәбияты XIX гасыр ахырларында ук барлыкка килсә дә, бары Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң гына ул чын-чынлап киң колач җәя алды. Инде егерменче елларда ук К. Митрейның «Агыр золым» исемле романы дөньяга чыкты. Ул удмурт телендә басылган беренче роман иде. Утызынчы елларның беренче яртысында исә Г. Медведевның авылда колхоз төзелешенә багышланган «Лозин кыры» исемле трилогиясе, М. Коноваловның Ижевскидагы корыч заводы эшчеләре тормышыннан алып язылган «Җойле йөз» һәм удмуртларның Пугачев восстаниесендә катнашуы турындагы «Гаян» исемле романнары,

П. Блиновның ятим балалар язмышы хакындагы «Яшисе килә» романы кебек күренекле проза әсәрләре иҗат итэлде.

Сугыштан соңгы елларда сәләтле прозаикларыбыздан М. Петров аеруча актив эшли башлады. Аның 1952 елда ук язылган «Таң алдыннан» исемле повестенда сугыштан соңгы колхоз авылы өчен аеруча җитди саналган мәсьәләләрдән колхозчыларны материаль кызыксындыру проблемасы күтәрелә. Шушы ук авторның патша самодержавиесе шартларында удмурт халкының кимсетелүе, хур һәм мыскыл ителүе турындагы «Карт Мултан» романы укучылар тарафыннан гаять җылы каршыланды. Роман шулай ук илебез халыклары телләренә дә тәрҗемә ителде.

Партиянең XX съездыннан соң туган иҗат атмосферасы шартларында удмурт әдәбияты моңарчы күрелмәгән темплар белән алга китте. Удмурт язучылары хәзерге көннең актуаль проблемаларын теләбрәк һәм кыюрак күтәрә башладылар. Бу яктан Т. Архиповның «Лудзинка елгасы буенда» исемле дилогиясе аеруча характерлы. Проблематикасының кискенлеге һәм актуальлеге белән дилогия укучыларның зур игътибарын җәлеп итте, һәм ул «Советская Россия» нәшриятында массовый тираж белән рус телендә дә басылып чыкты.

Илленче еллар ахырында бөтенсоюз укучылары арасында Г. Красильников исеме киң танылды. 1956 елда яшь прозаик үзенең «Иске йорт» исемле повестен бастырып чыгарды. Анда ул, тышкы дөньядан качып, биек койма эчендәге өйләренә бикләнеп яшәргә омтылган Кабышевлар гаиләсе мисалында, кешеләр аңындагы хосусый милекчелек калдыкларын фаш итә. Күпме генә тырышсалар да, Кабышевларга үзләре теләгәнчә яшәү насыйп булмый, коллективта чыныгу үткән бердәнбер уллары Олексан аша бу йортка да тормышның саф җилләре үтеп керә. «Иске йорт» әсәрендәге геройларның күбесе белән без Г. Красильниковның «Тол чәчкә» исемле яңа романында кабат очрашабыз. Бу роман 1964 елда, «Олексан Кабышев» исеме белән, «Советская Россия» нәшриятында рус телендә басылып чыкты. Язучының «Синең белән калам» (1960 ел) повесте бүгенге тормышның дулкынландыргыч мәсьәләләренә багышланган. Г. Красильниковның «Ел башы» исемле соңгы романы интеллигенция тормышы турында. Автор бу әсәре белән медицина хезмәткәрләре арасында очраган мещанлык калдыкларын фаш итә.

Яшь прозаик С. Самсоновның 1963 елда басылган «Сине яратам» повестеның төп герое — яшь зоотехник Тоня Платонова. Ул актив герой булуы белән аерылып тора. Тоня намуссыз кешеләр, бюрократлар һәм кузбуяучыларга каршы чыга, хаклык һәм гаделлек өчен көрәшә.

Илленче еллар ахырында удмурт язучылары халкыбызның рухи яңару процессын сурәтләү эшенә керешәләр. И. Гавриловның «Туган якларда» трилогиясе — шушы темага багышланган әсәрләрнең иң күренеклесе. Язучы башлыча удмурт театрының һәм әдәбиятының 1927 елдан башлап 20 ел дәвамында барган формалашу процессын күрсәтә. Удмуртия АССРның атказанган артисткасы А. Колесникованың 1963 елда басылган «Мин бәхетле» исемле автобиографик повесте аеруча яхшы тәэсир калдыра. Кыерсытылган авыл кызының танылган артистка булып җитлегү юлын автор мавыктыргыч һәм кызык итеп сурәтләп биргән. Повестьта берничә генә персонаж булып, аларның һәрберсе тормышчан һәм үзенчәлекле итеп эшләнгән. С. Широбоковның «Җыр юл таба» (1963 ел) исемле повестеның үзәгендә композитор образы тора. Язучы Яша Кукушкинның балалык елларыннан алып зур иҗат уңышына кадәрге үсү юлын сурәтли.

С. Самсонов үзенең «Буталчык эш» исемле повестенда удмурт әдәбияты өчен яңа тема күтәрә. Ул, тормышта чыннан да булган фактларга һәм вакыйгаларга нигезләнеп, милиция хезмәткәрләренең тынгысыз тормышын сурәтли һәм халык иминлеген саклаучыларның истә калырлык образларын тудыра. Шул ук авторның «Кама өстендә яшен» (1968 ел) исемле икенче бер повестенда хезмәт халкының акгвардиячеләргә каршы батыр көрәше күрсәтелә.

М. Лямин, үзенең фронт көндәлекләренә нигезләнеп, Удмуртиядә төзелгән һәм авыр юл үткән 357 нче укчы дивизиянең сугышчылары һәм командирлары турында «Дүрт ел буе шинельдән» исемле повесть язды. Т. Архиповның промышленность эшчеләре тормышыннан алып язылган «Кешенең матурлыгы» романы 1963 елда аерым китап булып басылып чыкты. Автор Воткин ГЭСын төзүчеләрнең тормышын

һәм героик хезмәтен сурәтли. Төп образ Владимир Романов һәм башка персонажлар язмышы аша автор совет кешесенең формалашуына һәм рухи яктан үсүенә коллективның уңай йогынты ясавын күрсәтә, әсәрдә кешенең матурлыгы һәм бәхете иҗтимагый файдалы хезмәт һәм иптәшләрчә ярдәм күрсәтә белүе белән билгеләнә, дигән фикер үткәрелә.

Прозаның повесть һәм роман кебек күләмле жанрлары белән берrәттән, соңгы биш елда замандашларыбыз турында бик күп кызыклы хикәяләр һәм очерклар басылып чыкты. Аларның иң яхшыларын танылган прозаиклардан Г. Красильников, С. Самсонов, Т. Архипов, М. Лямин, Е. Самсонов һәм башкалар иҗат итте. Гомумән, хәзерге вакытта удмурт әдәбиятында проза төп урынны алып тора. СССР һәм чит ил халыклары телләренә тәрҗемә итү нәтиҗәсендә, иң яхшы әсәрләр республикабыздан тыш та киң танылдылар.

Соңгы елларда удмурт поэзиясендә дә җанлану сизелә. Шигърият кешегә игътибарлы булуы һәм тормышка актив үтеп керергә омтылуы белән аерылып тора. Халык иҗаты традицияләренә таянып, шагыйрьләр мәхәббәт һәм дуслык, халкыбызның мәдәнияты чәчәк атуы турында чын күңелдән язылган лирик әсәрләр тудырдылар. Поэзиядә Ватан-ана темасы аеруча зур урын алды.

С. Широбоков шигырьләренә тирән хис һәм җылылык хас. Ул фольклор алымнарны оста файдалана белә. Халкыбызның культурасы чәчәк ату турында дулкынландырырлык итеп сөйләгән «Күптәнге хыяллар» поэмасы — шагыйрьнең зур казанышы. Н. Байтирәков үзенең «Эштерек», «Югалган җыр» поэмаларында, шапрынуларсыз һәм ялган патетикага бирелмичә генә кеше хисенең тирәнлеген һәм матурлыгын сурәтли. А. Лужанин гражданлык лирикасына күбрәк мөрәҗәгать итә, безнең җәмгыятьтә очрый торган кайбер ямьсез күренешләрне камчылый торган кызыклы мәсәлләр, сатирик шигырьләр дә яза.

Соңгы елларда шигъри яшьләр тавышы көчлерәк ишетелә башлады. А. Белоноговның шигырь җыентыкларында мәхәббәт һәм дуслык, туган табигать турындагы шигырьләр образлы эшләнгән. Мәктәп һәм институт турындагы шигырьләрендә Н. Васильевның поэзияне үзенчәлекле аңлавы күренә. Д. Яшин җыентыкларында студентлар тормышының күңелле картиналары, үзенә җәлеп итә торган кечкенә күләмле шигырьләре кызыксыну тудыра. Үзенчәлекле шигырьләр аша П. Поздеевның халык иҗаты поэтикасына зур игътибар бирүе сизелә. Ф. Васильев шигырьләре укучылар арасында киң танылды. Удмуртия комсомолы премиясе белән билгеләп үтелгән «Синең хакта» исемле соңгы җыентыгы бигрәк тә җылы каршыланды. Монда гражданлык пафосы белән сугарылган шигырьләр мәхәббәт һәм дуслык турындагы әсәрләр белән оста аралашып килә. Шагыйрәләрдән С. Иванова һәм А. Аникина хатын-кызларның эчке дөньясын оста һәм тәэсирле итеп бирә беләләр. А. Уваров, В. Губякин, Г. Архиповның беренче җыентыкларында кызыклы һәм үзенчәлекле шигырьләр очратырга мөмкин.

30 һәм 40 нчы еллардан үзгә буларак, соңгы елларда драматургия дә хәзерге заман тематикасына күбрәк мөрәҗәгать итә, геройларның эчке дөньясын, кичерешләрен, теләкләрен, омтылышларын һәм уйларын тирәнтен ачып бирә. Т. Архиповның «Лудзинка елгасы буенда» дилогиясе буенча язылган «Иртәнге чык» драмасында бу нәрсә аеруча нык сизелә. Г. Красильниковның «Иске йорт» повесте буенча эшләнгән пьесага да андый сыйфатлар хас.

Соңгы елларда иҗат ителгән сәхнә әсәрләреннән С. Широбоковның авыл яшьләре турындагы «Мәхәббәт булмаса» комедиясендә, Е. Загребинның «Язгы яңгыр» драмасында бүгенге көннең кискен конфликтлары алынган. И. Гавриловның «Яңгыравык көз» һәм «Сандугачлар сайраганда» комедияләрендә, А. Перевощиковның «Моны онытмагыз» һәм А. Бутолинның «Яктылыктан яшеренеп булмый» драмаларында кызыклы проблемалар күтәрелгән һәм совет кешеләренең тормышчан образлары сурәтләнгән.

Шулай итеп, удмурт әдәбияты кыска гына вакытта хәзерге чор романнарына, повестьларына, поэмаларына һәм тулы метражлы пьесаларына сикереш ясады, бөтенсоюз һәм чит ил укучылары казанышына әверелде.

Ф. ЕРМАКОВ,
филология фәннәре кандидаты

## Аркадий Клабуков-Багай

# Ленин янына бару

*Баллада*

Башта бүрек, өстә иске чикмән,
Чамасыз күп әйтер сүзләре.
Ә узарга Ленин бусагасын
Тартыналар ләкин үзләре.

Ишек ачып каршы ала Ильич:
— Рәхим итеп, әйдә керегез.
Сез халыктан нинди йомыш белән?
Хәлләр ничек? — сөйләп бирегез!

Бүлмәсенә аның керү белән
Крестьяннар иркен тын алды:
Аяклары туры басмый иде,
Күз аллары иде томанлы.

Сакаллысы алдан кергән иде,
Башта Ильич шуңа кул сузды.
— Исәнмесез! Исемегез ничек?
— Лавыр диләр... Илле ел узды...

— Ә атагыз исеме белән әйтсәк?
— Андый хөрмәт безгә тимәде...
Бу гомердә миңа һичбер кем дә
Лавыр Иванович димәде.

— Анысы аның элек шулай булган ,
Ә хәзер бит власть үзгәрде.
Янартыла иске тормыш хәзер,
Янартабыз иске сүзләрне.

Сез Лаврентий Иванович, димәк...—
Кунакларны йомшак урынга
Утырта да Ленин сорый башлый
Авылдагы хәлләр турында.

Яңа власть ничек ныгый? Ничек
Эшкә аша яңа законнар?
Игәкләргә алар нәрсә әйтә,
Күңелләргә ничек якыннар?

Крестьяннар ничек яши хәзер?
Ничек үтә авыл көннәре?..
Кунакларның йөрәкләре эри,
Кунакларның ачыла телләре.

Үз белгәнен берсе башлап китә,
Берсе әзер элеп алмага.
Әйтик, диләр, бездә шундыйлар бар:
Ышанмаска куша аллага.

Кинәт Лавыр тамак кырып куйды
Һәм башлады нидер ымлап ул:

— Иптәш Ленин, власть безнеке дә,
Ләкин власть безне тыңламый.

— Ничек алай?
— Менә без күмәкләп
Кирпеч суккан идек авылда.
— Әйе, кирпеч.
— Шуңа күп көч куйдык,
Барчабызга төште авырга.

Иске иде агач чиркәвебез,
Кирәк дидек таштан салырга.
Власть белән комбед шул кирпечне
Карар кылды тартып алырга.

— Чиркәүгә дип, димәк, тырышкансыз...
Ә авылда мәктәп бармы соң?
Булса нинди — зурмы, яңамы ул?
Кем кайгырта аның кайгысын?

— Мәктәбебез, дөрес, яңа түгел,
Кыйшайган да инде бер очы...
Иптәш Ленин, бездә анысына да
Күп түгел бит әле йөрүче.

— Ә мәктәпсез, иптәшкәем, ничек
Үстерерсез совет илен сез?
Яңа тормыш төзүчеләр бит сез,
Төзеп булмый аны белемсез.

Уйлыйк әле: сезнең ул кирпечтән
Бик була бит мәктәп салып та.
Килешсәгез, хәзер әмер бирәм
Кайтарырга аны халыкка.

Юк, көтмәде Лавыр, һич көтмәде,
Сүзне Ильич шулай борасын.
Һәм уйлады тагы: каршы төшсәң,
Кайткач ничек җавап бирәсең?

Карый Лавыр ике иптәшенә
Һәм Ленинга карый: «Я, нишлик?»
— Дөрес әйтә,— диде иптәшләре,—
Ильич белән, әйдә, килешик.

Кичергәнне Лавыр күңеленең
Бәреп чыкты хәтта йөзгә дә:
— Мин аңладым, иптәш Ленин, тормыш
Асты-өскә килеп үзгәрә.

Өсти тагын Лавыр кулын селкеп:
— Зур акылны синнән алабыз.
Без кайткач ук халык кирпеченнән
Зур иттереп мәктәп салабыз!

Кремльдән чыкты крестьяннар
Таныш баскыч, таныш юл белән.
Дөрес якка бордың алар уен
Ильич шулай тугры кул белән.

**Зәки НУРИ тәрҗемәсе**

## Семен Самсонов

# ТУГАН КӨНЕМНЕ МИН БЕЛМИМ

ПОВЕСТЬТАН ӨЗЕК

I



Сергей белән Оксинья клубка килгәндә, халык җыелган иде инде. Оркестр уйный, киенгән-ясанган парлар вальста әйләнә, төрле җирдән сөйләшү һәм күңелле көлүләр ишетелә.

Сергей, ягымлы гына елмаеп, танышлары белән исәнләшә. Клубка, яңа ел кичәсенә заводныкылардан тыш, «Семилетка» колхозыннан да килгәннәр. Бу колхозга завод шефлык итә, ә Сергей анда өч ел буе башта МТС инженеры, аннан соң РТС директоры булып эшләгән иде. Узган ел аңа яңадан заводка кайтып, цех начальнигы булып эшләргә куштылар. Сергей шәһәргә шатланып кайтты. Завод өчен шулай яхшырак иде. Ә бәлки шатлануы аның өчен генә дә түгелдер, Оксинья аркасындадыр...

Колхозда эшләгәндә Сергей бер үзе яшәде. Хатыны авылга килмәде. Ул кайтып Оксиньяга үзенең Мужвайга җибәрелүен әйткәч тә, тегесе ничектер күңелсезләнеп, борчылып калды. Сергей хатынының янына утырып, иркәләп кенә кулыннан алды да, елмаеп сорады:

— Нигә борыныңны салындырдың? Авылдан курыктыңмы әллә?

Оксинья дәшмәде.

— Барыйк, Оксинья. Соңыннан үзең дә шатланырсың. Уйлап кына кара, табигать нинди анда?

— Табигать матур,— дип җавап бирде тавышы кысылган Оксинья.— Ләкин Мужвайга... мин... бармыйм...

Бу көтелмәгән хәлдән Сергей ни әйтергә дә белмәде. Бераз вакыт ул дәшми утырды. Аннары торды һәм бүлмәдә әрле-бирле йөргән хәлдә җитди итеп әйтте:

— Хикмәт табигатьтә генә түгел, Оксинья. Мужвайга мине эш өчен җибәрәләр. Партия җибәрә. Икеләнеп торырга урын юк. Без Мужвайга китәргә һәм шунда эшләргә тиешбез.

— Ләкин Мужвайга түгел,— дип ирен бүлдерде Оксинья.— Теләсәң кая барыйк, ләкин Мужвайга гына түгел. Ялгыз калсам да, анда бармам... Юк, бармам!

Колхоз, Мужвай турында Сергей бер генә тапкыр сүз башламады. Ләкин Оксинья үзенекендә торды — бармыйм булгач бармыйм!

«Нигә дип әле ул Мужвайга барырга теләми?» — дип уйлады Сергей. Сорасаң — дәшми, күләгә шикелле тып-тын гына йөри, күрсәң, ни турындадыр уйлана. Ни турында — аңламассың. Йөрәк — сандык түгел, ачып карап булмый. Шул берничә көн эчендә Оксинья бик үзгәрде, ябыкты, агарынып калды.

Сергей Мужвайга бер үзе китте. Вакытлар үтәр һәм хатыны бервакыт авылга күченеп килер дип, күңеле белән ышана иде әле ул. Ләкин Оксинья өч ел буена Мужвайга бер генә тапкыр да килеп карамады, ул гынамы, бүген клубта Мужвайлыларның булачагын ишеткәч кенә дә, яңа ел кичәсенә барудан баш тартты.

— Яңа елны өйдә каршыларбыз,— диде ул иренә.

Сергейга клубка бармый калырга ярамый иде. Колхозчыларны бәйрәмгә чакыртучы да ул үзе булды бит.

Менә Оксиньясын култыклап, ул фойедан килә. Әледән-әле аның белән баш иеп исәнләшәләр, я кулын килеп кысалар. Сергейның зәңгәр күзләре әчке җылылык белән елмаялар. Мөгаен, әнә шул җан җылылыгы да аны кешеләргә якынайтадыр әле.

Фойеның аргы башыннан, елмаеп, Сергейга таба яшь солдат килә. Күргә, Сергей үзе аның каршысына китә һәм солдатны кысып кочаклап ала:

— Мишка!

Бераз гаҗәпкә калып, шунда гына Оксинья басып тора.

— Таныш булыгыз,— ди аңа Сергей.

Яшь солдат хатынга кулын суза:

— Смирнов Михаил.

Оксинья кинәт уңайсызланып кала һәм, Сергей белән Михаил һич нигә игътибар бирмичә үзара сөйләшеп торган арада, инде онытылып барган нииндидер бер нәрсәне хәтерләргә тырышкандай, солдатны читтән генә күзәтә башлый.

Сөйләшүләрдән Оксинья солдатның элек Сергей белән бергә МТСта эшләвен, ә хәзер отпускага кайткан булуын аңлады.

Звонок шалтырады. Халык тамаша залына керде. Яшь солдат та, гафу үтенеп, китеп барды.

Завод эшчеләренең үзләре шефлык итә торган колхоз вәкилләре белән очрашуына багышланган кичәнең тантаналы өлеше озак бармады.

Яңа елны кайсының нинди уңышлар белән каршы алуы турында сөйләделәр, бер-берсен тәбрик иттеләр. «Семилетка» колхозы председателе ярдәмнәре өчен шефларга рәхмәт әйтте. Завод директорының кулын кысып, ул:

— Яңа елда кысышкан бу куллар, эшче һәм игенче куллары, дуслыгыбызның тагын да ныграк булуын белдерсен,— дип әйтте.

Аның сүзләрен алкышлар белән күмделәр.

Соңыннан концерт башланды.

Башта эшчеләр чыгыш ясады. Аннан соң сәхнәдә Михаил Смирнов күренде. Ул елмаеп куйды һәм әле берни дә эшләмәсә дә, аңар кул чаптылар. Егет тагын елмайды һәм:

— «Семилетка» колхозының үзешчәннәр концертын башлыйбыз,— дип куйды.

«Мишка, Миша — менә ул нинди булган, танырлык та түгел»,— дип уйлады Сергей, яшь солдатка карап.

Сергей аның белән беренче очрашкан вакытын хәтерләде. Мужвай МТСына килгәч, беренче эше итеп, ул мастерскойга керде. Зур, шыксыз сарайда әче җил уйный иде. Мастерской буп-буш, бары тик почмактан бүлеп алынган бер кечкенә бүлмәдә сөйләшкән һәм көлгән тавышлар ишетелә.

Сергей тынчу бүлмәнең ишеген барып ачты. Ут күк кызган тимер мич тирәсенә бер төркем кеше җыелган. Кайсылары тәмәке тарта, кайберләре тик кенә утыра, ә почмактагы сәкедә, шау-гөр килеп, карта сугалар:

— Дама тәресе — туз! Валет — сигез козырь!

Сергей ишек янында туктап калды.

— Эшлисезме? — диде ул, ачуын көчкә тыеп.

Ертыкларыннан керләнгән мамыклар салынып торган телогрейкалы бер яшь егет урыныннан сикереп торды. Карталы кулы белән честь биргән булып:

— Нәкъ шулай, иптәш начальник,— диде.— Һәркемнең үз эше. Сезнең эшегез тикшереп йөрү — безнеке — менә туз кую!

Егет шап итеп картасын ташлады да, артына әйләнеп, сызгыра башлады. Барысы да кычкырып көлеп җибәрде.

Сергей хуҗалык белән танышып, ике сәгатьләп йөрде, һәр җирдә ул бер үк хәлне күрде: кешеләр теләмичә генә, дәртсез эшлиләр.

МТСның ни өчен арттагылардан саналуын, кыш уртасы җитеп килсә дә, әле һаман тракторларның яртысы гына ремонтлану сәбәпләрен аңлады ул. Авыр, шундый авыр булачак аңа биредәге эшне җайга салу! Өстәмә частьлар җитми, күп колхозлардагы машиналар кар астында ята, МТС эшчеләренә ике ай инде эш хакы түләнмәгән.

Беренче көнне үк Сергей шунда, мастерскойда, директор белән ачуланышты.

— Сезнең эшегез — ремонт ясау,— дип төксе генә бүлдерде аны директор,— кеше эшенә тыгылмагыз! Акча тапсагыз, рәхим итегез,— кешеләргә түләгез, мастерскойны ремонтлагыз. Ә минем хәтта өстәмә частьлар алырга да акчам юк. Сез шуны аңлыйсызмы, юкмы?

Ремонтка акча югын юк та, түзеп булмаслык салкын мастерскойда эшләве дә мөмкин түгел.

Сергей эшчеләр белән сөйләшеп карады. Яшьләр үз көчләре белән кайбер нәрсәләрне эшләп тә куйдылар. Эштән соң тишекләрне томаладылар, тәрәзәләргә эчке рамнар куйдылар. Ертык телогрейкалы егет бу эшләргә бер тапкыр да катнашмады. Иртәләрен дә ул бик еш кына эшкә соңга калып килде, ә бер көнне бөтенләй күренмәде. «Михаил Смирнов дигән эшчегез исереп сугышкан вакытта кулга алынды»,— дип, кич белән милициядән шалтыраттылар. Милициядә аның МТСтан өстәмә детальләр урлап саткан акчага эчүен белгәннәр. Директор, ике дә уйлап тормыйча, судка бирергә, диде. Ләкин Сергейга ни өчендер ул егет кызганыч тоелды, аның үзе белән сөйләшергә дип милициягә китте.

Смирнов шул ук ертык телогрейкасыннан утыра иде. Ул инде үзен нәрсә көткәнне белә булса кирәк, елап, шешенеп беткән.

Алар бик озак утырдылар. Михаил аңа тормышын сөйләп бирде.

Ул әтисен дә, әнисен дә хәтерләми икән. Балалар йортында үскән. ФЗОда механизаторлыкка укыган, Мужвай МТСына эшкә җибәргәннәр. Эшләгәне өчен Михаилга әле бер вакытта да рәтләп акча алырга туры килмәгән, ә киеме, өстендә нәрсә — барысы шул.

Сергейның йөрәге сыкрады.

«Ашыкты директор,— дип уйлады ул.— Егет бит әле тормышка яңа гына аяк баса. Ә янында, ярдәм итеп, акыллы киңәшләр биреп торыр кешесе бармы соң аның. Юк бит андый кеше. Димәк, аның турында коллектив кайгыртырга тиеш».

Михаилны МТС та калдырдылар.

Сергей аның белән ешрак очрашырга тырышты, аның ничек яшәвен, нәрсәләр эшләвен күзәтте. Җәен Михаил трактор йөртә башларга тиеш иде, ләкин директор аңа ышанмады, трактор бирмәде. Шуннан соң Сергей егетне мастерскойга токарь ярдәмчесе итеп алды.

Әкренләп Сергейга Михаил Смирновның холкындагы яңа сыйфатлар ачыла башлады. Ул егетнең уен-көлке, җыр яратуын белеп алды. Михаил һәрвакыт нидер көйләп йөри, көйләрне егет үзе үк чыгара иде бугай әле.

— Безнең Мишка шагыйрь дә, композитор да,— диләр токарьлар инженерга.

Михаил оялчан гына елмая.

— Кая инде ул...— ди.

Көзен, кыр эшләре беткәч, Сергей яшьләрне үзешчән сәнгать түгәрәге оештырырга димләде. Бу түгәрәккә ул үзе житәкчелек итте. Спектакль куйдылар, жырлар, биюләр өйрәнделәр. Бер кичәгә Михаил МТС турында такмаклар чыгарды. Пьесада аңа иң көлкеле рольне бирделәр. Шундый кызык итеп уйнады ул, кешеләр эчләре катканчы көлделәр. Сәхнәдә ул менә дигән артист булып кыланды.

Ике ел үтте, егет бөтен районга атаклы булып китте: тамашачылар өчен ул Мужвай үзешчәннәр ансамбленең бер дигән артисты, район газетасын укучылар өчен — шагыйрь. Сергей хәтта гажәпкә кала иде, алыштырып куйдылармыни егетне.

Армиягә китәр вакыт житкәч, Михаилны тантаналы төстә озаттылар, бүләкләр бирделәр, бик күп яхшы сүзләр, изге теләкләр теләделәр. Ул вакытта инде директор булып эшләгән Сергей аңа аталарча үгет-нәсихәт бирде.

Михаил торып рәхмәт әйтте, каты итеп Сергейның кулын кысты, аннары кочаклады да, оялып кына үбеп алды һәм тагы да ныграк уңайсызланып, күзләрен читкә борды.

Шуннан бирле Сергейның Михаил Смирнов белән очрашканы булмады. Мужвайдан китәр алдыннан егеттән хат алды, ләкин җавап бирмәде, хат кайдадыр югалды, адресын Сергей хәтерләми иде.

Менә хәзер Сергей Михаилга сокланып карап тора, ул сәхнәгә чыккан саен терсәге белән Оксиньяга төртеп куя, кара, янәсе, «Семилетка»да нинди кешеләр бар. Оксинья үзен инә өстендә утыргандай сизә.

Чираттагы номер беткәннән соң ябык пәрдә алдына бер кыз чыга.

— Солдат ансамбле чыгыш ясый! — ди ул, кычкырып.

Пәрдә ачыла, сәхнәгә бердәнбер солдат килеп чыга — үзе бии, үзе жырлый, үзе гармоньда уйный.

Залда яңгыратып кул чабалар.

— Такмакларны ул үзе чыгара,— ди Сергей, хатынының колагына пышылдап.

— Ул... Ул үзе...— дип җавап бирә Оксинья, буылып.

Концерттан соң ул авырлык белән урыныннан кузгала, Сергей аны сәхнә артына, танышлары янына чакыра, ләкин Оксинья бармый, фойедан чыга да читтәге диваннарның берсенә килеп утыра.

## II

Оксинья Жинья авылында туа. Унжиде яшендә ул беренче тапкыр гашыйк була. Яшь йөрәкнең кайнар ялкыны белән ул авылларының гармоньчысы, менә дигән биючесе һәм жырчысы булган шаян бер егетне сөя. Петр да Оксиньяны ярата кебек була. Ләкин кыз авырга калгач, ничектер аннан читләшә. Ул арада сугыш башлана һәм аны армиягә алалар.

Үги анасы белән авылда яшәгән Оксинья, өйдә бала табарга куркып, читкә чыгып китә. Аның улы туа. Яшь бала күтәреп эштән эшкә күчә-күчә Оксинья бик күп җирләргә барып житә, ләкин тутан авылына әйләнеп кайтмый. Соныннан читтән генә Петрның үлгән хәбәрен ишетә. Яшәве торган саен авырлаша, улын илтә торган ясленә госпитальгә итәләр, баланы калдырыр кеше булмый, ә аның белән эшкә чыгу мөмкин түгел.

«Нәрсә эшләргә? — дип ачынып уйлана Оксинья.— Эх, Петя, Петя, мәсхәрәләдең син мине, тормышымны харап иттең... Кире какмаган булсаң син мине, улымны авылда табып, авылда үстергән булыр идем. Сиңа ошаган бит... Үз токымың... Исән булсаң, үзең дә шатланыр идең әле, йөрәк бит ул таш түгел... Ә хәзер син инде юк. Юк! Ничек үсте-

рермен мин ул баланы, ничек тәрбияләрмен?.. Минем икенче атна инде рәтләп ашаганым юк... Акча бетеп килә, шундый яшь башым белән хәер өстәргә чыкмам бит... Үзем генә булсам бер хәл иде, эшкә керер идем. Ә бала белән... Я, ничек яшәргә, ничек?»

Соңгы көннәрдә ул Сактыз станциясендә утыра иде, актыккы акчасына билет алды да поездга утырып китеп барды. Кая, ни өчен — үзе дә белми.

Станцияләр күренеп кала, тәгәрмәч тавышына йокымсырап барган Оксиньяның күз алдыннан төрле күренешләр уза. Менә ул Ижевскига килеп житкәндәй, тимер юлга эшкә кергәндәй була... Оксинья сискәнеп китә һәм инде уяу көе уйлап куя:

«Нәрсә, әгәр чынлап та Ижевскига китсәм...» Шул вакыт аның карашы улына төшә. «Китәргә? Ә аны кая куярга? Бәгырем минем.— кирәксезем минем... Аны кая куярга? Ташларгамы! Юк! Юк! Бу мөмкин түгел... Ни эшләргә соң?»

Поезд станциягә якынлаша. Уйлардан һәм хәлсезлектән баш әйләнә, ач Оксинья урыныннан кузгала, йоклап яткан улына карап ала да, каршыда утырган егет белән кыздан үтенә:

— Читен булмаса, зинһар, карап торыгыз әле. Уянса — кулга алыгыз. Бер генә минутка чыгып керәм.

Кыз ризалашып баш ия: карарбыз, янәсе.

Оксинья вагоннан төшә. Дөм караңгы төн була ул. Куе болытлар йолдызларны каплаганнар. Буш перронда ялгыз дежурный гына фонарен болгап тора. Поезддан берәү дә төшмәде дә, берәү дә утырмады.

Состав озак тормады. Паровоз сузып кычкыртты һәм, авыр сулап, урыныннан кузгалды. Оксинья катып калды. Поезд кызулыгын арттыра иде: пых, пых, пых! Ул поезд артыннан ташланды. Туктап калды... Вагоннар кызурак йөгерә башладылар, якты тәрәзәләр күз алдыннан узып торды. Рельсларны шакылдатып соңгы вагон да китте. Һәм тирәяк баздагы шикелле кап-караңгы булып калды.

Ни булганы шунда гына Оксиньяның башына барып житте. Җан ачысы белән кычкырып, ул поезд артыннан ташланды. Елый-елый, тыны бетеп, алга йөгерде, ә сонгы вагонның кызыл уты ераклашты да ераклашты. Аякларының хәле бетте һәм ул йөзе белән салкын кар өстенә килеп капланды.

Бу хәл яңа елга кергән кичне Мужвай станциясендә була.

Оксинья тимер юлда эшли башлый. Ул фронттан килгән хәрби эшелоннарга, санитар поездларына каршы йөгереп чыга, сугышның беренче көненнән үк хәбәрсез югалган атасын очратмаммы дип өметләнә.

Бер вакыт станциягә санитар поезды килеп туктый. Оксинья ак җәймә капланган носилкаларны бер вагоннан икенчесенә күчерүләрен карап тора. Бер носилканы күтәргәндә җәймәсе шуып төшә. Оксиньяның күз аллары караңгыланып китә: атасы! Ул носилкаларны алып кергән вагонга ташлана, ләкин аны якын да җибәрмиләр... Поезд кузгалып китә.

Шуннан соң Оксиньяның Мужвайда да яшәрлеге калмый. Җиргә шуып төшкән җәймә һәм иң кадерле кешесенең агарынган йөзе көнетөне аның күз алдыннан китми...

Шуннан соң күп сулар ага, Оксиньяның тормышында караңгы көз шикелле көннәр дә, язгы таң шикелле якты, күңелле вакытлар да була.

Еллар буе ул я совхозларда, я тимер юлда эшли. Туган авылына ул сугыш беткәч кенә кайта. Атасы сугышта үлгән, үги анасы өч бала белән тол калган була. Үги кызын ул төксе каршылый, иртәдән кичкә кадәр сукранып йөри, тиргәшә, баланңы кайда ташладың дип, күңел ярасын кузгата. Инде йомыла башлаган яра тагын сызлый. Димәк, авылга нинди дер хәбәр килеп житкән. Ә Оксиньяга туган җирдә болай да авыр. Бар нәрсә дә — урам да, юл буйлары да, бакча артындагы

чишмә дә, амбар алдындагы каен агачы да — барысы да үткәндәге шат көннәрен искә төшерә, барысы да дәшми генә аны шелтәлиләр төсле.

Ә кешеләр аңар нинди караш ташлыйлар!.. Әйтерсең лә алар да, ә балаң соң кайда? дип сорыйлар.

Һәм Оксинья авылдан качып китә. Туган якларына янадан бер вакытта да әйләнеп кайтмас өчен авылдашларының күзеннән югала.

Ижевскида ул слесарьлыкка укый, аннары механика институтына лаборантка булып урнаша. Шуннан соң инде тормышы җиңеләя башлый. Нәкъ шунда ул кичке бүлектә укучы Сергейны очрата.

Эштән соң Сергей озаклап-озаклап лабораториядә, китапханәдә утыра, шуның аркасында Оксинья еш кына эштә тоткарлана торган була. Кичләрен алар институттан бергә чыгалар, тора-бара киногa, театрга йөри башлыйлар.

Сергей буйдак егет була. Аның яраткан кызы әле сугышка хәтле үк медицина институтында укыган, санитарка булып сугышка киткән һәм әйләнеп кайтмаган. Шулай итеп егет өйләнми йөргән.

— Хатын эзләргә вакыт юк,— дип шаярган Сергей,— көндез эштә — кич укуда.

Оксинья да фронтта һәлак булган таныш егете турында сөйли. Бары шуны гына — калганы турында ләм-мим.

Еллар үтүгә барысы да, ничектер, онытылган сыман булса да, җанны тетрәндереп, хәзер искә төшә.

— Петяга бик охшаган,— дип уйлый Оксинья, Михаилга карап.— Күзләре дә, борыны да шуныкы. Өске ирене өстендәге чокырларына кадәр охшаган. Карлыгач канатыдай кашлары...

Фойе. Уртасында яңа ел чыршысы җемелдәп утыра. Алсу йөзле кыш бабай чыга, шау-шу, көлүләр башлана. Төне буе җыр, бию китә. Ә төн уртасы җитәрәк барысы да бәйрәм табыннарына утырырлар һәм шәрап тулы бокаллар күтәрерләр...

## III

Оксинья үзе утырган диван янына Сергей белән Михаилның килүен сизми кала. Иренең тавышын ишеткәч, ул кинәт сискәнеп китә.

— Менә, безнең солдат ансамбле шушы инде!

Михаил шатлыктан һәм бәйрәм тантанасыннан җемелдәгән зәп-зәңгәр күзләрен Оксиньяга төби. Оксинья, ирексездән, карашын читкә ала, бер агарып, бер кызарып китә.

— Сергей, минем башым сызлый... Әйдә, өйгә кайтыйк,— дип әйтә ул әкрен генә.

Сергей борчылып хатынына иелә.

Михаилның бер вакытта да аларның икесен бергә күргәне булмый. Хәзер ул авыр вакытта үзенә кул биргән кешенең хатынын кызыксыну белән күзәтә башлый.

«Авырудыр, ахры. Шуның өчен ире белән МТСка килмәгәндер»,— дип уйлый Михаил. Шулай да бизәнгән, яшь чырайлы бу матур хатынга, куе, йомшак чәчле башын горур гына артка ташлаган Оксиньяга карата күңеленең бер читендә туа башлаган өнәмәү хисен баса алмый. Ул якасы уелып торган яшел күлмәк кигән, матур ак муеныннан күкрәгенә сары һәм кызыл төймәле муенса төшкән.

Михаилга бу хатын бик көяз булып күренде.

Өйгә кайтышлый Сергей егетне үзенә чакырды.

— Әйдә безгә. Яңа елны каршыларбыз, очрашу хөрмәтенә күтәреп алырбыз.

Михаил риза булды.

Сергейлар клуб янындарак торалар икән. Автобус белән азрак баргач та төштеләр.

Бүлмәгә кергәч, егет як-ягына каранып алды. Сергейның фатиры зур гына, матур гына икән. Ялтыравыклы яхшы мебель белән җиһазландырылган.

Оксинья белән Сергей табын әзерләгән арада Михаил фоторәсемнәр альбомын актарып утырды. Ниһаять, Сергей, сәгатькә карап алды да, бүлмәдәгеләрне ашыктыра башлады:

— Утырырга вакыт!

Бокалларга шәрапләр салдылар. Оксинья чиланып, дәшми генә утыра бирде.

— Тың, тың, тың! — дип стена сәгате уникє тапкыр сукты.

— Яңа ел белән! Яңа бәхет белән! — диде Сергей, бокалын күтәреп. Чәкәштеләр һәм эчеп җибәрделәр.

Тагын бер тапкыр күтәрделәр. Кан тамырларына рәхәт җылы йөгерде, Михаил уңайсызланмый башлады. Өченче бокалны башлап үзе күтәрде дә, Сергейга карап:

— Әйдә сезнең өчен эчик әле, Сергей Тимофеевич,— диде ул.— Сез минем әтием бит. Шулай дип әйтүем өчен ачуланмагыз. Атам урынына калган кеше. Сезнең саулыкка, Сергей Тимофеевич.

— Рәхмәт, Миша,— диде Сергей.

Оксинья, эскәтергә шәрап чайпалдыртып, калтыранган кулларыннан бокалын куйды, өстәл янынан торды да радиоланы борып җибәрде.

Михаилның теле чишелде. Бүген ул Сергейга барысы турында да, армиядәге хезмәте хакында да, үзенең уйлары, хыяллары, үткәне һәм киләчәге турында да сөйләргә тели иде.

— Беләсезме, Сергей Тимофеевич, мин бит үземнең туган көнемне Яңа ел көнендә үткәрәм.

— Тәбрик итәм. Моның өчен дә күтәрергә кирәк,— дип Сергей тагын бокалларын тутыра башлады.

— Юк, мин эчәр өчен әйтмим,— дип туктатты аны Михаил.— Мин үземнең туган көнемне белмим. Әнием мине, имчәк баласы вакытымда, тимер юл вагонында калдырып киткән. Мужвай станциясендә.

Оксиньяның кулыннан пластинкасы төшеп китә. Идәнгә вак-вак кисәкләр чәчелә.

— Ой! — дип кычкыра ул, куркынып.

— Зыян юк, бәхеткә ватыла дип әйтәләр аны,— дип Сергей хатынын тынычландыра да, яңадан Михаилга борыла.

— Миңа моны бер тәрбияче хатын сөйләде. Ә фамилиямне мине балалар йортына китергән кешенекен биргәннәр. Ә исемемне, атамның исемен, нидән биргәннәр—белмим. Нәкъ Яңа ел кичендә була бу хәл... Әнием ташлаганда...

— Нинди ана булсын ул! — дип ачу белән кычкыра Сергей.— Үз баласын ташлаган! Ана кеше шулай эшли аламы?

— Мин бу турыда бик күп уйладым, Сергей Тимофеевич. Шуның өчен дә Мужвайга эшкә җибәрүләрен сорадым...

Шул вакыт Оксинья, ыңгырашып, хәлсез куллары белән стенага ябыша-ябыша, идәнгә чүкте.

— Оксинья, ни булды сиңа? — диде Сергей, каушап.

Михаил белән алар икесе Оксиньяны күтәреп алып, диванга салдылар. Оксинья агарынган, үзе көчкә-көчкә тын ала.

— Йөрәгең авыртамы? Хәзер дару бирәм,— диде Сергей.

— Юк, юк... берни дә кирәкми... Үтәр әле... Сергей, мин сиңа... сиңа,— диде дә Оксинья күзләрен йомды:

— Мин врач чакырам, Сергей Тимофеевич,— дип Михаил ишеккә ташланды.

— Кирәкми. Беркая да бармагыз,— дип туктатты аны Оксинья.— Монда врач ярдәме кирәкми... Мин барысын да сөйләп бирәм... Тыңлагыз... Икегез дә тыңлагыз...

## Даниил Яшин

### Икмәк турында җыр

Ишелеп унган икмәктә
Җир куәте тоела.
Башаклар шаулый кырларда,
Якты нурда коена.

Сайрый тургай зәңгәр күктә,
Туган як таңнарында.
Кырлар дулкыны сугыла
Кама урманнарына.

Кыр өстеннән җилфер-җилфер
Җәйге җилләр агыла,
Башакларның муегына
Канатлары кагыла.

Уып карыйм башакларны —
Өлгереп җиткән микән?
Игенченең изге эше
Күңелгә таныш күптән.

Балкый июль.
Күк болытсыз.
Җирнең көчле җырында
Алтын сүзләр бар шикелле
Бөек икмәк турында.

### Нарат

Җил-давылга иелмичә
Ялгызы тора бирә.
Күккә тигән ябалдашы,
Ә тамырлары — җирдә.

Көрәшләрдә җиңелмәгән,
Уйланып карап торам:
Бирешмичә яшә икән,
Нәкъ шушы нарат сыман.

## Флор Васильев

●

Дөм-караңгы төн уртасы.
Борынгы тынлык монда.
Агачларны йокы алмый
Карурман уртасында.

Кеше тормышка ашырды
Иң кыю хыялларны.
Кеше ачышын күзәтеп
Чыршылар күккә карый.

Көнләшеп алар сөйләшә,
Әкрен генә төн үтә.
Ракета кебек агачлар,
Очышка старт көтә.

●

Урманнарда
Артык агач булмый,
Куакларын тура, кыр аның —
Гади матурлыгын җуеп шунда
Шыксыз булып калыр урманың.

Язмышларны хәтта җиңеп була,
Кайгы белән була көрәшеп.

Бәхет кигә,
Ләкин ялгызларга,
Ялгызларга килми ул бәхет.

Ул кадәр киң, көчле булмас иде,
Кушылмаса Кама Иделгә.
Минем өчен Рәсәй булмас иде,
Нәни Удмуртиям
Яшәмәсә минем күңелдә.

●

Яз килүгә шытып чыга тере үлән.
Кыш килүгә кар астында чери үлән.

Озак еллар буе үскән агач биек —
Ул да ава вакыт җиткәч корып-кибеп.

Йөрәк сыман бәреп торган чишмәләр
бар —
Кем су эчәр, әгәр тынып калса алар?!

Бу җиһанда кеше барысын җиңә ала,
Шуңа кеше мәңге яши, җирдә кала.

## Николай Байтирәков

●

Зифа сынлы ак каеным,
Кайнар яшь тузларыңда.
Шулай үсәргә ашкынып
Яшиләр кызлар гына.

Зарыктыра каенымны
Камышмы, дулкын микән?

Әллә инде таң томаны
Каенга салкын микән?

Зарыкма син, бер көн җилләр
Тияр яфракларыңа,
Каен суы бирерсең син
Өзелеп көткән ярыңа.

●

Юлыңа кызлар юлыкса,
Ничек соң елмаймаска!
Яктыра кызның карашы
Исемсез инеш аша.

Шәп кешеләр белән бергә
Яшәп була лабаса!
Кыз саклый тик бер исемне
Бик озак еллар аша.

Әйлән-бәйлән уйнаганда
Ул да җырлаган иде,
Чишмәдәй көмеш тавышы
Тынмый чыңлаган иде.

Кисмәгез җырның канатын!
Ятларга күренмәде:
Җырласа да, еласа да,
Тетрәнде иреннәре.

Кыз җырындагы шатлыклар
Утларда янды мәллә?
Ташлап китеп барды бәхет,
Ятларга калды мәллә?

Кайда йөрисең син, бәхет?
Бик еракта йөрисең!
...Кышкы бәсләр каплап китте
Агачларның бөресен.

ЗӨЛФӘТ тәрҗемәләре

Гыйлемдар Рамазанов

# ЧЫН ШИГЪРИЯТ ИЛЕНДӘ

Татарстан китап нәшрияты шигърият сөючеләрне тагын да бер тапкыр куандырды: Казанда татар шагыйрьләренең иң яхшы әсәрләрен туплаган китаплар тезмәсе чыга башлады. Поэзиянең халык күңеленә барып җитәрлек үрнәкләрен туплаган бу серия «Шигырь китапханәсе» дип атала. Нәшриятның бу башлангычын ихлас күңелдән котларга, китапханәнең бай, төрле, сыйфатлы булуын теләргә генә кала. Ә моңа кадәр басылып чыккан беренче томнар сериянең әйбәт булачагын, һәрхәлдә, уңай башлангыч икәнлеген күрсәтеп тора. Моны мин хәзерге иң күренекле татар шагыйрьләренең берсе Сибгат Хәкимнең бертомлыгын укып чыкканнан соң ныклы ышаныч белән әйтә алам.

Халыкта «Яхшы сүз — җан азыгы» дигән бик тапкыр һәм матур бер мәкаль бар. Күренекле татар совет шагыйре Сибгат Хәким үзенең күптән түгел генә шушы яңа сериядә басылып чыккан бер томлык шигырь һәм поэмалар китабын тыйнаклык, басынкылык белән «Җылы сүз» дип атаган. Ләкин һич шикләнү һәм икеләнүсез әйтеп була: зур шагыйрьнең җылы сүзе — ул бик ихлас, йөрәктән чыккан сүз. Һәм, әлбәттә, үзенең иң яхшы әсәрләре белән күптән үк халык күңеленә барып җиткән шагыйрь сүзләре дә күптән үк әдәбият сөючеләрнең, совет поэзиясен яратучыларның җан азыгына әйләнде инде. Шуңа да шагыйрь белән, шигърият белән яңадан очрашу — куанычлы, күңелле хәл.

Олы шагыйрь, күренекле җәмәгать эшлеклесе Сибгат Хәким турында сүзне шушы яңа китапка таянып сөйлисе килә. «Җылы сүз» исемле бертомлык — шагыйрьнең соңгы елларда безнең кулыбызга килеп кергән иң тулы җыентыкларының берсе. Гади һәм пөхтә итеп чыгарылган бу том чынлап та шигырь сөючеләргә яхшы бүләк булды.

Сайланма җыентык зур булмаган, тик бик ихлас язылган «Шигырь ничек туа!» исемле мәкалә белән ачыла. Ул мәкаләдә Сибгат Хәким үз поэзиясенең чыганаклары, юнәлеше һәм тенденцияләре турында сөйли. Чынлап та кайда, ничек туа соң ул шигырь! Поэзиягә нинди юл белән барып була! Шундый олы сорауга җавап бирүе җиңел түгел. Шулай да Сибгат Хәким, үз иҗат практикасына таянып, зур шигъриятнең чыганакларын җитәрлек үк тирән ачып бирә, үз иҗатының үзенчәлекләрен шактый тулы күрсәтә. «Тормышны үзең аша кичерми торып,— ди шагыйрь,— юк, бер генә әйбәт шигырь дә тумый, ахрысы». Әйе, бу бәхәссез хакыйкать. Һәм ары табан бик әһәмиятле фикер әйтелгән: «Кешеләрне күбрәк яраткан саен, кимчелекләре өчен ныграк әрнисең; тормышны күбрәк яраткан саен, ныграк көрәшәсең, матурлыгын тулырак расларга тырышасың».

Чыннан да, чын шигырь мәхәббәт һәм нәфрәт җимеше булып туа. Безнең заманда шагыйрь, бөек Тукай әйткәнчә, коеп куйган саф язучы, мәхәббәт, гөлләр һәм сандугачлар җырчысы гына булып кала алмый. Татар халкының зур шагыйре Сибгат Хәким дә әнә шундый саф сәнгать, саф хисләр җырчысы гына түгел, алай гына булганда шагыйрь сүзенең кыйммәте кечерәк, аны ихтирам итүчеләрнең саны азрак булыр иде. Сибгат Хәким чын мәгънәсендә заман җырчысы, ул шагыйрь-патриот, шагыйрь-көрәшче, шагыйрь-коммунист. Бу сүзләрне мин тиктәскә генә язмыйм, аларда — шагыйрьнең бөтен барлыгы, язмышы, асылы.

Әдәбиятны, атап әйткәндә поэзияне, сөюче күпләргә билгеле булган кебек, Сибгат Хәким иҗаты миңа да күптән үк — шагыйрьнең сугышка кадәрге елларындагы беренче әсәрләре һәм китаплары буенча ук таныш. Шул заманнан алып мин шагыйрьнең эзләнү һәм табышларын җентекләп күзәтеп килəм, аның һәр яңа әсәрен, һәр яңа китабын көтеп алам. Шагыйрьнең әлеге сайланма бер томлыгын укыганнан соң берничә көн буе мин чын поэзия, ихлас шигърият тәэсире астында йөрдем. Укучы буларак минем күз алдыма олы бер заман, зур бер тормыш, бер үк вакытта катлаулы да, гади дә булып күренгән кеше язмышы — олы шагыйрь язмышы килеп басты. Бу язмаларда мин шагыйрь иҗатына тулы анализ бирү, аның әсәрләренә теге яки бу билгеләр кую максатын тотмыйм, ә бәлки шигырь яратучы, шуның белән яшәүче каләмдәшнең кайбер тәэсирләре белән генә бүлешмәкче булам.

Чын шагыйрьнең бөтен тормышы, аның уйлану-борчылулары, шатлык һәм хәвефләре — аның әсәрләрендә. Шигырьләре буенча шагыйрьнең кемне яратуын, нәрсәләр кичерүен — бөтен биографиясен белеп була. Сибгат Хәким дә шундый. Шигырьләренең кайберләрендә шагыйрь сирәк-мирәк кенә булса да үзенең яхшы кешеләрдән яхшы мәгънәдә көнләшүе турында язгалый. Баксаң, шагыйрьнең үзеннән дә шул яхшы мәгънәдә көнләшерлек бар икән. Шагыйрьнең иң зур бәхете, минемчә, аның иҗаты бер максатка юнәлтелгән булуда, авторның һәрчак үз иҗади принципларына, үзенең симпатияләренә һәм антипатияләренә турылыклы калуда, һәрвакыт үз-үзе була белүдә, ахрысы. Шагыйрьнең үз юлы, иҗат максаты, симпатияләре турында да берничә сүз белән генә әйтеп биреп булыр иде: алар — бик тирән, чын мәгънәсендәге халыкчанлык, шул халыкчанлыкның иң югары чагылышы буларак — партиялелек, иҗат манерасында армый-талмый халыкның үзеннән өйрәнү, остазлары һәм укытучылары — Тукай, Пушкин, Некрасов булган шигъри рухы ягыннан — беренче карашка бик басынкы, хәтта юаш та күренгән шагыйрьнең бик сугышчан, принципиаль позицияле солдат, партия солдаты булуы. Әлбәттә, югарыда әйтелгәннәр бик гомуми характеристика, алар әле шагыйрьнең үзенчәлеген, индивидуальлеген ачып җиткермиләр. Шулай да, минемчә, нәкъ менә шушы тирәдә Сибгат Хәкимнең шагыйрьлеге дә, аның поэзиясенең төп асылы да ята. Шагыйрьнең иң яраткан нәрсәсе — тормыш:

> Яратам мин үтеп баручының
> Кунар өчен ишек кагуын,
> Яшь киленнең җылы караш белән,
> Якын итеп каршы алуын.
>
> Яратам мин колхоз яшьләренең
> Клубка дип шаулап үтүен...
> Һәм тудыру йорты бүлмәсендә
> Медичканың бала көтүен...
>
> ...Яратам мин авыл кешесенең
> Күңелле итеп әкият сөйләвен...
> Әкият кебек матур Казан арты —
> Балалыгым үткән җирләрем.

Бу юллар Сибгат Хәким әдәбиятта беренче адымнар башлаган чакта — 1938 елда акка кара белән төшкән. Әйтергә кирәк, башта ук шагыйрь үзенең эстетик идеалын — олы матурлыкны, үз поэзиясенең идея-тематик юнәлешен шактый анык билгели. Ары табан ул бөтен иҗат гомере буена менә шул үзе бик нык яраткан нәрсәләрне: җылы

карашларны, шатлыклы һәм моңсу каршы алу һәм озатуларны, колхоз кешеләрен, туган авылын, туган җире Казан артын һәм зур Ватанны җырлады.

Сибгат Хәким поэзиясе мари авыллары арасында утырган Күлле-Киме дигән татар авылы янында гөрләп аккан саф чишмәләр кебек башланды. Азагырак инде бу чишмәләр елгаларга кушылды. Төздән олы шигырь диңгезе дулкынлана башлады. Шагыйрьнең шагыйрьлеген, аның индивидуальлеген идея-тематик юнәлеш һәм поэтик осталык билгели. Сибгат Хәкимнең дә бөтен иҗат гомере буена сузылып барган үз темалары бар. Шуларның берсе һәм иң үзәктәгесе — Ленин темасы. Минемчә, Сибгат Хәким Такташтан соң татар поэзиясендә лениниананы өзлексез төштә язып килүче бердәнбер шагыйрь булса кирәк. Шунысы куанычлы: Ленин шагыйрь өчен тема гына, шигъри образ гына түгел, ә аның бөтен гомеренең, бөтен барлыгының мәгънәсе. «Күңел Ленинга тора-тора кайта».— ди шагыйрь үзе. Чыннан да, безнең кулдагы том 1938 елда язылган «Кышкы салкын иде» исемле бик ихлас, бик табигый шигырь белән ачылып китә.

Кышкы салкын иде. Капкабызга
Кара читле флаг элгәнем
Һич онытылмас, ахры, көн буе мин
Өебезгә кайтып кермәдем.
Зурлар кебек кайгы кичердем мин,
Көлүләр дә кинәт өзелде.
Башкаладан ерак бер авылда
Ятим итеп сиздем үземне.
Башка көнне булса орышыр иде
Кичке чәен аның эчмәсәң,
Ул көн әнкәй безгә каты итеп
Ник бер сүз әйтсен, ичмасам.

Шигырьгә аңлатма биреп, төшендереп торуның кирәге юк: әсәрнең тоныннан, андагы басынкы кайгының зурлыгыннан ук сүзнең Ленин турында, аның үлгән көне хакында баруын бик тиз аңлап була. Әле генә без танышып үткән беренче шигырьдән соң шагыйрь Ленин темасына турыдан-туры атап бик озак шигырь язмый тора. Ләкин, минемчә, аның бик күп әсәрләре шушы зур темага багышланган идеяләр. Һәм, ниһаять, Ленин образы Сибгат аганың соңгы еллардагы поэма һәм шигырьләрендә үзенең бөтен күркәмлегендә балкып китте. «Ленин фәрманы белән», «Язгыезы, җир уллары» поэмалары, «Кокушкино крестьяннарының Ленинга хаты», «Баһавиның моңы» кебек шигырьләр татар һәм гомум совет поэзиясендә лениниананың әйбәт үрнәкләре булдылар.

Бүген дөньяда Ленин турында шигырь язмаган бер генә шагыйрь дә юктыр. Иң әһәмиятлесе шул: бу темага Сибгат Хәким татар шагыйре, татар халкының вәкиле буларак якын килә, бөек даһины татар хезмәтчәннәре белән бәйләнешләрендә, халык күңелендәге тирән эзе аша революцион юлын Казанда башлап җибәргән олы якташ итеп, даһи кеше буларак сурәтләргә омтыла. Шагыйрьнең Ленин темасына язылган әсәрләре барысы да бик табигый итеп, зур эстетик тойгы, гражданлык җаваплылыгы хисе белән язылганнар. Аларның һәрберсенең үз көе, үз моңы, үз нәфислеге бар. Шулар арасында минем үземә романтик пафос, үзенчәлекле шигъри стиле белән «Ленин фәрманы белән» дигән кечкенә поэма аеруча ошый. Бу әсәрдә халык үткән юлның зурлыгы шагыйрьнең якташы — Казан артыннан китеп ерак Төркстанда сугышкан Хисами образында гәүдәләнә. Поэма үзенең ритмикасы, строфикасы белән дә гаҗәеп үзенчәлекле, ул үзе бер романтик җыр, күтәренке гимн кебек яңгырый. Һәм менә шушы азат тормыш өчен көрәшкән гүзәл кешеләрнең батырлыгы шагыйрь йөрәгендә горурлык тойгысы уята һәм бу изге тойгы укучыга да килеп җитә, аны да тыныч калдырмый:

Яшь разведчиклар...
Үстергән җирем
Егетләрнең
Иң асылларын;
Башлап бит алар,

Алар үттеләр
Капкаларыннан
Бу гасырларның.

Поэманың герое, милләте белән «чыкылдап торган татар егете» Хисами менә шушы кырыс көрәштә чыныга да инде:

Яктының менә
Бер кыйпылчыгын
Илтүче булып
Ул да әверелде,
Бу кешеләрне
Дәверме ачты,
Әллә үзләре
Ачты дәверне?

Шул рәвешчә, бәләкәч бу әсәрдә бик зур проблема: кешене, дөньяны үзгәрткән заман, аның йөзе, ягъни Ленин дәвере, Ленинның үлемсезлеге турындагы мәсьәлә куела һәм бу зур проблема Некрасов басыять иткән аз сүз аша күп мәгънә бирү алымы белән бик оста хәл ителә. Хисами кебекләрне ком сахраларына Ленин фәрманы, заман таләбе китерә һәм яңа заман чүлләрдә дә җиңә, тантана итә.

Казан һәм гомумән Татарстан — анда бөек Ленинның, яшь Ульяновның эзләре калган бәхетле якларның берсе. Татар шигъри лениннианасын язганда Сибгат Хәким бу бик отышлы очракка еш кына мөрәҗәгать итә. Әйтик, Казан янындагы Кокушкино авылы крестьяннарының ат сорап Ленинга хат язулары халыкның үз юлбашчысына никадәр ышану хисе хакында сөйли. Кокушкино янындагы Апакай авылының яшь көтүчесе Баһави кайчандыр яшь Ульяновка: «Сары, сары, сап-сары, сары чәчәк саплары...» дигән татар җырын җырлаган. Болар барсы да шагыйрь йөрәге аша үткәрелеп, шигырь һәм поэма юллары булып тезеләләр. һәм шагыйрь Ленин колагында чыңлаган «Марсельеза»лар арасында гади бер татар моңы да булу өчен ихлас горурлана.

Ленин темасы Сибгат Хәкимне бөтен иҗади гомере буе озатып бара. Шагыйрь бу тема белән яши, үсә, канатлана, газаплана, һаман дә нәрсәдер эзләнә. Һәм — бәхетле табыш! — шушы илаһи хисләрнең йомгагы, төп аккорды төсле булып шагыйрь күңелендә гаҗәеп бер җыр туа. Ул җыр халыкның Ленинга бетмәс-төкәнмәс мәхәббәтен үзендә җыйган төсле. Ә ул җыр үзе бик гади, бик табигый сүзләрдән тора һәм шуңа күрә дә йөрәккә ныграк үтеп керә дә инде. Бу җыр үзе хәзер канатлы сүзгә, һәркем кабатлый торган афоризмга әверелде: «Күңелем Ленин белән сөйләшә...»

Казан әле, Казан уянмаган.
Яфрак белән яфрак серләшә.
Йөрим таңда Ленин урамында,
Күңелем Ленин белән сөйләшә.

Моңа кадәр без Сибгат Хәким поэзиясендәге бер генә аспект — Ленин темасы хакында гына сөйләдек. Күрдек ки: шагыйрь бу изге темага үзенең бөтен күңел көчен, барлык зур талантын бирә. Мондый үзәк, магистраль темалар Сибгат Хәким поэзиясендә байтак. Шагыйрь әлегәчә «кайта-кайта» Курск дугасы солдатларының батырлыгын җырлады. Әле аның бу китапка кермичә калган «Дуга», «Васыятьләр» исемле яңа поэмалары да шул ук җырны, шул ук көйләрне яңача, мастерларча дәвам иттерә. Бу тема да бик изге, үтә кадерле. Бөек Ватан сугышында җиңеп кайткан солдатларның зур күпчелегенең юлы шушы утлы дуга аша үткән бит. Шагыйрьнең бик хак әйтелгән сүзләре белән килешми мөмкин түгел:

Ватан сугышы ераклашкан саен
Ачыла бара бөтен зурлыгы.

Бу сүзләр бигрәк тә хәзер — изге сугышка чирек гасыр булган елда зур мәгънә белән яңгырыйлар. Шагыйрь күңелендә, шулай итеп, кичәге белән бүгенге очраша һәм алар ихлас күңелдән әңгәмә алып баралар.

Сибгат Хәким поэзиясендә кызыл җеп булып сызылып барган тагын да бер тема бар. Ул туган җир, туган як, атап әйткәндә, Тукай үскән Казан арты темасы. Картаюны, хыянәтне, онтылуны белми торган мәхәббәт кебек, туган як шагыйрьне һәрчак үзенә тарта. Әйткәндәй, Сибгат Хәким — хыянәтсез, бердәнбер мәхәббәт җырчысы, ул үзенең тәүге саф тойгыларын һичкинди яңа бәйләнешләргә алыштырмый. Туган җиргә дә шагыйрь шушы бердәнбер, үзгәрми торган сөю белән гашыйк. Менә ул сугыштан соң үзен үстергән, егет иткән туган як белән очраша:

Балаңнан, ап-ак сакаллы
Картыңнан оялмадым.
Туфрагың күңлем эретте —
Яшьләрем тыялмадым.
...Якын, бик якын тәгәрәп
Һәм аунап йөргән болын,
Кунычын капшый итекнең
Сукмакка үскән солың.

Туган җир, туган як тойгысы белән Сибгат Хәким иҗатында туган халык, аның иң яхшы традицияләре, мактаулы уллары турындагы тема бик тыгыз бәйләнгән. Шагыйрь аеруча бөек Тукайга иксез-чиксез ихтирам хисе йөртә. Китапка кергән ике поэма — Сибгат Хәкимнең сугышка кадәр язылган иң зур әсәрләре — «Шагыйрьнең балачагы» һәм «Пар ат» шушы олы ихтирамның җанлы шаһитлары. Тукай туып-үскән якtan әдәбиятка килгән шагыйрь үзен бөек остазының варисы дип исәпли һәм, әйтергә кирәк, бу изге миссияне ул яхшы үти. Сибгат Хәкимнең шигырьләре, аның поэтикасы, образлылык һәм тел чаралары аерым алып, иркенләп тикшерүгә лаеклы. Шунысы бәхәссез: ул чын мәгънәсендәге халыкчан гадилеккә, тирән образлылыкка омтыла. Шагыйрьнең байтак шигырьләренең халык җырларына әйләнеп китүе шул хакта сөйли («Фазыл чишмәсе», «Таң атканда», «Җил исми, яфрак селкенми» һ. б.). Күренекле рус шагыйре Михаил Исаковский әсәрләре кебек, Сибгат Хәкимнең дә байтак шигыре үзе үк көйгә килеп, җырга салуны сорап тора. Мәсәлән:

Алмагачның алмаларын
Бергә өзәсем килә,
Бергә янып, бергә көеп,
Бергә түзәсем килә.

Бу — беренче күзгә ташланган мисал. Ә мондыйлар шагыйрьдә биткисәп. Шунысы куанычлы: шагыйрьнең байтак җырын халык инде үзенеке итеп кабул иткән һәм аларның авторы бар икәнен меңләгән җырчылар уйлап та тормый. Шагыйрь өчен, халык җырчысы өчен моннан да зуррак бәхет булу мөмкинмени!

Шагыйрьнең иҗат практикасында тагын бер үзенчәлекле як, минемчә, Сибгат Хәкимнең өстән карауга шигъри булып күренмәгән хәл һәм күренешләрдә дә шигърият таба белүендә булса кирәк. Чынлап та, шигъриятнең биләмәләре чиксез, шигъри булмаган әйберләр юк, тик аларга шагыйрь күзе белән карый белергә генә кирәк. Бер карауга шагыйрь тегермән стенасындагы язуларда халыкның үткән юлын, аның тарихын күрә, икенче очракта суд залында әти-әнисе язмышын көтеп утырган зәңгәр башлык кигән баланы яландагы бер чәчәккә охшата.

Без яшәгән җир йөзенең зур проблемалары, заманның катлаулы мәсьәләләре хакында үтә халыкчан, бик гади итеп сөйләп бирә белү осталыгына Сибгат Хәкимнән байтак шагыйрьләр өйрәнә алырлар иде. Менә «Җирдә сөт котәләр кешеләр» дигән кечкенә генә бер шигырь:

Фронтны айкаган карт шофер,
Утырса машина чокырга,
Сүгенә... Юлларның акчасын
Сугышлар торалар йолкырга.

Чаба ак бүксәле машина,
Хуҗасы бик кырыс холыклы.

Әле бит Германия белән дә
Төзмәгән үзара солыхны.

Болында көтүләр... Кайтамын
Барсына соклана-соклана.
Юлларны сөт баскан, шәһәргә
Туктаусыз сөт ага, сөт ага.

Үтә гадәти күренеш бу: юллардан сөт тояган машиналар уза. Ә укучы шушы деталь, шушы картинадан гаҗәеп зур хәлне — безнең тынгысыз заманның тревогалы тын алуын сизә. Елларның хәвефле булуына карамастан, тормышның тантана итүен шәһәргә авыл юлларыннан сөт елгалары агуы турындагы образ аша шулай гади итеп бирү — үзе үк зур поэтик осталык дигән сүз.

Югарыда әйтелгәнчә, һәрбер чын шагыйрьнең бөтен тормышы, язмышы, бөтен барлыгы — аның шигырьләрендә. Сибгат Хәкимнең шигырьләре буенча да без шагыйрьнең Тукай туган Әтнә якларындагы безгә бик үк таныш булып тоелган Күлле-Киме авылында марилар күршесендә туып-үсүен, Курск дугасында Прохоровка дигән урында партия билеты алуын, мәхәббәттә турылыклы булуын — берәүне генә сөюен, үз иҗаты турында зур таләпчәнлек һәм борчылу белән уйлануын күрәбез. Сүз уңаенда шагыйрь иҗатында халыклар дуслыгы турында, атап әйткәндә, тугандаш мари халкы белән дуслык хакында бик ихлас шигырьләр булуы турында әйтми ярамас.

Шагыйрьнең бәхете бар: аның әсәрләрен кабат-кабат укыйсы килә. Һәр шигырьдә зур тормыш дереслеге, поэтик ачыш, дөньяны шагыйрьчә күрә белү. Әйе, Сибгат Хәким поэзиясендә үз укучыларына чын шигъри сүз, җылы сүз әйтә алды. Ә яхшы сүз, җылы сүз, шагыйрь сүзе — җан азыгы. Укучыга илһам бирерлек рухи азык ул. Иң мөһиме — шагыйрьнең иң җылы тойгылары озакка синең күңелеңдә кала.

Кайчандыр, үзенең иҗади язмышы турында уйланып, Сибгат Хәким зур басынкылык һәм һәрбер фикерләүче, уйланучы кешегә хас булган борчылу һәм моңсулык хисе белән болай язган иде:

Мин туктасам — туктый, арышлардан
Тагын тавышы килә тартарның.
Һәрнәрсәгә үземчә күз салам,
Бер шагыйре мин дә татарның.

Бер тирәдә гел әйләнде гомер,
Бер тирәдә шуңа бар моңым.
Тар-тар ди ул, үртәп искә төшерә
Сукмагымның минем тарлыгын.

Бәлки, тардыр, ләкин тапталмаган...
Березлексез яла кем ягa!
Мин бәхетле: фәкать шул сукмактан
Керсәм генә шигъри дөньяма.

Безнең каләмдәш дустыбыз, татарның гади бер шагыйре генә булмыйча, чын мәгънәсендәге халыкчан һәм партияле шагыйре тыныч була ала: аның юлы бер вакытта да тар булмады, һәр чак аның күңеле Ленин белән, үзенең партияле намусы белән киңәшеп яшәде, шуңа да ул күптән үзенең сукмагыннан зур совет поэзиясенең якты юлына чыкты. Бу юлда аның үз урыны, үз йолдызы бар. Юлдагы дустыбызга яңа табышлар телик. Ышанабыз: һәр чактагыча шулай булыр да.

# ДАВЫЛЛЫ ЕЛЛАРДА ТУГАН ДУСЛЫК

*1918—1919 елларда язучы Шамил Усманов III Интернационал исемендәге легионның комиссары булып хезмәт итә. Составында руслар, татарлар, венгрлар, немецлар, поляклар һәм башкортлар булган күп милләтле ул легион сугышчылары, революция казанышларын яклап, гражданнар сугышы көннәрендә иңгә-иң торып көрәшеп йөриләр. Менә шул давыллы елларда Шамил Усманов легиондагы венгрлар белән дә якыннан дуслашып китә. Ул дуслыкны соңыннан да өзми, сугыш беткәннән соң да хатлар аша алар белән хәбәрләшеп тора.*

*Түбәндә без Шамил Усманов хатларының берсен — венгр Месарошка язганын урнаштырабыз. Бу хат 1930 елның 2 декабрендә «Урак һәм чүкеч» исемле венгр журналында басылып чыккан. Татар телендә беренче тапкыр басыла.*

*РЕДАКЦИЯ.*

«Кадерле Месарош!

Әле шушы көннәрдә генә эсперанто журналларның берсендә, очраклы рәвештә, мин синең фамилияңне күреп алдым. Ничек шатланганымны белсәң иде: күптән югалган абыемны тапкандай булдым.

Без бер-беребездән аерылышканга унике ел вакыт үтте бит инде!.. Синең белән бер күрешеп, кулыңны кысып, аркаңнан кагып, кызыклы һәм матур итеп русча сөйләшүеңне тыңлыйсым килүен белсәң иде. Әмма бу мөмкин нәрсә түгел шул. Безне тимер чыбыклы һәм капиталистларның коралллы сакчылары белән уратылган ил чикләре аерып тора! Ләкин ут һәм үлем эчендә сыналган дуслыкны бернинди тимер чыбык та өзә алмый. Үзеңнең сугышчан иптәшеңнән һәм Советлар Союзындагы дусларыңнан сәлам сиңа!

Син исән икән Месарош! Ә безнең бүтән иптәшләребез: Фекет, Кертес, Ковач һәм башка бик күпләрнең хәлләре ничек? Исәннәрме алар, әллә фашистлар аларны төрмәгә яптымы?

Узган җәйдә миңа Төрксиб тимер юлы буйлап барырга туры килде. Янсан станциясенә җиткәндә поезд барышын акрынайта төште. Таң сызылып килгән чак иде ул. Вагон тәрәзәсе төбенә таянып, моннан унике ел элек без ак бандитлар белән сугышып йөргән урыннарны карап бардым. Ихтимал, син августның уникенче көнен — хәерсез санны онытмагансыңдыр әле. Хәтерендәме, траншеяларга посып, безнең икенче рота ак офицерлар батальонын көтеп торган иде. Теләсә кайсы минут эчендә дошманга каршы ут ачарга әзер булып, күзләребез авыртыр чиккә җиткәнче көтеп-күзәтеп торган идек без ул чакта. Таң ата башлаган вакытта тимер юлдан, соры хәшәрәт сыман булып, бронепоезд килеп чыккач, без аңа шундый итеп ут яудыра башладык — ул түзә алмыйча чигенергә мәҗбүр булды. Шул чак кыска гына команда тавышы яңгырады, окоплардан чыгып, рота атакага күтәрелде. Озын офицер шинеле кигән Белевич, ку-

лына тотенләп торган пистолет тотып, иң арттан чаба һәм, ясалма барьерларны үткән кебек ансат кына итеп, мәетләр өстеннән сикереп-сикереп бара иде.

Алланып кояш чыкканда мин шул урыннарны яңадан күрдем һәм, нәкъ тере кешеләр булып, күз алдыма үзебезнең легиондагы иптәшләр килеп басты... Станциядә бераз тукталып торгач, паровоз кычкыртып куйды һәм, истәлекле сугыш кырын артта калдырып, поезд мине алга таба алып китте.

Без Мартук станциясенә килеп туктадык. Анда тракторлар һәм авыл хуҗалыгы машиналары төягән берничә состав тора иде. Әйтергә генә ансат бит, Месарош: кайчан гына әле кан белән капланган һәм бер нәрсәсе белән дә игътибарга лаек булмаган Тургай хәзер якын киләчәктә илгә миллионнарча тонна икмәк бирәчәк зур дәүләт хуҗалыгына әверелгән ләбаса!

Месарош дустым! Синең турыда уйлаганда безнең үткән матур тормышыбызның тагын бер эпизоды күңелемә килеп төшә. Хәтереңдәме, Оренбургка ясалган уңышсыз һөҗүмнән соң, безнең часть Тургай далаларында адашып калган Дальный Нагорныйда ялга туктаган иде. Көннәр коточкыч салкын, крестьян өйләре түбәләренә тикле карга батып утыралар. Көн бик тиз караңгылана, ә кич утырырга керосин юк иде. Шуңа күрә без, өннәрендә яткан аюлар кебек, кичләрен караңгы өйләрдә утыра идек.

Шундый кичләрнең берсендә мин синең янга, рота канцеляриясенә бардым. Консерв банкасыннан ясаган лампа янына берничә кеше җыелган. Син шунда яшь кенә бер рота командирына, кызып-кызып, Австро-Венгрия монархиясендә гражданнар сугышы булуның котылгысыз икәнлеген аңлатып торасың, ә ул, сиңа каршы килеп, әлеге илләрдә демократия шул тикле алга киткән ки, барлык мәсьәләләрне дә парламентта күпчелек тавыш бирү юлы белән хәл итеп булачак, дип үҗәтләнеп маташа иде. Шунысы кызык: ул яшь егет кайда икән хәзер, үзе мактаган демократиянең рәхәтлекләреннән файдалана аламы икән? Хәтеремдә, ул чакта мин дә бәхәскә катнашып, безнең Советлар тиздән шундый промышленность булдырырлар, аның янында капиталистлар техникасы бөтенләй кечерәеп калыр, дип расларга тотынган идем. Син дусларча минем аркамнан кагып куйдың да:

— Борчылма, Шамил, без ул көннәрне үз күзләребез белән күрербез әле, менә мин әйтте диярсең! — дидең.

Дөресен әйтим, ул кырыс елларда мин иртәгәге көн турында бөтенләй уйламый идем диярлек. Мин җиңәчәгебезгә ышандым, әмма исән калачагыма бик үк ышанып җитми идем.

Журналда синең исемеңне күргәннән соң, тизрәк теге чакта әйткән сүзләреңнең тормышка ашканын сөйлисем килде. Дөрес, без әле ул чакта сукыр лампа яктысында күрергә хыялланган биеклекләргә үк менеп җитмәдек җитүен. Ләкин без авыр хезмәт һәм кыенлыклар аша бара торган ул матур киләчәк һаман саен реальрәк була бара һәм моның шулай икәнлеген безгә карата сыйнфый нәфрәттән сукырайган кешеләр генә күрми.

Безнең илдә барган грандиоз төзелешләр, инде эшкә үк керешкән гигант заводлар, үсеп баручы шәһәрләр һәм яңарып килүче авыллар турында сөйләп тормыйм мин. Болар турында син коммунистик матбугаттан укып та белә аласың. Үземнең көндәлек тормышымда очраштыргалый торган вак-төяк күңелсезлекләр хакында да язып тормыйм. Алары артыгын вак һәм күңелсез булыр иде. Мин сиңа башка нәрсә турында сөйләмәкче булам.

Гражданнар сугышы ахырында мин Казанга эләктем. Ул елларда Идел буенда коточкыч ачлык хөкем сөрә иде. Бар нәрсәләрен дә аллага ышанып тапшырырга гадәтләнгән татар крестьяннары корылыктан соң бер валчык икмәксез калдылар. Районлап-районлап ачыга башладылар. Кешеләр ачлыктан шешенәләр һәм урамда барган җирләреннән егылып үләләр иде. Менә шул вакытта, ярдәм сорап, Совет хөкүмәте бөтен дөньяга, барлык кешелек дөньясына мөрәҗәгать итте. Күп кенә капиталистик илләр продуктлары күплектән шартлап ярылырга җитешкән: икмәкләрен кая куярга белмиләр, яндыралар, елгага ташлыйлар һәм диңгезләрга ашаталар иде. Ләкин алар ачтан үлеп баручы кешеләргә бер сынык икмәк тә бирмәделәр. Ул бәхетсезлекне без үзебез җиңеп чыктык. Авыр заманалар үтте инде. Моннан сигез ел элек ачлык һәм бөлгенлек хөкем сөргән ул җирләрдә хәзер алтын башаклар үсеп утыра.

Крестьяннар бөтен авыллары белән колхозларга керәләр, тракторлар, машиналар сатып алалар, яңа тормыш төзиләр.

1929 елда мин Мәскәүгә күчтем, квартира алдым. Ике йөз квартиралы яңа йортта яшим: водопроводы да, ваннасы, радиосы, телефоны да бар. Квартиралар газ ягып җылытыла. Башкалабызда кварталы-кварталы белән шундый яңа йортлар төзелә.

Беләм, Месарош, син минем эшләрем белән кызыксынасың инде. Үземнең төп эшемнән тыш, мин Мәскәү губерна эсперанто комитетында (эсперанто телен мин бөтен нечкәлекләре белән беләм) эшлим, язучыларның профсоюз җирле комитеты члены, үзебезнең ЖЭК та идарә члены, Фәннәр Академиясе каршындагы СССР халыклары әдәбияты секциясендә, «Красный богатырь» заводында һәм башка кайбер заводларда түгәрәкләр белән җитәкчелек итәм. Ә үзем Язучылар союзында оештырылган тарихи материализм һәм партия тарихы түгәрәкләренә йөрим. Күрәсең, эш җитәрлек.

Көннәр шул кадәр тиз үтә, хәтта истәлекләр турында уйланырга да вакыт калмый. Без инде Октябрьның унөченчесен бәйрәм итәбез. Хәтерлисеңме, Октябрьның беренче еллыгын бәйрәм иткәннең икенче көнендә Яисан станциясендә казак бандаларының котырынган атакаларын кире каккан идек? Шунда алар, безгә ачуланып:

— Ну, кызыллар, Октябрьны бүтән күрә алмассыз инде! — дип җикеренгәннәр иде.

Ялгышканнар ул сатлык җаннар! Унөч еллыгын бәйрәм иттек инде һәм тагын ике елдан унбишенчесен каршылаячакбыз!

Бу бәйрәмне каршылаганда мин үземне һәрвакыт курьер экспрессында утырган-дай хис итәм. Үз максатыбызга тизрәк барып җитәр өчен, без баш әйләндергеч тизлек белән алга чабабыз шикелле. Безне иҗади хезмәт һәм энтузиазм тулы искиткеч матур тормыш көтә.

Әй, дустым, бу энтузиазмның көчен һәм кешеләргә ничек тәэсир итүен белсәң иде син! Октябрь тантанасын мин хезмәт ударниклары бәйрәмендә каршыладым. Удар бригадаларын ничек бүләкләүләрен күрдем мин анда. Шул чакта нинди хисләр кичергәнемне ничек сөйләп бирим икән сиңа! Андый хисләрне мин бары тик фронтта җиңү батырларын бүләкләгән вакытта гына кичергән идем шикелле.

Гафу ит, дустым, шушының белән тәмамлыйм. Синнән җавап көтәм, тагын да җентеклерәк итеп хат язарга вәгъдә итәм.

Кулыңны каты итеп кысып калам.

Шамил Усманов.»

## Зәйнәп Максудова

# ШАГЫЙРЬ ВӘЛИУЛЛА ЧҮПРӘЛЕ

«Казан утлары» журналының 1968 елгы 1 санында укучыларны халкыбызның бер онытылган шагыйре белән таныштырган идек. Билгеле булганча, әсәрләре кайчандыр халык арасында таралып та, исемнәре әдәбият тарихына керми калган әдипләребез байтак. Вәлиулла Хәбибулла улы Алкаев — шундыйларның берсе.

Вәлиулла Чүпрәле элекке Сембер губернасы, Буа өязе, Яңа Чүпрәле авылында 1830 елларда дөньяга килгән. Балалык елларын шул авылда үткәргән, башлангыч белемне дә шунда ата-бабасыннан өйрәнгән. Авыл мәктәбе күләмендә белем алып, укуязу һөнәрен беркадәр үзләштергәч, Вәлиулланы атасы, Казанга илтеп, Зәңгәр мәчет мәхәлләсендәге мәдрәсәгә укырга урнаштырган. Бу мәдрәсәдә күп еллар укып, Вәлиулла гарәп, фарсы, төрки телләрен һәм әдәбиятларын, шулай ук заманның кушуынча, ислам шәригате кануннарын үзләштерә, кирәк кадәр рус телен өйрәнә. Кыскасы, теләсә кайсы шәһәр яки авыл мәхәлләсендә имам, мөдәррис булырлык дәрәҗәгә ирешә.

Ләкин Вәлиулла мулла булырга, бәлеш ашап йөрүче соры корт булып калырга теләми — әдәбиятны, шигъриятне сөя. Ул көнчыгыш шагыйрьләре иҗатын өйрәнә, үз телендәге, ягъни Идел буе төрки-татар телендәге шигырь кануннарын өйрәнә, шулар нигезендә үзе дә шигырьләр яза башлый. Шигырь сәнгатендә фикер алышырлык, көч сынашырлык иптәшләр таба. Шагыйрь Вәлиулланың шундый дусларыннан берсе Гали Чокырый, икенчесе Казан шагыйре Кәрам Хафиз була...

Вәлиулла үзенең каләм көчен әхлак төзәтү, замандашларын яман-ямьсез гадәтләрдән арындыру мәсьәләләренә юнәлдерә. Шуңа да аның шигырьләрендә фаш итү, ачы көлү авазлары дидактика, үгет-нәсихәт мотивлары белән аралашып бара.

Менә шул хәлдә иҗат белән шөгыльләнеп, Казанда байтак вакытлар юанса да, каләм көче белән генә тереклек итәргә мөмкинлек табылмый. Язганнарын нәширләр ошатып бетермиләр, бастырмыйлар. Ахыр чиктә, бердән, икътисади тормыш мәҗбүрилеге астында, икенчедән, авылда караңгылык белән көрәшү, укытучылык итеп, азмы-күпме мәгърифәт орлыклары чәчү теләге белән, үзенең туган авылы Яңа Чүпрәлегә кайтып хезмәткә урнаша: кечкенә генә мәктәп-мәдрәсә ачып, авыл балалары арасында наданлыкны бетерү юлында эшкә башлый. Бу эшне сөеп эшли, балаларга игле-ягымлы холкы белән аларның кадерле остазлары булып китә.

Әмма Вәлиулла Алкаев шул кадәр гыйльме, шигырь язуга осталыгы була торып, үзенең хезмәт няләре — мәхәллә халкы өстеннән көн кичерергә мәҗбүр булуыннан хурлана. Аны билгеле бер күләмдә килере-акчасы булмау кол итә. Татар укымышлыларын изгән, аларның тормышларын чыгырыннан чыгарган бу кара богау — царизм

тарафыннан вак милләтләр өстенә ыргытылган иң авыр газапларның берсе иде. В. Алкаев, бу шартлардан ничек котылуның юлларын таба алмагач, дөнья-ахирәт ярлылыгы богавыннан коткар, дип алласына ялвара.

Югарыда әйткәнебезчә, шагыйрь Вәлиулла Алкаев заманына күрә яхшы гына гыйлем иясе, ачык фикерле, тотнаклы кеше булган. Шул заманның сәрешенчә, ул халыкка уку-язу, фән куллану кирәклеген тирән аңлаган, үзенең көчен, белемен халыкны агарту эшенә биргән. Моннан йөз еллар элек менә шул эшләрне үтәп, караңгы татар авылында бүленеп уздырган гомеренең сагышлы көннәрен, озын кышкы төннәрен китаплар уку, борынгы гарәп, фарсы, төрки телләрдәге матур әдәбиятны өйрәнү белән кыскарткан.

Вәлиулла Чупрәленең шигырьләре фикер ягыннан ягымлы булган кебек, тел-өслүб ягыннан да матур, кафияләре, үлчәүләре төзек, шигырь сәнгатенең иң кирәкле кагыйдәләренә ригаятә кылынган. Сүзлек составы гарәп, фарсы телләреннән алынма сүзләр хисабына чуарланган булса да, алар күп түгел, фикер аңлашыла. Шуның белән бергә, аның шигырьләрендә татар теленә генә хас булган тансык сүзләр, сүз формулалары, кинаяле тәгъбирләре — тел бизәкләре дә байтак очрый. Алар шигырьнең кәфасәтен, гүзәллеген арттырып, итле ашка суган-борыч өстәгән кебек, сыйфат һәм тасвирлау көчләрен, төрле күренешләрнең буяуларын тагын да ачып җибәрәләр. Түбәндәге өзекләргә игътибар итегез:

Хосус дәмулла Шиһаб тик әкбир,  
Табылса бу заман, белгел аны пир (юлбашчы)...  
Безем тикләр йөри мыек кабартып,  
Бәлеш буына сакаллар агартып...

Күрәсез, бер-берсенә капма-каршы куелган ике шәхеснең килеш-килбәте, аларның эчке һәм тышкы сыйфатлары никадәр ачык һәм хәтердә калырлык итеп бирелгән.

Йитәр инде сәлям язмага мул-мул!  
Бүтән сүз яз, йә язмактан күтәр кул! -  
дигәч, китте зиһен бәр дә таралып;  
Мишәр чумарасы илә каралып...

Алай да башка кидем кәләпүшне,  
Зиһен бирі — дип аңа кыйлдым хорушны.  
Кигәч кәләпүшне җыелды зиһен,  
Гүйә күз алдына килде дә Казан...

Ачубән укыдым тиз үк хатны,  
Язылмыш Сафа Хәмзиннең вафаты.  
Һушым китте, каләм төште кулымнан,  
Аералмадым уңымны сулымнан...

Менә бу көчле шигъри өзекләр үзләрендәге фикерләрне аңлатып кына калмыйлар, бәлки укучыны шагыйрьнең кичергән рухи халәтенә алып керәләр, ул кичергән авыр кайгыны йөрәгең белән сизәргә, аныңча сыкранырга, көяргә мәҗбүр итәләр. Бу сыйфатлар шагыйрьнең ни дәрәҗәдә көчле талант иясе, үткен каләмле, сизгер йөрәкле булганын аңлата.

Моннан алтмыш еллар элек бездән аерылган бу шагыйрьнең барлык иҗат җимешләрен эзләп-табып туплаганда һәм аларны нык тикшереп чыкканда, шагыйрьнең үз заманы өчен тоткан урыны тагын да ачыкланыр иде. Шуның өчен бу мәкаләне укыган иптәшләр шагыйрьнең тормыш юлын өйрәнүдә, иҗади әсәрләрен туплауда булышсыннар иде, дигән теләк белдерәсе килә.

**Гөлшат Зәйнашева**

# САНДУГАЧ



Халкыбызның бу сайрар кошын күпләр сандугач дип атый. Язучы Барлас Камалов 1959 елда Рәйсә Билалова турында болай дип язган иде: «Менә сәхнәдә Татарстанның атказанган артисткасы Рәйсә Билалова. Ягымлы һәм көчле тавыш, һәркемне җәлеп итәрлек мөлаем йөз, бай мимика... Ә инде Алябьевның «Сандугач»ын җырлаганда тыңлаучылар таң калдылар, гүя сәхнәдә җырчы түгел, табигатьнең мактанычы сандугач үзе дәртләнеп сайрый иде»... Филология фәннәре докторы, профессор Мөхәммәт ага Гайнуллин «Социалистик Татарстан» газетасының 1969 елгы 14 сентябрь санында Рәйсә Билалова иҗаты хакында зур мәкалә язып чыкты. Мәкаләсен ул «Татарстан сандугачы» дип исемләгән иде. 1965 елда Ленинградта татар әдәбияты атналыгы уздырылды. Атналык көннәрендә бер төркем язучылар, артистлар Киров исемендәге крейсерда Балтик диңгезе матрослары белән очраштылар. Очрашуда Татарстанның халык артисткасы Рәйсә Билалова да катнашты. Шушы очрашудан соң шагыйрь Мөхәммәт Садри, Рәйсә Билаловага багышлап, «Крейсерда сандугач» исемле шигырь язды... Кабатлау дисәләр диярләр, мин дә Рәйсәне сандугач дип атыйм, сандугач булгач, аны башкача ничек атыйсың?!

Сандугач һәм крейсер... Биредә артисткага аккомпанировать итәргә рояль дә, пианино да куелмаган — корыч һәм тимердән ясалган крейсер бит ул. Ләкин сандугач кайда да сандугач булып кала. Чын мәгънәсендә сәнгатькә гашыйк җырчы тиешле шартлар юк дип кенә җырламый каламы соң?! Җырлый һәм үзенең искиткеч мөлаем тавышы белән йөзләгән морякларны хәйран калдыра. Вакытлыча туып-үскән якларыннан, бала чактан күңелгә кереп калган татар моңнарыннан аерылган һәм туган як чишмәләренең агышын, урман, су буйларында сайраган кошлар җырын, яшьлек мәхәббәтләрен сагынган татар егетләре үзләрен туган өйләренә кайткандай хис итәләр. Мондый — тиешле шартлары булмаган урыннарда кайбер артистлар, бигрәк тә опера җырчылары, гадәттә, халык никадәр ялынып сораса да, җырламый. Син аңар рояль китер, рояль янына шәп пианист утырт! Юк, Рәйсә андыйлардан түгел. Син аны халык белән, музыка, җыр сөюче белән очраштыр гына — сәхнә юк, җил-яңгыр тия димәс, рояль яки пианино китер дип тормас, мөлаем гына елмаеп куяр да җырлап җибәрер. 1964 елда Казанга чит илдән бер төркем туристлар килә. Алар шәһәрнең

тарихи урыннарын карап йөриләр, В. И. Ленин яшәгән урыннарда булалар һәм күреп чыгу өчен генә Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрына керәләр. Театрда булган артистлар ашыгыч кына залга җыела. Сүз иярә сүз чыга, чит ил кунаклары татар җырчыларын тыңларга теләүләрен белдерәләр. Артистларның күбесе пианино юк диләр, аккомпанементсыз җырламыйбыз, диләр. Бу юлы да Рәйсә Билалова коткара. Торып баса да берничә әзерлексез үзенең сандугач моңнарын сайрый башлый. Татарча, русча, итальянча җырлый. Кунаклар тын да алмый тыңлый. Татар кызының шундый иркен, көчле, матур тавыш белән җырлавына сокланып кул чабалар. Гомумән, нинди генә очрашуларда булмасын, Рәйсә Билалова үзен гаҗәп гади, самими тота, кешеләр белән бик тиз уз булып китә. Шуңа күрә һәр очрашуда аны кабат-кабат җырлаталар. Бигрәк тә язучыларның якын дусты ул. Күп кенә әдәби очрашулар, атналыклар вакытында Рәйсә язучылар белән халык арасына чыга. Кронштадт матрослары белән шул ук очрашу дисеңме, Казагыстанда үткәрелгән татар әдәбияты һәм сәнгате атналыгы, Мәскәүдә үткәрелгән әдәби очрашулар, республикабыз районнарында булып узган әдәбият атналыклары дисеңме, аларның күбесендә Рәйсә Билалова даими рәвештә катнашып килә. Мин Рәйсәнең шәхси китапханәсе белән таныштым. Безнең күренекле язучыларыбыз, аны дус күреп, җырчыга яңа китапларын бүләк иткәннәр.

Күренекле язучыбыз Гомәр ага Бәширов үзенең китабына болай дип язган: «Күптән түгел ике тугандаш халыкның сәнгать осталары ярышында сезнең җырларыгыз татар халкының горурлыгы булып яңгырады, моның өчен мең рәхмәт, сеңелем!.. Саклагыз үзегезне, саклагыз тылсымлы тавышыгызны, моннан соң да бу сихри моң тагын да киңрәк мәйданнарга таралып, тагын да югарырак күтәрелсен».

Үзенең күп еллык сәхнә иҗаты белән халык арасында киң танылган күренекле җырчының тормыш юлы гади генә. Әмма бу әле аның иҗат юлы да гади һәм шома гына үтелгән дигән сүз түгел.

Рәйсә Билалова Казанда эшче семьясында, алай гына да түгел, потомственный пролетарий семьясында туып үсә. Рәйсәнең бабасы 40 ел буе Алафузов фабрикасында эшли. Әтисе һәм әнисе дә озак еллар завод-фабрикаларда эшли. Музыкага мәхәббәт Рәйсәдә бик яшьли тәрбияләнә. Әтисе Гайса абзый үзе оста гармунчы була. 1925—30 елларда хәтта атаклы артист Хуҗа Шонкаров җитәкчелегендәге концерт бригадасында катнаша. Әнисе Гайшә апа да җыр-музыка дигәндә җанын бирергә әзер кеше. Хәрби заводларда эшләп арып кайтуына карамастан, кичләрен балаларын җырлатып, Гайса абзый уйнаган гармунга биетеп шатлык таба. Шушы музыкаль семьяда халык көенең сәламәт рухын тоеп үсү, кечкенәдән күренекле җырчыларыбыз Галия Кайбицкая, Сара Садыйкова, Гайшә Камаева, Шәфика Котдусоваларның тылсымлы тавышын тыңлау, алар катнашкан спектакль, концертларга йөрү, мәктәптә, пионерлар сараенда, радиокомитет каршында төзелгән балалар хорында яшүсмер чактан ук җырлау Рәйсәне җыр сәнгате белән гомерлеккә дуслаштыра.

Менә җиденче класста укып йөргән кеннәр. Рәйсәләр класслары белән Нәҗип Җиһановның «Качкын» операсын тыңларга баралар. Сәхнә сәнгатенең бу катлаулы һәм тылсымлы төре белән очрашу, сихри авазлар дөньясына сәяхәт Рәйсәдә гаять зур, тирән тәэсир калдыра, аның җырчы артистка булырга дигән карарын ныгыта.

Профессиональ татар музыкасы гөрләп үсеп, милли операларыбыз сәнгатьнең олы юлына чыгып килгән 40 нчы еллар башында талантлы яшьләрне үстерү, яшь иҗат көчләрен тәрбияләү өчен зур мөмкинлекләр тудырыла. Бала чактан ук җыр-музыка яратып үскән Рәйсә Билалова музыка училищесына керергә була. Кабул итeлү имтиханнары аңа шактый җиңел бирелә. Тумыштан матур тавыш, ишетү сәләтенең камиллеге аның алдына артык киртәләр куймый. Комиссия каршына оялып кына чыкса да, ул матур итеп «Яңа кара урман» көен җырлап күрсәтә. Һәм имтиханнарын яхшы биреп, училищеның хаклы укучысы булганга шатланып-канатланып өенә кайта. Барлык семья шатлана. Рәйсә бала чактан хыялланган максатына беренче уңышлы адым ясый. Тик иртәгесен көтелмәгәндә Бөек Ватан сугышы башланып китә. Рәйсәнең матур хыялларын сугышның кара канаты каплап-күмеп калдырыр микәнни?.. Ләкин сугыш берган көннәрдә дә хөкүмәтебез сәнгать кадрлары әзерләү эшен туктатмый. Музыка училищесында укулар иң авыр сугыш көннәрендә дә дәвам итә. Сугыш елларында төннәрен маскировка өчен кинәт ут сүнгән чаклар еш була иде, дип сөйли Рәйсә. Шун-

дый чакларда кичке сменадагы укучылар, ут янганын көтеп, караңгыда утырганнар. Шул күңелсез минутларда укытучылар, студентлар сорап, Рәйсәне җырлата торган булганнар. Укудан тыш вакытларда училище укучылары еш кына Казан госпитальләрендә яралы сугышчылар алдында концертлар куялар. Рәйсә бу концертларның берсеннән дә калмый. Ул сугышчылар алдында татар халык көйләрен, композиторларыбыз әсәрләрен башкара. Училищены уңышлы тәмамлагач, Рәйсә Билалова, беренчеләрдән булып, Казанда әле генә ачылган консерваториягә керә. Консерваториядә ул зур ашкыну, дәрт белән, үз талантына, үз көченә ышанып, җырга, музыкага гашыйк булып укый...

Студент елларындагы концертларда, төрле шәһәрләрдә уздырылган смотрларда катнашу аның үз-үзенә ышанычын ныгыта, аңа һәртөрле шик-шөбһәләрдән арынырга булыша. Көннәрдән бер көнне музыка җәмәгатьчелеге алдында профессор Константин Ефимович Цветовның яраткан укучысы Рәйсә Билалова Алябьевның мәшһүр «Сандугач»ын башкара. Һәм матур, шундый зур зәвык белән башкара: тыңлаучылар яшь җырчыны да, укытучысы Цветовны да алкышлар белән күмәләр. Рәйсә бу әсәрне шундый гүзәллек белән җырлый ки, рус халкының бай эчке дөньясын, тирән уй-кичерешләрен чагылдырган атаклы романс татар кызы башкаруында үзенә бер төрле нәфислек белән яңгырый. Шушы романсны башкарган көннән алып, Рәйсә җәмәгатьчелек арасында таныла башлый. Аны күренекле артистлар белән берлектә концертларда чыгыш ясарга чакыралар, Татарстан районнарында һәм илебезнең башка шәһәрләрендә барган гастрольләргә алып чыгалар. Алябьев «Сандугач»ы белән рәттән, Салих Сәйдәшев һәм Мансур Мозаффаровларның «Сандугач»лары һәм башка композиторларыбызның әсәрләре, халык көйләре Рәйсә башкаруында матур яңгыраш ала.

Сүз уңаеннан әйтәсе килә, композиторлар, шагыйрьләр сандугач образын җырга коры матурлык өчен генә кертмиләр. Халкыбызның борынгы җырларында да бу шулай. Элек-электән сандугач образы гүзәллек символы булган. Сандугач... Нинди сихри көч бар соң аның моңында?!. Нигә аның сайравы күңелгә нәфис дулкыннар булып килеп бәрелә дә кешене тойгылар дәрьясына сала? Безнең яклар табигатенең иң матур сайраучы кошы булганлыктанмы? Кай илләрдән килеп түгел, ә бәлки үз җиребездә туып үскән үз кошыбыз булганлыктанмы?.. Ни генә булмасын, сандугач тавышы һәрвакыт безнең иң нечкә хисләребезгә кагыла, безне уйландыра, моңландыра. Һәм сәнгать әсәрләрендә тасвирлана торган төрле кошлар арасында сандугач аеруча гүзәл, нәфис, саф образ буларак йөртелә. Татар һәм башкорт сәнгатендә ул бигрәк тә матур чагылыш таба. Рәйсә Билалова кебек сайрап җырлаучы җырчыларны да халкыбыз әнә шуңа күрә сандугач дип атый. Сандугачка, аның гүзәл тавышына сокланып язылган иң матур җырлар туган илне, туган халкыбызны, гомумән тормышны, кешелекне сөю кебек олы кичерешләрне уята торган көчкә ия.

Ләкин училище һәм консерваториядә укыгандагы беренче концертлар яшь җырчының зур сәнгать дөньясына — опера сәнгатенә якынлашканда салган беренче сукмаклары гына иде әле.

1952 ел. Рәйсә Билалова, консерваторияне уңышлы тәмамлап, Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрына эшкә килә. Бу елларда опера театрының Мәрьям Рахманкулова, Фәхри Насретдинов, Мөнирә Булатова, Нияз Даутов, Халидә Зәбирова кебек ветераннары сафына, югары музыкаль белем алып, Зөләйха Хисматуллина, Азат Аббасов, Венера Шәрипова, Йосыф Гыйззәтуллин, Камил Якупов, Гөлшат Сәйфуллина, Фагыйлә Тимировалар килеп кушыла. Рәйсә шушы соңгы яшь талантлар арасында үзенең нәфис тембрлы колоратуралы сопрано тавышы белән аерылып торганы була. Аерылып торса да яшь артисткага театр сәхнәсендәге беренче адымнарны атлау җиңел булмый. Ләкин өлкән артистлар Рәйсәгә чын дусларча ярдәм итәләр, аңа сәхнә серләрен төшенергә булышалар. Танылган дирижерлар Җәләл Садриҗиһанов, Хәсби Фазлуллин, Николай Тихонов, җырчы, режиссер Нияз Даутов Рәйсәнең опера сәхнәсендә башланган иҗат эшендә якыннан торып, чын күңелдән ярдәм итәләр.

Рәйсә Билалованың Опера театрында беренче дебюты кызыклы була. Беренче тапкыр Рәйсә Римский-Корсаковның «Кар кызы» операсында патша пажы образында чыга. Тамаша залы халык белән шыгрым тулы. Утлар сүнә. Юпитерлар, күзне камаштырып, артистларга сихри нурлар сибә. Оркестр увертюра уйнап туктый. Сәхнәгә чы-

гарга кирәк... Менә Рәйсә сәхнәдә. Аның йөрәген нәрсәдер чемстеп алгандай була. Беркавым нишләргә белми аптырап тора. Ниһаять, җырлап җибәрә. Бу гади бер көн Рәйсә Билалова күңелендә онытылмаслык булып уелып кала. Ул көннәрне искә төшергәндә, Рәйсә Билалова бүген дә тәэсирләнеп сөйли:

«Паж роле кечкенә генә булса да, мин бик дулкынландым. Чөнки бу опера театрының зур сәхнәсендә танылган артистлар белән беренче тапкыр чыгуым иде. Миңа тапшырылган паж роле алты сүздән генә торса да шул алты сүзне җырлау минем өчен зур бәхет булды».

«Кар кызы»ннан соң Рәйсә Билалова бер-бер артлы яңа образлар иҗат итә. Чайковскийның «Пики дама»сы, Сметананың «Сатылган кәләш»е, Даргомыжскийның «Су кызы», Планкеттның «Корневиль кыңгыраулары», Җ. Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясе... Рәйсә образдан образга үсә бара, иң җаваплы партияләр башкарырлык чыныгу уза.

1955 елның җәендә Польша Халык Республикасы Варшавада яшьләрнең һәм студентларның V Бөтендөнья фестивале булып уза. Фестивальгә безнең Татарстан вәкиле булып Рәйсә Билалова да бара. Анда ул татар халык көйләрен, композиторларыбыз С. Сәйдәшев, Н. Җиһанов, А. Ключарев, З. Хәбибуллин әсәрләрен башкара. Рәйсә Билалова бу фестивальдән илһамланып, дәртләнеп, канатланып кайта...

Рәйсә көндәлекләр язарга ярата. Аның тормышындагы истәлекле көннәр турында көндәлегенә язып куелган төрле хатирәләре бар. Фестиваль көннәре турында Рәйсәнең көндәлегенә мондый юллар язылган:

«...Мин Варшава фестивалендә үзебезнең татар кызлары кия торган милли киемдә йөрдем. Кайвакыт, үзебезнең делегация яшьләреннән аерылып, чит ил яшьләре арасында каласың, төрле телләрдә сөйләшүләр яңгырый, бер чит телне дә белмәгән килеш чит ил кешеләре арасында уңайсыз булып китә. Ләкин дуслык, туганлык теле һәр милләт өчен дә уртак. Без, елмаеп, күзләр белән күләмсерәп аңлашабыз, автографлар бирешәбез. Чит ил яшьләре, минем СССР дан икәнлегемне белеп алгач, бик зур кызыксыну белән сораулар бирәләр. Киемнәрем, кайда эшләвем, кем булуымны сорыйлар. Казаннан килүемне, татар кызы булуымны әйткәч, татарча һәм русча автографлар язуымны үтенәләр. Ә концертларда тамашачылар татар җырларын бик кызыксынып яратып тыңладылар, кайнар алкышладылар. Совет делегациясенең чит ил яшьләре белән очрашулары күңелдә онытылмаслык тирән тәэсир калдырды. Миңа француз халкының тынычлык өчен көрәштә зур батырлыклар күрсәткән кыю кызы Раймонда Дьен белән очрашып сөйләшергә туры килде. Бу очрашулар, төрле халыклар музыкасын ишетү, аларның киемнәре, гореф-гадәтләре белән танышу — минем иҗат эшем өчен бик зур мәктәп булды...»

Фестивальдән кайткач, Рәйсә зур дәрт белән яңа образлар иҗат итә башлый. Әле 3—4 ел гына эшләвенә карамастан, опера сәхнәсендә дистәгә якын кызыклы образлар иҗат итеп өлгергән Рәйсә Билаловага вакытлы матбугат та игътибар итә. «Татарстан яшьләре» газетасының 1957 елгы 8 март санында яшь артистканың беренче иҗат уңышлары хакында мәкалә басыла:

«...Әнә шул миниатюр образларны, характерларны, социаль һәм психологик буяулары белән гаять төрле булган сәхнә портретларын иҗат итү артистканың иҗат лабораториясен дөрес сайлап алынган күп кенә вак детальләр, штрихлар белән баетты. Нәкъ әнә шул чорда артистка үз сәләтеннән, үз темпераментыннан дөрес файдалану, сәхнәдәге үенны спектакльнең логик агышына буйсындыру кебек уңай сыйфатларны үзләштерде...»

Рәйсә Билалова иҗаты торган саен камилләшә, баий бара. 1956—57 елларда инде ул опера спектакльләрендә иң җаваплы партияләрне үйный башлый. Вердинең «Риголетто» операсында Джильда образы шундыйларның берсе. Бу катлаулы классик партия яшь солистка өчен зур сынау була. Ул вакытта сәхнәгә беренче чыккан гүзәл кыз Джильданы опера сөючеләр бүген дә сокланып искә алалар. Гади генә яшь кыз югары даирәдән чыккан егеткә гашыйк була. Мәхәббәте аның гаять көчле һәм искиткеч саф. Хәтта җилбәзәк һәм бозык күңелле герцогка уенчык булганлыгын аңлагач та Рәйсә-Джильданың мәхәббәте сүрелми, ә бәлки аның йөрәге әрнү һәм газап белән тула. Джильда, шушы олы мәхәббәтенә тугры калган хәлдә, герцогның гомерен саклап калу өчен, белә торып үлемгә бара. Җырчы бу образны бөтен каршылыгы, катлаулы



*Р. Билалова Алтынчәч ролендә.*

психологик халәте белән җанлы итеп күз алдына китереп бастыра. Билалова башкарган Джильда яшьлек романтикасы белән сугарылган, балаларча беркатлы, самими, саф күңелле, шул ук вакытта зур газап, тирән кайгыларны да кичерә ала торган көчле ихтыярлы кыз.

Рәйсә Билалова бервакытта да үз тавышының колоратура руладаларын, ягъни халык теле белән әйткәндә, челтерәп, сайрап җырлый алуын үз максат итеп куймый, тавышының һәр мөмкинлеген урынлы файдалана. Джильда партиясен башкарганда бу бигрәк тә нык сизелә. Рәйсә-Джильда герцогка булган көчле мәхәббәтен эчке саклык белән кыюсыз гына белдерә. Бу күренештә аның тавышы йомшак, нечкә борылышларга гаять бай. Ә инде герцогның хыянәтен белгәч, Рәйсә-Джильда тавышында көчле, горур аһәңнәр яңгырый. Бу рольдән соң аңа яңадан-яңа җаваплы партияләрне ышанып тапшыралар. Татар дәүләт опера театры яңа бинага күчеп, 1957 елгы яңа сезонын ачканда, Рәйсә Билаловага Н. Җиһановның «Алтынчәч» операсындагы Алтынчәч партиясе тәкъдим ителә. Бу Рәйсәнең үзебезнең милли операдагы беренче зур иҗат эше иде. Заманында әлеге партияне Галия Кайбицкая, Шәфика Котдусовалар кебек опера мастерлары башкарган. Рәйсә өстенә гаять авыр һәм җаваплы эш йөкләнә. Ул нишләр? Моңарчы иҗат иткән артисткаларны кабатлап кына калмасмы? Үз Алтынчәчен иҗат итә алырмы?.. Шундый борчулы уйлар Рәйсәгә тынгылык бирми. Ниһаять, эзләнүләр, тырышулар бушка китми. Аңа кадәр Алтынчәчне җырлаган мастерларның тәҗрибәсен үрнәк итеп алган хәлдә, Рәйсә сәхнәдә үз Алтынчәчен тудыра. Аның Алтынчәче — гаять сөйкемле, нечкә күңелле, татар кызларына хас мөлаем, шул ук вакытта авырлыклар алдында сыгылып төшми торган нык рухлы кыз. Рәйсә Алтынчәчне шулай сурәтли ки, Алтынчәч әкиятчә сихри дә, реаль тормыштагыча гүзәл дә булып чыга. Лирик эпизодларда, Җик мәргәнгә булган мәхәббәтен аңлатканда, Рәйсәнең тавышы йомшак, нәфис, саф һәм тигез агышлы. Ә инде киеренке драматик эпизодларда Рәйсәнең тавышы тирән кичереш, көч белән яңгырый. Якты идеалларга омтылучан, халык бәхете өчен көрәшне гәүдәләндергән онытылмас бу образны бөтен тулылыгы белән ачуы өчен тамашачылар Рәйсәне кайнар алкышлар белән котлыйлар. Операның авторы күренекле композиторыбыз Нәҗип Җиһанов артисткага чын күңелдән рәхмәт әйтә һәм әсәренең клавирына: «Искиткеч тавышлы Рәйсәгә, инде кечкенә түгел, ә бәлки зур һәм мин тыңлаган иң яхшы Алтынчәчкә истәлек булсын. Сәламәтлек һәм озакка сузылган иҗат эшендә уңышлар телим»,— дип язып, Рәйсәгә бүләк итә.

1957 елда Мәскәүдә уздырылган татар сәнгате һәм әдәбияты декадасында инде Рәйсә Билалова безнең опера сәнгатенең төп иҗат көчләреннән берсе буларак катнаша. Декада вакытында ул татар һәм башка милләт операларында җаваплы рольләрне башкара, күп кенә концертларда чыгышлар ясый. Аның иҗатына үзәк матбугат битләрендә дә югары бәя бирелә. Декададан кайткач, хөкүмәтебез артистка Рәйсә Билалованы, татар сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен, «Почет билгесе» ордены белән бүләкли.

Рәйсә Билалова адресына илебезнең төрле почмакларыннан һәм чит илләрдән бик күп хатлар килә. Фестивальдә танышкан дуслар яза, музыка сөючеләр яза. Ә кайбер хатларда яшь музыка сөючеләр ничек опера җырчысы булырга дип киңәш сорый-

лар. Икенче берәүләр Рәйсәнең җырлавын радио аша тыңлап сокланганнар, өченчеләре аның сәхнәдә иҗат иткән матур-матур образларына гашыйклар. Рәйсә бер генә хатны да җавапсыз калдырмый. Күп кенә хатларны үзендә истәлек итеп саклый. Менә шундый хатларның берсе. Аны 1957 елда Латвия ССРда хезмәт иткән татар солдаты Рәис Абукин язган: «Мин татар малае, татар солдаты сезнең тавышыгызга шул кадәр сокланам, сезнең алда ант итәм: туган илемне дошманнардан саклармын, әгәр дә кирәк булса, батырларча үләрмен...» Музыка сөючеләрнең шундый эчкерсез мәхәббәтен тоеп торганда, артистка кешегә ничек иҗат дәрте белән янмаска да ничек яңа образлар тудыру турында хыялланмаска?! Рәйсә тынгысыз эзләнә, бөтен көчен, бөтен мөмкинлекләрен иҗат эшенә багышлый. Илебезнең күренекле җырчысы, вокалистлар педагогы, әрмән халкының танылган артисткасы Г. Гаспарян янына Ереванга барып, Рәйсә Билалова махсус вокаль курсы үтә, белемен, тәҗрибәсен баетып кайта. Бу озак булмаган уку, тәҗрибәле педагогтан киңәшләр алу аның өчен күп нәрсә бирә. Г. Гаспарян сирәк очрый торган колоратуралы сопрано тавышлы Рәйсәнең әле ачылып бетмәгән мөмкинлекләрен күрә, шуларны ачарга, тулысынча яңгыратырга киңәшләр бирә, күнегүләр үткәрә. 1962 елда Татар опера театры җитәкчеләренә язган бер хатында Г. Гаспарян болай ди: «Бик сәләтле җырчы. Вокаль мастерлыкка үсеш, яхшы якка үсеш бар аның тавышында».

Музыкаль комедияләрдәге җаваплы партияләрне башкарганда, Рәйсә Билалованың амплуасы күпкырлы булуы ачыла. Әнвәр Бакировның «Тальян моңы», Зәһир Исмәгыйловның «Кодача», Җәүдәт Фәйзинең «Башмагым» һәм «Акчарлаклар» исемле музыкаль комедияләрендә Рәйсә төрле төсмерләрдәге кызыклы образлар иҗат итә. Бу спектакльләрдәге образларның һәркайсына хас характерлы якларын ачып, заманына күрә яңгырашын табып, Рәйсә тулы канлы, җанлы портретлар тудыра. Шулар арасында «Башмагым» музыкаль комедиясендәге Сәрвәр образы Рәйсә Билалова иҗатында үзенә бер урын алып тора. Рәйсә иҗат иткән Сәрвәр образы озын гомерле, истәлекле булды. Бик озак еллар «Башмагым» спектаклендә Рәйсә РСФСРның халык артисты, опера театрының ветераны, тәҗрибәле артист Фәхри Насретдинов белән бергә җырлый. Рәйсә-Сәрвәр, Фәхри-Галимҗан дуэтлары опера сәхнәсендә генә яңгырап калмыйча, киң эстрада сәхнәләренә чыга, озак еллар радио аша яңгырый һәм әле хәзер дә еш кына тапшырыла. Рәйсә Билалова иҗатына багышланган зур программалы бер радио тапшыруда катнашып, Фәхри Насретдинов менә нәрсәләр сөйләде:

«Миңа «Башмагым» музыкаль комедиясендә Галимҗан ролендә 1942 еллардан башлап соңгы елларга кадәр уйнарга туры килде. Башта Сәрвәр ролен халкыбызның яраткан артисткалары Галия Кайбицкая һәм Шәфика Котдусова башкарды. Алар бу образны үзләренә генә хас осталык белән ачканнар иде. Рәйсә Билалова да спектакльнең яңа постановкасында Сәрвәр образына күп кенә яңалыклар кертте. Аның матур, ягымлы тавышы, яшьлеге, сәхнәдә үзен иркен тотуы һәм Сәрвәргә генә хас булган сыйфатларны ышандырырлык итеп күрсәтә алуы — артисткаының зур уңышы булды».

Татар милли операларында һәм комедияләрендә уңышлы уйнау һәм татар тамашачыларының мәхәббәтен яулап алу белән бергә, Рәйсә Била-



*Р. Билалова Ж. Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясендә Сәрвәр ролендә.*



*Р. Билалова Джульетта ролендә.*

лова, Гуноның «Ромео һәм Джульетта», Вердинең «Риголетто», Россининең «Севиль чәч алучысы», Сметананың «Сатылган кәләш», Чайковскийның «Пики дамасы», рус телендә барган башка опералар{да уйнап, рус тамашачыларының да игътибарын казанды.

Рәйсә Билалованың опера театры сәхнәсендәге иҗаты турында күп язарга мөмкин булыр иде. Безнең татар халкын опера кебек зур музыка сәнгатенә якынайтуда, опера сәнгатен гади татар тамашачысына аңлатуда Рәйсәнең хезмәте игътибарга лаеклы. Безнең милли операларыбыз, милли музыкаль комедияләребез, кызганычка каршы, аз, шулай да халкыбыз опера сәнгатен аңлап, яратып бара. Гади генә хезмәт кешесенең, мәсәлән, «Алтынчәч» операсына килеп, Рәйсә Билалова башкарган Алтынчәчне, Фәхри Насретдинов башкарган Җик Мәргәнне, Мөнирә Булатова башкарган Тугзакны яратып каравы бик күңелле күренеш.

Опера сәхнәсендәге иҗаты өстенә, Рәйсә Билалова зур концерт эшчәнлеге дә алып бара. Эстрадаларда, радиоконцертларда арияләр, дуэтлар башкара, зур осталык белән композиторларыбыз әсәрләрен башкара. Аның башкару манерасына, киң диапазонлы тавышына С. Сәйдәшев, Н. Җиһанов, М. Мозаффаров, А. Ключарев, Җ. Фәйзи, З. Хәбибуллин, С. Садыйкова, Б. Мулюков әсәрләре якын. Рәйсә Билалованың концерт программаларында татар һәм башкорт композиторларының әсәрләре белән бергә, СССР халыклары композиторлары җырлары, Европа халыклары музыкасы зур урын тота. Рәйсә шәһәребезнең завод-фабрикаларында, мәктәпләрендә күп чыгышлар ясый, еш кына республикабыз районнарына, авылларына гастрольгә чыга. Театр гастрольдә йөргәндә, «Советская Кубань» газетасының 1962 елгы 6 сентябрь санында зур мәкалә басылып чыга. Мәкаләдә Рәйсә Билалова турында болай диелә:

«Татарстанның атказанган артисткасы Рәйсә Билалова иҗат иткән Алтынчәч искиткеч гүзәл. Җырчының тавышы нәфис һәм чиста, якты интонацияләре белән аерылып тора. Рәйсә Билалова үзенең гадилеге, самимилеге белән, образны җиңел башкаруы белән тамашачыны җәлеп итә, партиясендә иң авыр урыннарны да ул уңышлы башкара ала»... Рәйсә Билалова елдан-елга үзенең башкару осталыгын камилләштерә бара. 1964 елда хөкүмәтебез аңа Татарстанның халык артисткасы дигән мактаулы исем бирде. Хәзер аның талантының иң камилләшкән чоры. Халкыбызның сандугачы Рәйсә Билалова үзенең күпкырлы иҗаты белән тыңлаучыларга һаман әле җан азыгы, эстетик байлык бүләк итәр, тормышыбызны ямьләп бар тавышына сайрар, опера спектакльләрендә яңадан-яңа образлар иҗат итәр дип өметләнәбез.

Рәйсә Билалова, артистлык эшчәнлеге белән бергә, күп кенә җәмәгать эшләре дә башкара. Берничә чакырылышта ул Казан шәһәр советы депутаты булып сайланды. Җәмәгать эшләрен ул бик бирелеп һәм теләп башкара. Рәйсә Билалова—Татарстанның атказанган артисты, танылган гобойчы Мөбәрәк Батталовның тормыш иптәше. Аларның музыкага гашыйк Әминә һәм Наилә исемле ике кызлары үсеп килә. Рәйсә семья мәшәкатьләреннән зарланмыйча иҗат дәрте белән яна, яңадан-яңа җырлар өйрәнә, яңа операларда кызыклы һәм тулы канлы образлар иҗат итү турында хыялланып, канатланып яши.

# Г. Р. ДЕРЖАВИН



Атаклы рус шагыйре Г. Р. Державинның тормышы (1743—1816) Казан белән аерылгысыз бәйләнгән. Ул 1743 елның 3 июлендә Казан өязенең Сокуры авылында (хәзер Лаеш районы) дворян нәселеннән чыккан офицер Роман Держаавин семьясында дөньяга килә һәм бала чагын шунда үткәрә. 1754 елда әтисе үлгәннән соң Державиннарның тормышы кинәт кыенлаша: күршеләрендәге байлар аларны тәмам кысрыклыйлар, шунлыктан яшь Державинның әнисе бөтен мал-мөлкәтен сата һәм шуннан килгән акчага өҗәтләрен көч-хәл белән генә түли дә алар Казанга күчеп китәләр.

Казанда Державинның әнисе, гаделлек эзләп, күршеләренең хаксызга кимсетүен әйтеп, казна судлары каршына барып йөрергә мәҗбүр була. Ә суд әһелләре аңарга игътибар итми, кая барса да бик дорфа каршылыйлар. Менә шул аяныч хәлләрне яшь Державин үз күзе белен күреп тора, аның күңелендә патша судларына каршы гомерлек нәфрәт туа.


1759 елда Казанда беренче ирләр гимназиясе ачыла һәм, ниһаять, Гаврил Державин үзенең бертуган абыйсы белән дәүләт хисабына шунда укырга кабул ителәләр.

Директоры, шул замандагыча әйтсәк, командиры драматург Веревкин булган ул гимназия нindирәк хәлдә булган соң? Бу сорауга җавапны Гаврил Романовичның үз язмаларыннан табарга мөмкин: «Барыннан да бигрәк,— дип яза ул,— безне укырга, язарга, аз-маз грамматиканы белергә, сүз тыңлаучан булырга, ул вакытта атаклы булган Сумароков трагедияләрен гимназия театрында уйнарга, танцыга, фехтованиегә һәм имтиханнар уңае белән үткәрелгән тантаналы җыелышларда нотык сөйли белергә өйрәтәләр иде. Менә болар барысы да, әллә ни зур фәнни белем бирмәсәләр дә, гимназиядә тәрбияләнүчеләрне кешеләр белән шактый иркен мөгамәлә итәргә өйрәтә иде... Чын мәгънәсендәге фәннәрне, яхшы укытучылар булмаганлыктан шул элекке иске кагыйдәләр буенча укыталар иде». («Державин язмалары», Мәскәү, 1860 ел. 11 бит.)

Казан гимназиясендә спектакльләр куюга бик күп вакыт сарыф ителә. Шәһәрдә бөтен театр булмаганлыктан, Казан халкы бу гимназия тамашаларына бик теләп йөри һәм билет акчасы гимназистларга тотыла. Дөрес, ул вакытта билет сату булмый, кем күпме тели — шул кадәр акча биреп керә. Шулай да гимназистларга ярап куя ул.

Гимназиядә укыган елларында Державин немец телен өйрәнә һәм рәсем ясау, сызым сызу белән мавыга. Гимназиядә үткәрелгән тантаналы бәйрәм көннәрендә «артиллерист» — пиротехник вазифасын үтәү дә күп вакыт аңа йөкләнә.

Гимназиядә тиешле дәрәҗәдә һәм системалы төстә бирелмәгән белемне ул үзлегеннән укып тутырырга омтыла. Бик күп укый торгач, Державинның үзенең дә язасы килә башлый һәм ул, үзе әйткәнчә, шигырьләр сызгаларга тотына. Яшь Державин күңелендә әдәбиятка мәхәббәт туугa, аның таланты ачылып китүгә, ихтимал, Казан



гимназиясендә драма әсәрләренә ихтирам белән карау һәм аларны сәхнәгә кую да билгеле бер дәрәҗәдә этәреш ясагандыр.

1761 елда, Мәскәү университеты кушуы буенча, 18 яшьлек Державин борынгы Болгар дәүләтенең башкаласы булган Шәһри Болгарга (хәзер республикабызның Куйбышев районына керә) барган археологик экспедициягә җитәкчелек итә. Бу экспедиция турындагы «Язмалары»нда ул болай ди: «Гимназия укучыларыннан Гаврил Державинны һәм аның берничә иптәшен алып, 1761 елның июнендә Веревкин Успенское[1] авылына килде. Анда берничә көн торып, туйдырып бетергәннән соң, башкаларны Державин карамагына калдырып, Болгар шәһәренең планын төзеп һәм шәһәр тирәсен казыганда табылган борынгы әйберләрне алып кайтырга боерып, үзе Казанга кайтып китте. Державин Болгарда кара көзгә тикле торды һәм, барысын да җиренә җиткереп үк булмаса да, кушылган эшләрне кулыннан килгәнчә башкарып чыкты. Кайбер корылма хәрабәләренең, ягъни хан сараеның, мунчаның һәм җир асты юллары белән тоташтырылган каланчаның планы төшерелде һәм тышкы күренешләренең рәсеме ясалды... Кабер ташларындагы язулар күчерелеп алынды, бакыр, көмеш һәм алтын акчалар, колак алкалары, йөзекләр, балчыктан ясалган төрле савыт-сабалар табылды һәм шуларның барысы да Казанга алып кайтылып, Веревкинга тапшырылды.

Веревкин аларны И. И. Шуваловка, ә Шувалов академик Е. П. Чемезовка тапшырган»[2].

Бу язмасыннан күренгәнчә, Державин үзе яшәгән крайның тарихын бүтән замандашларына караганда күп мәртәбәләр яхшы белгән һәм аны өйрәнүдә үзеннән дә шактый өлеш керткән.

Державин Казан гимназиясендә 1762 елга кадәр укый.

Яхшы укыганлыгы өчен бүләк йөзеннән Шувалов Державинны әле гимназиядә укыган вакытында ук гвардия полкына рядовой солдат итеп яздыртып куя. Гимназияне тәмамлаганда Державин читтән торып офицер дәрәҗәсен алырга ирешер дип уйлый. Ләкин асылда эш башкачарак килеп чыга. 1762 елда тәхеткә Петр III менеп утыра һәм, ул елларда бара торган сугышны дәвам итү өчен, хезмәт итмәсәләр дә хәрби исәптә торган барлык рядовойларны һәм гвардиячеләрне хезмәткә алырга боерык бирә. Шул боерык нәтиҗәсендә 18 яшьлек Державин гимназияне тәмамламас борын ук 1762 елда Петербургка китеп, Преображенский полкында солдат хезмәтен үти башларга мәҗбүр була.

Державинның бүтән туганнары Казанда кала һәм ул алар белән бик еш язышып, җае чыкканда үзе дә еш кына кайткалап, Казан белән тыгыз элемтәдә тора. Капрал чины биргәч, 1763 елның маеннан 1764 елның маена кадәр булган бер еллык ялының да шактый вакытын ул Казанда үткәрә. Аннары кече энесен дә үзе белән Петербургка алып китеп, хәрби хезмәткә урнаштыра. 1774—1775 елларда Державин шулай ук Казанга берничә тапкыр кайтып китә.

---

[1] Успенское — Шәһри Болгар янындагы авыл.

[2] «Державин язмалары». 14—15 битләр.

Гаврил Романович 1778 елда өйләнә һәм, хатынын әнисе белән таныштыру өчен, тагын Казанга кайтып бер ай торып китә. Шунда ул «Эпистола к Шувалову» («Шуваловка хат») исемле әсәрен тәмамлый. Аның ул әсәренә шул чордагы нашир П. И. Бартенев: «Бу язма фикер хөрлеге белән... яхшы. Анда Державинның байбичәләр вазифасы турындагы фикерләре бик җентекләп һәм кискен төстә әйтелгән», дип бәя бирә. «Хатын белән күрешергә йөргәндәге каршылыклар» («Препятствие к свиданию с супругою») исемле шигырен дә Державин шул кайтуында Мурзиха авылында[1] иҗат итә. Аннары, хатынын әнисе янында калдырып, Державин эш белән Оренбург губернасына китә. Ул аннан Казанга әйләнеп кайтканда инде ноябрь ахырлары җиткән һәм Кама елгасы боз белән капланган була. Кичү эшләмәгәнлектән һәм боз өстеннән йөрергә әле куркыныч булганлыктан, ул тагын Мурзихада берничә көн тоткарланып торырга мәҗбүр була.

Казанга Державин соңгы тапкыр 1784 елда, Олонец шәһәренә барышлый кагылып китә, ләкин ул вакытта аның әнисе вафат булган була инде. Туган-тумачалары булмаса да, шагыйрь Казанны һәм Идел буйларын гомеренең соңгы көннәренә тикле хәтерендә тота һәм сагынып искә ала. Аның ул хисләре «Арфа» исемле шигыреннән дә бик ачык күренә:

**Ни күңелле аның шулай җырлаганы**
**Моңын сөйләп туган җирнең, газиз илнең,**
**Гөлле язларымны кире кайтарганы,**
**Казандагы алтын чорларымны минем!**
**Әй, минем сабый чакларымның бишеге!**
**Яшьлегем, гөнаһсыз көннәремнең иле!**
**Кайчан таңнарың белән мин күрешермен,**
**Кайчан тагын үз кешең итәрсең мине!**
**Кайчан күзләрмен кырдагы көтүләрне,**
**Мәгърур һәм мәһабәт Кама иманнәрен!**
**Иделдә йөзәрмен ачып җилкәннәрне.**
**Һәм кочармын изге кабрең үлгәннәрнең!**
**Җырла, арфа, Казан хакында син миңа!**

Шушы шигыренең Казанга адресланган соңгы «Отечества и дым нам сладок и приятен» дигән юллары бөтен Россиягә танылып, мәкальгә әйләнеп китә. Бераз гына үзгәртеп, Грибоедов аны хәтта «Акыллылык бәласе» исемле комедиясендә дә файдалана.

Үзе читтә яшәгән вакытларында да Державин Казандагы әдәби тормыш белән кызыксынып торган. 1814 елда ул үзләренә чыбык очы тиешле кешедән — Александр Панаевтан:

— Казанда яшәүче һәм шигырьләр язу белән шөгыльләнүче Панаев дигән яшь кешенең кем икәнлеген белмисеңме син? — дип сораган.

Александр Панаев шигырь язучы ул кешенең үз энесе икәнлеген әйткәч:

— Зинһар, әйт әле син аңар: язган әйберләренең барысын да миңа җибәрсен! — дигән.

Аннары, әлеге яшь шагыйрьнең шигырьләре белән танышкач, аңа менә шушы хатны язып җибәрә: «Мәрхәмәтле әфәндем, Владимир Иванович, сезнең 26/X язган хатыгызны һәм җибәргән шигырьләрегезне алдым һәм рәхәтләнеп укып чыктым. Мин сезнең бик әйбәт талантыгызны хуплаудан башка берни дә әйтә алмыйм, әмма дусларча шуны киңәш итәм: ашыкмагыз, сүзләрнең мәгънәсенә бик зур игътибар бирегез. Бу шуның өчен аеруча мөһим, чөнки сез ирекле шигырьләр язасыз.

Бу өлкәдә бездә аз язылган. Әгәр грек һәм латин телләрен белсәгез, борынгылардан үрнәк алыгыз. Әгәр инде аларны яхшы белмисез икән, ул чакта табигатьне һәм кешеләрнең үз-үзләрен ничек тотуларын сурәтләүдә Геснерның немецчә шигырьләре үрнәк булып хезмәт итә алыр. Безнең климат кырыс булса да, анда йөрәк кылларын тибрәтерлек матурлыкны табарга була, ә ансыз барысы да коры һәм буш сүз генә булып калачак...»

---

1 Хәзерге Алексеевск районында.

1815 елда В. И. Панаев Петербургта Державинның үзе белән дә очрашып сөйләшә. Шул чакта Державин аңа, Казанның әдәбият сөючеләре җәмгыятенә тапшырырга кушып, автографы белән үзенең дүрт томлык әсәрләр җыелмасын һәм зур портретын бүләк итеп бирә. Әмма ул бүләкләрне алып кайтучы кибитка юлда көчле яңгырга очрый, китаплар да, Державинның портреты да юешләнә. Шулай да портретка артык зыян тими: Казанның Крюков дигән бер бик оста рәссамы аны яңадан элекке хәленә кайтара. Ә китаплар һәм шагыйрьнең автографы тәмам бозылып, саргаеп беткән була. Шунлыктан әдәбият сөючеләр җәмгыяте исеменнән Панаев Державинга яңадан дүрт том китабын сорап мөрәҗәгать итә. Державин бишенче томы чыгып җиту белән барлык биш томын да җибәрергә вәгъдә итә, әмма вәгъдәсен үти алмыйча кала — үлеп китә.

Державинның икенче хатыны Д. А. Дьякова шагыйрьнең Казанны яратуын яхшы белгән һәм аңа, үзе арфада уйнап, Идел буен хәтерләтә торган җырларны бик еш җырлый торган булган. Шагыйрь хатынының ул җырларын рәхәтләнеп тыңлаган. Д. А. Дьякованың ул арфасы һәм шул арфада уйнаган вакытында билгесез художник тарафыннан эшләнгән бер рәсеме Татарстанның дәүләт музеенда саклана.

Державин вафат булганнан соң (күрәсең, шагыйрьнең васыятен үтәү йөзеннән булса кирәк), ярлы студентларга стипендия итеп бирү өчен, Д. А. Дьякова 1816 елда Казан университетына утыз мең сум акча бүләк итеп бирә һәм шул ук университетның китапханәсенә Державинның бер дәфтәр шигырьләр кульязмасын тапшыра. Ә 1845 елда Дьякова үзе дә вафат була. Шуннан соң аның вәрисы Казан университетына шагыйрьнең язу өстәлен, кәнәфиен һәм язу приборларын тапшыра. Ул әйберләр башта университет китапханәсенең залында, аннары университетның башка кабинетларында саклана, ә XX гасырның утызынчы елларында ТАССР дәүләт музеена алына. Ул әйберләр, шагыйрьнең алтын сәгате белән бергә, XVII гасыр рус культурасының әдәби-тарихи истәлекләре буларак, шул музейда саклана.

1847 елда Казанда Державинга һәйкәл куела. Башта ул Казан университеты алдында тора, аннары, 1871 елда, Театр мәйданындагы бакчага (хәзерге Ленин бакчасы) күчерелә. Ләкин хәзер ул һәйкәл юк инде — сакланмаган.

**Вл. КЛИМЕНТОВСКИЙ**

Каюм Мостакаев

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ҺӘМ ФАТИХ ӘМИРХАН БЕЛӘН КҮРЕШҮ

...Үзләренең табигатьләре, кешеләрне беренче күрү белән үк таный белүләре ягыннан, миңа калса, Фатих Әмирхан белән Габдулла Тукай икесе бер төслерәк иде кебек... Шуңлыктан булса кирәк, Фатих белән очрашулар вакытында яшьләрне кызыксындырган теге яки бу мәсьәләләр турында фикер алышулар ансат башланып китә һәм иптәшләрчә эчкерсез дәвам итә иде.

Ул көннәрдә алдынгы татар интеллигенциясе алдында ике мөһим мәсьәлә тора иде. Шуның берсе: прогрессив фикерле вакытлы матбугатны халык арасында киңрәк тарату, ерак авылларга, бистәләргә, шәһәрләргә җиткерү. Шул матбугат ярдәмендә халыкның аң-белемен күтәрү, алар арасында мәгърифәт нурлары чәчү һәм аны, заманның политик мәсьәләләре белән таныштыра барып, революцион рухта тәрбияләү иде.

Икенче мөһим мәсьәлә исә ул замандагы яшьләрне, бигрәк тә мәдрәсәләрне ташлап чыккан татар шәкертләрен, русча укыту, аларга дөрес тәрбия, дөрес юнәлеш бирергә тырышудан гыйбарәт булды.

Ул елларда Казан, Уфа, Оренбург һәм башка шәһәрләрдә укучы күп кенә шәкертләр, уку-укыту программалары белән килешмичә, мәдрәсәләрне ташлап чыктылар. Аларның кайберләре — яшерлек акчалары булганнары яисә хезмәт таба алганнары — шәһәрдә калып, төрле юллар белән (билеле, зур газаплар, мохтаҗлыклар белән) русча укырга керештеләр, белем алуларын дәвам иттерделәр. Кайберләре исә, беркадәр белемнәре булганнары, авылларга укытучы булып киттеләр. Болар, кыш көне укытып, бераз акча туплап, җәй көне шәһәргә килеп, русча уку теләге белән яралдылар. Шәкертләрнең бер өлеше, күпчелеге дип әйтерлек, материаль мөмкинлекләре булмаганлыктан, шәһәрдә калсалар да, русча укый алмыйлар, җитәрлек белемнәре булмаганга, укытучылык итә алмыйлар иде. Шулай ук алар шәһәрдә дә хезмәт таба алмыйлар. Шәкертләрнең бу өлеше ярга чыгарылып ташланган балыклар хәлендә. Мәдрәсәне ташлап чыкканлыктан, алар әти-әниләре янына да кайта алмыйлар. Чөнки әти-әниләре аларны мәдрәсәне ташлап чыгулары өчен каргыйлар, орышалар иде.

Менә бу шәкертләр, төрле киңәшләр сорап, шуның өстенә бераз материаль ярдәм дә өмет итеп, «Әльислах» газетасы редакциясенә, Ф. Әмирхан, Г. Тукай янына агылалар, аларны үзләренең киңәшчеләре, рухи ярдәмчеләре, юл күрсәтүчеләре итеп саныйлар иде.

Фатих үзе мәдрәсәне ташлап чыккан шәкертләрнең берсе һәм аларның җитәкчесе иде. Шуңа күрә ул аларның хәлен, тормышларын, күңел кичерешләрен башкаларга караганда яхшырак аңлый, яхшырак белә һәм аларга кулыннан килгән ярдәмне күрсәтергә тырыша иде.

Фатих сүзгә бик оста иде. Ул нәрсә турында гына сөйләмәсен, аны матур итеп, кызыклы, җанлы итеп, тыңлаучыларның күңелләрен җәлеп итәрлек итеп сөйли белә иде. Рухы белән көчле юморист иде ул.

Мәдрәсәне ташлап чыккан шәкертләрнең русча укырга теләүләре турында сүз чыккач, ул үз башыннан үткән бер вакыйганы сөйләп бирде.

Фатих, мәдрәсәне ташлап чыкканнан соң, русча укырга керешә. Моның өчен аңа Яңа бистәдән (әтисенең йорты шунда иде) шәһәрнең югары өлешенә, рус ягына барырга кирәк. Аның юлы Печән базары, Болак күпере аша үтә. Печән базары кадимчеләре, динчеләре аның русча укырга йөргәнлеген белеп, каршысына чыгып, туктатып сүгәләр, хурлыйлар, мыскыллыйлар, артыннан төрле әшәке сүзләр әйтеп, кычкырып калалар:

— Чукынган, урысларга сатылган мөртәт! — диләр.— Ильминский шәкерте! Ефим попка уллыкка ялланган бәндә! — диләр.

Фатих, бер нәрсәгә карамастан, барлык хурлыкларга, мыскыллауларга чыдап, укырга йөрүен дәвам итә. Ахырда кадимчеләр, кара эчле көшеләр, Фатихны укырга йөрүеннән туктата алмагач, ярдәмгә фахишәләрне ялыйлар. Ул заманда Болак күперләре янында фахишәләр төркем-төркем булып басып торалар, узган-барганнарны аулыйлар иде. Кадимчеләр тарафыннан махсус ялланган шул фахишәләр, Фатихның укырга барганын күрү белән, аның өстенә ябырылалар, төрле әшәке сүзләр әйтеп, аны хурларга, мыскылларга керешәләр. Динчеләрнең барлык хурлауларын, мыскыллауларын батырларча күтәрә алган Фатих боларга түзә алмый, юлын үзгәртергә, һәр көнне башка юлдан йөрергә мәҗбүр була.

«Москва» номерына урнашканнан соң, Тукайның күңеле күтәрелеп, кәефе яхшырыбрак киткәндәй булды. Ул иртәнге чәйне эчеп утырганда ук:

— Әйдә, Каюм, бүген көнне «Әльислах» редакциясенә кереп чыгудан башлап җибәрик,— диде.

Киттек. «Әльислах» хәзерге Тукай урамындагы гади генә бер татар йортына урнашкан иде. Без барып кергәндә редакциядә бүлмә уртасына куелган зур өстәлдән һәм берничә урындыктан башка бер нәрсә дә һәм беркем дә юк иде. Бу хәлне күреп гаҗәпләнүемә каршы Тукай:

— «Әльислах»ның да хәле шушы бөлгән бай йортыныкыннан әллә ни әйбәт түгел булса кирәк,— дип куйды. Аннары: — Әйдәле, алар Фатих Әмирханнарда түгелме икән,— дип, мине үзе белән ияртеп алып китте. Кабан күле аша салынган басманы чыгып бераз баргач, тукталды да, каршыбыздагы бер өйне күрсәтеп:

— Фатих Әмирхан яши торган дача менә шушы була инде,— диде. Һәм мине шул өйгә алып керде.

«Әльислах» редакциясенең бөтен составы (Фатих Әмирхан, Кәбир Бәкер, Якуб Байбурин, Вафа Бәхтияров) шушында җыелган һәм, зур өстәл тирәсенә тезелешеп утырып, шау-гөр килеп чәй эчәләр иде.

Тукай мине:

— Мөгаллим Каюм Мостакаев була бу, Киев ягында укыта,— дип тәкъдим иткәч, барысы да кул биреп күрешеп чыктылар. Ф. Әмирхан пенснесен төзәтеп куйды да, мөлаем елмаеп:

— Бәрәкалла, хуш килгәнсез! — дип, күптәнге танышы белән очрашкандай иплән кенә сөйләшеп китте.— Сез дә аттестат авыруы белән мөфтәлә икәнсез, хәерле булсын, ул бик әйбәт авыру, аннан куркырга ярамый.— Аннары Тукайга карады да: — Нихәл, Тукай, котлыйм сине, номерга күчеп яши башлау теләгеңә ирешкәнсең икән, бик яхшы булган! — диде.— Иптәшеңне Казан белән таныштыруда кимчелек күрсәтмәсәң кирәк. Беренче нәүбәттә авыл хуҗалыгы промышленносте күргәзмәсенә, икенче нәүбәттә ташаяк ярминкәсенә һәм дә Казанның бай музеена барып чыгарга тәкъдим итәр идем.

Мин шаяртып:

— Нигә «Әльислах» редакциясенә барып чыгарга тәкъдим итмисез! — дигәч, Ф. Әмирхан, гадәтенчә, самими итеп елмаеп куйды да:

— Ул редакциянең хезмәткәрләре менә шушында утыручылар инде. Күрәсез, алар дачада ял итәләр. Хезмәткәрләргә ял иткәч, редакциянең ял итүе үзеннән-үзе мәгълүм инде,— диде.

Мин:

— Ялгыз кыска вакытлы ял гына булса ярар иде,— дигәч:

— Бу сорауга җавап алырга газета укучылары да мохтаҗдыр,— дип куйды.

Мин Ф. Әмирханнан «Әльислах»ның тиражы күпме икәнлеген сорадым.

— Ярты елга язылганнарын кертеп исәпләгәндә дә биш йөз данәгә тулар-тулмас кына дисәк, ялгыш булмас,— диде ул.

— Нигә соң мөгаллимнәрне абунә[1] җыярга кушмыйсыз!

Ф. Әмирхан тирән итеп көрсенеп куйды да:

— Бөтен фаҗига дә әнә шунда шул! — диде.— Ул бичаралар подписка җыю түгел, үзләренә газета алдырып укудан да мәхрүм ителгәннәр бит. Хәзер, моның шулай икәнлеген сез, шәять, газеталардан укып та беләсез кирәк.

Ул заманда байлар һәм муллалар, газета укыган укытучылар һәм шәкертләр өстеннән доносләр язып, аларны эшләреннән, укыта торган урыннарыннан кудырталар иде. Ф. Әмирханның «бөтен фаҗига дә шунда шул», дип әйтүе әнә шул хәлләргә ишарә итүе иде.

Ф. Әмирханның күңелен күтәреп җибәрергә теләп булса кирәк, Тукай елмаеп куйды да, куен кесәсеннән алып, аңа әле шул көннәрдә генә язган шигырен («Эштән чыгарылган татар кызына» исемле шигыре иде ул) сузды. Ф. Әмирхан, бөтен дикъкатен биреп, шигырьне укый башлады. Тукай исә, хәлфәсе ни әйтер икән дип көтеп торган шәкерт сыман, Ф. Әмирханга карап көтеп торды.

Шигырьне укып чыккач, Ф. Әмирхан Тукайга карап елмайды да:

— Гаять халыкчан булып чыккан бу! — дип, аның кулын кысты һәм: — Минем уйлавымча, синең бу шигырең шушы темага язылачак әйберләреңнең беренчесе генә бит әле, мин моның иптәшләре дә күбәюен телим! — дип өстәде.

Ф. Әмирхан бу сүзләрне әйткәндә Тукайның куанычы йөзенә чыккан иде һәм ул бу хисен ниндидә булса көлке сүз әйтеп Ф. Әмирханга да сиздерергә теләп булса кирәк:

— Мин дә үзеңне мактап алыйм әле алай булгач: «Татар кызы» исемле китабыңны зур дәрт һәм тирән ихтирам белән укып чыктым. Үзең әйтмешли, бу китабың өр-яңа бер стильдә язылган. Шуның өчен кулыңны кысып котларга рөхсәт ит! — диде.

— Дөрес,— диде Ф. Әмирхан, җитди итеп,— мин аны яңа стиль белән язган идем. Ләкин шул яңа стильдә язылган әйбергә әфкаре гамма[2] ни әйтер бит әле!

— Байгуралар, муллалар, Печән базары әһелләренең ни әйтәселәре билгеле инде,— диде Тукай.— Хәзер алар белән исәпләшеп торуның кирәге юк. Ә гади халыкка килсәк, алар, әлбәттә, бу китапны хуплап каршы алырлар. Тик кайберләренә матбугат аркылы нигә ул стильдә язуыңның сәбәпләрен аңлатып бирергә кирәк булыр.

Тукай сүзне тагын «Әльислах»ны яшәтү мәсьәләсенә борып җибәргәч, Фатих яңа бер көрсенеп куйды да:

— Кызганычка каршы, татар әйтмешли, вакытлы рәвештә генә булса да, язмышка баш иярга, ягъни «Әльислах»ның чыгуын туктатып торырга туры киләчәк, ахры,— диде.

Шуның белән ул көнге күрешү мәҗлесебез тәмам булды, без саубуллашып кайтып киттек. Кайтышлый Тукай үзенә генә хас булганча эчкерсез итеп Ф. Әмирхан белән беренче тапкыр ничек танышканнарын сөйләде.

— Аның белән мине Борһан Шәрәф таныштырды,— диде ул.— Мин Казанга килеп төшкәч, янымa килеп күрешкәч тә: «Синең Казан яшьләре белән танышасың килә торгандыр. Теләгең булса, әйдә, мин сине шул яшьләрнең иң күренеклесе белән таныштырам», дип, Фатих Әмирхан янына алып барды. Фатих ул чагында Яңа бистәдә әтисе йортында торадыр иде. Фатих безне ачык йөз, көлке сүзләр белән каршы алды. Аннары мин эшләгән «Әлгасрелҗәдит», «Фикер» вә «Уклар» газета-журналлары турында сораштыра башлаган иде, мин сүзне озынга сузмау нияте белән:

— Алар, Фатих иптәш, мәрхүм булдылар инде,— дип җавап бирдем

---

[1] Абунә — подписка.

[2] Халык нинди фикер әйтер.

Фатих бер көрсенеп алды да:

— Димәк, Уральск шәһәре ике газит һәм бер журналдан мәхрүм калган икән,— дип куйды.

Үз нәүбәтемдә мин дә Фатихтан «Әльислах» турында сораштырдым. Ул теләр-теләмәс кенә итеп:

— Хәзергә мәгънәви[1] яклары канәгатьләнерлек әле, ә материаль ягына килсәк, аңсы инде безнең, шул җөмләдән сезнең дә, халыкны ни дәрәҗәдә мавыктырырлык тырышып эшләвебезгә бәйләнгән,— диде.

Шунда мин аның читләтеп кенә әйтелгән сүзләреннән бердәнбер яшьләр газетасы булган «Әльислах»ның да гомере чикләнгән икәнлеген аңлап, эчемнән кайгырып куйдым.

Тукай миңа шушыларны сөйләп биргәч, мин аннан Фатих Әмирханның авыруы хакында[2] сорадым. Ул тирән сулап куйды да:

— Хәзергә бу бик четерекле мәсьәлә булып тора. Моңарчы врачлар да, профессорлар да ярдәм күрсәтә алмадылар, моннан соң ни буласы да билгеле түгел әле,— диде...

Тукай таныштырганнан соң, җае туры килгән саен, мин Фатих Әмирхан янына еш кына барып йөри торган булдым. Кайчан гына килеп керсәм дә, ул, авыру булуына да карамастан, мине һәрвакыттагыча якты йөз, ачык чырай, тәмле сүз белән каршы ала торган иде. Бер баруымда шулай үзара сөйләшеп утырганда мин аннан аяклары төзәлергә өмет бармы икәнлеген сорадым. Ул бер дә исе китмәгән кыяфәт белән:

— Шушы килеш торып калыр, ахры, минем аяклар. Чөнки хәзерге докторларның, галимнәрнең киңәш вә дәвалары карчык-корчыкларның тәҗрибәләреннән әллә ни ерак китә алмаганлыгы аңлашылды инде,— дип кенә җавап бирде дә ул хакта бүтән сүз кузгатмады.

Фатих Әмирхан чын мәгънәсендә сүзгә тапкыр һәм бик акыллы кеше булып, кемнең кем икәнлеген бер күрүдә төшенеп ала торган әдип иде. Аның янына Казан яшьләре генә түгел, бәлки Казанга килеп-китеп йөри торган бик күп мөгаллим һәм мөгаллимәләр дә еш киләләр иде. Ул аларның барысы белән дә сөйләшергә вакыт таба һәм һәрвакыт мөһим мәсьәләләр хакында гына сүз алып барыр иде. Кешеләргә дә акыллы киңәшләр бирә, шул ук вакытта үзенең әдәби әсәрләре өчен кирәк булган материалларны бик оста итеп, такт белән генә сораштырып алып кала торган иде. «Әльислах» газетасы чыгудан тукталып, аяклары төзәлүгә өмете өзелгәч тә, Фатих элеккечә дәртле оптимист һәм бик эшчән булып калды. Әдәби әсәрләр язуын дәвам итү белән беррәттән, өлгергәнлек аттестаты алу өчен, гимназия программасы буенча русча укырга тотынды. Ләкин имтихан вакытында, Тукай әйтмешли, бик пустяк кына фәннәрдән (латинчадан һәм физикадан) имтихан тапшыра алмагач та төшенкелеккә бирелмәде, яңадан имтиханга (бу юлы университетка керү өчен) әзерләнә башлады.

Ул елларда Казанда «Бәянелхак» һәм «Йолдыз» газеталары чыгып килсә дә, аларның беренчесе игълаклар биреп, кара фикер таратып тора, икенчесе мулла-мөнтәгайларга һәм Печән базары байгуралары ярарга тырышып эш итә иде. Шунлыктан халык Казанда адәм рәтлерәк бер газета чыгара башлауны бик кирәксенә иде. Нәтиҗәдә үзәра бик күп тарткалашулардан һәм сатулашулардан соң «Кояш» исемле газета чыгарыла башлады. Җаваплы редакторы итеп, заманның алдынгы фикерле кешеләреннән саналган Зәкария Садретдиновны, җаваплы секретаре итеп Фатих Әмирханны куйдылар. Бертуган Кәримовлар сәүдә компаниясе акчасына чыгарыла торган бу газетада Тукай мәрхүм гомеренең соңгы көннәренә тикле үзенең мәкаләләрен бастырып килде. Суллар рәтендә саналмаса да, «Кояш» газетасы урта күп либерал-демократ газета булып яшәде. «Кояш»та секретарьлык итү әдәби эшләренә комачауласа да, Фатих ул газетаның соңгы көннәренә кадәр шунда җитәкчелек итте. «Хәят» романының язылып бетми калуына, минемчә, Фатихның әнә шул газетада артык тырышып эшләве комачаулады. Аннары аңа Тукайның үлеп китүе дә бик нык

---

[1] Мораль ягы дигән мәгънәдә.

[2] Ф. Әмирханның ике аягына да паралич суккан иде.

тәэсир иткән иде. Тукайның Фатихка дустанә мөнәсәбәте һәм ышанычы никадәр көчле булса, Фатихның Тукайны якын итүе дә шулай ук бик көчле иде.

Бөек Тукайның иң якын дусты, фикердәше, киңәшчесе булган, татар халкының азатлыгы өчен гомер буе көрәшкән, аны алдынгы культуралы халыкларның берсе итеп күрергә теләгән классик әдипнең Бөек Октябрь революциясен чын күңелдән кабул итүе бик табигый иде һәм аны кабул итмичә калуы мөмкин түгел иде. Кайбер тәнкыйтьчеләр аның әдәби-иҗтимагый эшчәнлегенең бу ягын күрмәделәр, күрергә теләмәделәр. Хәзер татар совет әдәбияты тарихчыларының бу ялгыш карашны юкка чыгарулары, аның иҗатына һәм политик позициясенә дөрес бәя бирүләре, аны интернационалист язучы, ялкынлы публицист итеп санаулары барыбызның да күңелен шатландыра.

Фатих егерме елга якын гомерен аягүрә басып тору, үзе теләгәнчә йөрү бәхетеннән мәхрүм булып яшәде. Шуңа карамастан, ул тормыштан аерылмады, алдынгы татар иҗтимагый хәрәкәтенең һәрвакыт үзәгендә торды, аны әйдәп барды, үзенең күп санлы әдәби һәм публицистик әсәрләре белән татар халкын прогрессив рухта тәрбияләде.

1925 елның ахырында булса кирәк, Фатих каты авырып китте. Хәле начарланганнан начарланды. Без, аның иптәшләре, дуслары, янына ешрак баргалый башладык.

Фатих бик түземле кеше иде. Тормышында очраган күңелсезлекләрне, авырлыкларны, ах-ух итмичә, зарланмыйча, ыңгырашмыйча, батырларча күтәрә белә иде. Егерме елга якын каты авыруы, ике аяксыз да калуы турында югарыда әйтеп узган идем инде. Шул еллар эчендә мин аның авыруыннан зарлануын, уфтануын беркайчан да ишетмәдем. Ул үзен сәламәт кеше кебек итеп тота һәм без дә аның авыру икәнен, аякларын хәрәкәтләндерә алмый, йөри алмый икәнен онытып җибәрә идек.

Соңгы авыруын да ул зур түземлелек белән кичерде. Шулай да ул үзенең хәлен белә иде булса кирәк. Без, моны күреп, хәлен аңлап, күңелен күтәрергә тырыша идек.

Каты авыру булуына карамастан, безне ул елмаеп каршы ала иде.

Соңгы күрешүләремнең берсендә аның янында озак утырдым. Өзек-өзек итеп булса да, күп нәрсәләр турында сөйләштек, күп нәрсәләрне искә алдык. Аның кайбер сүзләре әле дә күңелемдә саклана.

— Каюм,— диде ул миңа,— заманыбызның кая таба барганын беләсеңме син!

Мин, аның нәрсә әйтергә теләвен аңлап бетермичә, бераз аптырабрак карап тордым:

— Кая таба бара соң!

— Бик матур елларга таба,— диде ул һәм озын керфекле, акыллы күзләре белән миңа карап, сөйләвен дәвам итте: — Табигатьнең шундый бер хәлен күргәнең бармы синең! Бик каты күк күкрәп, яшен яшьнәп, давыллы яңгыр узып киткәннән соң дөнья кинәт тынып кала, кояш чыга, барлык кош-корт уяна, агачлар, үләннәр яшәреп, яңарып китә. Кешеләр җиңнәрен сызганып җибәреп, үзләренең эшләренә тотыналар, бирелеп, яратып эшлиләр. Тел белән әйтеп, аңлатып бирүе мөмкин булмаган бәхетле, шатлыклы сәгатьләр була апар... Безнең тормышыбызда да шундый давыллы, яшенле, өермәле еллар булды... Авыр еллар, сынаулы еллар, каты көрәш еллары... Аннары, нәкъ табигатьтәге кебек, тынлык урнашты, кояш чыкты, кешеләр моңарчы булмаган зур иҗади эшкә керештеләр. Бирелеп, яратып, сөеп эшлиләр... Мин барысын да күреп торам. Безгә дә, халык белән бергә эшләргә, кулыбыздан килгәнчә тырышып эшләргә кирәк... Әгәр терелсәм,— диде ул һәм нигәдер туктап калды.

Мин, аның сөйләвен дәвам иттерергә теләп, сорау бирдем:

— Терелсәң, нишләр идең!

— Терелсәмме!.. Терелсәм, иң әүвәл бик тулы рәвештә үземнең тәрҗемәи хәлемне язар идем. Минемчә, бу эш минем хакта ялгыш уйлаучыларга, минем турыда гайбәт сатучыларга урын калдырмас иде. Аннары «Хәят»ка тотынып идем. Аны тәмамлар идем. Күп главалары язылган инде аның. Газеталарга да активрак катнашыр идем. Эшләргә кирәк безгә, Каюм, бик тырышып эшләргә кирәк... Халык белән бергә барырга, аның үзәгендә булырга кирәк...

Бу аның минем белән соңгы тапкыр сөйләшүе иде. Шуңа булса кирәк, аның бу сүзләре күңелемә нык уанашып калды.

# МУСА ИСЕМЕ АЛАР ТЕЛЕНДӘ

Ленинград фронтына барышлый, Муса Җәлил юлдан болай дип яза: «...үлгәннән соң, халык күңелендә, халык аңында яши торган гомер бар. Әгәр дә мин исән чакта нинди дә булса әһәмиятле, үлми торган эш эшләп калдыра алсам, моның белән мин икенче кабат яшәргә — үлгәннән соң яшәргә хокук алам».

Мусаның үзе үлгәннән соң яшәве — аның күп санлы шигъри җыентыкларында, шагыйрьләрнең, прозаикларның, драматургларның, композиторлар һәм художникларның аңа багышлап иҗат иткән әсәрләрендә. Аның үлемсезлеге — Казанда һәм ул туган Мостафа авылында аңа куелган мәһабәт һәйкәлләрдә, Татарстанда төзелә торган нефтьчеләр һәм химиклар шәһәренең, күп кенә колхозларның, авыл һәм шәһәр урамнарының һәм, ниһаять, Ленинград янындагы Кириши шәһәрендә яңа салынган икенче номерлы урта мәктәпнең шагыйрь исеме белән аталуында.

Муса Җәлилнең үлемсез исеме совет кешеләренең йөрәгенә мәңгелеккә кереп урнашты. Аның иҗаты, туган илгә булган мәхәббәте һәм дошманнарга карата нәфрәте, ихтыяр көче һәм мораль принципларының югарылыгы сугышчы-шагыйрьне безгә чиксез якын һәм кадерле кеше итте. «Дөньяда шундый итеп яшәргә кирәк, үлгәннән соң да үлмәслек булсын — яшәүнең бөтен максаты шунда түгелмени!» — дип язды Муса Җәлил үзенең тормыш иптәшенә 1942 елның гыйнварында җибәргән хатында.

Ленинград җире шагыйрьне зур ихтирам белән искә ала. Монда, Волхов фронтында, Муса Җәлил Октябрь революциясенең бишеге булган Ленин каласын фашист илбасарлардан саклаучы куркусыз көрәшчеләрнең алгы сафында атлады. Герой-шагыйрьнең исеме Ленинград өлкәсендәге Кириши шәһәрендә яшәүчеләргә аеруча кадерле. Ил өстенә аяусыз үлем ябырылып килгән дәһшәтле көннәрдә Муса Җәлилнең сугышчан юлы шушы шәһәр тирәсеннән узган.

Тагын шунысы характерлы: сугыш елларында бөтенләйгә җимерелеп, җир белән тигезләнгән Кириши шәһәре урынында алтмышынчы елларда нефтьчеләр һәм химиклар каласы үсеп чыкты, нефть эшкәртү заводы төзелде. Ә бу заводка нефть Муса Җәлилнең җуелмас эзләре калган Татарстаннан китерелә. Кириши нефть эшкәртү заводы КПССның XXIII съездын каршылаган көннәрдә сафка басты һәм үзенең беренче продукциясен бирде. Нефть һәм химия индустриясе гиганты белән беррәттән яшьлек һәм бәхет, тынгысызлар һәм романтиклар шәһәре — Зур Кириши барлыкка килде. 1962 елда бу төзелешләр ВЛКСМ Үзәк Комитеты тарафыннан комсомол-яшьләрнең удар төзелеше дип игълан ителде. Якты киләчәк өчен гомерен биргән шагыйрь Кириши яшьләренә бигрәк тә якын.

Яңадан үсеп чыккан Кириши шәһәре, яшьләр кулы белән төзелгән нефть эшкәртү заводы, нефть һәм химия промышленносте өчен кирәкле күп кенә башка корылмалар — болар барысы да татар халкының данлыклы улы Муса Җәлилгә һәм аның иҗат батырлыгына мәңгелек һәйкәл. Фашист палачлары тарафыннан җәзалап үтерелгән герой-шагыйрьнең исеме Кирišида яшәүче һәр кешенең күңелендә. Зурлар да, үсмер яшьтәгеләр дә аны һәр вакыт олылап искә алалар.

КПСС һәм ВЛКСМ райкомнары, профсоюз һәм җәмәгать оешмалары, шулай ук «Кириши факелы» газетасы халыкны, бигрәк тә яшьләрне, пионерларны һәм кече яшьтәге мәктәп балаларын Муса Җәлилнең тиңсез батырлыгы мисалында тәрбияләү буенча зур эш алып баралар.

Районда чыга торган «Кириши факелы» газетасы 1966 елның 26 мартында «Шәһәребез урамнарына нинди исемнәр бирергә!» рубрикасы белән «Тагын бер тапкыр традицияләр турында» дигән хәбәр бастырды. Ул хәбәрдә машинист А. Никитин, яңа төзелгән шәһәребез урамнарына исем биргәндә, Бөек Ватан сугышы елларында Совет Ватаны өчен көрәштә һәлак булганнарны онытмаска кирәк, дигән иптәшләрнең фикерен яклап чыкты. Бу фикергә иптәш Л. Водолазов та кушылды һәм уп киләчәктә төзелгән яңа урамнарның берсенә Муса Җәлил исемен бирергә тәкъдим итте. Күп тә үтмәс, яңа барлыкка килгән кварталлар арасында Муса Җәлил исеме белән аталган урамны да күрәчәкбез.

Халкыбызның суынмас мәхәббәтен һәм ихтирамын казанган чын кеше һәм шагыйрь, сугышчы һәм патриот буларак, Муса Җәлилне ярату Коммунистлар партиясенең һәм совет халкының революцион һәм сугышчан традицияләрен дәвам итүче яшь буында аеруча көчле. Шагыйрьнең тууына 60 ел тулу уңае белән, 1966 елның 15 февралендә хезмәт ияләре депутатларының Кириши шәһәр комитеты бирелгә 2 номерлы урта мәктәпкә Советлар Союзы Герое Муса Җәлил исемен бирү турында карар кабул итте. Мәктәпкә бу исемне бирү тантаналы шартларда уздырылды. Мәктәп залында быргылар тавышы яңгырады, укучылар рәт-рәт булып тигез сафларга тезелделәр. Менә 2 номерлы Кириши урта мәктәбенә Муса Җәлил исеме бирелүгә багышланган тантаналы линейка башланды. Дружина советы председателе Лариса Григоренко линейканы башларга әзер булу турында рапорт биргәч, яңадан барабаннар һәм быргылар телгә килде, дружина байрагы чыгарылды. Тантаналы линейканы хезмәт ияләре депутатларының Кириши шәһәр комитеты председателе Е. Д. Сурин ачты. Ул мәктәпкә көрәшче һәм шагыйрь Муса Җәлил исеме бирелү турындагы карарны укыды. Аннан соң VIII класс укучысы Лена Масофалова шагыйрьнең биографиясен сөйләде. Муса Җәлилнең Наташа Пунзина укыган «Катильгә» шигырен мәктәпләшләре тыннарын да алмыйча тыңладылар. Шагыйрьнең тагын берничә шигыре укылганнан соң, сүз мәктәпнең уку-укыту бүлеге мөдире Н. С. Фетисовага бирелде. Ул Муса Җәлилнең данлы тормыш юлына һәм үлемсез иҗатына тукталды. Мәктәп залы буйлап укучыларның ант сүзләре яңгырап үтте:

— Коммунистларга алмашка Муса Җәлил шикелле лаеклы булып үсү өчен аның кебек укырга һәм яшәргә!

Шагыйрьнең: «Үлгәннән соң да үлмәслек булып» яшәргә дигән сүзләре һәрбер укучының тормыш символы булып әверелде. Тыгыз сафларда басып торган һәр укучы Мусаның да үз тавышын ишеткәндәй булды:

Туфрак күмәр тәнне, күмә алмас
Ялкынлы җыр тулы күңелне.
«Үлем» диеп әйтеп буламы соң
Җиңеп үлгән мондый үлемне!

Аңа җавап булып, укучыларның көчле җыр авазы яңгырады:

Һәм без яңадан яшь,
Батырлыкка әзер!
Теләсә нинди эшкә
Җитә көчебез.

Барабан һәм быргылар тавышы астында дружина байрагын озаткач, укучылар, дулкынланып, үзләренең классларына таралдылар. Һәр пионер отряды шагыйрьнең тормышына һәм иҗатына бәйләнешле документларны туплап, Җәлил почмагы булдырырга карар итте. 1967 елның 15 февралендә исә мәктәптә Муса Җәлил музее ачылды. Бу вакыйгага багышланып уздырылган тантаналы линейкада мәктәп директоры Б. Н. Лешкет Муса Җәлилнең батырлыгын тагын бер кат укучыларның исләренә төшерде. Директордан соң сүз кайчандыр шагыйрь яшәгән урыннарда булган укучыларга

бирелде. Галя Смирнова Татарстанда булуы, шагыйрьнең үзен күргән кешеләр белән очрашуы, Кирнши һәм Казан пионерларының дуслыгы турында иптәшләре кызыксынып тыңларлык итеп сөйләде. Линейкада мәктәп коллективының Татарстан язучылар союзына җибәргән телеграммасы укылды. ВЛКСМ комитеты һәм пионер дружинасы советы карары нигезендә ал лентаны кисү һәм Муса Җәлил музеен ачу Зина Карасева белән Таня Богдановага тапшырылды.

Укучылар музейга Җәлилнең һәм аның туганнарының, дусларының фото-рәсемнәрен, җыентыкларын һәм шагыйрь турында язылган китапларны түпладылар. Музейдагы стендларның берсенә Муса Җәлилнең соңгы җыентыгының — фашистлар тоткынлыгында иҗат ителгән «Моабит дәфтәрләре»нең фото-копиясе куелды. Музей яңа материаллар һәм экспонатлар хисабына көннән-көн тулылана бара.

Бу мәктәп Муса Җәлилнең туган көнен һәр ел саен зур бәйрәм итеп билгеләп үтә. Ул көнне барлык классларда шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы турында әңгәмәләр уздырыла, мәктәп музеенда экскурсияләр үткәрелә. 1969 елда, Муса Җәлил туган көндә, мәктәп пионер дружинасы советы иң яхшы пионер отряды исемен яулап алу өчен барган ярышка йомгак ясады. Ярышта җиңеп чыгучы отряд җәй көне Казанга — Муса Җәлил озак еллар буена яшәгән һәм иҗат иткән шәһәргә бару хокукына лаек булачак иде. Бу хокукны VI А классы яулап алды.

Моннан тыш, 2 номерлы мәктәптә беренче класска укырга керүчеләрне һәр ел саен җәлилчеләр сафына кабул итү уздырыла. Менә аларның ант сүзләре:

«Барыгыз да тыңлагыз! Бу тантаналы көндә, байракларны югары тотып, без, Муса Җәлил, сиңа ант итәбез!

Без — җәлилчеләр!
Тырышып укырбыз,
Кирәк булса әгәр
Туган ил өчен —
Кулларыбызга
Корал алырбыз
Дәвам итәргә
Әтиләр эшен.
Ант итәбез, ант итәбез, ант итәбез»!

1969 елның февраль аенда мәктәптә Муса Җәлилгә багышланып язылган шигырьләргә конкурс игълан ителде. Уңышлы дип саналган шигырьләр линейкада укылды. Конкурста дүртенче класс укучысы Надя Миловидова җиңеп чыкты. Ул язган шигырь «Җәлилгә» дип атала:

Юк, дошман сине үтерә алмады,
Кара син безнең бердәм сафларга.
Безнең бу мәктәп — синең мәктәбең,
Йөрәгебездә җырың саклана.
Без — җәлилчеләр, улларың синең,
Ил-ана безне кадерли-сөя.
Һәркайсыбызның барыр юлына
Чулпан йолдызы нурларын сибә.

Муса Җәлилнең якты истәлеген мәңгеләштерүдә район газетасының авторлар коллективы зур игътибар бирә. 1966—1969 еллар эчендә газета битләрендә шагыйрьнең героик тормышына һәм үлемсез батырлыгына багышланган бик күп мәкаләләр, хәбәрләр һәм башка материаллар басылды. 1969 елның ноябрендә газета ВКП(б) сафларына керер өчен карт коммунист А. С. Дәүләтшинның моннан 37 ел элек Муса Җәлилгә биргән рекомендациясен басып чыгарды. Бу документ Уфа шәһәрендә табылган. 1967 елның февралендә газета Киришидагы 2 номерлы урта мәктәптә Муса Җәлил музее ачылу хөрмәтенә уздырылган тантаналы митинг турында хәбәр итте. Газетаның шул ук санында шагыйрьнең «Җырларым» һәм «Батырлык турында» дигән шигырьләре урнаштырылган иде. Аннан соң ике ай чамасы үтүгә, В. Береговая «Кириши факелы»нда Муса Җәлилнең 1966 елда Мәскәүдә, «Матур әдәбият» нәшриятында чыккан җыен-

тыгына карата язган рецензиясен бастырды. Рецензия Муса Җәлилнең фашистлар төрмәсендә язган васыятеннән алынган сүзләр белән башланып китә: «...Бәлки аны үлем җәзасына хөкем итәрләр. Ул үләр. Ә аның әсирлектә һәм төрмәдә язган 115 шигыре бар. Ул шулар өчен кайгыра. Әгәр бу китап кулыңа төшсә, шигырьләрне яхшылап, дикъкать белән акка күчер, сакла һәм сугыштан соң, Казанга хәбәр итеп, үлгән татар халык шагыйренең шигырьләре итеп дөньяга чыгар. Минем васыятем шул!

Муса Җәлил, 1943 ел, декабрь».

Аннан соң автор шагыйрьнең шигырьләренә анализ ясый. Рецензиянең йомгаклау өлешендә В. Береговая Муса Җәлил шигырьләренең һәрбер юлы Ватанны, халыкны, азатлыкны сөю хисе белән сугарылуы, яшь буынны якты киләчәк өчен көрәшкә өндәве турында басым ясап әйтә.

Кырны тутырып алтын бодай үссен,
Ауган йортлар торып бассыннар.
Җиңгән илнең хезмәт тире белән
Кырлар көлеп чәчәк атсыннар!

«Муса Җәлил шигырьләрен күз белән түгел, йөрәк белән укыйсың».— Рецензия әнә шундый сүзләр белән тәмамлана. 1968 елның августында газета Кириши шәһәрен немец-фашист басып алучыларыннан азат итүгә 25 ел тулу көнендә үзенең укучыларын күп санлы материаллар белән таныштырды. Бу данлыклы дата уңае белән газетада көрәшче-шагыйрь Муса Җәлил сүзләренә дә урын бирелде:

Утны, суны кичеп, кешелеккә
Яулап алдык бөек чынлыкны.
Безнең яшьлек менә шулай үтте,
Корыч менә шулай чыныкты.

В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуны каршылауга хәзерлек көннәрендә «Кириши факелы» газетасында «Җәлил исемендәге дружинада» дигән мәкалә басылып чыкты. Анда комсомолларның һәм пионерларның бу бөек датаны укуда һәм эштә яңа уңышлар белән каршы алырга әзерләнүләре турында язылган иде. Бөек Ленин идеяләренең тулы җиңүе өчен тормышын һәм гомерен кызганмаган герой-шагыйрьнең исемен бу көннәрдә Киришида торган сиен ешрак кабатлыйлар. Әйе, аның исеме — халык телендә, халык күңелендә. Кириши кешеләре татар халкының турылыклы улы Муса Җәлилне бер кайчан да онытмаслар. Үзенең бөтен гомерен Ленин эшенә, ул төзегән Коммунистлар партиясенә багышлаган көрәшче-шагыйрьнең исеме совет халкының якты киләчәге өчен көрәш юлында сүнмәс факел булып озак еллар буена яктырыр.

П. М. САВЕЛЬЕВ,
Ленинградтагы Төньяк-Көнбатыш Политехник
институтының марксизм-ленинизм кафедрасы
өлкән укытучысы.

# КӨТЕП АЛЫНГАН СҮЗЛЕК

Китап сөючеләргә яна сюрприз итеп, нәшрият «Татар теленең диалектологик сүзлеге»н чыгарды. Дөньяга килгән тагын бер капиталь хезмәтне «Төкле аягың белән!» — дип дулкынланып кулга алабыз. Зәвык белән бизәлгән, яхшы төпләнгән, жыйнак хәрефләр белән жыелган 650 битлек саллы бер китап. Ашыга-ашыга битләрен актарабыз: әле беренче танышуда ук эчтәлеге бик бай һәм күп яклы икәне күзгә бәрелә.

Иң элек сүз башында татар теленең диалектологик сүзлекләрен эшләү тарихы (18 гасырдан алып бүгенгәчә) кыскача яктыртыла, бу сүзлекнең чыганаклары күрсәтелә. Конкрет мисаллар белән бик кыска һәм төгәл итеп, мондый төр сүзлек төзүнең төп принциплары аңлатып бирелә.

Сүзлекне татар теленең урта һәм көнбатыш диалектларының сүз байлыгы тәшкил итә. Баш сүзләрнең мәгънәләре, үз телебездә төгәл аңлатылганнан соң, кыскача гына русча да бирелә. Мәсәлән:

**АЙЫР КУЗН.** ярь (развилка, развилина у вилы и т. п.). **Синәкнең бер айыры сынган.**

**АЙЫРА НОКР.** бигрәк тә (тем более, тем паче). **Аштан сыңра айыра эчәсе килергә тийеш.**

**АЙЫРЫ МИНЗ.** 1. аерым (отдельно, особо, самостоятельно). **Алар айыры тордолар...**

Менә бу алым — рус телендәге аңлатмалар, кирәк икән реаль энциклопедик белешмәләрдән дә тартынмау — сүзлекнең гыйльми кыйммәтен, куллану даирәсен тагын да арттыра. Сүзләрнең әйтелешен төгәлрәк билгеләү өчен, къ-гъ-w һәм йа-йә-йу-йү-йы-йе кебек бик җиңел һәм уңайлы транскрипция билгеләре кулланылган. Мәсәлән: а н г ъ а р у (аңлау, төшенү), к ъ а к ъ л а у (чагу, чәнчү), б а л а б ә w е т ү (тирбәтү), й а л а у (әлгеч, элмәк), й ә ш е н ү (яшеренү), й е з е л ү (өзелү), й е р е (эре), й ү л ә ү (тегү) һ. б.

Сүзлектә тулаем 14 меңләп сүз (тамыр, ясалма, кушма, парлы һәм тезмә сүзләр) һәм тәгъбир тупланган булып, аларның шактый өлеше күп мәгънәле (мәсәлән: а й а з — 10, б и р н ә — 7, й а н т ы к сүзенең 11 мәгънәсе теркәлгән) һәм һәр мәгънәсе житәрлек мисаллар белән расланган. Моның өчен еш кына жыр, такмак, мәкаль, фразеология кулланылган. Бу исә сүзлекнең сыйфатын, байлыгын, күп төсле-төсмерле булуын тагын да арттыра төшкән. Мәсәлән:

**АРДАКСЫЗ** (кадерсез): **Ардаксызның аркасы туза,**
**йеңгәсезнең йеңе туза** (әйтем).

**ЧЕБЕЛДЕК** (чыбылдык): **Чебелдек кенәм чып-чывар,**
**Чебеннәр кунса, кем кывар** (борынгы жыр).

Әүвәлге телебездә булып та, хәзер исә сөйләшләрдә генә сакланып калган никадәр сүз-тамырлар очрый! Мәсәлән: а б р а у (коткару, саклау), а р д а к ъ (кадер), а л ы с (бик ерак), а р г ы ш (туй кунаклары, кәрван), б е л е к л е (белемле), б и л ә, б ө й л ә — бу илә (болай), ш и л ә (шөйлә — шу илә, шулай), и р м ә к (кызык) һ. б. Әдип күзлегеннән караганда, боларның борынгы тормышны сурәтләү, тарихи романнар язу өчен нинди кыйммәтле «төзү материалы» икәнлеге ачык булса кирәк. Телебезнең күркәм бер үзенчәлеге булган а г а ч-б о г ъ а ч, а л м а-т и л м ә, к ъ а р г ъ а-к ъ о з а н... кебек парлы

сүзләр дә монда искиткеч күп очрый! Болар барысы борынгы язма истәлекләрне тикшергәндә, этимологик сүзлек төзегәндә кыйммәтле чыганак булып хезмәт итәчәк.

*Җайдакъ* (всадник), *элемтә* (связь), *бөҗәк* (насекомое), *оныкъ* (внук), *мизгел* (момент) кебек сүзләр вакытында төрле сөйләшләрдән алынып әдәбиләшкән иде. Киләчәктә, һичшиксез, бу сүзлектәге сүзләрнең дә шактый өлеше гомум кулланышка кереп китәр. Анда моңа лаек булырдай сүзләр байтак. Мәсәлән: *ару* (чиста, пакь), *иркәк* (самец), *йапан* (буш дала), *йагъа* (чит, ерак җир), *оныкъа* (внучка), *тудыкъа* (туганнан туган), *отры* (һаман саен) һ. б. Ә инде балык, җәнлек, кош-корт, үсемлек исемнәре, авыл хуҗалыгы һәм көнкүреш төшенчәләреннән әдәби телгә алынырлык мөһим атамаларны тагын да күбрәк күрсәтергә булыр иде. Кыскасы, сүз житмәүдән йөдәгән тәрҗемәче һәм журналистларга, гомумән барлык каләм әһелләренә бу хәзинәдән сайларлык материал байтак табылачак.

Сүзлектә татар халкының төрле төркемнәренең этнографиясенә (кием-салым, бизәү әйберләре, аш-су, азык-төлек, мифология, им-том, дәвалар, һөнәр-кәсепләргә һ. б.) кагылышлы бик күп атама һәм белешмәләр теркәлгән. Мисалга календарь һәм вакыт төшенчәләреннән генә беркадәресен күрсәтеп үтик: *билек ае* (5 ай), *буш ай*; *кавыс айы*, *келәү айы*, *кырлач айы* (ягъни кышкы чиллә), *наруз* (нәүрүз) *айы* (борынгы яңа ел башы), *сабан айы*, *урак айы*; *атна*, *атна кич*, *кечатна*, *атнакөн*, *атнарас*, *атнарты*, *къанкөн*, *йома*, *ара*, *чор*, *бер каwым*, *кайкөн* һ. б.

Кушымта өлешендә, миңа якын үсемлек атамалары тупланып, аерым сүзлекчә итеп эшләнгән. Латинча төгәл фәнни термины һәм диалектлардагы мәгънәдәшләре дә күрсәтелеп, еш кулланыла торганына җибәрү-кайтару юлы белән һәр үсемлек-үлән хакында дөрес төшенчә бирелә. (Ботаника терминологиясен тәртипкә салу өчен бу гаять мөһим бер тәҗрибә.)

Урта һәм көнбатыш диалектлар турында кыскача, әмма эчтәлекле белешмә (612—640) шулай ук бик урынлы. Ахырда төп әдәбият (641—643) һәм сөйләшләрнең географик таралышын күрсәткән карта бирелә.

Шулай итеп, сүзлекнең эчтәлеге белән җентекләп танышып чыккач, халкыбызның телен, гореф-гадәтен, матди һәм рухи культура традицияләрен аңлаган һәркемнең күңелендә жылы бер хис уяна. Бик хаклы горурлык тойгысы бу. Чөнки тел безнең тарихыбыз да, бүгенге тормыш, эш һәм иҗатыбызның нигезе дә.

Икенчедән, бу хезмәтнең дөньяга чыгуына теге я бу дәрәҗәдә катнашы булган кешеләргә — сүз исемлекләре тапшырган галим, язучы, тәрҗемәче һәм журналистларга, укучы, укытучы, студент һәм аспирантларга, авылдан язышып торучы һәвәскәрләргә (болар сүз башында исемләп аталганнар) һәм, әлбәттә, авторлар белән редакторларга, Институтның гыйльми-техник көчләренә, нәшрият хезмәткәрләренә рәхмәт тойгысы туа.

Батырлык, фидакарьлек, зур хезмәт нәтиҗәсе бу. Шулай ук монда диалектологиябезнең һәм сүзлекләр төзү тәҗрибәсенең 18 гасырдан алып бүгенгәчә үсеше дә чагыла. Сәгыйт Хәлфин (урта диалект), Дамаскин (көнбатыш диалект), И. Гиганов, Н. Б. Атнометов (көнчыгыш диалект), А. Троянский, Н. П. Остроумов, А. Воскресенский, К. Насыйри, С. Рахманкулов, Л. Җәләй һ. б. хезмәтләре төрле урында бик хаклы искә алына, тәкъдир ителә.

Хәзерге диалектологиянең колачы аеруча киңәйде. Сүзлек төзү белән бергә, диалектологик атлас өчен дә материал җыела. Дистәләрчә өлкә, меңләгән авыллар буйлап, елның вакыты-һавасына карамыйча, аркага биштәр, кулга каләм-дәфтәр алып йөргән «илгизәр диалектологлар» гаскәре күз алдыннан үтә... Аннары кышкы төннәрне кенгә ялгап, ал-ял белмичә тупланган материалны тәртипкә салу, сүзлек төзү... Ниһаять, кулъязма тәмам, ул матбугат йорты редакцияләренә килеп керә...

Татар теленең төрле сүзлекләре республикада гына түгел, бөтен союз (хәтта чит ил) фәнни җәмәгатьчелеге тарафыннан да түземсезлек белән көтелүе, Казанның данлы тюркологик традицияләрен лаеклы дәвам иттерү кирәклеге, мәгариф-культура практикасы өчен дә зарур булуы һ. б. лар аңлатылгач, гадәттә, кулъязма матбугатка кабул ителә. Инде барсы да ал-гөлме? Һич юк! Һәр сүз, җөмлә вә тәгъбир өчен авторлар белән редакторлар арасында «принципиаль», «аяусыз» көрәш-тартышлар гадәттәгечә дәвам итә әле. Ике тараф та үз ягыннан хаклы кебек. Редактор, билгеле, кыскарту

ягын каера. Авторлар: «Монда да кермәгәч, бу сүзләр кайчан чыгар?» диләр. Сүзлек эше әнә шундый объектив вә субъектив кыенлыклар белән бәйле. Моңа мәгърифәт дөньясын күптән төшенгән бер шагыйрь 18 йөздә үк:

**Әгәр берәү газапка хөкем ителсә,**
**Мескеннең башына зур кайгы көтелсә,**
**Себергә дә сез аны озатмагыз,**
**Тар караңгы зинданга да япмагыз —**
**Кушыгыз ана телнең лөгатен төзергә,**
**Иң кыен җәза булыр бу гомергә! —**

дип язган.

Ни булса да булган, әмма диалектологик сүзлек инде безнең кулда!

...Әлбәттә, мондый зур, четерекле эштә кайбер кимчелек, төгәлсезлекләр булмый калмас. Тик, бәхеткә каршы, аларның күбесе сүзлекнең техник ягына кагыла. Мәсәлән, транскрипция билгеләре кулланылгач, гадәттәге алфавит тәртибе үзгәрә, димәк, аны махсус күрсәтү яхшы булган булыр иде. Сүзлек мәкаләсе бик бай һәм күп мисаллар белән иллюстрацияләнгән, дидек. Әйе. Ләкин аларны күргәзмәлерәк, ачыграк итеп бирү өчен, шрифт төрлелегеннән файдалану җитенкерәми. Мисаллар (күпләгән җөмлә, җыр, мәкаль, әйтемнәр) аңлатма белән бертөсле үк һәм бик вак хәрефтән җыелганнар, бу исә укырга-аерырга бик читен. Гадәттәге «Эчтәлек» битенең булмавы да җайсыз.

Диалекталь сүзне аңа иң якын торган, табигый, җиңел һәм гомум аңлаешлы әдәби сүз белән генә төшендерәсе урында бик ерак һәм тар кулланышлы диалекталь сүзгә җибәрү очраклары мәшәкать тудыра. Мәсәлән:

**ШЫПША**...к. азман 1 (**шөпшә диелсә һәркем аңлар иде**).

**ШӘРКЕ** минз.к. сыпкылы (шапшак, пычрак, җыймаган диярга мөмкин) һ. б. ш. кебекләр. Мондый очракта (икенче сүзләргә җибәргәндә) кайчак мисал бирелми, димәк, аңлатырга тиешле сүзнең мәгънәсе, кулланышы расланмый, аныкланмыйча кала. Касыйм, гәйнә сөйләшләренә караган кайбер мисал, җөмләләрнең үзләренә дә сирәк булса да аңлатма кирәк булыр иде.

Алынма сүзләрнең (рус-европа, гарәп-фарсы, угро-фин телләреннән алынмаларның) чыганагын күрсәтү сүзлекнең фәнни-теоретик кыйммәтен арттыра. Мондый белешмәләр, башлыча, дөрес билгеләнгән. Әмма:

**ШАЙ** I (русча «чай» сүзеннән)... кебек бер-ике сүзнең генә чыганагы ышандырмый, чөнки татар телендә аның фонетик вариантлары: **шайы, шәй-шай**<**ошай/яки: тия, тыя, тоя**<тоела кебек семантик параллеле бар. Рус телендәге сүз белән тышкы ошашлык очраклы туры килү генә мөмкин, эчке семантик модельләрнең, оядашлык һәм сүз ясалу бәйләнешләренең исә дәлилләү көче зуррак.

Сирәк булса да **аралау, арата, арпа, ачыргалану, бирнә, борсалану, чабалану**... кебек әдәби һәм гомумсөйләү сүзләренең мәгънәләре күренгәли (боларның диалекталь төсмере юк, һәр диалектта очрарга мөмкин). Тик ялгыш аңланмасын: бу артык дукуптарырлык, сүзлекнең бәясен төшерерлек нәрсә түгел. Бердән, аларның кайбер мәгънәләре диалектларда гына очрый. Икенчедән, шундый әдәби сүзләрнең дә диалекталь таралышын күрсәткән махсус сүзлек кирәк. Чөнки төгәл-тарихи тикшеренүләр өчен, әдәби тел сүзлегенең диалекталь базасын, ягъни кайсы диалектлар нигезендә оешуын аныкларга кирәк була...

Китапның бизәеше әйбәт, мәсәлән, титул битләре җитди академик стильдә бирелгән (шулай да тышлыктагы артык кычкырып торган эре хәрефләр публицистик әсәр өчен яраклырак булыр иде; диалек-тологик дип аеру да бик үк төгәл түгел). Гомумән алганда, соңгы елларда Казан басмаларының график-полиграфик эшләнешендә кимчелекләр булгалады. Матбугат битләрендә һәм киң җәмәгатьчелек тарафыннан урынлы искәртүләрдән соң, хәзер сыйфат ягы яңадан күтәрелешкә таба үзгәрә. Мәсәлән, фәнни-техник редакциядән чыккан сүзлек, альбом һәм фәнни хезмәтләрнең тышкы күренеше үк елдан-ел яхшыра бара. Бу да бик әһәмиятле, әлбәттә...

Әйтелгән искәрмәләр һич тә сүзлекнең бәхәссез кыйммәтен инкарь итми. Алар сүзлекне тагын да яхшырту теләге белән белдерелә. Һәрхәлдә, авторлар сүзлекнең яңа, тагын да тулырак басмасын чыгару өстендә эшләрләр дип ышанабыз.

**Ф. ФАСЕЕВ,**
**филология фәннәре кандидаты.**

# БӘЛӘКӘЙ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

### Г. ЛЕВАШЕВА. Синең дустың музыка. Казан. 1969 ел

Балалар безнең киләчәгебез. Шуңа күрә аларны без кече яшьтән үк дөрес тәрбияләргә тиеш. Дөрес тәрбия дигәнең исә үзе гаять катлаулы һәм киң мәгънәле төшенчә. Ул һич тә физик тәрбия, акыл һәм әхлак тәрбиясе белән генә чикләнми. Бала кече яшьтән үк гүзәллек һәм матурлык дөньясы белән танышып үсәргә, сәнгать әсәрләре, сәнгатьнең төрле тармаклары һәм өлкәләре турында азмы-күпме хәбәрдар булырга тиеш. Алар һәрьяктан килгән, тулы канлы кешеләр булып үссен өчен, нәни гражданнарга без мәгълүм бер күләмдә эстетик тәрбия дә бирергә бурычлы.

Галина Левашеваның «Синең дустың музыка» исемле китабы нәкъ менә эстетик тәрбия, тагын да төгәлрәк итеп әйткәндә, балаларга музыка тәрбиясе бирү мәсьәләләренә багышланган. Автор кече яшьтәге мәктәп укучыларын музыка грамотасына караган иң гади төшенчәләр белән таныштыра, көндәлек тормышыбызда аеруча зур урын тоткан бу сәнгать төренең роле һәм әһәмияте турында алар белән ихлас күңелдән җылы әңгәмә алып бара, балаларны музыкаль әсәрләрне тыңларга, аңларга өйрәтә.

Китап бәләкәй-бәләкәй аерым бүлекчәләрдән тора. Һәр бүлекчә музыка грамотасының яки музыка сәнгатенең берәр конкрет мәсьәләсенә багышланган. «Трам-та-та-там», «Авазлар һәм ноталар», «Ноталар бездә кунакта», «До, ре, ми һәм аларның кардәшләре», «Түгәрәкләр, таяклар һәм койрыклар турында», «Ноталар йортындагы тәртипсезлек» кебек бүлекчәләрдә, мәсәлән, сүз музыка грамотасына караган аерым төшенчәләр турында бара. Әлеге бүлекчәләрдә автор нота станы һәм ноталар, ноталарның исемнәре һәм үлчәүләре, музыкаль ачкычлар һәм аларның әһәмияте, диез, бемоль һәм бекар билгеләре, такт һәм такт сызыгы кебек әйберләр турында аңлата. Балалар аңларлык гади һәм җиңел итеп, мисаллар, конкрет фактлар ярдәмендә аңлата.

«Яңгыр һәм синең рухи халәтең турында», «Балалар уеннары», «Кларага багышлана», «Музыка һәм ел фасыллары» исемле бүлекчәләрдә исә музыканың тормыштагы әһәмияте аңлатыла, музыка әсәрләрен аңларга һәм тыңларга өйрәтелә. Бу эш шулай ук конкрет мисаллар ярдәмендә алып барыла. Г. Левашева Жорж Бизе, Вольфганг Моцарт, Роберт Шуман, Петр Ильич Чайковский кебек мәшһүр композиторларның махсус балаларга багышлап язылган әсәрләренә мөрәҗәгать итә, шулар мисалында әйтергә теләгән фикерләрне җиткерә...

Татарстан китап нәшрияты Г. Левашеваның «Синең дустың музыка» исемле бу китабын татар телендә басып чыгарып дөрес эшләгән. Чөнки безнең үзебездә мондый характердагы китаплар, кызганычка каршы, бик аз языла.

Китапны татарчага Роза Хафизова тәрҗемә иткән. Аерым авыр җөмләләре, механик рәвештә генә тәрҗемә итеп узылган урыннары булуга да карамастан, китап татарча да гомумән җиңел һәм мавыгып укыла.

### Л. ШАФИКОВА. Исәнме, Камил! Хикәяләр һәм очерклар. Казан. 1969 ел

Укучылар, бәлки, хәтерлидер: моннан 7—8 еллар элек яшь язучы Лена Шафикова исеме матбугат битләрендә шактый еш очрый иде. Республикабыз газета-журналларында әледән-әле аның яңа хикәя һәм очерклары чыгып тора, ул әсәрләр, тегеләйме-болаймы, әдәбиятыбызның еллык үсеше хакындагы гомуми докладларда, яшьләр иҗатына багышланган тәнкыйть мәкаләләрендә телгә алына иде. Шуннан күпмедер еллар Лена Шафикова югалыбрак торды. Яшьлек мавыгулары узды, иҗат эшен ташлады, ахры, дип уйларга гадәтләнеп килә идек инде. Юк икән, ташламаган икән. Узган ел Татарстан китап нәшрияты аның «Исәнме, Камил!» исемле хикәяләр һәм очерклар китабын басып чыгарды. Җыентыкка кергән уналап әсәрнең бары бер-икесе генә теге елларда язылган электән таныш әйберләр. Калганнары соңгы елларда язылган яңа әсәрләр.

Лена Шафикова әдәбиятка тормышның үз эченнән, аны өйрәнеп һәм белеп килде. Бу — аның әсәрләрендә дә нык сизелә. Беренче чорда язылган әсәрләренең күбесе чирәм җирләрне үзләштерүчеләр тормышына багышланган була иде. Соңгы берничә ел ул Әлмәттә яшәп, нефтьчеләр тормышы белән танышып кайтты. Җыентыктагы яңа әсәрләрнең күбесе әнә шул темага карый, республикабызның йөзен үзгәрткән нефть промышленносте эшчеләре тормышыннан алып язылган.

Дөресен әйтергә кирәк, автор бу яңа өлкәне дә шактый әйбәт үзләштергән. Нефтьчеләрнең авыр хезмәтен, аларны борчый һәм

дулкынландыра торган мәсьәләләрне ул ярыйсы ук тирәнтен белә. Аның «Төнге сөйләшү», «Тормыш дәфтәренең дүрт бите» кебек әдәби очерклары белән танышкач, бу фикер тагын да көчәя төшә. Шуның белән бергә, Лена Шафикова нефть чыгаруга бәйле процессларны, технология мәсьәләләрен сурәтләү белән артыграк та мавыгып киткәли шикелле. Аерым очракларда аны тормыш материалы үз артыннан ияртеп алып китә. Нәтиҗәдә кайбер хикәя һәм очеркларында тере кешеләр, аларның үзенчәлекле язмышлары күләгәдәрәк кала, андый әсәрләр сүлпәнрәк укылалар, укучыны битараф калдыралар.

Ләкин бу әле язучы үз хикәяләренең әдәби эшләнешенә игътибар итми икән дигән сүз түгел. Лена Шафикова әлеге авыр жанрда ныклап һәм җитди тәстә эшли. Ул хикәя законнарын шактый әйбәт белә, үз әсәрләрен мавыгып укырлык хәлгә китерү өчен күп көч куя. Ул үз әсәренә, анда сөйләнәчәк вакыйгаларга һәм сурәтләнәчәк геройларга карата укучыларда кызыксыну уятырга тырыша. Аның күпчелек хикәяләре контраст вакыйгаларга, көтелмәгән хәлләрне тасвирлауга корылган. Бу яктан караганда, җыентыктагы «Күңел көен көйләп» исемле хикәя аерылып тора. Дөрес, һәр яктан килгән, коеп куйган әсәр түгел ул. Анда тормыш хакыйкате белән ярашып бетмәгән нәрсәләр, очы-очка ялганмаган, логика кысаларына сыешып бетмәгән аерым моментлар очрый. Шуларга да карамастан гомумән алганда, хикәя унай тәэсир калдыра. Әсәрнең баштагы 11—12 бите аеруча җылы, чын әдәби югарылыкта язылган. Димәк, Лена Шафиковадан матур-матур хикәяләр көтәргә безнең тулы хакыбыз бар.

### Р. БАТУЛЛИН. Уйларымны кеше белсен. Хикәяләр. Казан. 1969 ел

«Уйларымны кеше белсен» — Роберт Батуллинның дүртенче китабы. Ана өметле яшь авторның унлап хикәясе һәм «Бүген концерт була» исемле бер юлъязмасы кертелгән.

Җыентыктагы әсәрләр белән танышып чыккач, иң элек шул нәрсә күзгә ташлана: чагылдырылган чорлары һәм тема-проблемалары, әдәби эшләнешләре һәм характерлары, ниһаять, күләмнәре ягыннан алар бик тә төрле-төрле. Зурлыклары 5—6 биттән бер табакка кадәр, аларда Бөек Ватан сугышы еллары өчен хас драматик вакыйгалардан алып бүгенге көннәргә хәтле булган тормыш хәлләре сурәтләнә. Характерлары ягыннан исә алар тагын да чуаррак: лирик янгырашлы настроение хикәяләре һәм юмористик хикәяләр бар, «Җинаять» һәм «Алыбаяк» кебек, детектив яки фантастик жанрга тартымнары очрый. Кыскасы, кайсы җәһәттән генә якын килеп карама, китаптагы һәр хикәя диярлек үзенә бер төрле, һәр әсәр үзенә бер манерда язылган. Бу — Роберт Батуллинның төрле жанрларда көч сынап карый һәм өзлексез эзләнә торган, тынгысыз характерлы һәм киң диапазонлы язучы булуы турында сөйли.

Әммә берсе икенчесеннән нык аерылып торган шушы әсәрләрнең һәммәсен бер уртак сыйфат үзара якынайта. Сүз әсәр идеясенең, автор позициясенең ачыклыгы турында бара. Аның әсәрләре белән танышканда укучы: «Тукта әле, үзенең бу әсәре белән язучы нинди фикер уздырмакчы булды икән? Нәрсә диярга теләде икән?» — дип аптырап утырмаячак. Р. Батуллин хикәяләренең идеясе, төп фикер әллә каян кычкырып тора.

Яхшымы бу, әллә начар сыйфатмы? Кайчан нечек бит. Әгәр язучы чама тойгысын югалтмаса, тормыш чынлыгын бозмаса — һичшиксез, яхшы нәрсә. Бу аның әсәрләренең эмоциональ тәэсир көчен, тәрбияви әһәмиятен арттыра. Җыентыктагы «Офыклар әлсу иде», «Соңгы чабыш» кебек хикәяләр һәм башка уңышлы әсәрләр нәкъ шул фикерне куәтли. Әйе, автор фикеренең ачык булуы нигездә — әйбәт сыйфат. Ләкин кайчакларда әнә шул ук нәрсә аңа зыян да китергәли бугай. Укучының хисләренә тәэсир ясыйсы, тойгыларын уятасы урында, автор аны үгетләргә, аңа акыл сатарга тотына, дидактизмга бирелә. Нәтиҗәдә, әдәби детальләр, буяулар артык куертыла, тормыш материалы автор фикерләрен иллюстрацияләүгә генә хезмәт итә башлый, хикәяләрнең ышандыру көче кими, геройлар автор фикерен укучыга җиткерүче рупорга әйләнәләр. «Укалы фәрештә», «Фасил белән Василә» исемле хикәяләрдә бу аеруча нык сизелә. «Җинаять» исемле өченче бер хикәягә дә шул ук нәрсәнең зыяны тигән шикелле...

### Р. ГӘРӘЙ. Уйланган минутларда. Шигырьләр. Казан. 1969 ел

Рәшит Гәрәйнең яңа җыентыгы ике зур бүлектән тора. «Тыныч көн теләп» дип исемләнгән беренче бүлеккә төрле зурлыктагы, төрле характердагы шигырьләр тупланган.

Заман сулышын тоеп һәм бүгенге көн проблемалары белән якыннан кызыксынып яшәүче тынгысыз шагыйрь буларак, Р. Гәрәй үз әсәрләрендә тормышның төрле якларын сурәтли. Шуның белән бергә, һәр иҗат кешесенеке кебек үк, аның да аеруча белеп һәм яратып эшли торган үз өлкәсе, үз темасы бар: тынычлык өчен көрәш, туган җир темасы, яшьлек-мәхәббәт хисләре... Ул, мәсәлән, элек-электән шул мәсьәләләр турында күп яза, һәм аның нәкъ шул темаларга багышланган шигырьләре аеруча җылы тәэсир калдыра. «Сагынып кайтам», «Һәр игенче солдат шикелле», «Хисләреңне җилгә таратма», «Танклар дәһшәтле гөрлиләр», «Алмагачлар алма койганда», «Бергә булырбыз тагын» кебек шигырьләре әнә шул турыда сөйли.

Беренче бүлеккә кергән әсәрләр арасыннан, үзенең темасы, характеры белән, тагын «Үзәннәрдә окоплар» исемле озын шигырь аерылып тора. Сүз анда революция еллары вакыйгалары турында бара, әсәр, ата-бабаларның изге туфрагын яклап, акгвардиячеләргә каршы изге көрәшкә күтәрелгән каһарманнарның якты истәлегенә багышланган.

Әйбәт эшләнгән, уңышлы шигырьләр белән бергә, бу бүлектә тапталган темаларга язылган, күренеш һәм вакыйгаларның тышкы билгеләрен санап чыгуга гына корылган әсәрләр дә очрый. Кайбер очракларда шагыйрьнең тормыштан алган тәэсирләре поэтик кичереш дәрәҗәсенә күтәрелми.

«Язгы җыр», «Морякларны шунысы куандыра», «Диңгездән хат», «Шахта душында», «Кузбасс егете космоста», «Ямәширмә» кебек әсәрләр шундыйрак тәэсир калдыра.

Икенче бүлек баштан ахырга кадәр уяники юллыклардан тора һәм ул бүлектәге барлык әсәрләр өчен эпиграф кебегрәк яңгыраган «Уникe юл шигырь яздым» исемле шигырь белән ачыла:

**Уникe юл шигырь яздым,**
**Уникe төнем үтте.**
**Уникe юл шигырь яздым,**
**Уникe кайгым бетте.**

**Дуслар ни дияр... Шул сорау**
**Йөрәкне кысып тора.**
**Уникe юллык шатлыгым**
**Бер читтә посып тора.**

**Ятсына дәү хисләр белән**
**Кул биреп көрешергә...**
**Шул шатлыгымны да, дуслар,**
**Әзер мин бүлешергә.**

Мәсьәләгә бары тематик яктан гына якын килеп караганда, алар беренче бүлектәге шигырьләрдән әллә ни аерылмыйлар диярлек. Монда да нигездә туган җир, туган ил, яшьлек, мәхәббәт, тынычлык темаларына багышланган шигырьләр өстенлек итә. Әмма хикмәт аларның сыйфатында. Беренче бүлек белән чагыштырганда, икенче бүлектәге күпчелек шигырьләр тагын да тирәнрәк һәм көчлерәк яңгырыйлар. Авторның тормышка мөнәсәбәте ачыклана төшкән, гражданлык хисләре активрак яңгыраш алган. Мисал өчен тагын бер әсәргә мөрәҗәгать итик. Исеме — «Ир егетләр кайтып килә».

**Ир егетләр чыгып китә,**
**Артларына карый-карый.**
**Үпкәләгән ак каеннар**
**Һәркайсына бармак яный:**

**— Шушы җирдә бергә үстек,**
**Ник аны ташлап китәсез?**
**Чит-ят җирләр туфрагына**
**Үз микән, якын микән сез?**

**Ир егетләр кайтып килә,**
**Башларын никтер игәннәр.**
**Ак каеннар, яулык болгап,**
**Йөгерешеп каршы киләләр.**

Эчке мәгънәгә ия булган һәм бер уку белән хәтердә кала торган мондый әйбәт шигырьләр җыентыкта әллә ни хәтле: «Әй, кайда син, яшьлек...», «Кешнәүләре колак төбендә», «Безнең балачакны сагалап...», «Бер уйласаң...» һәм башкалар, һәм башкалар...

Рәшит Гәрәйнең күп кенә шигырьләре үзләре үк көйгә салуны сорап тора («Көннәрем», «Тургайлар, тургайләр...», «Туганүскән җир кирәк», «Күгәрченнәр гөлдергөлдер» һ. б.). Алар композиторларыбызның да игътибарын үзләренә тартырлар дип ышанасы килә.

# ХАЛИКЪ САДРИ

*(1890—1955)*

Әдәбиятыбызны үстерүгә озак еллар буе хезмәт итеп килгән язучыларыбыздан Халикъ Садриның тууына 80 ел тулды.

Габделхаликъ Гариф улы Садриев 1890 елның 4 августында Куйбышев өлкәсенең Камышлы районы Иске Ярмәк авылында крестьян семьясында туа. Бик яшьли ятим кала. Башта авыл байларына батрак булып эшли, аннары 1902 елдан 1917 елга кадәр Оренбург, Уфа, Баку, Самара шәһәрләрендәге заводларда һәм нефть промыселларында эшли. Эре промышленность предприятиеләрендә эшләве, алдынгы эшчеләр белән аралашуы нәтиҗәсендә, Х. Садри патша Россиясендәге гаделсезлекләрнең асылын аңлый башлый һәм Бөек Октябрь революциясенең беренче көннәрендә үк революцион көрәш юлына баса. 1917 елның 3 мартында Х. Садрины В. В. Куйбышев рекомендациясе буенча большевиклар партиясенә кабул итәләр. Гражданнар сугышы чорында Х. Садри партизан отрядларын оештыручыларның берсе була һәм Идел буен акгвардияче бандалардан чистартуда катнаша.

Х. Садри Кремльдә уздырылган татар-башкорт коммунистларының беренче киңәшмәсендә катнаша. Биредә ул В. И. Ленин белән очраша. Х. Садри Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын оештыру турындагы закон проектына кул куйган татар халкы вәкилләренең берсе була.

1919—22 елларда Х. Садри ВКП(б)ның Самара губкомында татар секциясе председателе була, 1922—25 елларда, партия чакыруына кушылып, промышленностьны торгызу эшенә күчә — электростанциядә механик булып эшли. 1925—28 елларда Казанда Коммунистик университетта укый, аны тәмамлагач, «Спартак» комбинатында директор була һәм башка промышленность предприятиеләрендә җаваплы урыннарда эшли.

Бөек Ватан сугышы елларында Х. Садри Сталинград янындагы каты сугышларда катнаша. Сугышчан батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз, II нче дәрәҗә Ватан Сугышы орденнары һәм медальләр белән бүләкләнә.

1912 елда Уфада Халикъ Садриның «Тегермәндә» исемле беренче хикәясе басыла һәм шушы елдан аның әдәби эшчәнлеге башлана. Ул «Безнең таң», «Ил батырлары», «Тимерче малае», «Зиатдин балалары» һәм башка әсәрләрендә татар эшчеләренең һәм крестьяннарының революциягә кадәрге тормышын, аларның рус халкы белән берлектә азатлык өчен көрәшләрен чагылдыра.

Х. Садриның барлык әсәрләре дип әйтерлек автобиографик характерда язылган. Аларда автор үзенең бай тормыш юлында кичергән вакыйгаларын, күренешләрне сурәтли.

Х. Садри драматург буларак та укучыларга һәм тамашачыларга таныш. Аның «Уникe ел сөргендә» исемле беренче пьесасы 1919 елда язылган. «Идел буенда сугышлар», «Партизаннар» исемле пьесалары озак еллар буе колхоз-совхоз театрлары сәхнәләрендә, авыл һәм завод клубларында уңыш белән барды.

1936—56 елларда Х. Садриның 8 китабы басылып чыкты. Авторның иң популяр әсәрләре 1954 елда «Ил батырлары» исемендә басылып чыккан сайланма әсәрләре җыентыгына кергән.

# В. М. БАХМЕТЬЕВ

*(1885—1963)*

Шушы елның август аенда танылган язучы, күренекле революционер һәм җәмәгать эшлеклесе Владимир Матвеевич Бахметьевның тууына 85 ел тулды.

Владимир Матвеевич гаҗәеп дәрәҗәдә үзенчәлекле талантка ия иҗат кешесе була. Аның әсәрләре шагыйрьләргә хас җылылык һәм журналистлык кайнарлыгы, драматургларга хас үткен караш һәм тәнкыйтьчеләргә хас максатка омтылышлылык белән аерылып тора. В. М. Бахметьевның әдәби иҗат эшчәнлеге, беренче рус революциясе елларында башланып китеп, ярты гасырдан артыграк дәвам итә, һәм шул еллар эчендә ул безгә өч дистәдән артык роман, повесть, хикәя язып калдыра.

В. М. Бахметьев үзенең иҗат эшен үткен каләмле, ялкынлы публицист буларак башлап җибәрә. Аның барлык язганнарын бер үзәккә туплый торган төп тема бар. Ул — талантлы һәм революцион рухлы рус халкы темасы, ул — йокыдан уянып килгән Россия темасы, ул — эшче кварталларында, себер төрмәләрендә, ярлы крестьян йортларында туган яңа Россия темасы. Шахтерлар турында, депо эшчеләре, я булмаса типография эшчеләре турында язамы, ул һәрвакыт бер максатны күздә тота: әлеге уянып килгән яңа Россия иске Россияне — алпавытлар һәм капиталистлар, помещиклар һәм полицейскийлар Россиясен — җиңәргә тиеш. Россиядәге төп көч — эшчеләр сыйныфы, Россиянең төп куәте — халыклар дуслыгында. В. М. Бахметьевның мәкалә һәм хәбәрләрен укыган һәр кеше әнә шуңа ышана. Язучы изелгән халык массаларына чын бәхет китерерлек бердәнбер дөрес юлны белә. Шуңа күрә аның публицистикасы оптимистик характерда, һәм аның тормыштагы вак-төяк күренешләрдән социаль гомумиләштерүләргә күтәрелә, конкрет көнкүреш детальләре аша тарихи процессларның асылын күрсәтә алу осталыгы да шуннан килә. Бу исә чын публицистиканың иң мөһим сыйфаты.

...1919 елның октябрендә большевиклар партиясе Владимир Матвеевич Бахметьевны Казан шәһәренә җибәрә. Биредә аны «Революция байрагы» («Знамя революции») газетасының, ә инде Татарстан республикасы төзелгәч, «Тат. ЦИК хәбәрләре»нең редакторы итеп куялар. Күп көч һәм вакыт сорый торган редакторлык вазифаларын башкару белән бергә, В. М. Бахметьев үзе дә тирән эчтәлекле, революцион рухлы мәкаләләр яза. Мисалга «Тыныч тормыш якыная» дигән бер мәкаләсен алып карыйк. Гражданнар сугышы фронтларындагы гомуми хәлне сурәтләгәннән соң, турыдан-туры хезмәт ияләренең үзләренә мөрәҗәгать итеп, автор болай ди:

«...Мылтыкларыгызны кысыбрак тотыгыз, дошманны ныграк кыйнагыз, эчке контрреволюцияне тизрәк туздырыгыз, һәм без, көнбатыш пролетариатының да ярдәме белән, тыныч тормыш яулап алырбыз»[1].

Шул ук 1920 еллар башында ул «Деревенские думы» исемле тагын бер газетаның редакторы итеп билгеләнә. Ике атнага бер тапкыр чыгып килгән бу газета үзенең күләме һәм калынлыгы белән журналга тартым була. «Деревенские думы»да В. И. Ленин мәкаләләре басыла, газета битләрендә авыл тормышы яктыртылып барыла, крестьяннарга игенчелекне үстерү буенча файдалы киңәшләр бирелә. Үзенең беренче саннарыннан ук диярлек газета җәмәгатьчелек тарафыннан уңай бәя ала. Менә шул хакта сөйли торган бер факт. 1920 елның 1 мартында Казан губерна комитетына РКП(б) Үзәк Комитеты секретаре Е. Стасовадан ашыгыч хат килеп төшә. Анда шундый юллар бар.

«Үзәк Комитетның авыл белән эшләү бүлеге. «Деревенские думы» журналының 2 санын алганнан һәм аны хуплаганнан соң, Сездән әлеге журналның 1 санын 50 данә һәм алга таба һәр яңа санын даими төстә 50 данә җибәреп торуыгызны үтенә».

1921 елның мартында, Татарстан партия оешмасыннан кунак сыйфатында, Владимир Матвеевич Бахметьев партиянең X съездында катнаша. Съезд барган көннәрдә Татарстан делегациясе бөек юлбашчыбыз В. И. Ленин белән очраша. Соңыннан

---

[1] «Знамя революции» газетасы. 1919 ел. 12 ноябрь саны.

В. М. Бахметьев бу очрашу турында матбугатта да язып чыкты[1]. Билгеле булганча, әлеге әңгәмә вакытында В. И. Ленин Казанны, университетны искә төшерә, татар совет әдәбиятының шул еллардагы хәле, үсеш дәрәҗәсе белән кызыксына.

...Владимир Матвеевич Бахметьевның Совет власте чорында иҗат иткән күпчелек әсәрләре илебездә социализм җәмгыяте төзү, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү һәм, барыннан да бигрәк, батырлык, тәвәккәллек, патриотизм темаларына багышланган. Язучы бу елларда егерме бишләп әсәр иҗат итә. Күләмнәре, материаллары, тон һәм формалары, хәтта мәсьәләне хәл итү рәвешләре белән бер-берсеннән нык аерылсалар да, аларны ниндидер эчке якынлык берләштерә. Шуңа күрә әлеге егерме биш әсәрне бер әсәрнең егерме биш бүлеге дип карарга мөмкин. Үзенең әсәрләрендә язучы, я ерак киләчәккә күз ташларга теләп, иркләе хезмәт хакимлек иткән камил дөньяны сурәтли, я бүгенге көн мәсьәләләренә кайтып, тормышта, кешеләр арасында очраган кимчелек һәм җитешсезлекләрне камчылый.

Владимир Матвеевич Бахметьевның байтак әсәрләре безнең Татарстан тормышы белән бәйле. Шундый әсәрләр арасыннан аеруча популярлары — «Бер төн» исемле хикәя һәм «Таң атканда» дигән пьеса. «Таң атканда»ны автор үзе өч картинадан торган драматик этюд дип атый. Ул егерменче елларда Казан сәхнәләрендә уйналып та йөри. Бөек Ватан сугышы елларында, башка күренекле рус язучылары белән бергә, В. М. Бахметьев Чистай шәһәрендә яши, шунда үзенең яңа әсәрләрен яза. Аның ул әсәрләре терлекчеләргә һәм судно ремонтлаучыларга, хатын-кыз тракторчыларга һәм врачларга багышланган. Нинди генә әсәр язмасын, кечкенә генә гади бер мәкаләме, әллә булмаса зур күләмле әдәби әсәрме ул, аларның һәркайсында В. М. Бахметьев төп бер идеяне уздыра: тынычлыкны саклау кешеләрнең үз кулларында, тик аның өчен көрәшергә кирәк. Аның бу сүзләре бүген дә искермәгән, алар әле бүген дә бик урынлы яңгырый...

Партиябез һәм хөкүмәтебез Владимир Матвеевич Бахметьевның революцион һәм язучылык эшчәнлегенә югары бәя бирде. Халыкка күрсәткән хезмәтләре өчен ул Ленин һәм ике тапкыр Хезмәт Кызыл Байрак орденнары, шулай ук медальләр белән бүләкләнде. Тууына 85 ел тулган бу көннәрдә Татарстан хезмәт ияләре дә аны хөрмәт белән искә алалар.

Н. ГАЙНУЛЛИН.

---

[1] «Совет әдәбияты» журналы. 1957 ел. 8 сан.

## Гәрәй Рәхим

Күкрәгемнән
Йөрәгемне алып,
Мәҗнүн йөрәген куйдым.

*Р. Харисов.*

●

Муенымнан
Башымны алып,
Электрон-исәпләү машинасы куйдым;
Иннәремнән
Кулларымны алып,
Күтәрү краннары куйдым;
Күкрәгемнән
Үпкәмне алып,
Компрессор насосы куйдым.

Һәм җирдәге һәр кешедән
Көчле булдым.

Акыл әйтте:
«Әгәр үзең булып каласың килсә,
Үз әгъзаларыңны кире куй!» — диде.

Мин шулай эшләдем дә.

### Ачуланган минутта

Түзеп тормам,
Тагын тик бер тапкыр
Купшы сүзләр белән ялтыра —
Пычак кебек үткен шигырь белән
Мин суярмын сине, халтура.

## Рәсгәр

●

Борын-борынныдан таулар биек,
үзән җирләр — түбән.

*Р. Гатиуллин.*

Борын-борыннгыдан
Ак әйберләр ап-ак.
Ташлар гелән каты,
Ә мамыклар — йомшак.

Балыклар гел суда,
Ә кошлар — һавада.
Кавын пешә җирдә,
Ә коймак — табада.

Яфраҡ язын яшел,
Көзен сары һаман.
Укыган — белемле,
Укымаган — надан.

Мачыга эт дошман,
Ә этләргә мачы.
Кәнфит һәр чак татлы,
О, борычлар — ачы...

## Идрис Туктар

## Җөмләләр

Хакыйкатьне алдау-йолдау юллары белән алдап та, юллап та булмый.

Туры сүзгә осталык кирәкми, кыюлык кирәк.

Мәхәббәт сагышын үстереп була, үтереп булмый.

Кесә үзеннән алуны яратмый, үзенә салуны ярата.

Берни чәчмәсә дә, ура бирә.

Мәхәббәтле — чын бәхетле, мәхәббәтсез — иң зур бәхетсез.

Күзсез бүкәннең күзсезлегенә гаҗәпсенеп, күзле бүкәннең күзе шартлаган.

Роман яки поэма язарга өйрәнгәнгә кадәр, иң башта укучыларны кызганырга өйрән.

Сөйли торсын оратор, кирәгеңне ала тор.

Тәҗрибәсез оптимист: «Са-а-алып — са-а-алып җибәрәм дә ба-а-арып — ба-а-арып төшәм!»

— Мин акыллы,— дигән акыллы кешене очратып булмаган кебек,— мин юләр,— дигән юләрне дә очратып булмый.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ



## БЕРЕНЧЕ ДӘРӘҖӘ ДИПЛОМ

Татарстан китап нәшрияты күренекле шагыйрь Сибгат Хәкимнең «Күңелем Ленин белән сөйләшә» исемле шигырен татар һәм рус телләрендә аерым китап итеп бастырып чыгарган иде. Китап В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга багышланган. Аның тышлыгы да, эчендәге рәсемнәре дә зур зәвык белән, матур итеп эшләнгән. Китап Татарстан китап нәшриятының һәм К. Якуб исемендәге матбугат комбинатының зур казанышы. Бу китапның Мәскәүдә үткәрелгән Бөтенроссия конкурсында Беренче дәрәҗә диплом белән бүләкләнүе әнә шул турыда сөйли.

Художнигы Тавил Хаҗиәхмәтов, редакторлары Р. Даутов һәм М. Зарецкий.

## ТАТАР ШАГЫЙРЬЛӘРЕ КАЗАКЪ ТЕЛЕНДӘ

«Лениншил жас» (Алма-ата), «Орталык Казакстан» (Караганда), «Ленин тугы» («Ленин байрагы», Петропавловск) газеталарында татар шагыйрьләреннән К. Нәҗми, Б. Рәхмәт, Г. Кутуй, Ш. Маннур, С. Хәким, Г. Хуҗиев, Ш. Галиев, М. Хөсәен әсәрләре басылып чыкты. Аларны казакъ теленә шагыйрь һәм әдәбият белгече Бөркет Исхаков тәрҗемә иткән.

* * *

Алма-Атада «Җазушы» нәшриятында татар шагыйрьләренең әсәрләре тупланган «Татар жырлары» дигән китап басылып чыкты. Бу җыентыкка кергән Г. Тукай, һ. Такташ, М. Җәлил, К. Нәҗми, Н. Исәнбәт, Ф. Кәрим, Б. Рәхмәт, Х. Туфан, Ш. Маннур, Ә. Фәйзи, Ә. Исхак, Ә. Ерикәй, С. Хәким, Г. Хуҗи, З. Нури, Ш. Галиев, С. Сөләйманова, Г. Зәйнашева, И. Юзеев, Г. Рәхим, Р. Харисов һ. б. ларның әсәрләрен Т. Жароков, Ж. Сыздыков, С. Машапов, Ж. Мулдагалиев, С. Сәетов, С. Мәүленов, М. Алимбаев, Б. Исхаков, Ж. Мулдагалиев, С. Жиенбаев, А. Дуйсенбиев, К. Мырзалиев, К. Жумагалиевлар тәрҗемә иткән. Кереш сүз авторы — филология фәннәре кандидаты, шагыйрь С. Сәетов.

## «КАЗАКЪ ҺӘМ ТАТАР ӘДӘБИЯТЛАРЫ АРАСЫНДАГЫ БӘЙЛӘНЕШ»

Казагыстан ССР Фәннәр Академиясенең М. Ауэзов исемендәге әдәбият һәм сәнгать институтында шул темага Бөркет Исхаков филология фәннәре кандидаты дигән фәнни дәрәҗә алу өчен диссертация яклады. Фәнни җитәкчеләре Каз. ССР Фәннәр Академиясенең член-корреспонденты Е. С. Исмәгыйлов һәм филология фәннәре кандидаты М. Базарбаев.

Диссертация авторы бу ике тугандаш халык арасындагы рухи бәйләнешне бик борынгы заманнардан — V—VIII йөзләрдән башлап тикшерә. Ул бу бәйләнешне раслый торган шактый күп материал туплаган һәм аларны тирән фәнни нигездә анализлаган, әсәрләренә дә, XIX йөздә һәм Совет чорында тыгыз әдәби бәйләнешләргә дә киң тукталган.

## ТЕАТРЫБЫЗ МӘСКӘҮДӘ

Татарстанның 50 еллыгы уңае белән Мәскәүдә 1 июльдән 30 июльгә кадәр Г. Камал исемендәге Ленин орденлы Татар дәүләт академия театры гастрольләр үткәрде.

Гастроль вакытында башкалабыз тамашачылары Ленин премиясе лауреаты Н. Погодинның «Баһадирлар» («Третья патетическая»), Ч. Айтматовның «Гүзәлем Әсәл», А. Островскийның «Соңгы корбан», К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл», «Американ», Т. Гыйззәтнең «Кыю кызлар», Н. Исәнбәтнең «Миркәй белән Айсылу», А. Гыйләҗев белән А. Яхинның «Шамил Усманов», Х. Вахитның «Күк капусы ачылса» һ. б. әсәрләр буенча эшләнгән спектакльләр карадылар.

Театр артистлары спектакльләрдән буш вакытларда Мәскәү завод-фабрикаларында, предприятиеләрендә, культура учреждениеләрендә, иҗат оешмаларында очрашуларга йөрделәр.

## ЯЗУЧЫЛАР СӘЯХӘТТӘ

Язучылардан А. Гыйләҗев белән Х. Сарьян Татарстан туристлар делегациясе составында Төркиягә бардылар. Алар, Төркиянең күп шәһәрләрендә булып, андагы тормыш, халкының гореф-гадәте белән танышканнар.

## ФӘННИ КОНФЕРЕНЦИЯ

СССР Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты Татарстанның 50 еллыгы уңае белән фәнни конференция үткәрде. Конференцияне КПСС өлкә комитеты секретаре М. Вәлиев ачты. Анда тарих фәннәре докторлары М. Мөхәррәмов, И. Ионенко, Р. Нәфиков, А. Халиков, Я. Шәрәпов, философия фәннәре докторы М. Абдрахманов, юридик фәннәр докторы А. Вахитова, химия фәннәре докторы Ю. Китаев, медицина фәннәре докторы Х. Хәмитов, композитор Н. Җиһанов, СССР Педагогия фәннәре академиясе член-корреспонденты М. Мәхмүтов һ. б. лар — барлыгы утыздан артык галим докладлар белән чыгыш ясады.

## БЕРЕНЧЕ ОРАТОРИЯ

Казан шәһәренең Актерлар йортында композитор М. Яруллин белән шагыйрь Р. Харисовның «Кеше» исемле ораториясе тыңланды. Ораторияне башкаруга Казан музыка училищесы хоры, дирижер Нурия Жураева, Муса Җәлил исемендәге Татар опера һәм балет театры солисткасы Хәдичә Гыйниятова, Татар дәүләт академия театры артисты Равил Шәрәфиев, Казан дәүләт консерваториясе студенты Ренат Бәшәров һәм концертмейстер Е. Спасскаялар катнашты.

Әсәр турында фикер алышканда музыка белгечләре Ф. Бикчурина, Я. Гиршман, язучылардан М. Әмир, Ә. Еники, Г. Ахунов, Б. Камалов, сәнгать фәннәре кандидаты Х. Гобәйдуллин, композитор, профессор Н. Җиһанов, үзешчән композитор Ә. Хәйретдинов татар музыка тарихындагы бу беренче ораториягә уңай бәя бирделәр.

## ОЧРАШУЛАР, КОНФЕРЕНЦИЯЛӘР

Татарстанның 50 еллык юбилее уңае белән республикабыз язучылары төрле районнарда авыл хуҗалыгы хезмәт ияләре белән очраштылар.

Г. Ахунов, С. Сабиров, Г. Рәхим Питрәч районының «Алга» газетасы редакциясе каршындагы әдәби берләшмә коллективы белән очраштылар. Башлап язучылардан В. Гайсин, Р. Галәвиева, Г. Фазлыев, С. Закиров, В. Хәмидуллина, П. Кнайнов, С. Гаязов һ. б. ларның әсәрләре тикшерелде.

Язучылар «Заря» һәм Ильич исемендәге колхозларда чыгыш ясадылар, авыл эшчәннәренең тормышлары һәм хезмәтләре белән таныштылар. Г. Ахунов бу очрашуларда татар әдәбиятының бүгенге торышы, язучыларыбызның иҗаты турында сөйләде. С. Сабиров Татарстан китап нәшрияты чыгарган яңа китаплар һәм аның 1971 елга планы белән таныштырды. Аннары Казан кунаклары һәм урындагы яшь язучылардан Г. Рәхимов, П. Апушев, В. Гайсин үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар.

* * *

Г. Ахуновның «Канатлар кая илтә» исемле документаль хикәяләре буенча Казанның 109 һәм 91 мәктәпләрендә укучылар конференцияләре үткәрелде. Укучылар республикабыз турында үзләре дә күп кенә өстәмә мәгълүмат җыюларын әйттеләр. 91 мәктәптә «Канатлар кая илтә» китабына багышлап әдәби викторина оештырылды, конференциядә иң яхшы сөйләгән, викторинада иң дөрес җавап биргән укучыларга истәлекле бүләк—китаплар бирелде. Шул ук әдипнең «Хуҗалар» романы буенча укучылар конференциясе Казан дәүләт педагогия институтында үткәрелде.

Конференцияләрдә Гариф Ахунов үзе дә катнашты, иҗат планнарын сөйләде, укучыларның сорауларына җаваплар бирде.

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Бүлек җыелышларының берсе РСФСР язучыларының IV съезды йомгаклары турында сөйләшүгә багышланды. Съезд делегаты, бүлекнең җаваплы секретаре Р. Фәйзуллин съезд утырышларында күтәрелгән төп әдәби мәсьәләләр һәм нефть якларында яшәүче язучылар алдында торган бурычлар турында сөйләде. Съездда кунак сыйфатында катнашкан драматург Ю. Әминов федерация язучыларының бу зур форумында алган тәэсирләре белән уртаклашты.

* * *

Драматург Ю. Әминов Чаллыда «Коммунизм байрагы» газетасы каршындагы әдәбият түгәрәгендә яшь һәм башлап язучыларга РСФСР язучыларының IV съезды йомгаклары һәм алда торган бурычлар турында сөйләде.

* * *

Ленин юбилее уңае белән быел партиянең Әлмәт шәһәр комитеты язучыларының байтагына «Хезмәттәге батырлык өчен» медале тапшырды. Бүләкләнүчеләр арасында Г. Афзал, Ю. Әминов, Р. Фәйзуллин, Р. Төхфәтуллин, Ә. Маликов, С. Кальметов һ. б. иптәшләр бар.

* * *

Шагыйрь Р. Фәйзуллин «Восход» кинотеатрында мәктәп балалары белән очрашты. Язучылар иҗаты турында сөйләде, яңа шигырьләрен укыды.

* * *

Драматург С. Кальметовның нефтьчеләр тормышына багышланган «Сөенечләр һәм көенечләр» исемле яна драмасы укып тикшерелде. Әсәрне камилләштерү өчен күп кенә киңәшләр әйтелде. Шул ук җыелышта Татарстан язучылар союзы җаваплы секретаре Г. Ахунов идарәнең эше һәм планнары турында сөйләде.

* * *

«Җәлилнефть» идарәсе эшчеләре һәм хезмәткәрләре Әлмәт язучылары Г. Афзал, Һ. Сафина, С. Сөләйманова, Ю. Әминов белән очраштылар. «Җәлилнефть» идарәсе начальнигы Г. Әхмәдиев нефтьчеләрнең эшләре белән таныштырды, ә язучылар исә бүгенге әдәби хәрәкәт турында сөйләделәр, яна әсәрләрен укыдылар. Шул ук көнне язучылар мәктәп балалары белән дә очраштылар.

* * *

Укучылар белән очрашуларның берсе Чупай авылында үтте. Анда Р. Фәйзуллин, С. Сөләйманова, С. Кальметов, яшь шагыйрьләр З. Юсупов, Ә. Исхаков чыгыш ясадылар, балаларның күңелле концерты булды.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ КОНСУЛЬТАЦИЯ БҮЛЕГЕНДӘ

Яшь тәнкыйтьчеләр семинарында Миләүшә Маннурова һәм Ил Саттаровның иҗатлары тикшерелде. Семинар эшендә Рафаэль Мостафин, Фәрваз Миннуллин, Ренат Харисов һәм Илдар Юзеев катнаштылар.

* * *

Башкорт дәүләт университеты студенты Рәдиф Тимершин иҗаты индивидуаль семинарда тикшерелде. Семинарны Шәүкәт Галиев һәм Илдар Юзеев алып барды.

* * *

Утырышларның берсендә Роберт Миннуллин, Фәннур Сафин һәм Зиннәт Мансуровның шигырьләре тикшерелеп, аларның уңышлы табылган әсәрләре «Беренче карлыгачлар» җыентыгына тәкъдим ителде.

## ЧАЛЛЫДА СӨЙЛӘШҮ

Чаллы шәһәрендә чыга торган «Коммунизм байрагы» газетасы каршындагы әдәбият-иҗат берләшмәсе утырышында драматург Ю. Әминов һәм Чаллы шәһәр партия комитетының агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире урынбасары Н. Евдокимов катнашты. Бу җыелышта автозавод төзелү уңае белән яшь һәм башлап язучыларның бурычлары турында сөйләшү булды.

## ШАГЫЙРЬ ИСТӘЛЕГЕНӘ БАГЫШЛАП

Фронтовик шагыйрь Нур Баян колхозлашу елларында Чаллыда район газетасы редакторы булып эшләгән. Быел шагыйрьнең туган көне уңае белән шул газета Нур Баян тормышына һәм иҗатына багышланган әдәби сәхифә чыгарды. Әдәби берләшмә членнары шәһәр радиосыннан чыгыш ясадылар.

## «ТУКАЙ» ТЕПЛОХОДЫ КАЗАНДА

«Агыйдел» пароходчылыгының Габдулла Тукай исемен йөртүче теплоходы Уфа — Мәскәү маршруты буенча туристлар йөртә. Теплоходны венгр дуслар эшләгәннәр һәм ул быелгы навигациядә генә йөри башлады. Бу теплоходны Татарстан язучылары союзы һәм Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе шефка алганнар иде. Чираттагы рейс вакытында Казанда теплоход экипажы белән әдәбият һәм культура хезмәткәрләре Елга портында очрашу үткәрделәр. Очрашуга язучылардан А. Шамов, Г. Кашшаф, Г. Әпсәләмов, Г. Ахунов, Л. Ихсанова, Татарстан дәүләт музееның әдәбият бүлеге хезмәткәрләре һәм Идел буе районы 35 нче мәктәп укучылары катнашты.


Язучылар һәм музей хезмәткәрләре «Тукай» теплоходы коллективына татар халкының бөек шагыйре бюстен һәм портретын, Тукай әсәрләреннән торган китапханә бүләк иттеләр. 35 нче мәктәп укучылары «Пар ат» шигырен татар, рус һәм инглиз телләрендә укыдылар. Ахырда «Тукай» теплоходы капитаны В. А. Чиглинцев (Казан елга техникумында укыган) экипаж исеменнән язучыларга, музей хезмәткәрләренә, укучыларга һәм барлык Казан хезмәт ияләренә рәхмәт белдерде.

# АЛМАГӨЛ

Х. ВӘЛИУЛЛИН музыкасы

Г. ӘПСӘЛӘМОВ сүзләре






Кунак кызы килгән Иделгә,
Мәхәббәтен сагынып, күрергә,
Исеме аның Алмагөл.

Алмагөл,
Ал гөлләрдән,
Гөл гөлләрдән
Һич кенә дә,
Һич кенә дә
Ким түгел.

Бергә чаклар нигә тиз үтә,
Аерылышу нигә тиз җитә,
Башың имә, Алмагөл.
Алмагөл,
Моңсуланма,
Сагышланма,
Һич шикләнмә,
Һич боекма,
Яшь күңел.

Очраштыра Идел парларны,
Кавыштыра сөйгән ярларны,
Бәхет алда, Алмагөл.

Алмагөл!
Сине эзләр,
Сине табар,
Һич шикләнмә,
Һич шикләнмә,
Яшь күңел!

*Хөрмәтле иптәш!*

Шушы елның сентябрь аеннан «Казан утлары» журналына подписка кабул итү башланачак. Әгәр син киләсе елда да безнең журналны системалы рәвештә алып, укып барасың килсә, аңа вакытында язылып куярга онытма!

«Казан утлары»на Советлар Союзының барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин. Аның өчен журналның газета-журналлар каталогына 73210 номерлы индекс белән теркәлгән икәнлеген әйтергә һәм 6 сум акча түләргә кирәк.

Киләсе елда «Казан утлары»нда басылачак әсәрләр турындагы тулырак мәгълүматны журналның 9 нчы санында укырсың.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210